
ISSN 0206—4189

# Казан утлары

10.1999



# БАШКАЛАБЫЗ КАЗАНГА 1000 ЕЛ

*Казан тарихы буенча илебез һәм чит ил галимнәре*
*уздырган киң масштаблы фәнни тикшеренүләр нәтиҗәләре һәм*
*Казан шәһәренең барлыкка килүе хакында*
*Татарстан Фәннәр Академиясе әзерләгән,*
*Россия Фәннәр Академиясе раслаган бәяләмә нигезендә,*
*Казан шәһәренең Татарстан Республикасы башкаласы буларак*
*аерым әһәмияткә ия булуын билгеләп*

**Русия Федерациясе Президенты Б. Н. Ельцин,**
**Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиев**

**"КАЗАН ШӘҺӘРЕНӘ НИГЕЗ САЛЫНУНЫҢ 1000 ЕЛЛЫГЫН БӘЙРӘМ ИТҮ ТУРЫНДА"**

## УКАЗЛАР

**кабул иттеләр.**

Казан шәһәренә нигез салынуның 1000 еллыгы 2005 елның августында бәйрәм ителәчәк. Ә аннан соң ул даими рәвештә һәр елны 30 августта—Татарстан Республикасы төзелгән көнне уздырылачак.

Указларда, шулай ук, Казан шәһәренә нигез салынуның 1000 еллыгын бәйрәм итүгә әзерләнү һәм аны уздыру буенча Дәүләт комиссиясе төзү; 2000 елның 1 гыйнварына кадәр төзелергә, реконструкцияләнергә тиешле объектларны ачыклап, аларны финанслауның күләмен һәм чыганакларын билгеләү; бу чараларны хәл итү өчен федераль һәм республика бюджетларыннан, шулай ук Казан шәһәре бюджетыннан, бюджеттан тыш фондлар, юридик һәм физик затларның ирекле кертемнәреннән файдалану; Казан шәһәренә нигез салынуның 1000 еллыгын бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча махсус чаралар программасы булдыру күздә тотыла.

Мең еллык уңае белән Татарстан башкаласы Казан шәһәренең аерым статусы булдырылачак, бәйрәм үзе исә ЮНЕСКО катнашында уздырылыр һәм бөтен дөньяда яңгыраш табыр дип кңтелә.

Россия Федерациясе Президенты Казан шәһәренең 1000 еллыгын бәйрәм итүгә зерлектә һәм аны үткәрүдә Россия Федерациясенең субъектлары башкарма хакимият органнарына да катнашырга тәкъдим итте.



# Казан утлары
# Qazan utlarь

*1999*

**10**

**(924)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Гариф Ахунов,**
**Харрас Әюпов,**
**Хәлим Гайнуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Ринат Мөхәммәдиев,**
**Нажар Нәҗми,**
**Булат Солтанбәков,**
**Ренат Харис,**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Фәйзуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова.**

---

✉ 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎ Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИЖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Наис ГАМБӘР. Арбада, юлда, дөньяда... *Шигырьләр* ... 5
Марат ӘМИРХАНОВ. Тәкъдир. *Роман* ... 11
Илсөяр ИКСАНОВА. Ә бәхетне... саклау кирәк... *Шигырьләр* ... 82
Фәүзия СОЛТАН. Мәңгелектә, якты бу аланда... *Шигырьләр* ... 86
Рөстәм МИНГАЛИМ. Яна-яна киткән торналар. *Шигъри новелла* ... 95
Рәшит ГАТАУЛЛИН. Жәй белән кыш арасында. *Шигырьләр* ... 99

ПУБЛИЦИСТИКА

Әгъләс БОРҺАНОВ. Россия жәмгыятенең кризис чыганагы ... 89

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Галимжан ГЫЙЛЬМАНОВ. Туксанынчы еллар әдәбияты. *(Анкетага җаваплар)* ... 102

ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

Әдәби тәнкыйтьне ничек «терелтергә?» (*Әдипләребез фикерләре*) ... 108

ТАРИХ

Равил ФӘХРЕТДИНОВ. Казан ханлыгы ... 111

НӘКЫЙ ИСӘНБӘТНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Нәкый ИСӘНБӘТ. Мәкальләребез турында ... 118

МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕБЕЗ ЧИТ ИЛЛӘРДӘ

Илбарис НАДИРОВ. Татарга тугры Төркәр... ... 159
Төркәр СОУККАН. Швециядән татар тавышлары ... 161

МОСТАЙ КӘРИМГӘ 80 ЯШЬ

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Прометей утын сүнмәсен ... 166

СӘНГАТЬ

Кыям МИҢЛЕБАЕВ. Кодрәт иясе *(Рәссам Илдар Зариповка 60 яшь)* ... 169

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ләйсән КӘШФИЕВА. «Атларым, колыннарым» ... 180

РӘШИТ БӘШӘРГӘ 50 ЯШЬ

Фагыйль ӘМӘК. Күнелләгә кызыл миләшләр ... 182
Рәшит БӘШӘР. Мин бит татар егете. *Шигырьләр* ... 183

Укучы сүзе ... 186
Ижтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 191

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

« Проза и поэзия»: роман М. АМИРХАНОВА. «Судьба» *(начало)*; стихи Н. ГАМБАРА, И. ИКСАНОВОЙ, Ф. СУЛТАНОВОЙ, Р. МИНГАЛИМ, Р. ГАТАУЛЛИНА.
«Публицистика»: А. БУРГАНОВ. «Источник кризиса Российского общества».
«Литературная критика»: Г. Гильманов. «Литература 90-х годов».
«Актуальная проблема»: Писатели на тему: «Как «оживить» литературную критику?»
«История»: Р. ФАХРУТДИНОВ. «Казанское ханство».
«К 100-летию Наки Исанбет»: статья выдающегося писателя и ученого-фольклориста «О пословицах».
«Татары зарубежом»: И. НАДИРОВ. «Преданный Туркер», статья доцента полицейской академии Швеции Т. СОУККАН. «Голоса татар из Швеции».
«К 80-летию Мустая Карима»: Р. ФАЙЗУЛЛИН. «Пусть не пагаснет огонь Прометея».
«Искусство»: статья К. МИННИБАЕВА посвящена творчеству художника И. Зарипова.
«Книжное обозрение»: Л. КАШФИЕВА рецензирует новую книгу Н. Ахмадеева.
В. номере отмечается 50-летие поэта Р. Башара.
Слово читателя.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Возлюбленная» - картина художника И. Зарипова; «Защитники Казани» - работа художника Р. Загидуллина, писатель Марат Амирханов.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and Poetry": M. AMIRKHANOV'S novel «Fate»; the verses of N. GAMBAR, I.IKSANOVA, F. SULTANOVA, R. MINGALIM, R. GATAULLIN.
"Publicism": A. BURGANOV «Spring crisis of Russian public».
"Literary criticism": «Tatar literature of 90 th years» G. GILMANOV
"Actual problem": writer for topic: «How «resuscitate» of literary criticism».
"History": R. FAKHRUTDINOV «The Kazan khan state».
"Commemorating the 100 Anniversary of N. Isanbat": article of eminent writer and scientific-falclorman «About proverb».
"Tatar in abroad": I. NADIROV «Loyal Turker» article of docent police academy of SwedenT. SOUKKAN «Voice of tatars from Sweden».
"Commemorating the 80th Anniversary of M. Karimov": R. FAIZULLIN «Let's don't extinguist fire Prometei».
"Art": article of K. MINNIBAEV devote creative work s artist of I. Zaripov.
"Book review": L. KASHFIEVA criticize a new book N. Akhmadiev.
In issue note 50th years poet R. Bashar.
«Reader's word».
The diary of social and cultural life.
In our covers:«Lover»-picture of artist of I. Zaripov; «Protectors of Kazan»-work of artist of R. Zagidullin; writer of M. Amirkhanov.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итергә кирәк.

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 29.09.99 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8029 Заказ 3-478
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 1999 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Наис Гамбәр

### АРБАДА. ЮЛДА. ДӨНЬЯДА...

* * *

Шундый дымык, тонык иртәләрдә
Кошлар канат кагып үтәләр дә,—
    Үлән арасына җил керә.
Күкрәк читлегеннән чыгар булып,
Сыкрап яткан җанны авырттырып,—
    Әрни-әрни йөрәк җилкенә
... Шундый дымык, тонык иртәләрдә.

Сайрар кошлар—ялгыз... (Янымда юк беркем!),
Кара кошлар гына төркем-төркем.
    Агач башларыннан җил исә.
Гомернең бу кайсы төше икән?—
Еракларда йөзә ап-пакъ җилкән...
    Син кайларда икән җан кисәк?—
... Шундый тонык, дымык иртәләрдә

Мескен тургай!—күмелеп бетә инде,
Ут-Кояшка кереп китә инде,—
    Күк төбендә ул бит бер нокта.
Башлар тулы уйлар—кибән-кибән,
«Очты күңел кошы...» Ник җилкенәм?—
    Хәл җыярга иде бер туктап
... Шундый дымык, боек иртәләрдә.

Ослан өсләрендә күкшел монар,
Яна йөрәк—юк бер чара моңар,—
    Шәмем мае яна, савылып.
Кошлар арты, язып, хәбәр җибәр!—
Мин танырмын сине... Ике җуләр
    Очраша калсак, сау булып.
... Кошлар кунар микән киртәләргә—
Шундый дымык, тонык иртәләрдә?!

* * *

**Кем әйтте?—**
**«Дөньяда**
**Яшәүләре куркыныч...»**

**Әй, мәхзүн йөрәк!—**
**Бул тыныч!**
**Тыныч!**
**Тыныч!**
**Башыңның өстендә**
**Торса да сөнге-кылыч.**

**Ярсынма, талпынма—**
**Бул сабыр!**
**Сабыр!**
**Сабыр!**
**Күкрәгең, югыйсә,**
**Күмергә тик калыр.**

**Туктамый—яна ул...**
**Яныр!**
**Яныр!**
**Яныр!**
**Сүндерә алмый аны**
**Җил, яңгыр, буран, давыл.**

**... Тук та тук, тук та тук,—**
**Туктама, йөрәгем!—**
**... Юллар түрендә—талир...**

* * *

**Туу—ул сәбәп кенә,**
**Яшәү дә—сәгать кенә!**
**Шаяртма, туган, «күкү...»—**
**Күкеле сәгать көлә.**

* * *

**«И-и»,—дисәң, башлар иелә,—**
**Кайчак шулай диелә.**
**Иелмә, башым: иелгән**
**Башка мунчак киелә.**

* * *

**Алмадым да... (аңладың ла!)—**
**Сөюгә нигә чылбыр?**
**Алтыннардан кадерле син,**
**Бу сөю, бәлкем, чындыр.**

* * *

*Мело, мело по всей земле*
*Во все пределы.*
*Свеча горела на столе,*
*Свеча горела.*

Б. Пастернак.

**Буран да буран...—**
**Күмелгән урам.**
**Шәм генә яна өстәлдә,**
**Шәм генә яна.**

**Утлы тәрәзгә сарылган**
**Черкиләр сыман,—**
**Кар мамыкларын рамга**
**Җил йөри сылап.**

**Буран—пыяла битенә**
**Ак кершән яга.**
**Шәм генә яна өстәлдә,**
**Шәм генә яна.**

**Мин карап ятам... Түшәмгә**
**Күләгә ятты,—**
**Аяк-куллар сурәте бу,**
**Язмыш сурәте.**

**Ике башмак, дөбердәп,**
**Идәнгә төште;**
**Күлмәккә тамды балавыз**
**Шәмнән—яшь төсле.**

**Аклыкка креп күмелде**
**Тыкырык, урам...**
**Шәм генә яна өстәлдә,**
**Шәм генә яна.**

**Шәмгә җил үтте кагылып,—**
**Ак болыт булып.**
**Ялкын телләре уйнады**
**Тын бүлмә тулып.**

**Февраль. Буран. Ак көрткә**
**Күмелде урам.**
**Шәм генә яна өстәлдә,**
**Шәм генә яна.**

* * *

*Беләсеңме, Зөлфәт, Мәсеготьнең*
*Урыны гына калган җирләрдә...*
*Һәм истәлек булып ярлар калган*
*Билсәпитле зәңгәр төннәрдә.*

**Беткән авыл... Оясы**
**Таралган, җилгә очкан.**

Сиртмәле кое һәм тупыл
Моңая Югарочта.

Җилләрсез, тыныч көннәрдә
Сиртмәле шушы кое
Арып талган карт ат кебек
Тын гына тора, оеп.

Чыкса җил, авыл өстеннән
Чиләге дулап-дулап
Әйләнә... Тимер чылбыры
Куя да авыр сулап...

Асылма чиләк сиртмәдә—
Бу авыл йөрәгедер!
Дидем: эчкән коеңны да
Онытма, кирәгер бер.

* * *

Бу өйдә күптәннән
Яшәми берәү дә;
Капкасы—йозаклы,
Коймасы—терәүдә.

Тик һәр иртә бу юллар
Себерелгән, көрәлгән булырлар.
Кешеләр ничектер елмаеп
Үтәләр аларның турыннан:

«Һай, үзе дә сиксәндә, Гаптери
Кайчан бу эшеннән тыелыр;
Дөнья бит—кары да явылыр,
Канат та, яфрак та коелыр».

... Кемнәрдер: «Җүләрдер!»—диделәр.
Кемнәрдер: «Әҗерен...»—диделәр.
«Җүләрме?», «Әҗереме?»—бер Хода беләдер,
Алар бит күршеләр иделәр.

* * *

«Гел турыдан гына ярганнарның
Урау була кайтыр юллары...»
Поезд киткән, шлагбаум ябык,—
Бу юлы да җитешеп булмады.

Озатучым, каршы алучым да
Булмас, ахры, төнге вокзалда;
Диван почмагына башны салып,
Мин онтылып тордым беразга:

«—Сөю-сөелүләр, имеш!... Болар бары
Вакытлыча гына, ялган ич!
Нәҗагайлар, юкса, чикләвекнең
Төшкәйләрен күптән алган ич!

Нигә кирәк шундый мәҗүсилек,
Нигә кирәк шулай җан ату?!
Ярату—ул китапларда була,
Фанилыкта булмый ярату!»

... Шлагбаум ачык... Казаныма дигән
Поезд килеп җитәр бераздан.
... Урау-урау юллар ялтырашып
Сузылып калды төнге вокзалдан.

* * *

Аһ, китәсе килми синнән, Казан,—
Мине алып китәр поездның
Уты да юк, номер-чутыры да,
«Проводнигы»на хәтле... мылтыклы.

Көпшә күзләреннән, үрелеп-үрелеп,
Озатып калды Ослан таулары.
«Авар!» дигәннәрдер...
Ауган чагымда да
Тотып калды Туфан «ау-у»лары:
«Һәрбер көпшә—ядрә атмый ла ул,
Чәчәкнең дә була көпшәсе;
Гөлләр, әнә, гөлләр нишләр иде,
Бу көпшәләр өзелеп төшсәме?!»

Шушы көннән башлап, ахрысы, мин
Чәчәкләрне бигрәк үз күрдем.
...Кичер, Туфан абый, кичерәлсәң,—
Мин «анда» да чәчәк үстердем.

* * *

*Төлке уйный торган орлар бар.*

Халык җыры.

Чалгылар тагын чормага
Эленде. Кибәннәрнең
Итәген җилләр тарый.
Умартачы Мирхәйдәр карт
Шул якка карый-карый
Уйланып тора. Уеның
Исәбе-хисабы юк:
«—Төлкеләр уйный, ах, мут,
Күзләрендә—кызыл ут!
Димәк ки, еллар алга да
Киекле, кошлы булыр.
Чүннек эчендә тәпәннәр
Бал белән тулып торыр».

... Кибәннәр кипте. Мирхәйдәр
Инде күптән «тегендә».
Кызыл төлке уйнап йөри
Шәрә кырлар түрендә.

* * *

Атлар тугарылган. Кабык арба
«Зенитка»сын күккә төбәгән;
Йолдыз ярчыклары шыбыр-шыбыр
Коелдылар калай түбәгә.

Өйалдында йоклап яткан кызый
Рәтләп куйды мамык юрганын;
Һәм күкләрдән йолдыз атылуын
Бәхет килеренә юрады.

Таңнар аткач—тәртә каерылыр,
Сыеры савылыр, аты җигелер;
Мирхәйдәр карт кына тормый калды
Урын өскәендә, йөгенеп.

* * *

Буш кырлар, инеш буйлатып
Наҗагайлар уйнатып
Көз йөри... Сүнгән—йолдызлар...
Җил дә исми... Ул да—тын.

Йокыга талган, әлсерәп,
Өйләрнең күләгәсе.
(Кайгылар түгел, җаннарны
Тик сөю телгәләсен!)

Соңгы арба үтеп киткәч
Сызгырырлар,.. Китмә, көт!
... Аю көткәндәгедәй лә—
Йөрәк һаман дөп тә дөп.

* * *

Эскерт өстендәге Айның
Кыерчык кына чагы;
... Әле яңарак кына
Сүнде юлчы учагы.

Уянды төнге шәүлегән,
Шым гына чыкты аугa;
Бер арба менеп килә
Төн ката—Калатауга.

Арбада—икәү. Арба ул
Теркелдәп кенә бара.
Атасы «кучер» улының
Башыннан сыйпап ала:

«—Дилбегәңне, дим, катырак
Тот, улым, атың сизсен
Егетләр кулын. (Алда—тау,
Нишләрмен, әткәй, синсез?)

Эскерт өстендәге Айның
Тәгәрәп тулган чагы.
Арба. Юл. Әткәй һәм мин...
Бу—минем бала чагым.

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Марат
Әмирханов

## ТӘКЪДИР

РОМАН

*Тәкъдир каләмнәре миндә булса...*

Жырудан.

Елан елы үзенең чын йөзен тора-бара ачты. Еланы юхага әйләнгән аждаһа булган, күрәсең. Югыйсә, барысы да уң иде. Үзләре исән-сау. Бала-чага житеш. Йорт-жир тәртиптә. Ашарга-эчәргә бар. Умарта кортлары көр, балны ишеп ташыйлар, жыеп кына өлгер. Авыл кешесенә тагын ни кирәк? Шатланып-куанып яшисе генә.

Боларга Жәүһәриянең шәхси сөенечен дә өстәсәң, бинһая зур шатлык тавы хасил булыр иде. Ул бәби көтә. Бәбиенең исеме-аты да әзер инде. Жәмилә булырсың, кызым, дип ниятләп куйды. Хәлбуки, ире Нуруллага малай кирәк. Ул моны бик яхшы белә, билгеле. Ләкин берни дә кылып булмый: Ходай шулай язган, күрәсең. Эчен тишеп чыгардай булып тибенгән бу нарасые да кыз затыннан—жаны-бәгыре белән тоеп тора. Унган хатын ул китерер, изге хатын кыз китерер, ди. Кыз бала икеләтә шатлык.

Бу хакта Жәүһәрия үзе генә белә, бер кешегә бер сүз әйткәне юк. Тумаган балага исем кушмыйлар, дип өләрләр иде бугай. Әлеге баланың соңгысы икәнен дә сизенә әле ул. Йоклаганда колагына фәрештәләр пышылдады булса кирәк.

Ни өчен Жәмилә? Монысы бик гади. Ул үзе игезәк сыңары. Пары, Жәмилә исемлесе, кечкенә чакта суга батып үлгән. Әнисе самаур агартырга дип, Шушма буена төшкән булган. Шөгыленә булышып, бәләкәчен абайламыйча калган. Иң чибәр кызым иде, дип һаман исенә төшереп елый иде әнисе мәрхүмә.

Жәмиләсен ул жинел күтәрде. Инде жиденче аен тәгәлләп килсә дә, йорт арасында жил жилләтеп эшләп йөри әле, йөгенә сылтау иткәне юк. Тән таза чакта эш рәхәт кенә ич. Зур кызлары инде кул арасына керә башлады. Аларына карап бер куана.

Иртәгә, әнә, печән өмәсе, ди. Питрау явымнары бераз тоткарлады шул, печән эше инде күптән бетәргә тиеш иде үзе. Тирә-як авылларда уракка да төшкәннәр дип сөйлиләр.

Тик иртән Жәүһәриянең күзләре ни сәбәпледер шом белән ачылды. Тамагына кадалган балык кылчыгы шикелле күңелен ниндидер бер кайнар төер бимазалап тора иде. Яшенгәдер, дип офыкка күз ташлады. Яшенле янгыр алдыннан шулай кәефе киткәли аның. Явымга ошамаган. Күк

гөмбәзе ак мунча сыман чип-чиста. Кояш тирәсендә колак рәвешендәге ак нурлар күренсә, эссе вә янгырлы булыр, дигән сынамышны ишеткәне бар иде Җәүһәриянең. Кояш ак нурлар эчендә түгел, ал нурлар эчендә елмая. Димәк, яңгырдан түгел.

Өмәгә бөтен авыл халкы купты, гүя сабан туе. Иртәннән үк тальян тарттылар, җыр суздылар. Шушы күңелллелек белән Җәүһәриянең әлеге халәте дә үзеннән-үзе үтте. Кеше арасында онытыласың бит ул.

Аны аш пешерүчеләр янына куйдылар. Күбә асларын булса да тырмаштырыйм соң дип, каударланып караган иде дә, Нурулла тешетырнагы белән каршы килде.

—Малайны сакла, синең хәзер беренче бурычың шул,—диде.

Болын эшлекле шау-шуга чумды. Гөр килә. Ярыша-ярыша кибән коялар. Тик берсе дә Нурулла кибәнчеләренә житә алмады. Башкалар бер кибән күтәргәндә, алар икенчесен очлап куйдылар.

—Бөтен эш сездән тора, җәтрәк кыймылдагыз,—дип, Нурулла чүмәлә тарттыручы малайларны чөшкенләп кенә торды. Ә үзе сәнәгенә берәр-берәр чүмәлә кадап ала.

Әбәт вакытында парторг Мөсбиха ярты көнлек эшкә йомгак ясады. Стена газетасы да чыгарырга өлгергәннәр. "Дисәнә" җырын үзләренчә үзгәртеп, пионерлар Нуруллага җыр багышладылар.

> Батыр егет кибән коя, дисәнә,
> Сәнәге ут уйната, дисәнә...
> Исеме аның Нурулла, дисәнә...

Әлеге мактаулардан соң эшкә тагын да үҗәтләнебрәк тотынганнар иде. Печән өсте төгәлләнү уңаеннан бүләкләр дә бирмәкчеләр, ди. Анысы үзенә җилкендереп тора. Тик адәм әйткән түгел, алла боерган була. Кояш куянны иярләргә дә өлгерә алмый калды, Чирмешән елгасы өстендә яшелле-зәңгәрле болыт кисәге калкып чыкты. Башта ул карга оясы кадәре генә иде, челтәрдәй үтә күренмәле иде. Күп тә үтмәде, күәс чиләгеннән ташып чыккан арыш камыры шикелле бүселеп, ян-якка таралды. Кояшның аңа каршы торырлык көч-куәте юк иде инде.

Агач яфракларын шыбырдатып җил йөгереп узды. Аның артыннан өермә купты, чыпчык башыдай эре бөртекле яңгыр коя башлады. Буранлап-буранлап ява. Яшен яшьни, күк күкри. Печәнчеләр кибән ышыгына кереп постылар.

Гарасатлы яңгыр тиз үтүчән. Бу кунак та озакка килмәгән иде. Ләкин үз эшен эшләп өлгерде. Ике кибәннең муенын сыпырып төшерде. Күршеләрнең бер кибәнен бөтенләй пыран-заран китереп ташлаган. Чүмәләләрне кире пакуска сипте. Адым саен күлләвек, бөтен нәрсә су эчендә.

Менә, ышан син "колаксыз" кояшка?! Инде эш турында сүз дә була алмый иде. Кайтырга җыена башладылар. Нурулла да атын җикте. Кибән аслыгыннан бер кочак коры печән алып арбасына салды да, хатынын, балаларын утыртты.

Авыз-борыннар салынган. Гармун тавышы да ишетелми, җырламыйлар да. Ачуны китереп, дегете юылган арба тәгәрмәчләре генә чыелдаша. Җәүһәриянең күңеленә янә шом кайтты.

Авыл белән болын арасында Озын кул дигән бер ерганак бар. Тирән түгел, тавы да сөзәк. Әмма яңгыр аны да шактый җебеткән иде.

—Ябышыбрак утырыгыз,—дип кисәтте Нурулла арбадагыларны. Үзе дилбегәсен кысыбрак тотты. Тик тауның нәкъ урта бер җирендә уң яктагы алгы тәгәрмәч ниндидер чокырга төшеп утырды, арба кисәк кенә янтаеп китте. Бу шулкадәр көтелмәгәнчә килеп чыкты ки, Җәүһәрия дә, балалар да җиргә тәгәрәде.

Балаларның сөяге җиңел, алар шундук чыр-чу килеп сикерешеп тә тордылар. Җәүһәрия әле бераз ухылдап ятты. Арбага да ире ярдәмендә генә утыра алды.

—Кара аны, канәт, малайга зыян килә күрмәсен, — дип шөбһәләнде Нурулла.

Җәүһәрияне дә шул уй борчый иде. Әмма үзе: "Кайгырыр нәрсә юк, атасы",—дип Нурулланы тынычландырырга ашыкты.

Басу капкасы янында печәнчеләрне авыл Советы рәисе шадра Әлтаф көтеп тора иде. Йөзе кырыс, сүзләре дә мылтык көпшәсеннән сибелгән ядрәләр шикелле атыла.

—Туктан!—дип әмер бирде дә, тиз генә киртә әрәтәсенә менеп басты.

—Өс-баш лычма, нинди бетмәгән җыелыш инде ул,—диде бер хатын ризасызлыгын белдереп. Аңа башкалар кушылды.

—Сон, алайса тизрәк бул, нәрсә катып калдың?

—Көтү кайтыр вакыт җитә.

—Мунча житкерәсе бар.

Әлтаф кепкасын салып, кулына йомарлады да юлпычтай олы учы белән һаваны ярды.

—Җитәр! Тыңлагыз! Сугыш! Немецлар сугыш башлаган!

Рәиснең сүзләре көткән нәтиҗәне бирмәде.

—Фин сугышы чыккач та шушындый алапа корган иден, бетте бит әнә, сизми дә калдык,—диде бер кибәнче.

Нурулла дилбегәсен тарткалап, атын урыныннан кузгатты.

—Кая төртеләсең мүкләк сыер кебек,—дип акырды аңа Әлтаф.

— Сугыш кайгысы юк әле монда, хатынның хәле хәл,—диде Нурулла. —Синең белән миннән башка да немецларның муенын борырлар. Кызыл Армиябез бар.

Сугышның нинди афәтләр алып киләсен күз алдына да китерә алмыйлар иде шул әле урман ышыгына сыенып утырган бу кечкенә авыл кешеләре.

Җәүһәриянең тулгагы башланды. Кендек әбисен кайтышлый ук үзләре белән арбага утыртып алып кайттылар...

Җәмилә житлекмичә, жиде айдан туды. Бик интегеп тернәкләнде. Үлә дип көттеләр. Багучы чегән хатыны да, яшәмәс, диде.

Аның вакытсыз дөньяга килүен берәү дә өнәмәде. Зур Авыл мулласы әйткән, имеш: "Тума үлмәсә, илгә бәла кала",—дип. Кайберәүләр сугыш авырлыкларын да шушы гөнаһсыз сабыйга якты.

Тума атлы кош әнә шулай Җәмиләнең баш очында Гали кылычы шикелле асылынып калды.

Ләкин ул үзе юраучыларның да, багучыларның да гөманын акламады. Барысына да үч итеп, ахыры чиктә үз сүзле, иркә, сау-сәламәт, тәвәккәл бала булып үсте. Унганлыкта да, чибәрлектә дә тирә-якта бер иде. Инде, әнә, егерме сигезенче жәен каршыларга жыена.

* * *

Җәмилә төшендә Мансурны күрде. Имеш, житәкләшеп тауга менеп баралар. Көн әле туып кына килә. Әнә, назлы Кояшсылу күз кысып алды да, алсу йөзен балкытып, елмаеп жибәрде. Агыйдел өстенә, әйтерсең лә, укалы жәймә жәйделәр, жемелдәпме-жемелди. Төсләреннән күзләр камаша. Ак, кызыл, зәңгәр, яшел, сары, көрән... Нәкъ салават күпере.

Бәхетнең төсе булмый, ул күңел халәте дилэр иде, дөрес түгел икән ич! Күр, Агыйдел дулкыннарында аларның бәхете нур чәчә ләбаса! Ә нинди матур, нинди бизәкле икән бәхет. Их, кулга да тотып карыйсы иде үзен. Шушы жәйге иртә шикелле жылы, йомшак, саф вә пакьтер ул, мөгаен. Бәлкем, кояш кебек түгәрәктер? Кайсы ягыннан карасаң да, рәвеше үзгәрми, түгәрәк килеш кала бирә. Түгәрәк бәхет, бәхете түгәрәк, дигән тәгъбир дә, ихтимал, шуннан киләдер.

—Мирсәй Әмирнең "Агыйдел" әсәрендә сурәтләнгән урыннар

түгелме бу,—дип сорады Җәмилә уйларыннан арынып.

—Бик мөмкин. Ә нигә, Идел—агабыз, Җаек—тутабыз, Агыйдел—бил путабыз. Путасының кызыл төене нәкъ шушында инде аның, Сөн белән Агыйдел кушылган урында.

—Безнең Чирмешән яклары да ким-хур түгел анысы, алай бик борыныңны күтәрмә,—дип Җәмилә Мансурны этеп җибәрде дә, кәҗә бәтие сыман сикергәли-сикергәли йөгереп китте. Һәм ире күтәргәнче ул куш кыя артына кереп поскан иде инде.

Мансур як-ягына карангалап алды да:

—Күү-күү, Артыкбикә, син кайда,—дип кычкырды.

Ташлар арасыннан Җәмиләнең башы калыкты.

—Ә-ә, шулаймыни, Артыкбикәмени инде мин хәзер?

Мансур өскә ыргылды.

—Тукта, Кучәрбай, аста тарак белән пәкебезне табып алсалар, ни җавап?

Мансур хатынының биленнән кысып, үзенә таба тартты. Җәмилә иренең кайнарлыгын иң элек күкрәк алмалары белән тойды. Шул ук мизгелдә тәне буйлап нindidер ярсу дулкын йөгереп узды. Иреннәр иреннәргә тиде...

Әмма Мансур тән теләгенә узынырга ирек бирмәде. Җәмилә моңа рәхмәтле генә иде. Чөнки бу Табигать-Ананы хурлау, мәсхәрәләү булыр иде. Алар үзләре дә шул Ананың балалары ич. Кешенең асылы да табигать хозурында гына тулысы белән ачыла. Тормышны да табигать бүләк итә, табигатьтән башка адәм баласы яши алмый. Шуңа күрә кеше аңа баш иярргә, хөрмәтләргә тиеш.

Иртәнге илаһи тынлыкта Җәмиләнең уйлары әнә шулай шәфкатьлелек кайтавазы булып сибелде.

Якында гына куактан-куакка, ботактан-ботакка кунып, сары түшле кечкенә кошчыклар чыркылдаша. Бала шатлыгыннан куаналар булса кирәк. Ана кошлар ояда, күкәй өстендә утыра. Сайрар чаклары узган. Киләсе елда инде җырны әле генә борын төртеп килүче яшь буын дәвам итәр. Табигатьтә барысы да уйланылган, барысы да көйләнгән.

Мансур да дулкынланган иде. Тик аның уйлары Җәмиләнеке шикелле үз эчендә йомылып калмый. Гадәттә, алар моңга әверелә, җыр булып яңгырый. Җыр аның менә шушы иртә шикелле үк табигый халәте. Әле хәзер дә күкрәк төбеннән чыккан йомшак тавыш белән җыр сузды:

Тәрәзәгә үреләсең,
Гөлләргә күмеләсең,
Гөлгә карыйм, сиңа карыйм,
Син матур күренәсең.
Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.

Мансурның тавышы көчле түгел, әмма үзенә генә хас моңы, аһәңе бар. Ул күңелнең иң тирән төпкелләрендә яшеренгән хисләрне уята, сагышларны яңарта, йөрәкне җилкендерә. Ни хикмәт, бу сагышлар күңелне яраламый, киресенчә, сүз белән аңлатып булмый торган нindidер тынычлык катыш сабырлык алып килә.

...Җәмилә бишектә тирбәнгәндәй шушы җыр кочагында уянып китте.

Салкын сулар сибеп кенә
Үстердем гөлләремне...

Игътибарлырак тыңлап бакса, радиодан да әлеге көй яңгырый икән ләбаса! Мөгаен, төшенең сәбәпчесе дә шул җырдыр әле.

Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.

Бу гап-гади көйне Җәмилә үз исеменә чыгарылган җыр сыман кабул итә. Беренче тапкыр әлеге җырны институтның соңгы курсында укыганда Мансур авызыннан ишеткән иде. Мансур аны ана, Җәмиләгә багышлап җырлады.

Бүгенгедәй хәтерендә. Дус кызы Мөнирә туган көн мәҗлесенә чакырган иде. Ул теләмичә генә килде. Гомумән, тулай торакны өнәп бетерми, аны азып-тузып йөрү урыны дип саный иде. Дөресе дә шулай. Ял йортындагы кебек студентлар берничә көн эчендә парлашып-якынлашып бетәләр. Соныннан хыянәт, көнләшүләр китә. Лекция-семинарлар вакытында да тулай торак кызлары гел шул хакта гәпләшәләр. Бер-берсе артыннан күзәтәләр, бер-берсенең гайбәтен саталар. Егетләрнең дә тетмәсен тетәләр анысы, ә үзләре кич җиткәч, шуларның кочагына атылалар. Монысы инде иң зур мактанычлары.

Җәмиләгә бу "куркыныч" янамый. Әтисе белән бертуган абыйларында торып укый. Башта педучилищены тәмамлады. Хәзер инде институтны тәгәлләү алдында тора. Сигез ел. Аз гомер түгел. Абыйсы да, җиңгәсе дә бик коры, кадим кешеләр. "Әти-әниең алдында без җавап бирәбез синең өчен",—дип һәрдаим тукып торалар. Шуңа күрә ул алардан сорамыйча рөхсәтсез беркая чыкмый. Иң зур юанычы—спорт. Педучилищеда җиңел атлетика, гимнастика белән шөгыльләнде. Соңгы елларда фәкать гимнастика белән генә мавыга. Хәер, мавыга дип әйтү дөрес үк булмас, чын-чынлап мөкиббән ул спортның бу гаять нәзакәтле, нәфис төренә. Мастерлык дәрәҗәсе алды, ярышларда катнаша. Егетләр арасында да абруе зур. Кемнәр генә сүз кушып карамады үзенә, ризалашмады. Юк, абыйсы белән җиңгәсе каты куллы булган өчен генә түгел, үзенең холык-фигыле, тәрбиясе шулай. Әти-әнисе артык динле булмасалар да, мишәрләргә хас сыйфатта гореф-гадәтләрне бик нык саклыйлар. Тыйнаклык, өлкәннәр сүзеннән чыкмау, сабырлык, үҗәтлек ана карынында ук канына сеңгән. Моны инде үзгәртеп булмый.

Педучилищеда укыганда Рәис исемле егет үзенә дә ошаган иде. Дөрес, ул "яратам", дип әйтергә батырчылык итмәде, артык оялчан иде. Эчтән янып йөри торган хыялый зат. Ә хыялыйлар тормышны бөтенләй башкача, һавадагы торна шикелләрәк күз алдына китерәләр. Кыенлыкларны авыр кичерәләр, еш кына югалып калалар. Бәхетсезлек тә алар өстенә ешрак төшә. Рәис тә армиядән имгәнеп кайтты. Ничек җөрьәт иткәндер, Җәмиләне алиһәгә тиңләп хат та язган иде. Шуннан соң озак та үтми, машинага тапталып үлгән.

Җәмиләнең иреннәренә әле егетләр ирене тиеп караганы юк. Ул сөешү-яратышуларны нигездә әдәби әсәрләр, кинофильмнар аша гына белә. Җаны ашкынган, зиһеннәре томанлаган, тәненә йөгергән ниндидер татлы дулкыннан үзен-үзе кая куярга белмәгән чаклары да булгалый анысы. Ләкин ул аларга шайтан вәсвәсәсе дип кенә карый. Аның өчен шунысы ап-ачык: кочагына алган, иреннәреннән суырып үпкән егет аның ире булырга тиеш! Тукайның "Фатыйма"сы хәленә төшсәң нишләрсең?

Бер егет үбә килеп, ике егет,
Фатыйманың да кала авызы жебеп...

Әлеге мәҗлестәге "йөгәнсезлек"кә дә исе китеп утырды Җәмилә. Хәмерен дә кире бормыйлар, касәләр тулы тормый. Ләкин мәҗлес-мәҗлес инде ул, авызыңны чөйгә элеп утыру килешми. Бераздан ул үзе дә шау-шуга кушылды. Сабакташына зиннәтле кысага куелган көзге бүләк итте.

—Көзге бик мәгънәле бүләк,—диде ул үзенең котлау сүзендә,—күңелләре керле кешеләр аны дошманлык дип тә саный. Ә мин дустым Мөнирә бу көзгене һич икеләнмичә кабул итәр, дип уйлыйм. Чөнки ул көзгегә караган саен үзенең чибәрлеген, эчкерсезлеген күреп шатланачак. Ә шатлык кешене бәхетле итә.

Бүлмә алкыштан урыннан куба язды.

—Бис. Афәрин!

—Булдырдың, Җәмилә!

Егетләр болай да Җәмиләдән күзләрен алмыйлар иде, әлеге тостан соң аның абруе яңа чүпрәдәй кабарды. Кайбер кызларга бу ошамады, егетләрен тартып алыр дип шүрләделәр ахырысы. Галим исемле бер шук егет моннан мәзәк тә кыландырып алды.

—Нәсимә,—диде ул үзенә елышып утырган сары чәчле сипкелле кызга,—тәрәзәгә барып кара әле, җанаш, яңгыр яумыймы икән, нигәдер уң колагым кычыта.

Нәсимә икеләнебрәк торса да "җанаш" сүзен ишеткәч, карышырга базмады, күрәсең, урыныннан кузгалды.

—Яңгыр яумый, Галим, чалт аяз,—диде ул.

—Гафу, Нәсимә, ялгышканмын, уң колагым түгел, сулы кычыта икән ич!

Ул арада егет Җәмилә янына барып чүмәшкән иде инде. Көлештеләр. Көлкене Индус атлысы да дәвам итәргә чамалап карады. Ләкин мәзәгеннән бигрәк, үзе кәмиткә калды. Чөнки "Вәли—койрык",—ди дә шаркылдап көлә, "Вәли койрык",—ди дә шаркылдап көлә. Тәки ни өчен көлгәнен башкаларга аңлата алмады.

—Стипендияңә койрык ал, койрык,—дип көч-хәл белән туктаттылар тегене. Индус әле аннан соң да шактый вакыт тыела алмыйча хихылдады.

Бераздан Җәмилә бу уен-көлкеләргә кушылмый гына утыручы тәкәбберрәк кыяфәтле бер егеткә игътибар итте. Үзе генә, кызы юк. Шома йөзле, ачык маңгайлы, озын чәчле бу егетне нигәдер ошатып җиткермәде. Күзләре майлы, андыйлар ышанычлы булмый, дигән нәтиҗә чыгарды ул. Җә берәр шагыйрь аламасыдыр, җә җырчыдыр...

Юраганы юш килде. Күп тә үтми егет урыныннан торып басты да:

—Рөхсәт итсәгез, шушы чәчәк бәйләменә өстәп, мин Мөнирә туташка бер җыр багышлар идем,—диде.

Бу—бүгенге кичәдә беренче чәчәк бәйләме һәм тәүге җыр иде.

Егет ашыкмыйча гына баян каешларын җилкәсенә элде, аннан соң бармакларын төймәләр өстеннән йөгертеп узды. Барысы да тынып калды. Инде бүлмәгә җыр хуҗа иде.

Идел бит ул, тирән бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул.
Идел өсләрендә йөзгән
Аккошларга тиң бит ул.

—Браво, Мансур!

—Афәрин!

Җәмилә, ниһаять, җырчы егетнең исемен дә ишетте. Исеме җисеменә туры килә икән, дип уйлады. Алдагы фикереннән баш тарту идеме бу — юкмы, әмма күңеле йомшаган иде инде. Җыр-моңга һәвәс булмаса да, музыка аны бик әсәрләндерә. Бу минутларда ул кешенең даһилыгына тәмам ышана, дөнья фәкать яхшылыктан гына торадыр сыман тоела. Яманлыклар, гаделсезлекләр онытыла.

—Ялгышмасам, бу мәҗлестә минем шикелле тагын бер ялгызак бар,—диде Мансур, алкышлар тынгач, — исеме дә бик килешле. Җәмилә! Әүсафе Җәмилә! Матур, гүзәл, күркәм, сылу, чибәр дигән сүз. Үзеннән үзе җыр сорап тора.

Мансурның каз мамыгыдай йомшак тавышы янә бүлмәне тутырды.

Гөлләремнең ал чәчәге
Таң нурында балкыды.
Мәңге сүнмәс, һич сүрелмәс
Сөюемнең ялкыны.
Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.

Бу җырны тынлаганда Җәмилә үзен җәй кызыдай хис итте. Күз күреме җитмәс киң болын. Җиһан илаһи бер хозурлыкта. Аллы-гөлле чәчәкләргә кунып күбәләкләр оча. Якында гына чишмә челтери, кошлар сайраша. Кемдер чалгы кайрый. Шунда ук черт-черт итеп пакуска ауган үлән тавышы колакка инә. Җылы җил чәч толымнарын сыйпап уза...

—Җәмилә туташның йөрәге синең учыңда, Мансур, кара аны очып китмәсен,—дип көлде Галим.

Аннан соң күмәкләшеп җырлаштылар. "Кыйгак-кыйгак, бак-бак" дигән җырны җырлаганда Җәмилә дә башкалар белән беррәттән бар көченә "кыйгак-кыйгак", дип кычкырды. Тора-бара мәҗлеснең дилбегәсен Мансур үз кулына алды. Бу яктан да сәләте бар икән. Ә Җәмилә үзенә атап җырланган җыр тәэсиреннән кич буе арына алмады. Искиткеч рәхәт иде ана. Йөзеннән елмаю китмәде. Үзенең чибәр икәнен элек тә белә иде. Ул бары борыны белән генә риза түгел, тумпак дип саный ул аны. Озынча нәфис йөзен шул борын бозып тора шикелле. Кайвакыт көзгедән ыспай гына да күренә үзе. Бу инде кәефенә бәйле. Кәефсез чакта хәтта иң зур горурлыгы дип санаган тыгыз, тулы чем кара чәч толымнарын да кисеп ташлар хәлгә җитә.

Буй-сыны коеп куйган кебек. Кем әйтмешли, бал кашыгына гына салып йотарлык. Гимнастика белән шөгыльләнү табигый күркәмлеген тагын да нәфисләндерә...

Мансур кичәдә Җәмиләнең йөрәген ешрак тибәргә мәҗбүр иткән бердәнбер егет иде. Ихтимал, соңгысыдыр да. Чөнки ул ярәшелгән кыз. Егете Уфада, нефть институтында укый. Рөстәм исемле. Җәйге каникул вакытында Әлмәткә баргач, апасы Мәгъсүмә таныштырган иде. Соңыннан аңлашылганча, ул бу очрашуны махсус оештырган булып чыкты.

—Бик мөхтәрәм заттан,—диде апасы,—әти-әнисе, үзебез кебек ипле, акыллы гаилә белән туганлашыр идек, улыбызга Казанда укучы кызыгызны алмакчы булабыз, аллаһы боерса, дип торалар.

—Без бит әле таныш та түгел, апа, аннан соң...

—Дәвам итмәсәң дә була, сеңлем, ни әйтәсеңне алдан ук белеп торам,—дип бүлде аны Мәгъсүмә,—мәхәббәт димәкче инде син. Мәхәббәт ул, сеңлем, тора-тора килә. Баштарак җизнәң җен пәрие кебек күренә иде. Хәзер, күреп торасың, күгәрченнәр кебек гөр-гөр килеп яшибез, балалар үстерәбез. Минем арттан да калай әтәч кебек егетләр йөрде ул. Мал-мөлкәтсез сукбайлар. Рәхмәт әтигә, ай-ваема карамыйча җизнәнә ярәште. Әти-әни күбрәк белә бит ул, сеңлем. Безнең татарның гадәте инде ул. Шуңа гаиләләребез нык безнең, аллага шөкер.

—Минем бу хакта уйлаганым юк бит әле, апа,—дип каршы төшеп карады Җәмилә.

—Белемле кыз—бирнәле кыз ди, бәһаң югары чакта урнашып калуың хәерле. Син аның буй-сынына карама. Буе буйдан кечене куены оҗмах эче ди. Буй белән су буйламыйлар. Биек үкчәле итек кияр. Аннан китереп, ирнең үзеңнән кайтышырагы кулай аның. Андыйларны камыр кебек изәргә була. Гаиләгезнең башы да, муены да үзең булырсың. Әнә, җизнәң артымнан тотам да калмый. Чөнки дә көнләшә. Ачуым чыккан вакытларда: "Карт пәри",—дип кенә җибәрәм мин аңа.

—Син инде, апа, бигрәк...

—Бигрәкме, бигрәк түгелме, сүземне тыңласаң уңарсың, пычагың май өстендә генә йөзәр. Әти-әни хакы—алла хакы. Аларның сүзен читкә тибәргә ярамый, гөнаһка чумарсың.

Рөстәмгә дә шул ук сүзләрне тукыганнар иде ахры, Җәмиләне күрүгә колак очларына кадәр кып-кызыл булды. Ләкин бу озакка бармады. Кәтүк буйлы кешеләргә хас булганча, бик телчән икән. Биш-алты минут эчендә барысын да сайрап чыкты. Инде эшкә юллама да алдым, ди. "Әлмәтнефть" идарәсендә промысел башлыгының урынбасары булып эшләячәкмен, ди. Машинада гына йөриячәк, имеш. Ул, әлбәттә, моның белән генә чикләнмәячәк, үсәчәк, зур түрә булачак.

Кичен кинога бардылар. Рөстәм, чынлап та, озын үкчәле ботинка кигән иде. Кисәткәннәр, димәк ки. Аны күргәч, чак кына пырх итеп көлеп җибәрмәде Җәмилә. Кайчандыр күзенә чалынган бер кыйсса хәтеренә төште: "кече буйлы ир хатын-кыз өчен зур бәхет, барысы да кул астында..."

Тик Рөстәм Җәмиләгә якын килергә кыймады. Мактанды гына. Күрәсең, кызларны шулай үзенә каратып була дип уйлый иде. Җәмиләнең исә тел бистәләрен җаны сөйми, Рөстәмнең дә авызына йозак эләр дәрәҗәгә җитте.

Кызның тын гына дәшмичә баруын Рөстәм ризалык, дип кабул иткәндер, мөгаен. Ул инде өйләнешү, туй турында планнар корырга тотынды.

Җәмилә исә әлеге сүзләрнең чын-чынлап үзенә кагылуын бөтенләй тоймый да, гүя аларны бу егет башка берәүгә сөйли, ә ул ирексездән тыңлап кына тора.

Йокыга яткач кына аңына килде Җәмилә. Җә, алла, базар малы кебек саталар түгелме соң аны! Борынгы заман диярсең. Сүз өчен генә булса да, син миңа ошыйсың, мин сине яратам дисең икән. Мокытның мокыты.

Аннан ул Рөстәмне аклау ягына күчте. Ярату дигәне, бәлки, дөрестән дә соңрак киләдер. Алар бит әле чит-ят кешеләр. Апасы да шулай ди. Кайчандыр Кәрәм җизнәсе дә ана чит-ят булган ич. Буй-сыны да әллә ни түгел. Инде әнә мичкә шикелле кабарды, тәгәрәп кенә йөри. Барыбер бер-берсе өчен үлеп торалар.

Рөстәм, һичшиксез, булдыклы егет. Кара, эш мәсьәләсен ничек алдан хәстәрләп куйган. Фатиры да була ди. Ә акча дигәне нефтьчеләрдә бар да бар инде. Болар барысы да тормыш өчен бик мөһим. Шәһәрдә урнашып калу да күпләрнең хыялы. Әти-әниләренә дә ярдәм кирәк. Өйләрен сиплисе, мунча өлгертәсе...

Мәхәббәт ул романнар, кинофильмнар темасы. Белгән кызлары егетләр белән йөреп карады ич инде. Һаман күз яшьләре: җә алданалар, җә ташлап китәләр. Үтә җете тиз уңа ди. Әнә, Таһир-Зөһрәләр дә ятарышкан. Фәрхад һәм Ширин, Ромео-Джульетта... Җә, кайсы бәхетле? Күрәсең, мәхәббәт кешегә бәхет алып килми. Ә аның бәхетле буласы килә. Ышанычлы ир, җитеш тормыш, яраткан эш, таза балалар – хатын-кыз өчен бәхет шушы ич инде. Матур булып тума, бәхетле булып ту, дигән бер аксакал.

Шул рәвешле уйлана-уйлана Җәмилә үзен күндерде. Ризалыгын да бирде. Рөстәм нәкъ сөйләшкәндәге шикелле озын-озын хатлар язды. Кая барган, кем белән очрашкан, институтта нинди яңалыклар бар – халыкара хәлләрне дә кертеп, барысын бәйнә-бәйнә ирештереп торды. Ун-унбиш ел бергә яшәгән ирнең командировкадан хатынына язган утсыз, ялкынсыз хатларын хәтерләтә иде алар. Хис беткән, ялкын сүнгән, җанны җылытырлык сүзләр онытылган... Күңелдә юшкын кебек исәп-хисап кына утырып калган.

Җәмилә бу очы очка ялганмаган әлеге уйларны күңеленнән куа. Һәм бернәрсәгә карамый үзен Рөстәмнең хатыны булырга хәзерли иде. Вәгъдә— иман. Дөньяда аны бозарлык көч юк.

* * *

Туган көн мәҗлесендә Мансур белән биюе, авыз күтәреп җырлап утыруы, гомумән, үзен җилбәзәкләрчә тотуы өчен соңыннан үкенеп йөрде Җәмилә. Мөнирәнең: "Мансур сине бик ошаткан",–дигән сүзенә дә кабынып китеп, дустын нахакка кыерсытып ташлады. Хәлбуки, Мөнирә аның шушылай сәер рәвештә Рөстәмгә вәгъдәләшүенә чын-чынлап каршы иде. Бу серне Җәмилә фәкать аңа гына чиште. Башка белүче юк.

—Кызма, Җәмилә,—диде Мөнирә,—сине Мансурга кодалаучы юк ич әле. Белеп тор гына дидем, әллә гаепме?

Мансурны ул eрактанрак кына булса да тагын бер мәртәбә күрде. Һаман шул Мөнирә инде, һич тынгы белми. Әле театрга өнди, әле концертка. Елмаеп-көлеп килеп керә дә, өстәлгә билет сала. Бу, билгеле, өйдәгеләргә ошамый, борыннарын салындыралар. Ә Мөнирә тиз генә чигенә торганнардан түгел. Сыйпый, көйли, барыбер үзенекен итә. Татлы теле еланны да өненнән чыгарыр иде, шәт. Абыйсы да, җингәсе дә ахыр чиктә боларны елмаеп озатып калалар.

Берсендә ул аны Укытучылар сараена алып китте. Үзешчәннәр театры премьера күрсәтә икән. "Нинди спектакль соң ул?"—дигән сорауга серле генә елмаеп: "Сюрприз, баргач күрерсең",—диде.

Әйе, сюрприз иде ул. "Җәмилә" дигән спектакль хәзерләгәннәр икән. Җәмиләнең аны беренче күрүе иде. Дөресен генә әйткәндә, бу исемдәге пьеса барын белми дә иде әле. Анда Җәмилә исемле кызның фаҗигале мәхәббәте тасвирлана.

...Менә сәхнәгә Җәмиләнең сөйгән егете чыкты. Борчулы, әмма мәхәббәтен саклап калу өчен утка-суга керергә әзер. Хисләрен җырга сала.

Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә...

Мөнирә аның кабыргасына төртеп куйды, янәсе, таныйсыңмы? Җәмилә Мансурны сәхнәгә аяк басуга ук танып алган иде инде. Йөрәге әллә нишләде дә китте. Ирек куйсаң, җаны күбәләккә әверелеп, Мансурның күкрәгенә очып кунар иде. Ләкин соң инде, бу мөмкин хәл түгел. Шуңа күрә башым сызлый, дигән хәйлә табып, залдан чыгып китте.

Ә аннан соң? Аннан соң Җәмилә өчен чын мәгънәсендә мәхшәр башланды. Кая ул күңел ачулар? Рөстәм дә онытылды хәтта. Һәр минуты исәптә. Чөнки аны социалистик илләрдә укучы студентларның Варшавада үтәргә тиешле Кече спартакиада командасына керттеләр. Ул кышкы каникуллар вакытында узачак. Шуңа күрә имтиханнарны да вакытыннан элек бирдерәләр. Көндез—институт, кич—гимнастика залы. Ә төн имтиханнарга хәзерлек белән үтә.

Җәмиләне бу авырлыклар, бу мәшәкатьләр куркытмый, түбәсе күктә. Җил кебек очып кына йөри. Шулай булмыйча, нинди иләк аша узды бит. Бик нык сайладылар. Гимнастика белән шәһәр кызларыннан күпкә соң шөгыльләнә башлаган Җәмилә өчен бу киртәне үтү җиңел булмады. Көч күп сарыф итүне сорый торган снарядларда ул үзен иркен хис итә. Бу яктан аны уздыручы юк. Ә менә сыгылмалылыкта башкалардан калыша. Шуңа күрә әлеге аерманы бетерү, һичьюгы киметү өчен һәр мөмкинлектән файдаланырга тырыша.

Спортка кагылышсыз каршылыклар да килеп чыкты. Бер түрә танышлык белән кызын командага төртмәкче, имеш. Җәмиләнең яклаучысы юк. Аны сызмый кемне сызсыннар. Институт җитәкчелеге шулай эшләгән дә. Бу, әлбәттә, Җәмиләгә дә килеп ишетелде. Җылап-ярсып бетте. Рәхмәт, тренеры Сабир Хәкимович нык торды. Көч-хәл белән сине коткарып калдым, дип сөйләде соңыннан, алтын медаль алып кайтып, шуларның борынына чиертик әле, диде. Бу хәлләрдән соң Җәмилә күнегүләргә тагын да үҗәтләнебрәк тотынды. Ул үзен күрсәтәчәк әле! Күрсәтәчәк!

Шулай көн артыннан көн үтте, инде киемнәр дә әзер, һәрберсенә махсус үлчәп тектеләр. Затлы мехтан кыска тун, беретка, чем кара җылы туфлиләр. Карап туймаслык. Болары кешелеккә дигәннәре. Спорт формасы аерым. "СССР" дип язылган язуы да бар. Әлегә алар институтта саклана. Спартакиададан соң бөтенләйгә бирәчәкләр. Бер ай инде ашау да бушлай. Коммунизм! Берүк күз генә тимәсен, ул-бу гына була күрмәсен, дип теләде Җәмилә. Кешегә күрсәтми генә садакалар бирде, дога кылдырды.

Иншалла, китәр сәгатьләре дә житә. Билетлар инде кесәдә.

Жәмиләнең бик бәхетле көннәре иде бу. Рөстәмнең чираттагы хаты да кәефен бозмады, рәхәтләнеп көлде генә. Ул кышкы каникуллар вакытында өйләнешик, туй ясыйк дип язган иде. Имеш, бу фатир алу мәсьәләсендә зур роль уйнаячак. Әгәр көмән турында белешмә дә булса, ул чагында кулыңа тутый кош кунды дип исәплә, дигән.

Әйе, кош кунды анның беләгенә. Тик тутый кош түгел, кара кош!

Жәмилә соңгы күнегүдән дә төнге уннарда гына кайтты. Кыл кыймылдатырлык та хәле калмаган иде, телен әйләндереп сүз дә әйтәсе килми. Поезд иртәгә кичке якта гына китә. Туйганчы йоклыйм әле, аллаһы боерса, дип инде тәнендә шул булачак йокының ләззәтен тоеп трамвайда ук оеп китә язды.

Ни сәбәпледер өйдәгеләр ятмаган иде әле. Башка вакытта абыйсы телевизордан соңгы хәбәрләрне дә азагына кадәр карап бетерә алмый, диванда утырган килеш гырылдый башлый иде. "Интегеп утырма, кереп ят",–дисәң: "Мин Наполеон кебек бит, берьюлы бернечә шөгыль башкара алам: телевизор да карыйм, иртәгәге мәшәкатьләр турында да уйланам, йоклыйм да",–дип көлә. Ә бүген кызмача иде. Моны белү бик жинел. Чөнки бераз кабып алса, иреннәрен жыя алмый башлый, авызы иләк кебек жәелергә генә тора. Елый торган гадәте дә бар. Әле әти-әнисен кызганып яшь түгә, исән чакларында кадер-хөрмәт күрсәтә алмадым, ди. Әле Шушма елгасында су коенып йөргән балачагын сагына. Әле... хәер, йомшак күңелле кешегә сәбәпләре табыла инде анның.

Бик ярдәмчел, тиз ышанучан, беркатлы кеше анын Шәйхелислам абыйсы. Әмма булдыклы, тырыш, намуслы. Шул булдыклылыгы, авыл кешеләренә хас үҗәтлеге тота да инде аны жәмәгать туклануы дип аталган гаять мәшәкатьле, давыллы, алыш-бирешле дөньяда. Бик күпләрнең көймәсен челпәрәмә китерде инде анын ярсу дулкыннары. Шөкер, әлегә бу давыллар абыйсын читләтеп уза. Өйгә ул хезмәт хакыннан башка бернәрсә алып кайтмый. Хәлбуки, деликатес ашамлыкларны, азык-төлекне фатирга китерүчеләр булгалады. Шуңа күрә жингәсе Маһруйны да, аласы булма, дип кисәтеп тора. Ялагайлар күп бит ул. Шулар ук жае чыгуга сатып жибәрергә дә күп сорамыйлар.

Жәмилә ишектән керүгә абыйсы да, жингәсе дә бер-берсенә карашып алдылар.

–Әллә май урлап ашадыгызмы, күзләрегез мәченеке шикелле ялтырый,–дип шаяртты Жәмилә,–яшермәсәгез дә була, бик арыдым, хәзер ятагыма авам.

–Капкалап ал, хәл кереп китәр,–диде жиңгәсе үзенә хас булмаган йомшаклык белән.

Бу сәер хәл Жәмиләне аптырашта калдырды. Югыйсә, кайтып керүгә сорау ала башлыйлар иде: "Нигә соңга калдың?", "Кем озата килде?" Бу үзгәрешнең сәбәбенә кереп торасы килми иде Жәмиләнең. Шуңа күрә:

–Рәхмәт, апа, йокыдан башка бернәрсә дә теләмим,–дип урын-жирен рәтләргә тотынды.

Көтмәгәндә абыйсы аны кочаклап алды, үксеп еларга тотынды. Үзе авыз эченнән нидер мыгырдана.

–Шәйхел, зинһар борчыма әле сеңелне, үзем әйтәм,–диде жингәсе.

"Үзем әйтәм" дигән шомлы сүз Жәмиләнең йөрәген телеп алды. Аны гүя, аяк-кулларын бәйләп, упкын төбенә ташладылар. Һәр минут, һәр секунд аны котылгысыз фажигага якынайтты. Хәзер, әнә, сөңгегә ошаган очлы борынлы ташлар тәнен тишкәли. Юк, тәне түгел, жаны әрни икән. Жан инде тәннән аерылган. Аны нидер кыса, умыра, тешли... Шуңа күрә жингәсенең сүзләрен дә аңлап житкермәде.

–Жәмилә сеңлем, сиңа авылга кайтырга кирәк,–диде ул.–Иртүк самолет белән очарсың. Шәйхел барысын да сөйләшеп куйды. Чирмешәннән якынрак булыр, ат белән илтеп куярлар...

—И, Җәүһәрия жинги, Җәүһәрия жинги...—дип абыйсы аһ ора.

—Ни булган, нигә кайтырга сон мина?—диде Җәмилә. Ул әле һаман бернәрсә дә анламый иде.

—Әниен, Җәүһәрия астай үлгән... телеграмма килде,—диде Маһруй.

—Ничек үлгән?

Бу мәгънәсез сорауга ничек итеп җавап бирергә дә белмәде Маһруй. Бары Җәмиләне кочагына гына алды.

Алар бик озак шушы хәлдә басып тордылар. Бераздан Җәмилә калтырана башлады, теше тешкә бәрелә, кул-аяклары көзән җыерган кешенекедәй тартыша. Җингәсе көчләп диярлек кайнар чәй каптырды. Шуннан сон гына бу өянәге үтте. Ләкин чишенмәде дә, ятмады да. Әнисенә бүләккә йон кофта алган иде, төнен шуны сыйпаштырып үткәрде. Ә иртән абыйсы самолетка утыртып озатып җибәрде.

* * *

Кышкы көн чыбыркы сабыннан да кыскарак, кояш чыгарга өлгерми, баю ягына борыла. Ә менә көрт басып киткән юл өчен егерме чакрым ара дилбегәдән дә озынрак икән. Шәпле ат та аны кыскарта алмады, үзе йомшарды.

Алар эңгер-меңгер төшә башлагач кына басу капкасыннан керделәр. Әле ут алырга өлгермәгәннәр иде. Мөселманнарда мәетне көнендә алла йортына индерүне мәгъкуль күрәләр. Җәмилә моны белә. Әмма әнисен аннан башка җирләүләренә ышанасы килми. Бик зур гаделсезлек булыр иде бу. Ничек инде бала газиз әнкәсен, бу дөньядагы иң кадерле кешесен соңгы юлга озатканда күрми, бәхилләшми калсын ди? Юк, Мәгъсүмә апасы мона юл куймаячак. Җәмиләнен әнисен ничек яратканын белә ич ул. Кәрәм җизнәсе дә анлы кеше, үз сүзен әйтми калмас. Дин дә беренче чиратта кеше ихтыяҗын якларга тиештер, мөгаен. Эзләп-тикшереп карасаң, Коръәндә дә шундый гадәттән тыш хәлләрдә ташлама ясарга мөмкинлек бирүче сүрәләр бардыр. Әлбәттә, бар!

Җәмилә юл буена шушы хакта уйланып, үз гөманлауларына үзен-үзе ышандырырга тырышты, саллы-саллы дәлилләр эзләде. Ләкин ат тотучы абзый аның бу өметләрен бер сүз белән юып ташлады.

—Кызым, белгән догаларынны укы, ястү вакыты, әнкәң мәрхүмә янына гүр фәрештәләре килгән чак,—дип, үзе дә догага оеды.

Авылда кечке ыгы-зыгы. Кайсынындыр сыеры мөгри, берәвенең сарыгы ярсып-ярсып бәэлди, иртә бәрәнләгән ахры, бәләкәчләрен юксына. Әледән-әле йокы аралаш казлар кангылдашып куя. Капкалар шыгырдап ябыла, кешеләр көнлек шөгыльләрен тәгәлләп өйләренә ашыгалар. Кичке аш та өлгереп киләдер, инде морҗалардан аксыл баганалар сузылган. Борынны мал исе, төтен, печән-салам исе кытыклый.

Авылга гына хас самими манзара. Әйтерсең лә, берни булмаган, барысы да гадәттәгечә, барысы да элек-электән көйләнгәнчә үз эзеннән баруын дәвам итә. Тормыш шулайдыр инде ул: берәүләр китә, берәүләр килә, ә яшәеш тукталмый, аның чылбыры бервакытта да өзелми.

Җәмилә атның туктавын да көтмичә чанадан сикерде. Абынасөртенә кече капкага килеп төртелде. Куллары калтырана. Һич кенә дә капканың тәләкәсен таба алмый.

Ишек алдында кеше булган ахры: "Кем бар анда, хәзер үзем ачам", —дип аваз салды.

Җәмиләгә гүя яшен ташы бәрде. Күз аллары әлле-мәлҗе килеп алды да, аның югалтып кар өеменә ауды, бер генә сүз әйтергә өлгерде:

—Әни...

* * *

Җәмилә күзләрен ачканда түр караватта ята иде. Карашы әүвәле түшәмгә төште. Анда тимер дүнгәләк асылынып тора. Күнелен, кайда күрдем сон әле мин бу божраны, дигән уй биләп алды. Китми дә, куймый да, гүя шушы минутта ук шуны тәгаенламаса, бер-бер хәл булачак. Ми күзәнәкләре, ниһаять, хәтер эзенә төште. Бәрәч, бу бала бәллүе элә торган җайланма ич! Әнисе, сезнен барыгызнын да бишеген шунарга элеп тибрәттем, дип сөйли иде. Күр, авылда икән ләбаса ул! Җәмиләнен күзләре тәрәзә пәрдәләрен, мендәр өемнәрен сыйпап узды да, ишек өстендәге шәмаилдә туктап калды. Ул аны узган ел Казанда бер рәссамнан эшләтеп алган иде.

Тукта, тукта, нишләп авылда сон әле ул? Спартакиадага китәргә тиешләр иде ич. Төшләнә ахрысы. Сонгы атна бик киеренке булды шул, күнегүләрдән косасы килә башлады, спортзалга әйләнеп карамас хәлгә житте. Ә әнисе турындагы шомлы хәбәр? Анысы да төшме?

—Кызым, Җәмилә, уяндынмы?

Әнисе тавышы ләбаса бу! Әнисе, әйе, әнисе! Әнә, янында ук басып тора. Башында сөт кебек ап-ак яулык, кул-бармакларында йөзек-беләзек. Ул шулай төзү йөрергә ярата. Нинди матур анын әнисе! Нигәдер йөзе генә күләгәле. Үзе жылы, йомшак куллары белән бертуктаусыз Җәмиләнен чәчләреннән сыйпый.

Юк, төш түгел бу! Җәмилә тәмам уянды, барысын-барысын да хәтер җебеннән үткәрде.

—Әни, әнием!

—Тынычлан, кызым, тынычлан, алланын рәхмәте кин, терелерсен боерган булса.

Бала көегә йөрәктә ди, Җәүһәрия төнен керфек тә какмый үткәрде. Ходаем, теге вакыттагы юрауларнын раска килүе шушымы әллә, дип бик кайгырды. Тума бала үзе дә бәхетсез, башкаларны да бәхетсез итә, дип чистый бәгырен ашаганнар иде ич.

Уянды бит, әнә, уянды!

Җәмилә, ниһаять, әнисенен исән-сау икәнлегенә инанды. Һәм шушы ике көндә скрипкә кыллары кебек тартылган күнел җебе шартлап өзелде. Өйләгә кадәр берөзлексез яшь түкте Җәмилә. Әтисе дә, әнисе дә анын ни өчен шулай өзгәләнүен белмиләр иде әле, хастага калган икән дип кенә борчылдылар. Хәл сонынннан ачыкланды.

Көн кичке якка авышкач, Әлмәттән Мәгъсүмә апасы кайтып төште. Үзе генә түгел, Рөстәмне дә иярткән.

—Әһә, тәти күбәләк очып кайттымы?—дип үзеннән-үзе канәгать кыяфәттә өйне янгыратып көлеп жибәрде.—Әшне шулай коры тотарга кирәк аны, югыйсә, әллә нинди ярыш, дип авыз суын корыта. Монда ул ярышлардан да житдирәк эшләр чыгып тора әле.

—Мәгъсүмә, нинди эшләр ул, кызым?—дип сорады әнисе.

—Кияү балакайнын түзәр чамасы калмаган монда, һа-һа-һа.

—Ни сөйлисен син, кызым, күрмисенмени, Җәмилә урын өстендә ята.

—Алай гына була инде ул, әни. Хәзер безгә ике бүлмәле фатирны эләктереп калырга кирәк. Кулга үзе керәм дип тора, йотасы гына. Шуна телеграм суктым да инде сенелгә... Әзрәк борчылгандыр анысы, минеке инде, үзегез беләсез, туп-турыдан тут пошел. Башкача кайтмый иде Җәмилә, беләм мин аны, үзсүзле...

Мәгъсүмә берни булмагандай яшькелт күзләрен уйнаткалап, Җәмиләнен бит очыннан үбеп алды.—Синен өчен тырышам, сенлекәем, Рөстәмебез дә бик жилле егет булып чыкты, тимерне кызуында сугарга ярата.

Ишек катында кыенсыныбрак басып торган Рөстәм Мәгъсүмәнен бу сүзләрен һөҗүмгә күчү әмере итеп кабул итте, ахры, сайрарга тотынды.

—Диплом практикасына Әлмәткә, үзем эшләячәк промыселга

кайтачагымны язган идем инде, Җәмилә. Начальник фатир мәсьәләсен дә хәл итәбез, ди. Өйлән, ике бүлмәле фатирга хуҗа булырсың, ди. Монысын да беләсең инде...

—Күземнән югалыгыз! Икегез дә!—дип кычкырды Җәмилә ачы тавыш белән.—Сез, сез... сез вәхшиләр... Мин сезне күралмыйм...

Тагын нәрсәләр әйткән булыр иде Җәмилә, анысы билгесез, шул вакыт ишек ачылып китте. Әтисе икән. Пәһлүән гәүдәле, типсә тимер өзәрдәй таза бәдәнле ир аның әтисе. Ул атлаганда идән сайгаклары сыгылып-сыгылып китә. Бердәнбер физик кимчелеге - сул як күзе зәгыйфь. Сугышта ядрә кыйпылчыгы эләккән.

—Әнисе, тизрәк табынынны әзерлә, һай, канәт, кадерле кунаклар кайткан икән,—дип өй эчен шаулатты Нурулла.

—Сине көттек, әтисе...

—Әти, сөйләшәсе сүз бар иде,—диде Мәгъсүмә,—аш өенә чыгып керик әле.

—Юк, әти,—дип кырт кисте Җәмилә,—бернинди яшерен сүз дә була алмый. Әле син белмисең, менә бу ике әшнә миңа: "Әни үлде, тизрәк кайт",—дип телеграмма суктылар. Мин җеназага кайткан кеше...

—Ничек инде, канәт, без... ни...

—Мә, үзең укып кара.

Җәмилә сумкасыннан алып әтисенә телеграмма сузды.

Нурулла лып итеп урынына чүмеште.

—Мин барлык вәгъдәләремнән баш тартам,—диде Җәмилә,—бернинди ярәшү дә, туй да булмаячак!

Һай, ул чаклар хәтеренә төшсә, йөрәге сыкранып, тәннәре калтыранып китә.

Җәмилә авылда айга якын торды, көч-хәл белән рәтләнде. Казанга урап кайтканда укулар башланган иде инде. Аннан соң да әле шактый ара игә кила алмыйча йөрде.

Рөстәм белән аларның мөнәсәбәте алыш-бирешкә корылган иде. Димәк, андый матди мөнәсәбәткә генә корылган гаилә иртәме-соңмы барыбер таркала. Мәхәббәтне, хисне аркылы чыгып булмый икән. Ләкин ничек кенә булмасын, кызлар ир-егетләргә караганда гаилә җанлырак. Алар соңгы курста ничек тә кияүгә чыгу әмәлен эзлиләр. Чөнки беләләр, авылда иң уңышлы дигәндә дә, син тракторчы яки шофер куенына керәчәксең. Институтта укыганда кияү таба алмаган кыз сайландык һәм калдык кыз санала. Җәмиләнең дә утырган кыз булып каласы килми, әлбәттә. Карт кыз булса, өйгә эт керәкми диләр бит, аллам сакласын. Ләкин бер авызын пешкәч, өреп кабарга туры килә икән шул. Йөрәгендәге яра әле төзәлеп җитмәгән, гыйшык-мыйшык турында уйларгамы соң? Язмыш көймәсе нинди ярга китереп терәр, моны белсә, бер алла үзе генә беләдер.

Күңелен битарафлык, чарасызлык хисе богауга алган, бәгыре бозга әйләнгән шушы чакта аңа янә Мансур килеп очрады. Ул бу егетне мәңгегә үз юлымнан алып ташладым, дип уйлап йөри иде инде. Чөнки Мансур үзе дә табышмак. Тормыш җыр-моңнан гына тормый. Һәркем сайлаган кешесенең гомерлек терәк булуын тели. Рөстәм пыяла кебек үтә күренмәле иде, ышанычлы иде. Уч төбендәге шикелле барысы да ачык, барысы да алдан билгеләп куелган. Конвейердагыча, кайсы юнәлештә хәрәкәт итәсең, кай тарафта тукталасың—һәммәсе билгеле. Баш ватасы юк. Әмма бу канун да сынау үтә алмады. Шуның белән бергә, Җәмиләнең дә тормыш кагыйдәләре җимерелде. Мансурга да ышаныч шул кадәр генә.

Март башлары иде. Күзләрне камаштырырлык якты, матур көн. Кар өсте ялык-йолык итеп тора. Һавада ылыс исе, март инде җиһанга яз күзе белән карый башлаган. Бүген—студент яшьләрнең "Хуш, Кыш бабай" исемле спорт бәйрәме. Җәмилә дә эстафетада катнаша. Физматның кызлар командасы көчлеләрдән санала да, өченче чаңгычы трассада егылып, хәлне бик нык катлауландырды. Ике минут әрәмгә китте. Хәзер бөтен

ышаныч—Җәмиләдә. Команда абруен кайтарса, ул гына кайтара ала.

Трассаның буеннан-буена тамашачылар тезелгән. Һәрбарчасы үзләренекенә көч биреп тора. Физматлылар да шактый. Хор белән: "Җәмилә, Җәмилә",—дип оран салалар. Ул болай да мөмкин булганның барысын да эшләячәк. Тәҗрибәсе җитәрлек, азау ярган спортчы.

Көндәшен ул, алдан планлаштырганча, үр менгәндә куып җитте. Чөнки иң авыры үр менү. Күпләр очколарны шунда югалта.

Юл шома, чаңгылар үзләреннән үзләре бара кебек. Ләкин артык шома юлның үз кимчелекләре бар, адымнарны алыштырганда чаңгы нindидер бер мизгелдә артка таба шуышып ала. Мондый очракта кулларның көчле булуы зарур. Ә Җәмиләнең куллары гимнаст куллары, нык, талуны белми торган куллар. Шуның белән алдырды да. Финиш тасмасын ул өзде. Аны күтәреп алып һавага чөйделәр. Кемдер чәчәк бәйләме тоттырды. Ялгыш күрмимме дип, Җәмилә сыкылы керфекләрен җилпеп-җилпеп алды. Юк, ялгышмый. Бу—Мансур! Шушы көн кебек үтәли балкый. Иреннәре генә түгел, күзләре, кашлары, колаклары, хәтта чәчләре дә елмая.

—Котлыйм, Җәмилә,—диде ул,—филфак мактанчыкларының борынына чиерттең, афәрин...

—Син үзең дә филфак вәкиле түгелме соң әле?

—Филфагын филфак, ә йөрәгем физматта.

—Сез күптәнге тел бистәләре инде...

—Спорт киемендә син шаһинәләрнең дә шаһинәсе икән...

Җәмилә нидер әйтмәкче иде дә, өлгерә алмый калды, егет кабалана-кабалана сүзләрен әйтеп калырга тырышты: "Мин сине театрга чакырам, Җәмилә, "Профессор кияве" дигән спектакль. Яшь драматург Шәриф Хөсәенов язган. Зинһар өчен ризалаш, ә?"

Мансур гөнаһсыз сабый шикелле күзләрен мөлдерәтеп аңа карап тора. Сүзен тыңламасаң, хәзер елап җибәрергә әзер. Җәмиләнең болай да күптән театрда булганы юк иде. Гомумән, теге хәлләрдән соң тоткын хәлендә яшәде. Ярышта җиңеп чыгу, март кояшы, ылыс исе аны йомшартып җибәргән иде. Тотып ашамас әле, бераз күңел ачып кайтырмын, дип ризалыгын бирде. Ләкин бер шарт куйды, Мөнирәне дә чакырсаң, диде.

Мансур монысына да шат иде. Чөнки бу тәкәббер кызның йөрәген менә шулай акрынлап яуларга туры киләчәк. Ул әлегә Җәмилә кичергән фаҗиганы белми иде.

"Профессор кияве" аларга ошады. Кайтканда да юл буена шул хакта сөйләштеләр. Һәм дә театрга ешрак йөрергә кирәк дигән фикергә килеп саубуллаштылар. Бу инде үзара мөнәсәбәтләрнең якынаюы дигән сүз иде. Дөрес, Җәмилә Мөнирәнең туган көн бәйрәмендәге кебек ашкынулы хисләр кичермәде, йөрәге әле яралы иде. Тик барыбер туң күңеленең кайсыдыр почмагына нindидер җылы нур кереп оялады. Сүнәргә ирек куймасаң, кабынып китүе дә бик ихтимал.

Шулай да ул кабынып китмәде. Араларына янә таракан керде. Җәмилә нindидер гайбәткә таянып, егетне донжуанлыкта гаепләде. Мансур исә, мин кармакларны җыям, дип үпкәләп китеп барды. Аның, мәхәббәт балык тоту белән бер, капмый икән, димәк, кармакларны җыярга кирәк, дигән канатлы сүзләрне укыганы бар иде.

* * *

Пароход ак башлы ярсу дулкыннар өстендә тибрәлә-тибрәлә алга омтыла. Вакыты белән ул очарга әзерләнгән аккош кебек талпынып-талпынып та куя. Менә-менә күккә ашар сыман. Бәлки бу Җәмиләгә генә шулай тоеладыр? Ник дисәң, су арбасына беренче утыруы әле аның. Чистайда аны бергә укыган иптәш кызы көтеп тора. Аларда бераз кунак булмакчы.

Ул су буйларын күзәтеп, хозурланып барырмын дип уйлаган иде. Хәерчегә жил каршы дигәндәй, нияте барып чыкмады. Кичтән капыл гына һава хәлләре үзгәреп китте. Төньяктан искән жил үзе белән салкын гына түгел, яңгыр да алып килде. Спастагы кебек ниндидер энә күзеннән үтәрдәй вак яңгыр. Томан шикелле һавада асылынып тора.

Шулай да палубадан суга карап бару үзе бер рәхәт икән. Күңелгә әллә нинди ашкындыргыч уйлар керә. Тик барыбер моңсу. Чөнки тормышның иң мавыктыргыч, иң кызык, иң жилбәзәк чоры инде артта калды. Ялынып-ялварсаң да ул кире кайтмаячак. Узган болытны тотып булмый. Шул ук вакытта аның үтеп китүенә әллә ни борчылу-кайгыру да сизелми кебек. Имтиханнар тәмам, диплом кесәдә. Ул хәзер югары белемле укытучы. Теләгенә иреште. Урта мәктәптә балаларны математика фәненә өйрәтәчәк. Бөтенләй яңа тормыш башлана.

Тик әле ул алда. Бу хакта, дөресен генә әйткәндә, уйлыйсы да килми әле аның.

Пароход талпынып-талпынып караса да, очып китә алмады. Иделнең уң як ярындагы таулар ышыклады булса кирәк, аның йөреше тигез ритмга керде, калтыранулары тынды. Хәзер инде ул гүя бер урында тора. Яр кырыендагы йортлар, эреле-ваклы корылмалар, агачлар гына артка таба йөгерешәләр кебек. Нинди сәер жиһанның бу серләре. Ул менә тик тора. Чынлыкта исә алай түгел. Галәмдә һәр жисем, тереме ул, жансызмы —даими хәрәкәттә. Жир үз күчәрендә әйләнә, шул ук вакытта аның Кояш системасында үз орбитасы бар. Кояш системасының да Галактикада үз юлы. Галактика янә... Кыскасы, яшәеш, тормыш тоташ хәрәкәттән гыйбарәт. Кеше туа, үсә, картая, үлә. Монысы да хәрәкәт, табигатьнең илаһи могжизасы, яшәешнең асылы. Буыннар алышынып торганда гына тормыш дәвам итә.

Кешенең жаны бу фани дөньяга берничә тапкыр килә, имеш. Философиядән семинар дәресләре алып барган Иван Иванович Назаров атлы өлкән укытучы шулай әйтә иде. Бик тә сәер кеше иде мәгәр. Ленинны да, Марксны да тәнкыйть итүдән шикләнми иде. Соңыннан үзе дә юкка чыкты. Хакмы-түгелме, эшеннән куганнар, дип сөйләделәр.

Кызык, элек кем сыйфатында дөньяга килгән булган икән ул? Үзеңнең үткәнеңне, киләчәгеңне күреп булса икән? Алай дисәң, андый тормышның мәгънәсе калмас иде. Билгесезлек үзе бер тәртип, үзе бер стимул, омтылыш.

Жәмилә ирексездән башына кергән әлеге бик тә акыллы, әмма урынсыз уйларын куарга теләгәндәй тиз генә урыныннан торды. Палуба буш иде. Шыксыз көн пассажирларны каютага куып керткән. Алай да палубаның иң түрендә бакчадагы карачкы сыман бер ялгыз шәүлә шәйләнә. Башта ук Жәмиләнең күзенә чалынып алган иде ул. Һаман шул урында кукраеп басып тора икән әле. Хәер, икесе бер сынар...

Жәмилә сәгатенә күз төшерде. Тамак ялгап алыр вакыт та житеп килә икән. Кеше ишәйгәнче ашханәдә урын алып калу зыян итмәс.

Шәүлә Жәмиләнең аяк тавышын ишетте, күрәсең, ялт итеп борылып карады, һәм үзен-үзе белешмичә кычкырып жибәрде.

—Жәмилә!

—Мансур...

Икесе дә бу көтелмәгән очрашудан өнсез калды. Шактый ара берберсенә карашып, ни әйтергә белмичә аптырашып тордылар.

Иң беренче Мансур телгә килде.

—Нинди жилләр ташлады сине монда, Жәмилә?

Кыз да үз халәтенә кайткан иде инде.

—Төньяк жиле, Мансур, салкын жил...

—Дөрес әйтәсең, син чыннан да Котып кызы бит, Жәмилә.

—Нигә алай дисең, Мансур?

Егет дөресен әйтергәме-юкмы дигәндәй, икеләнебрәк торды. Аннан соң гына:

—Үзем гаепле, йөрәгенне эретә алмадым. Син минем өчен Котып кызы булып калдың,— диде.

Җәмиләнең күнеле исә бу мизгелдә утка эләккән балавыз шикелле тамып китәргә әзер иде. Мансур аңа бик якын булып тоелды. Бу очрашуга бик шат иде ул. Нигә мин аны шулай бик озак интектереп йөрттем соң? Ярата ул мине, ярата! Әнә бит күзләре нинди ачык. Ә күзләр алдамый. Ләкин үз уйларыннан үзе куркып, Мансурның Агыйдел якларыннан икәнен белсә дә, тизрәк сорау бирергә ашыкты:

—Ә син үзең бу көймәгә ничек тап булдың?

—Пароход минем корыч аргамагым, Җәмилә. Казанга алып килә, өйгә кайтарып куя.

Әңгәмә башка юнәлеш алды.

—Ишеттем, син юлламаны нефть төбәгенә алгансың икән, — диде Мансур.

—Мин бит үзем дә шул яктан, әти-әниләргә якынрак булсын дидем. Кормаш нефтьчеләр бистәсендә эшләячәкмен. Анда өч урта мәктәп бар икән, мин татар мәктәбен сайладым.

—Нигә Әлмәт түгел, анда да татар мәктәбе бар диләр бит.

—Шулай килеп чыкты инде. Ә үзең?

—Мин Казанга якынрак булсын дип Питрәчкә тукталдым. Көзен барыбер армияга китәсе.

—Пединститутта хәрби кафедра булмау бәласе инде бу, шулаймы?

—Хәрбиләр өчен кызлар үлеп китә бит, солдат каешын бусак, бәлкем безне дә яратырлар?

Җәмилә егетнең төртмәле сүзләрен уздырып җибәрде. Аннан соң бергәләшеп ашханәгә керделәр. Мансур шәраб тәкъдим итеп караган иде дә, Җәмилә кул-аягы белән каршы килде.

Озак кына палубада гәпләшеп йөрделәр. Нинди генә темага кагылмадылар, нәрсә турында гына сөйләшмәделәр?! Телләре ачылды. Әмма күнелләрдәге илаһи гөләп куагы әле һаман шәрә килеш кала бирде. Инде аңа бөреләнү, яфрак яру гына түгел, шау чәчәккә күмелергә вакыт, югыйсә. Мансурның моннан алдагы омтылышлары сагыш кына алып килде. Өстәвенә, бер гаепсез Дон Жуан атамасы алды. Шуңа күрә Җәмиләнең үзенә карата хисләре үзгәрүгә ышанып җитми. Якынаеп беткәннәр иде ич инде, мәхәббәткә бер генә карыш калган иде. Бер хәерсез гайбәт барысын да бозды. Аңлашу да тискәре нәтиҗә генә бирде. Үзе дә инде, әтәчләнеп сөйгән кызына әллә ниләр әйтеп бетерде. Янәсе, мәхәббәтне көчләп такмыйлар, янәсе, кармакларны җыяр вакыт җитте. Горур, имеш. Каян килгән Әстерхан шаһзадәсе.

Җәмиләнең эчендә дә ут. Ләкин ул кара күмергә калганчы янып бетсә дә, хисләрен ачмаячак. Кулы сынса, җиң очында, аягы сынса, итек эчендә калыр аның. Кыюлыкны егетләр күрсәтергә тиеш.

Мансур белән очрашуларның гадәти очрашулар түгеллегенә ул хәзер генә ышанып җитте. Җирнең үз орбитасында әйләнүе Галәм өчен ничек зарури булса, аларның күрешүе дә үзләре өчен шундый ук зарури нәрсә. Ул поезд белән кайтырга тиеш иде. Чистайга сугылу исәбендә дә юк иде. Соңгы сәгатьтә барысы да үзгәрде дә куйды. Ул Мансур белән бер пароходка туры килде. Зарурилык ич инде бу! Димәк, аңлашырга мөмкинлек бар...

Яңгыр туктады булса кирәк, яр буена тезелешкән авыллар аерымачык күренә башлады.

—Мин төнге утларны күзәтергә яратам,—диде Мансур,—үзеңне ниндидер серле утраудагы төсле хис итәсең. Күңел тынычлана, чөнки утлар сиңа юл күрсәтә, адаштырмый. Кечкенә чакта кышкы озын кичләрдә убыр утына мөкиббән идем. Тау буендагы зират өстендә пәйда була иде алар. Зурлар курка, ә миңа кызык.

—Миңа хәзер төшәргә вакыт җитә,—диде Җәмилә уены-чыны белән, —кыз баланы куркытып, убыр утларынны сөйләмәсәң дә була иде.

–Мин сине озатып куярмын, пароход Чистайда унбиш минут тора.

– Рәхмәт, мине каршы алачаклар.

Пароход озын-озын итеп сәлам бирде дә, йөрешен акрынайтып, очлы борынын яр ягына борды. Бер-берсенә карашып алдылар. Сәгатьләре сукты. Әмма араларындагы томан таралмады. Менә аерылышабыз да, дип сыкранып типте Җәмиләнең йөрәге, бәлки инде алар башка бервакытта да очрашмаслар. Кысыр очрашуларның да чиге була торгандыр ич...

Пароход янә сагышлы тавышын суызды. Шуны гына көткәндәй Мансур батыраеп, ниһаять, Җәмиләне кочагына алды да шашып үбәргә кереште: күзләрен, кашларын, чәчләрен, колакларын, кулларын... Үзе бертуктаусыз кабатлый: Җәмиләм, Җәмиләм, Җәмиләм...

Җәмилә бу мизгелне күптән көтсә дә, аңышмыйчарак торды. Әмма егетнең назы, дәрте, яратуы аның әлегә яралгы хәлендә оеган самими хисләрен йокысыннан уятты. Иреннәр иреннәргә беректе, ике жан бергә кушылды. Җәмилә әле упкынга тәгәрәде, әле күккә ашты, кый чәчәк яшел болыннарда хозурланды, ярсу дәрьяларда йөзде, ап-ак кар өстендә аунады... Беренче мәртәбә үзен хатын-кыз итеп тойды. Моңа кадәр ул аны чаңгыда текә таудан жилдертеп аска шуып төшкәндә генә сизгәли иде. Тизлек иң югары ноктасына ирешеп, менә-менә очып китәр дәрәҗәгә житкәч, тәнне ниндидер ләззәт биләп ала. Ул бер генә мизгел дәвам итә. Әмма шушы мизгелдә башка берни белән дә чагыштырып булмый торган татлы хис тоясың.

Үбешеп тыннары кысылгач, бер-берсенә карашып утырдылар. Мансур Җәмиләнең кайнар учлары белән үзенең битен сыйпады, бармакларын үпте. Җәмилә егетнең назларын бик теләп кабул итсә дә, үзе активлык күрсәтми, ояла. Чөнки ул мондый яратуларга күнмәгән.

–У-у-у-у...

Пароход тавышыннан икесе дә сискәнеп китте. Ул китәргә әзерләнә иде инде, шуны пассажирларның исенә төшерүе.

–Мансур...

–Җәмилә, син мине котәрсеңме?

–Көтәрмен, Мансур...

–Вәгъдәме?

–Мин инде синеке...

Пароход соңгы гудогын бирде.

–Җәмилә, без әле сөйләшмәдек тә ич, Җәмилә...

–Иң кирәген сөйләштек инде, Мансур. Хуш!

Җәмилә урыныннан кубып, тар аралыктан чыгу ягына йөгерде. Мансур тотам да калмый аның артыннан бара.

–Җәмилә, кал, әйдә, минем белән, Җәмилә...

–Мансур, акылыңа кил, мыскыл итмә мине.

Матрослар басманы алып маташалар иде инде. Җәмилә чак-чак чыгып өлгерде. Мансур аның чемоданын пароход кузгала башлагач пристань идәненә ыргытты.

Ара ераклашканнан-ераклаша. Кояш инде офык читенә кунаклаган. Аның сыек нурлары йокымсыраган Идел өстенә тасма булып сузылган. Су өсте жем-жем килә. Пассажирлар әле һаман кулларын болгыйлар. Мансур ак күлмәген кулына алып, әләм кебек җилфердәтә. Берара ул күздән югалып торды. Шуннан күп тә үтми, капитан мөнбәреннән Идел киңлекләренә аның бәхетле тавышы янгырады:

–Җәмилә-ә-ә, мин сине ярата-а-а-там...

* * *

Бүген аның дәресләре төштән соң. Шуңа күрә иркәләнеп ята. Жыр да күңелен ашкындырып жибәрде. Шул арада хәтер аша күпме вакыйгалар узды. Югыйсә, әле барысы да кичә генә булган кебек. Кызы

Ләйсәннең дә уяныргa исәбендә юк ахрысы. Бәләкәй песи баласыдай мыр-мыр килеп йоклый. Рәхәтлектән мырылдый, әнисенең җылысын, яратуын тоеп ята ул хәйләкәр.

Ләйсән дә әнисе шикелле үк Елан елында җиде айдан тума булып дөньяга аваз салды.

Кичтән бер дусларында туган көн бәйрәмендә булганнар иде. Җәмилә, гадәттәгечә, биеде дә биеде. Чегән биюе дә калмады, башкорт биюе дә. "Баланның эчен катырасың, чашма",—дип тә кисәтеп карады хуҗа хатын. Тыңламады. "Борчылмагыз, бу безнең икебезгә дә файда гына, аңа да, миңа да хәрәкәт кирәк",—дип үзенекен эшләде.

Төнге уникеләрдә тулгагы башланды. Ләйсән, ашыга-ашыга, машина эчендә үк туды.

Икесенең дә туган көне—22 июнь. Бу могҗизаның сәбәпләрен берәү дә төгәл генә аңлатып бирә алмады. Өлкәннәр Аллаһу рәхмәте белән диделәр. Ә фән исә аны очраклылык дип кенә саный. Әмма мондый "очраклар" булгалый икән үзе. Җәмиләгә шушындый гадәттән тыш хәлләр турында язылган китап та бүләк иттеләр. Дөнья хикмәтләрдән генә тора диярсең. Мәсәлән, мәшһүр күз буучы Мессинг Сталин белән булган бер әңгәмәсендә бер ел алдан Җиңү көненең төгәл датасын атаган—1945 ел, 9 май. Ә Михаил Ломоносов 1741 елда Германиядән кайтканда төшендә балык тотарга киткән әтисенең көймәсе батканын күрә.

Күп тә үтми, Архангел балыкчыларының хәбәрсез югалганлыгын ишетә. Төшен туганына сөйли. Тегесе шул сөйләү буенча дингез буеннан әтисенең үле гәүдәсен табып ала.

Ләйсән әнисе кебек үк чырышң булды, авырлыгын да тиз җыйды. Тупылдап торган искиткеч тере бала. Авыз тутырып ашый, бүселгәнче йоклый. Еласа, дөнья бетереп елый, тавышы урамга ишетелеп тора. Мәгәр назлы инде, әнисе сыңары. Бер генә минутка да аерылып тормас иде, һаман итәккә тагылып йөри. Үзенә инде дүрт яшь . Бакчага да бик авырлык белән өйрәнде, бармаска җай гына эзли. Әнисенең кайсы көнне икенче сменада эшләвен дә белә, кичтән үк бакча мәсьәләсен хәл итеп куйды. Әтисе юкта йоклавын да бергә йоклыйлар. Иртәгә Мансур кайтырга тиеш инде, алла боерса. Бу юлы әллә нигә озак тоелды. Бик сагындырды. Үзе дә Ләйсән сыңары инде ул. Яңа гына кавышканнар диярсең. Гобәй белән Хөбәй шикелле һаман бергә. Халык та шуна күнде, ялгызын гына очратсалар, кояш башка яктан чыкмагандыр бит бүген, дип шаярталар. Шөкер, инде ир белән хатын булып биш ел яшиләр, әлегә кыз белән егет кебек, сөешеп туймыйлар. Бер кечкенә мәрәкә булып алды алуын. Телгә алып сөйләрлек вакыйга да түгел инде ул. Җәмилә аны белә торып үзе күпертте. Башмак керсез, хатын-кыз мәкерсез булмас ди. Монысы инде чын-чынлап хатын-кызлык.

Узган ел булды ул хәл. Җәмилә Бөгелмәгә методик берләшмә утырышына киткән иде. Мансур белән Гайшә исемле укытучы кыз эштән бергә кайтканнар. Тегесе юл уңаена кибеткә кереп өч килограмм бал сатып алган. Мансур шуны күтәреп кайткан, кызны фатирына кадәр озатып куйган. Мансур моны Җәмиләгә мактана-мактана сөйләде. Минем ирем нинди джентельмен икән дип, Җәмиләнең мактавын көткәндер, мөгаен.

Мактаумы соң? Иреннәре турсайды, күзләре мөлдерәмә, менә-менә чайпалырга тора. Ашарга әзерли иде—тәлинкәләре шак та шок килә башлады, кашыклары бөтенләй идәнгә сибелде.

—Җанаш, син нәрсә?—дип Мансур гаҗәпкә калды.—Бу гап-гади игътибарлылык билгесе ләбаса!

Кәефе киткән чакларда Җәмилә аякларын бөкләп диван читенә чүмәшеп утырыр иде дә, кулына китап алыр иде. Мансурга хатынының менә шундый үпкәләве ошый иде. Билгеле, ул үпкә дигәннәре җиңелчә шаяру, назланулы чытыклану гына, гүя кичке эңгер-меңгердә оеп утырган

күл өстеннән жилбәзәк жилбикә йөгереп уза. Яратышу өчен үпкәләшү. Күп тә үтми, гыйшык табигый эзенә төшә, барлык төсләре белән балкый башлый.

Ә бу юлы Жәмилә чын-чынлап үпкәләгән иде. Чөнки араларына икенче хатын-кызның исеме килеп керде. Монда, билгеле, Мансурны гаепләү өчен нигез дә юк. Ир-ат табигате белән кин күңелле, ул үзенең бәйсезлеген генә түгел, һәр даим экерсезлеген дә исбат итәргә тырыша. Хатын-кыз исә беренче чиратта үз ишен көндәше итеп кабул итә. Һәм шуның белән яраткан кешесен сер яшерергә өйрәтә, икейөзлелеккә этәрә. Әлеге вакыйгадан соң Мансур да телен тешләде. Жәмилә моны үзе дә сизде. Бераздан ул әлеге карашларына фәлсәфи нигез дә тапты. Бер Аргентина язучысы әйткән, имеш, "Хатыны көнләшмәгән ирнең поты бер тиен",—дигән.

...Ләйсән иреннәрен чупылдата-чупылдата киерелеп алды да, әнисенә сыеныбрак ятты. Йокла, йокла, пескәем, дип Жәмилә аның чәчләреннән сыйпады.

Ләйсәнне Мансурныкылар Сөргенгә сөрелгән Әкрәм бабаларының Зәйтүнә исемле кызына охшаталар. Бик чибәр, бик горур, үз сүзле кыз булган, имеш. Гомере генә кыска булган. Жәмиләнекеләр дә әнисе ягының шундый ук мөхтәрәм бер абыстайга тартым диләр. Ләкин Ләйсәннең кулак кызы кебек тә, абыстай кебек тә буласы килми. Аның әтисенә охшыйсы килә. Фотоальбомны исенә төшкән саен актарып чыга. Ана бигрәк тә әтисенең армиядә төшкән сурәтләре якын. Мансурның фотодагы күзләрен, иреннәрен, кашларын, борынын, ияген, колакларын бармаклары белән капшый-капшый да: "Мин әтием кебек",—дип куана.

...Мансур бер елдан соң Жәмилә янына кунакка кайтты. Аңа хәрби күнегүләрдә күрсәткән нинди дер тапкырлыгы өчен дивизия командиры кыска вакытлы ял биргән икән. Армиядә Мансур радист булып хезмәт итте. Ул бу һөнәре белән жае чыккан саен мактана. Радистлар Кораллы Көчләрнең зыялы катламы, ди, моның өчен музыкаль сәләт зарур, ди. Вакыт-вакыт әле дә радиоалгычтан морзе билгеләре белән бирелә торган тапшыруларны кәгазьгә төшерергә ярата.

Ул сентябрь аенда кайтып төште. Мәһабәт гәүдәле солдат. Хәрби кием килешеп тора үзенә. Тагын да ыспайланып киткән. Кайткан көнне тулай торакта кечкенә генә мәҗлес үткәрделәр. Жәмилә Жанна исемле рус теле укытучысы белән бер бүлмәдә яши иде. Тагын берничә яшь укытучы килде. Мәктәптән баян алып кайттылар. Мансур уйнады да, жорланды да, көлдерде дә. Кичә сонында бер яна жыр да жырлап күрсәтте. Гадәттәгечә, тавышы йомшак, моңлы, самими иде. Көе дә аһәңле, үзенең башкару рәвешенә туры килеп тора.

Кил, бәгърем минем, кил син миңа!
Карашыңнан моңнар агылсын,
Фәрештәләр безгә канат каксын —
Бәхет жиле килеп кагылсын.

Мәжлес дәвамында язгы чыпчыклар шикелле чырык-чырык чыркылдашып утырган кызлар тып-тын калды.

—Нинди көй бу, Салих Сәйдәшевныкы түгелдер бит?—дип сорады Жанна жыр тәмамлангач.

—Башкорт жырына да тартым,—диде икенчесе.

—Сүзләре бик матур...

—Жәмилә исеме кергән жырларның коллекциясен жыясың, ахры, син, Мансур.

—Әйе, кызлар дөрес әйтәсез, жыям шул. Монысы яңасы. Ошыймы?

—Ошамыйча. Безгә дә өйрәт әле, син киткәч, Жәмиләгә жырларбыз.

Жәмилә нинди дер эчке бер тоемлау белән әлеге жырның үзенә атап чыгарылганын сизеп алган иде инде. Мансур аны гел аңа карап

жырлады. Күзләрендә—наз, моң, сөю, ышаныч, өмет—барысы бергә укмашкан. Үзенең дә тәне, барча күзәнәкләре ярату хисе белән тулды.

—Рәхмәт, кызлар,—диде Мансур үтә бер дулкынлану белән,—бу үземнең жыр, Жәмиләгә багышлап чыгардым. Хәзер, сезнең алда, мин аны иясенә тапшырам.

Мансур "Кил, Жәмиләм" дигән жырның нотасы, сүзләре язылган буклетны Жәмиләгә тоттырды. Жәмиләнең күзләреннән яшь бәреп чыкты. Мансур ул яшьләрне кайнар иреннәре белән корытты. Пароходта беренче мәртәбә яратышкандагы кебек Жәмилә ләззәт чишмәсенә инде.

Яратышулары үбешүдән узмады. Мансурның әле бер ел хезмәт итәсе бар иде. Шул вакыт эчендә ул экстерн рәвештә хәрби училище өчен имтихан бирергә тиеш, офицер дәрәжәсе алгач кына запаска китәчәк.

Тагын бер көннән алар Жәмиләнең әти-әнисе янына авылга кайтып киттеләр. Мишәрләрдә егет ияртеп кайту мәртәбә саналмый. Әмма Жәмилә югары белемле укытучы, авылдан чыгып китүенә дә дистә ел тулып килә. Янә бер сәбәп: кодалаучылар күбәйде, үзенә дә сүз кушалар, әти-әниләрен дә интектереп бетерәләр икән. Апасы берни булмагандай һаман Рөстәм мәсьәләсен кузгата, янәсе, аның бер гаебе дә юк, кара эт баласен ак эткә якма, ди.

Туган-тумачаны Мансур белән таныштыру әлеге ыгы-зыгыга чик куярга тиеш иде. Ул шулай булып чыкты да. Яхшылап сөйләшкәч, әти-әнисе аның хәлен аңлады, күтәрелеп бәрелмәделәр. Мансур абзар-кура тирәсендә Нурулла абзыйга булышкалап та йөрде. Бу аңа бик ошады. Ир баласы булмаган әти өчен үзе күңелле манзара. Армия турында сораштырды, дөнья хәлләре белән кызыксынды. Ул үзе сугышта катнашкан, кырык дүрттә бер күзен ядрә кыйпылчыгы изгәч, кайтарып жибәргәннәр. Сугыш тәмам желегенә үткән. Бервакыт бөтен авылны күтәргән.

Ул көнне эштән кызмачарак кайткан бу. Ашап-эчеп алган да ятагына ауган. Ә бераздан куркынып уянып китмәсенме. Жә, ходай, кайдадыр туплар гөрселди, бомбалар шартлый. Туктаусыз пулеметтан аталар... Мәхшәр инде. Шул мәхшәр эчендә кемдер: "Сугыш, сугыш",—дип һаман әлеге куркыныч сүзне кабатлый.

Башы чуалган чак фронтовикның. Урамга атылып чыга бу. Шул кызудан клубка бәреп керә дә:

—Сугыш чыккан!—дип кычкыра.

Китә кычкырыш, этеш-төртеш, ыгы-зыгы. Әйтерсең лә, сугыш инде авыл уртасына килеп житкән.

Ахырдан ачыклана, радиодан сугыш турында спектакль тапшырган булганнар икән.

Нурулла абзыйның мажараларына шушы кыска гына вакыт эчендә Мансур да шаһит булды. Иртән иртүк өйдә мичкәдән чыккандай калын тавыш янгырады: "Торыгыз, тор, Алиулланыкылар инде бер юл печән алып кайтты, эшкә тотынырга вакыт". Хатыны Маһруйның: "Сиңа әйтәм, алапа корма, кунакларны уятасың бит",—дип еландай чыжылдавы да файда бирмәде.

Ә ун-унбиш минуттан абзыебыз исә чалкан төшеп гырлый-гырлый йоклап та китте.

Жәмилә инде боларга күнгән. Әтисенең мөгез чыгара торган гадәтләре хакында егетен алдан кисәтмәде, үзе күрсен, белеп торсын, дип уйлады. Мансурга нәрсә? Кызык кына. Аңа шундый кыбырсык, шаталак кешеләр ошый. Андыйлар эчкерсез була. Ачу сакламыйлар, кешегә начарлык эшләмиләр. Әмма тынгылык та бирмиләр.

Монысын да исбат итте булачак бабасы. Кормашка алар кич белән кайтып життеләр. Ә иртәгәсен иртүк Нурулла ишек какты. Чәй эчеп утыралар иде. Мансурның соңгы көне, поезды төнге сәгать унбердә китә. Аныңчы әле Бөгелмәдә шөгыльләре бар.

Жәмилә авызындагы кабымын йота алмый торды. Аннан соң гына: "Әллә берәр хәл булдымы, әти"?—дип сорады.

Нурулла кызының өзгәләнүенә әһәмият бирмәде, йомышын йомышларга ашыкты:

—Кыз, заемга акча цыккан анда, давай, китер әле заемнарны!

Җәмиләнең күзләре кашына менде.

—Нинди заем, әти?

—1965 елгы заем. Шуның берсе откан. Мин аның нумерларын язып калдырган идем. Ять бул, ашыгам!

—Ут капмагандыр бит, әти, үзем алып кайтып биргән булыр идем, —диде Җәмилә. Мансур алдында оят иде аңа.

Чыннан да, моннан ике-өч атна элек, әтисе бер төргәк заем облигацияләре тоттырган иде, тираж таблицасын җә күрми калырбыз, син күз-колак бул әле, кызым, дигән иде. Ут борчасы. Кай арада тикшергән дә, кай арада килеп житкән?

—Һай, әти, кыланып та карыйсың инде.

—Канәт, ирнен ире ком өемен тау итәр ди,—дип Нурулла Мансурга сыңар күзен кысып куйды. Бу аның ир кеше дилбегәне кулыннан ычкындырмаска тиеш дигәнен аңлата иде, ахры.

—Монда киткәненне әни беләме сон?—дип сорады Җәмилә. Үзе сорады, үзе үкенде. Чөнки әтисе төпченгәнне яратмый, акылына ни килсә, шуны эшли. Вакыт-вакыт ул савым сыерын базарга алып чыгып китә. Сатып җибәрергә җае чыкмаса да, сатулашудан тәм таба. Кайчандыр мунча бурасы юнәткән иде. Аның белән дә әш-мәшә килеп бетте: әле сата, әле баш тарта. Апасы Мәгъсүмә дә әтисенә ошаган, ордымбәрдем.

— Әтсәм белер иде, канәт, әтмәдем бит,—дип көлде Нурулла.— Барысын да катынга әйтеп эшләмиләр аны.

Әтисе киткәч, алар мәктәпкә бардылар, Мансурга эш мәсьәләсендә директор белән сөйләштеләр. Мин ике куллап риза, диде директор, мәктәптә ир-ат укытучыларның күбрәк булуы хәерле. РОНОга сугылдылар. Анда да җавап уңай иде.

Мансурның кайтуын гына көтәсе калды.

...Җәмилә кызын уятмаска тырышып, иплэп кенә урыныннан торды, китап шкафыннан яшел бәрхет белән тышланган альбом алды. Альбом эчендә Җәмилә өчен иң кадерле ядкарь — Мансурның аңа багышлап чыгарган "Кил, Җәмиләм" дигән җыры. Бу җыр шатлыкта — куанычы, кайгыда—таянычы. Мансур аны бик матур итеп бизәгән (бу яктан да сәләтле иде!), текстын кара тушь белән һәр хәрефне миллиметрына кадәр китереп язган. Карап кына торырлык. Ул, әлбәттә, үз җырының сүзләрен яттан белә. Тик Мансур үз куллары белән бизәгән бу китапчык бөтенләй башка. Ул аңа рәхәтлек, тынычлык китерә. Аны кулга алгач, мәхәббәтнең, яратуның барлыгына ышанасың. Әнә шундый сихри көчкә ия бу китап.

Җәмиләнең күзләре шигъри юлларны иркәләде:

Кил, Җәмиләм минем, кил син миңа,  
Таң кошыдай күңел кагынсын.  
Алсу таңнар янсын безнең өчен,  
Керфегеңдә йолдыз кабынсын.

Кил, бәгърем, якты илһам бул син  
Яз шагыйре—назлы былбылга—  
Сиңа атап былбыл моңын сибәр,  
Өзелеп сайрар синең алдыңда.

Кил, бәгърем минем, кил син миңа!  
Карашыңнан моңнар агылсын,  
Фәрештәләр безгә канат каксын—  
Бәхет җиле килеп кагылсын.

Кил, Җәмиләм минем, кил син мина
Бәхет җиле булып офыктан —
Син онытма минем назларымны,
Назларынны синең онытмам!

* * *

Мансурның семинарда сөйләгән докладын бик игътибар белән тыңладылар. Уңай образлар үрнәгендә югары класс укучыларында ихтыяр көче тәрбияләү мәсьәләсе тыңлаучыларны да кызыксындырды. Сораулар да күп булды. Министр Мирзанур Мостафин да бар иде. Алар аз-маз таныш. Узган ел татар теле һәм әдәбиятын укытуны камилләштерү буенча Әлмәт шәһәрендә булып үткән фәнни-гамәли конференция вакытында очрашканнар иде. Министр ул үткәргән ачык дәрестә булды. Анализ вакытында мактады да. Һәр мәктәптә Мансур Әмиржанович шикелле бер-ике генә иждади эшләүче укытучы булса да, милли мәктәпләрнең абруен бик нык күтәрә алыр идек, диде. Бу өлкәдә министрлык кайбер чаралар да күрергә җыена икән. Мәсәлән, терәк мәктәпләр булдыру. Шулар базасында якын-тирә мәктәпләрдә эшләүче укытучыларның методик хәзерлеген күтәрү мөмкинлеге ачылачак, диде.

Бер-ике ай үткәч, Кормаштагы 1 нче урта мәктәпкә дә татар теле һәм әдәбият буенча шундый статус бирелде. Төбәк методик берләшмәсенең җитәкчесе итеп Мансур билгеләнде. Мәктәпне "Мансур мәктәбе" дип йөртә башладылар.

Әлеге ачык дәрестән соң министр белән алар икәүдән-икәү калып та фикер алыштылар. Ул аның диссертациясе белән кызыксынды. Хуплады. Җитәкчесен генә өнәмәде, арыш боламыгы ич ул, дип Мансурны борчуга салды.

Мостафин аны тагын бер гаҗәпкә калдырды. "Син яхшы укытучы", —диде ул.—Ләкин шуны колагыңа киртлә, әдәбият дәресе—ул сәнгать дәресе, уй-фикер, эстетика дәресе. Әдәби әсәрләр аша без балаларны матурлык дөньясына, сәнгатьчә сүз дөньясына алып керергә тиеш. Кинопроекторлар, эпидиаскоп, магнитофоннар кулланып, без әдәбиятның асылына балта чабабыз. Болай барсак, тиздән безнең укучылар сөйләшүләрен онытачак, карга кебек авызларын ачып, тамаша гына көтеп утырачаклар.

Министрның бу концепциясе Мансурны нык уйландырды. Ник дисәң, һәр киңәшмәдә, һәр конференциядә, матбугат, радио-телевидениедә дәрестә техник чараларны куллану — заман таләбе, фән-техника прогрессы таләбе, дип лаф оралар. Мәктәпкә килгән тикшерүчеләрнен, инспекторларның да сүзе шуннан башлана: Липецк тәҗрибәсен ничек кулланасыз, техник чаралардан файдаланасызмы? Ләкин бу эш әле бик авыр бара. Чөнки ул укытучыларның әзерлегенә, техник чараларның сыйфатына бәйле. Еш кына дәрес барышында аппарат ватыла. Бу инде дәрес өзелде дигән сүз.

Тырышып-тырышып керткән яңалыкны министр абзый әнә шулай тетеп салды. Ул укыту процессын "тоташ техникалаштыру"га каршы икәнен сиздерде. Мансур тора-бара үзе дә шул якка авышты. Сарык бәрәннәре шикелле аңгыра бәндәләр инде без, дип үз-үзеннән көлде. Һәр нәрсәнең урыны, чамасы була ләбаса! Кешегә ияреп, үз биюенне дә онытып җибәрергә мөмкин.

Мирзанур Мостафин алтмышынчы еллар дулкынында күтәрелгән демократик карашлы кеше. Андрей Возненский, Эрнест Неизвестный кебек шәхесләргә табына. Бәйсез татар зыялыларыннан Нәкый Исәнбәт, Аяз Гыйләҗевларның иҗатын хуп күрә. Аеруча аңа "Өч аршын җир" повесте ошый. Яшь, чибәр, тәвәккәл, эрудит. Берничә тел белә. Ул министр кәнәфиенә утыргач, татар мәктәпләренең хәле күзгә күренеп яхшырды, татар теленә игътибар артты. Әлмәттә үткән конференция дә

зур йогынты ясады. Сугыштан соң татар телен укыту проблемалары турында болай зурдан кубып сөйләшү булмаган икән әле. Татар теле белгечләре үзләре үк ана телennән ваз кичә башлаганнар иде ич инде. Үзе тарих мөнбәреннән куып төшерелсә дә, Сталинның, вакыт узу белән кулланышта бер генә тел калачак, дигән тәгълиматы һаман яши. Бу, әлбәттә, бөек рус теле булачак! Башкалар иртәме-соңмы—үләчәк. Милли гореф-гадәтләр, халык йолаларын да шундый ук язмыш көтә. Аларны Совет йолалары, коммунизм төзүченең мораль кодексы алыштырачак.

Армиядән кайтышлый ук Мансур институтка сугылган иде. XX гасыр татар әдәбияты укытучысы, доцент Вәзирә Җамалиева белән очрашып сөйләште. Аны аспирантура мәсьәләсе кызыксындыра иде. Доцент, гадәттәгечә, ачык чырайлы иде, теле ипигә ягып ашарлык татлы. Ләкин, кем әйтмешли, тел өсте баллы булса да, тел асты тозлы икән апабызның.

—Якын күреп әйтәм, Әмирҗанов,—диде иреннәрен бөрештергәләп,—башка өлкәне сайла, татар теленең киләчәге юк. Үзем дә үкенеп бетә алмыйм.

Лекцияләрдә татар теленә мәдхия җырлаган, татар язучыларын күкләргә чөеп мактаган укытучының бу сүзләре Мансурны пошаманга салды. Бәлкем, дөрестән дә шулайдыр, дип шикләнеп калды. Берара, кирәксез һөнәр сайлаганмын икән, дип үз-үзен битәрләп тә йөрде. Ләкин бу озакка бармады. Әгәр барыбыз да туган телебездән, ата-баба мирасыннан, гореф-гадәтләребездән ваз кичә башласа, татар халкы, чыннан да, юкка чыгачак ләбаса! Кайчандыр үзенең мөстәкыйль дәүләтчелеге булган зур халык: "Бетәбез, бетәбез",—дип кул кушырып утыра алмый. Теле өчен, җаны, рухы өчен көрәшергә тиеш ул. Мансур да шуларның берсе. Зур мәктәпнең завучы буларак, аның гамәли яктан мөмкинлекләре дә бар ич әле. Җәмәгатьчелек фикерен формалаштыруга да үз өлешен кертергә тырыша. Республика матбугатында аның үз урыны бар инде. Кушып та яздыралар, үз инициативасы белән дә яза. Шул язмалар буенча Милли мәктәпләр институтының өлкән фәнни хезмәткәре Габбас Ярмиев эзләп тапты да инде аны.

Тыныч табигатьле, акрын хәрәкәтле, йомшак характерлы бу кеше кайчандыр партия өлкә комитетында эшләгән, күпмедер вакыт хәтта кайдадыр бер педагогия институтында ректор вазифаларын да башкарган. Сүзләре теш арасыннан саркылгандай сөзелеп кенә чыга. Тыңлый-тыңлый арып бетәсең.

Мансур аның басынкылыгын, салмаклыгын галимнәргә хас үзенчәлекле сәерлек дип кабул итте. Трамвайга галошларын салып кергән профессорлар турында укыганы бар. Эйзенштейн шикелле әре каеш урынына билләренә киндерә дә бәйләп йөргәннәр, имеш.

Габбас Ярмиев аңа диссертация темасы тәкъдим итте. "Язганнарыгызны күзәтеп барам, укучыларның мөстәкыйль фикер йөртүен үстерү буенча максатчан эшлисез икән, мөстәкыйльлек шул ихтыяр көче инде ул, алынгыз шул темага",—диде. Үзе докторлык диссертациясе яза икән, Мансурның эше әлеге саллы хезмәтнең бер канаты булмакчы. Бергәләп анкета сораулары әзерләделәр. Роно мөдире белән килештереп, Мансур район мәктәпләрендә анкеталар үткәрде. Шул арада философия, немец теле фәннәре буенча кандидатлык минимумы имтиханнарын тапшырды. Диссертациягә ул чынлап тотынды, инде төгәлләү алдында. Көн тәртибенә планга кертү мәсьәләсе килеп басты. Яклау Мәскәүдә, Баш институтта үтәчәк, диделәр. Укыту белән фәнни эшне бергә алып бару, әлбәттә, бик авырга туры килә.

* * *

Министр бу юлы да тыңлаучыларны әсир итте. Аудитория алдында ул үзен чын артистларча тота. Кирәк урында елмаеп җибәрә, шунда ук хатын-кызларныкына охшаш кыйгач кашлары дугаланып китә. Иреннәрен

уйнаткалап куя. Мимикасына туры китереп, тавышын да үзгәртә. Ул тамак төбе беләнрәк сөйләшә, шуна тавышы яңгырабрак чыга.

Мансурга исә Мостафинның бәйсезлеге, тәвәккәллеге ошый. Әле дә урындагы житәкчеләрне һич курыкмыйча тәнкыйтьләде. Бу авыл укытучыларының эченә сары май булып ятты. Чөнки түрәләр укытучының төп эшен эшкә санамыйлар. Кулларыннан килсә, укытучыларны кырыкка ярырлар иде. Укытучы көтү дә көтә, йон да тетә. Агитатор да, пропагандист та, үзешчән артист та, унлаган комиссия әгъзасы да... Хуш, аларына түзәргә дә булыр иде әле, ни әйтсәң дә, укытучы авылның интеллектуаль йөзе, укымышлы катламы. Бу эшләрне ул башкармый, кем башкарсын? Әмма халыктан сөт жыю, мал исәбе алу кебек эшләр аның абруена да суга, төп эшеннән дә аера. Мондый шартларда укытучының үз белемен күтәрү, гамәли осталыгын камилләштерү турындагы сүзләр стенага сибелгән борчак кебек кенә була түгелме? Менә шуннан китә инде күз буяу, ярым-йорты белемле балалар.

—Бу мөһим мәсьәләне мин хөкүмәт алдында бөтен катгыйлыгы белән куячакмын,—диде министр.

Укытучылар гөжләтеп кул чапты.

Мондый хәлләрне Мансур да үз башыннан шактый күп кичерде. Татар түрә булса, чабатасын түргә элә диюләре хак инде аның. Тәкәббердер үзләре, дорфа, кешене чүп урынына да санамыйлар. Түрәлекләрен дәлилләү өчен теләсә-нинди гамәлгә дә барырга әзерләр. Аеруча түбәнрәк баскычта торучылары азына. Үсәргә кирәк бит, шуңа тиреләре ертылганчы тырышалар.

Бервакыт мәктәп партия оешмасын совхозныкына куштылар. Интеллигенцияне "шефка" алу модага кергән иде. Партком секретаре аяк терәп мәктәп эшенә тыгыла башлады. Бик үз сүзле, тискәре адәм иде. Элеккеге мал врачы. Интеллекты да үгез печүченекеннән узмаган.

Мәктәпкә чын-чынлап балансы-ние белән куян фермасын тага язды бит. Тәрбия ижтимагый файдалы хезмәткә нигезләнергә тиеш, янәсе. Көч-хәл белән котылдылар. Алай да мәктәп ихатасында куян оялары барлыкка килде. Әле булса интегәләр.

Жыелышлар турында әйтәсе дә юк. Алар һәрвакыт ачык булыр, партия әгъзасымы син, юкмы—катнашырга тиешсең. Төнге уникеләргә кадәр авызларыннан хәмер исе анкып торган совхоз белгечләренең үзара әрләшкәнен тыңлап утырырга туры килә иде.

Ә бер вакыйга, мөгаен, фельетонистларның башына да килмәс иде. Алар жәйге ялны авылда үткәрәләр иде. Башта Жәмиләләрдә булалар, аннан соң Сөн хозурына кайталар. Укытучының ялы озын, барысына да өлеш чыгарырга була.

1968 нче елда да ял тәртибенә үзгәреш кермәде. Чирмешәндә хәл алгач, Актанышка юл алдылар. Бажасына рәхмәт, машиналы итте. Иске "Москвич"ы бар иде, көтәргә бирде. Бер елдан аны Мансур энәдән-жептән диярлек рәтләде. Кузовын буятты, моторын алыштырды, яңа тәгәрмәчләр куйды. Акчаны суырды—суыруын, әмма машинаң булу жан рәхәте. Кешегә ялынычың төшми, кая телисең, шунда сәгате-минуты белән чыгып китәсең.

Урак өсте иде. Көн аяз. Кояш кыздыра. Юл буе басуларны күзәтеп, шатланып-куанып кайттылар. Күренеп тора, быелгы ел зур уңыш елы булачак.

Кайтып тузаннарын да кагарга өлгермәделәр, почтальон телеграмма китереп тоттырды. Ашыгыч телеграмма. Молния! Бер генә жөмлә: "Иртәгә үк эш урынына кайтып житегез, партком".

Нинди ашыгыч хәл килеп чыкты икән соң? Директор белән бер-бер нәрсә булганмы әллә? Ул чагында ни өчен партком, ни өчен дирекция түгел? Фәттаховның чираттагы мөгез чыгаруымы? Алай дисәң, мондый ук башбаштаклыкка ул да бара алмастыр. Моның өчен ахмакның ахмагы булырга кирәк. Ул законлы ялда. Аны фәкать директор гына чакыртып

ала ала. Анда да ике якның да ризалыгы зарур.

Җәмилә белән икәүләшеп баш ваттылар. Ахры директор авырып киткәндер, ремонт эше тукталгандыр, шуна чакырталардыр, дигән фикергә килделәр. Партком секретаре Фәттаховка килгәндә, аның ат дагалаганда ботын кыстырган бака кебек һәммә нәрсәгә тыкшынып йөрүе һич тә гаҗәп түгел. Абруйлырак булсын дип сырлагандыр имзасын.

—Чукынышып китсеннәр, кайтмыйм,—дип киреләнде Мансур бераздан,—мин—ялда! Телеграммагызны алмадым диярмен.

—Син хәйләкәр, алар синнән дә хәйләкәррәк шул, телеграмманы уведомление белән сукканнар, кул куеп алдың ич,—диде Җәмилә.

Мансур ачу белән чынаягын читкәрәк төртеп куйды. Ашъяулыкка каракучкыл төстәге чәй тамчылары сибелде.

—Ипләп, улым,—дип моңа кадәр аларны тынлап кына утырган әнисе сүзгә кушылды,—алай дуамалланып тәртәгә тибү килешмәс. Юкка-барга гына хәбәр җибәреп маташмаслар. Кирәген чыккандыр.

—Әнкәй дөрес әйтә,—дип Җәмилә дә аны хуплады.

Иртә таннан Мансур юлда иде инде. Кормашка төш вакытында ук килеп житте. Мәктәптә бер җан иясе дә юк. Әбәткә киткәннәр ахры, эш кораллары, буяулар шунда аунап ята. Ремонт бара. Димәк, директор урынында. Мөгаен, Фәттаховның этлегедер. Шуңа охшаган. Ул парткомга китте. Секретарь шунда иде. Мансурга сөзгәк үгез шикелле каш астыннан карап алды да:

—Уборкы вакытында ничек шулай арт кыздырып йөрү ул?—диде.— Хәзер үк агитаторларны җыегыз. Сезнең аркада кичә Өлкә комитеты вәкиленнән шелтә алдым...

—Карагыз әле,—дип бүлде аны Мансур,—сез чыннан да ахмакмы, әллә ахмак булып кыланасыз гынамы? Мин сезнең ялыгызга кысылмыйм бит. Шулай ук сез әйткән Өлкә комитеты вәкиленең ялына да дәгъва белдергәнем юк. Аннан соң, мин партия әгъзасы түгел. Сез миңа әмер бирә алмыйсыз. Сез ничек миңа телеграмма җибәрергә җөрьәт иттегез?

Фәттаховның күзләре акаеп чыкты, йөзен тимгел басты. Берара этенеп сүзен әйтә алмый торды.

—Э-э, пар... э-э, пар...

Мансур аның кулына сулы стакан тоттырды. Тегесе голт-голт итеп эчеп бетерде. Әмма усаллыгы бетмәде.

—Партия ул, Әмиржанов, теләсә-кемгә әмер бирә ала. Телеграмма да җибәрә ала. Аңладыңмы? Кирәк тапса, синең кебек шома абзыйларны эшеннән дә куып чыгара ала. Аңладыңмы?

—Партком секретаре әле ул партия дигән сүз түгел.

Фәттахов бу юлы графиннан үзе су салып эчте.

—Син үзеңне бик акыллыга, булдыклыга чутлыйсың инде, Әмиржанов, иеме? Юк, брат! Теләсәм мин сине кандала урынына сыта алам. Аңладыңмы?

—Сыткан диярләр.

—И һәм сытам да. Сине мәктәптән кудыртырга бер сүзем житә минем. Менә хәзер телефон трубкасын күтәрәм дә әйтәм, Әмиржанов урак өстендә эшкә аяк чала, агитколлектив житәкчесе булуына карамастан, кәеф-сафа кылып йөри, бер агитаторның кырга чыкканы юк, дим, Совет укытучысы дигән олы исемне акламый, дим. И һәм хуш, Әмиржанов!

Фәттахов канәгать кыяфәт белән ырҗаеп куйды. Мансур чак-чак аның йөзенә стакан җибәрмәде.

—Син чыннан да ахмак икәнсең, Фәттахов!

—Тукта, кая киттең, мин сине бюрога куйдыртам,—дип кычкырып калды аның артыннан парторг.

Бу мәрәкәнең ахыры ничек тәмамланган булыр иде, әйтүе авыр, Мансурлар ялдан килгәндә ул урында икенче кеше эшли иде инде.

Фәттаховны күрше районга партия комитетының икенче секретаре итеп җибәргәннәр.

* * *

Семинар тәмам. Ә Мансурның эшләре әле муеннан. Тагын берике көнен Казанда үткәрер әле, мөгаен. Диссертация мәсьәләсе аны чын-чынлап борчый башлады. Габбас Ярмиев ни сәбәпледер соңгы вакытта сүнеп, тынып калды. Әлегәчә, моны эшлә, тегене җибәр, дип теңкәсенә тиеп бетә иде. Мансур ул сораганнарның барысын да үтәде, бурычы калмады. Укытучыларның белемен күтәрү институты янында аптырап басып торганда, кемдер җилкәсенә кагылды. Борылып караса, институттагы бүлмәдәш дусты Галим басып тора. Авызы колагында, әйтерсең лә, сабан туенда батыр калып, тәкә откан.

—И, Мансур, сине күрер көннәр дә бар икән, малай. Хәтерендәме Идел буенда грузчик булып йөргән чаклар? Ул цемент тузанын тәннән әле дә юып бетереп булмый. Ха-ха-ха.

Галим һич тә үзгәрмәгән. Элек тә юк кына нәрсәдән дә кызык таба торган уенчак иде, хәзер дә шул килеш калган. Алар институтның Товарищеская урамындагы тулай торагында яшәделәр. Көзен Әмәт станцасына көнлекче булып яллаланалар иде. Станца башлыгы ашыгыч состав килүгә телефоннан гына шалтырата. Кичме ул, иртәме, җиде төн уртасындамы — барыбер. Бригада тиз генә җыенып эшкә элдертә. Стипендия акчасы тамакка китә, читтән килгәненә кием-салым, кирәк-ярак юнәтәләр. Мансур эшләгән акчасына баян алды, фотоаппарат алды.

Галим дөрес әйтә, иң җикне чыгарганы цемент бушату иде. Цемент тузаны тәнгә сеңә, бөтен күзәнәкләргә кереп сылана, ике-өч мунчасыз бетми, каһәр.

—И, малай, исеңдәме, теге "хыянәтче"не ничек кызык иткән идек? Ха-ха-ха.

—Михаилны әйтәсеңме? Хәзер ул Казанда бер зур мәктәпнең директоры, авызыңны үлчәп ач?

—Һо, кандаладан бет туар ди, тычкан җигеп йөргәнен оныткан алайса.

Михаил Трофимов тарих бүлегендә укый иде. Үзен бик зурга куеп сөйләшә, түбәнрәкләрне санга да сукмый, "чаплашка" дип кенә җибәрә. Баксаң, татар малае икән! Миңнулла Тимербаев. Беленде бу. Һәм үзенә "хыянәтче" дигән кушаматны тагып та куйдылар. Шуннан соң көн бетте егеткә. Бөтенесе аңа каршы берләште.

Яхшы укый иде ул. Төннәр буе уку залында утырыр иде. Имтиханнарны да гел "бишле"гә генә бирә иде. Ләкин студентлар арасында абруй белемгә генә карап йөрми шул.

Бервакыт бүлмәдәге егетләр кызык итәргә булдылар Михаил-Миңнулланы. Ишек өстенә сулы савыт куеп, җеп ярдәмендә аны ишек токтасы белән тоташтырдылар.

Утны сүндереп, зур түземсезлек белән кайтуын көттеләр. Менә коридорда аның аяк тавышы ишетелде. Шак-шок итеп үкчәсенә басып йөри иде ул. Гадәттәгечә, ишекне киереп ачып җибәргән иде, шалт, башына сулы савыт мәтәлеп төшмәсенме. Башка чакта бернәрсәгә карамый утны кабызыр иде. Юк, бу юлы кыймады, җә тәпәләп ташларлар, дип шикләнгәндер, тавыш-тын чыгармады.

Кызыкның төбе сызык, монысы әле баласы гына иде. Нишләптер ул елны тычканнар күп үрчегән иде. Агулап та карадылар, һич бетерә алмадылар. Тумбочкаларга керәләр, юньсезләр, идәндә чабышып йөриләр. Мәзәк өчен Галим бер тычканны тотып банкыга ябып куйды. Ашата тегене, су эчерә. "Тычканнан фил ясыйм",—дип шаярта.

Тычкан филгә әйләнмәде, әмма тамаша өчен ярады тагын. Галим аның бер аягына кәтүк җебе бәйләде, икенче очын Михаилның тумбочка-

сына беркетте. Ә жанварны тумбочка эченә япты.

Көтәбез. Михаил әле киемнәрен генә сала. Ул пөхтә егет. Костюмын, күлмәк-чалбарларын жайлап элеп, гәжит белән каплап куя. Аннан соң караваt читенә утырып капкалап ала. Ә юеш киемнең мәшәкате тагын да күбрәк.

Барысы да гадәттәгечә. Михаил, ниһаять, кием-салымын рәтләп элде дә, тумбочкага үрелде. Ә тычкан анын өстенә сикерде...

Ялган белән хыянәт үз жәзасын алмыйча калмый ул.

—Булды инде хәлләр,—диде Мансур,—яшь чак—дуамал чак.

—Педагогик парчаларынны укып барам, бик мәгънәлеләр,—диде Галим.

—Рәхмәт. Монда башка планнар әле, Галим. Ә үзен ничек? Педтан соң КАИны бетергәненне ишеткән идем.

—Мин кол, дустым, кара негр. Кол биләүчеләр әби белән бабай. Хатын—управдом.

—Шаяртырга дисәң сина куш инде...

—Чынлап, Мансур.

Бәбкәләрен саклаган ата каз шикелле Галимнең муены алга сузылды. Кытайлыларныкы сыман кысык күзләре тегәржеп калынлыгында гына калды.—Йортка кергәнче утка кер икән.

—Фатирга чират торасындыр әле, авиация заводы бик дәрәжәле завод бит.

Галимнең бу юлы кабартма иреннәре бүлтәеп үк чыкты.

—Көт, тоттырырлар фатир, чират анда гүргә аяк салындыргач кына житә. Шуна да коллык изүе астында яшәргә мәжбүрмен.

—Балагыз барын да ишеткән идем.

—Баламы? Бала... Галимнең кысык күзләре шар рәвешенә керде.— Бала түгел ул, Мансур, әулия! Баһадир үстерәбез бит, малай. Туганда ук дүрт кило ярым иде. Бабай белән әби артын гына яламыйлар инде. Безгә тәтеми дә.

—Безнеке кыз. Ләйсән исемле. Әнисе кебек иркә. Сагынып беттем инде, төшләремә керә.

—Әле безнең кодалар буласы бар икән, малай. Ләйсәннең колагын тешләтеп куйсак та зыян итмәс иде. Әйдә, шул хөрмәткә, печтик кенә тамак төбен чылатып алабыз. Син командировкада, минеке — отгул.

—Тәкъдимең бик шәп, Галим, ләкин бу юлы барып чыкмаска ошый, институтка барышым. Мин бит диссертация дә язып маташам. Кичектергесез хәл итәсе мәсьәләләр бар иде.

—Теге колонизаторларның телефоны бар, шалтыратыштыр, араны өзмик,—диде Галим,—дуслар булып калыйк. Гафу, тоткарладым.

—Ни сөйлисең син, Галим, ул нинди гафу ди? Мин Казанда еш булам, очрашырбыз әле. Үпкәләмә, жәме?

Милли мәктәпләр институтының Казан филиалы оешуга дүрт-биш ел гына әле. Үзләренең урыннары да юк. Яңа Бистәдәге татар урта мәктәбе бинасының бер канатында өйдәш булып көн күрәләр.

Мансур ашкынып-кабаланып килсә дә, юлы уңмады. Габбас Ярмиевны очрата алмады, ижади ялда, диделәр. Мансурга хәзер иң мөһиме, диссертацияне алдагы елга планга керттерү. Монысын филиал мөдире хәл итә.

Мөдир—хатын-кыз, рус теле белгече. Баскетболчы кебек озын буйлы, көр тавышлы, чытык йөзле ханым. Аңа карауга, теше сызлый ахры монын, дип уйлыйсың. Сөйләшә-сөйләшә генә әлеге кыяфәтнең түрәлек билгесе икәнлеге аңлашыла. Күрәсең, түрә шулай тәккәббер булырга тиеш дип саный иде мөдир.

Көттеребрәк булса да, Мансурны кабул итте үзе. Янына кергәч, хәтта йөзендә елмаюга охшаш чаткылар да кабынып алды. Ләкин алар иреннәргә, күзләргә барып житмәде, сүнделәр.

—Мин диссертацияне планга кертү турында сөйләшергә килгән

идем, Гөлнур Кәримовна,—диде Мансур,—ул инде әзер.

—Сез житәкчегез Габбас Ярмиевич белән сөйләшмәдегезмени? Ул сезгә бернәрсә дә әйтмәдемени?

Мөдир каш астыннан гына аңа сөзеп карап алды.

—Габбас Ярмиевичны ижади ялда диләр, берничек тә тота алмадым.

—Әйе, әйе, ялда... Дөрес, ул хәзер институтта эшләми... Без аны пенсиягә озаттык...

—Ә.. ни... ул барыбер минем житәкче булып каладыр ич инде, — диде Мансур тотлыга-тотлыга.

—Кала ала, әлбәттә, ләкин...

—Нәрсә "ләкин", аңлатыбрак сөйләгез әле, Гөлнур Кәримовна.

—Ярми иптәш сезгә теманы жентекләп уйламыйча, регистрны өйрәнмичә генә тәкъдим иткән булган. Сез Башкортостан филиалындагы бер диссертант белән параллель эшләгәнсез. Ә ул күптән түгел яклады инде.

—Ничек инде, Гөлнур Кәримовна...

Мансурның башы әйләнеп китте, тамак төбенә нindидер кайнар төен килеп кадалды. Ничек инде, өч елга якын баш күтәрми эшләгән эшләре шулай жилгә очтымыни?

—Мин берничек тә ярдәм итә алмыйм, иптәш Әмиржанов,—диде мөдир әңгәмәсенең төгәлләнүен белдереп,—секретарьдан институтның рәсми жавабын алырга онытмагыз.

—Гөлнур Кәримовна...

—Мин хәлегезне аңлыйм, Әмиржанов, сез безнең штаттан тыш фәнни хезмәткәребез. Икенче темага алынырга мөмкин, уйлап карагыз.

Мансур институттан чайкала-чайкала чыкты, бераз коймага сөялеп торды. Аннан соң аякларын көчкә өстерәп урам буйлап китте. Башы буш мичкә кебек, бер уй юк. Кая бара, нишләп йөри, маңгаена мылтык терәсәләр дә әйтә алмас иде. Әнә, трамвай баядан бирле чиркәү кыңгыраулары тавышы чыгарып өзгәләнә. Мансур ишетми дә, атлавы атлау. Хәер, ул үзенең трамвай юлыннан баруын белми дә иде.

Кемдер аны жилтерәтеп читкә тартып алды. Шул ук секундта аркасын нindидер кайнар нәрсә өттереп алды. Шунда гына исенә килде Мансур. Аны ике милиционер машина эченә төрткәләп кертергә азаплана иде.

—Нишләтәсез мине, кая алып барасыз? — дип мыгырданды Мансур, —минем ни гаебем бар?

—Штраф түләгәч аңларсың, әлкәш!

"Кара козгын", юлда төтен алкалары калдырып, китеп барды. Аның артыннан ике узгынчы хатын карап калды.

—Аекка оят, иреккә пливайт ди, бу ир-атны әйтәм, аракы лаканына баш-аяклары белән чумалар бит, ә?

—Яшь кенә күренә үзе, киемнәре дә әйбәт, милициядә чишендерәләр инде моны.

Хатыннарның гөманы чак раска килмәде. Чөнки Мансурны һичнигә карамый айныткычка китереп яптылар. Киемнәрен салдырып салкын душта коендырып чыгардылар. Тешләре тешкә тиеп калтыранды. "Мин аракы эчмәдем",—дип никадәр акланырга тырышса да ышанучы булмады, нигә егылып үлмисең шунда. "Бер әлкәш тә үзен әлкәшкә санамый",—дип кырт кисте табак битле сержант. Аның сүзе сүз монда. Аны беркем дә шик астына ала алмый.

—Якташ, куй, милтон мүкләк сыер белән бер ул, ни тели, шуны эшли. Ят та йокла.Ату кичкә монда энә төртерлек тә урын калмый, иртәгә барысы да ачыкланыр,—дип киңәш бирде Мансурга үзе кебек бер бәхетсез бәндә. Аны чыгаралар, монда төн үткәргән инде ул.

—Ә нәрсә ачыкланырга тиеш соң, минем бер гаебем дә юк.

—Монда килеп эләгүең үзе зур гаеп инде, якташ. Милтон телеграф баганасыннан, син туры түгел дип, гаеп таба ди. Мине дә туйдан кайтканда эләктерделәр. Инде ачыклауга килгәндә, штраф түләтәчәкләр, эш урынына

язу жибәрәчәкләр. Ә анда сине җә партия җыелышында, җә профсоюз җыелышында тикшереп, арт сабагыңны укытачаклар.

—Ничек укытачаклар?

—Шулай, якташ, бу тәрбия алымы дип атала.

Мансур шыр җибәрде. Шушы гына җитмәгән иде. Әгәр мәктәпкә аның айныткычка эләгүе турында белешмә килеп төшсәме? Юк, асылынып үлүең хәерлерәк. Болай да бөтен планнарының асты өскә килде. Инде әлкәш дигән даны чыксынмы? Мона һич тә юл куярга ярамый. Ярамый! Җәмилә хакына, кызы Ләйсән хакына, үзенең абруе хакына көрәшергә тиеш ул.

Мансур ике куллап тимер ишекне дөбердәтергә керешге.

Табак битле сержантның ачуыннан күзләренә кан йөгерде.

—Бәйләп ташлыйм бит сабакы,—дип бакырды ул.

—Мине экспертизага җибәрегез!—дип Мансур аннан да уздырыбрак кычкырырга тырышты.

Мансурның бәхетенә, айныткычка ниндидер капитан килеп керде, башлык булса кирәк.

—Нәрсәгә кычкырышасыз, нинди тавыш бу, — диде ул кашларын җыерып.

—Менә бу әлкәш котырына...

Мансурга күршесе ярдәмгә килде.

—Иптәш капитан, ул дөрестән дә авызына тамчы да капкан кеше түгел. Кайгысы зур аның. Шуна күрә үзен-үзе белешми трамвай юлына килеп кергән.

—Нинди кайгы?

—Диссертациясен "яндырганнар".

Калганын Мансур үзе сөйләп бирде, институтта биргән белешмәне дә күрсәтте. Капитан гафу үтенеп, аны айныткычтан чыгарып җибәрде. Милициядә дә кеше хәленә керә белүче кешеләр була икән.

Ә Мансурның хәзер эчеп исерәсе килә иде инде. Ул Галимгә шалтыратты. Ярты төнгә кадәр сыйланып йөрделәр. Милиционерлар да очрады. Кагылмадылар. Көндез кәпрәеп йөрсәләр дә, караңгыда кикрикләре шиңә икән.

—Әйдә, Ярмине кызык итәбез,—дип дуамалланды Галим бераздан.— Синдә аның адресы бардыр ич.

Мансурның да кызган башындагы шөрепләр кузгалышып алды. Кара, Ярмиев аны бервакытта да фатирына чакырмады. Ә үзе Мансурларда озаклап кунак була иде. Еш кына яңа бал сората иде. Китергәч, әҗерен соңыннан кайтарырмын, акчам икенче костюм кесәсендә калган, дип хәйләли иде.

—Мин аның кайда яшәгәнен белмим,—диде Мансур.—Һәм белергә теләмим дә!

—Телефоны, телефоны бардыр бит инде.

—Бар, ник булмасын, хәзер номерын эзлибез.

Мансур куен дәфтәреннән җитәкчесенен телефон номерын эзләп тапты. Галим телефон-автоматтан шул номерны җыйды.

—Әллү, бу галим иптәш Ярмиев фатирымы?

—Әйе,—диде ир тавышлы хатын-кыз.—Кем сез, ни йомыш?

—Минем Габбас абый белән сөйләшәсем бар иде.

—Ул ял итә, иртәгә шалтыратырсыз.

—Мин узышлый гына, Мәскәүгә барышым, ике сәгатьтән поезд китә.

—Йомышыгызны әйтегез соң, җиткерермен.

—Мин Алабуга районыннан. Габбас абыйның укучысы. Күчтәнәчкә бал алып килгән идем, ул бал ярата бит.

Хатын үзе дә күчтәнәчләрне хуп күрә иде, ахры, тавышы йомшап китте.

Мансур бер читтә эчен тотып, ухылдый-ухылдый көлде.

Бераздан трубкада: “Тыңлыйм”,—дигән чәрелтек тавыш яңгырады. Галим хәтта аңышмый торды. Чөнки нәкъ менә монысы хатын-кыз тавышы иде. Катынша икән Ярми абзый, хатын тавышлы иргә ир тавышлы хатын тансык ди. Туры килсә дә килер икән.

—Тыңлыйм,—дип кабатлады Ярми,—кем әле бу, Рамазан, әллә синме?

—Әйе, әйе, мин бу, Габбас абый, кучтәнәчкә бал алып килгән идем, вокзалга килеп китә алмассызмы?

—Улым Артем барыр...

Галим тиз генә трубканы Мансурга төртте.

—Габбас агай беләсезме сез кем? Ишәк! И-о-о,—дип шырык-шырык көлде Мансур,—Сез и-о-о...

—Нәрсә-нәрсә, кем бу?

—Мин Мансур Әмирҗанов дигән аспирантыгыз, хәтерлисездер бәлки? Сез лыгырдык, надан, җаһил бәндә, кысыр галим...

Мансурның соңгы сүзләрен Ярмиев ишетмәде, чөнки ул трубкасын куйган иде инде.

Диссертация кыйссасы менә шулай бик күнелсез тәмамланды.

* * *

Кормаш Бистәсе ике өлештән тора, авыл һәм шәһәр өлешләре. Шәһәр өлеше нефть белән бәйле. Кормаш үзе мәшһүр Ромашкино нефть ятмасының урта бер җирендә урнашкан. Бу ятманы вәхшиләрчә файдаландылар. Чөнки СССР әлеге елларда Татарстан нефте исәбенә яшәде. Аны жир куеныннан тизрәк һәм күбрәк суыртырга кирәк иде. Шушы максат белән илдә беренче мәртәбә җир астына күп күләмдә су, кислота, башка агрессив катнашмалар кудыра башладылар. Алар күпмедер вакыт үткәч, елга-күлләргә бәреп чыкты. Әлмәт—Бөгелмә тирәләрендә табигатьтә охшашы булмаган сәер су кошлары төркеме барлыкка килде. Шыксыздыр үзләре, карыйсы килми. Болар—нефть маена батып, йон-каурыйлары коелган өтек казлар.

Әйе, нефтьне эче-бавыры белән суырдылар. Чөнки Советлар Союзының валюта фондын күп еллар буе Татарстан нефте тәэмин итте. Үрмәкеч пәрәвезләредәй чуалып беткән торбалар аша елына 100 миллион тоннадан артык “кара алтын” ага иде. Мактаулы әзербайджанлылар аны бервакытта да 20 миллион тоннадан арттырмадылар. Башкортлар да 40-50 миллион тонна белән чикләнделәр.

Мансурга бервакыт Румыниядән килгән нефть белгече белән очрашырга туры килгән иде. Республикагызны алтын койма белән әйләндереп алырга житәр иде байлыгыгыз, дигән иде ул. Ләкин Татарстан бу байлыктан файда күрмәде.

Кормаш тау исеме. Авыл шул тауның итәгенә утырган. Шуңа күрә аңа да Кормаш исеме биргәннәр.

Авыл зур. Халкы кырыс. Әби патша юлының Кормаш аша узуы да зур йогынты ясаган, күрәсең. Уфа, Оренбург якларына кәсепкә йөрүче сәүдәгәрләр монда куныл, ял итеп, ат ашатып чыга торган булганнар. Акчалы җирдә үтереше дә, бурлыгы да, пычак уйнатулар да була. Авыл аларның барысын да башыннан кичергән.

Хәзер яңа буын. Октябрятлар, комсомоллар буыны. Ләкин кан коткысы ата-бабадан килә. Аны өндәмәләр, фестивальләр, җыелышлар ярдәмендә генә куып чыгарып булмый.

Мансур үзе ярым ятим үсте. Әтисе сугышта һәлак булган. Әнисе колхоз эшендә. Берсеннән-берсе кече ике сеңлесе. Балалар әбисе Шәмсебәдәр кулында. Ул аларны динчә тәрбия кылырга тырышты. Урлашсаң, кулың корыр, дия иде. Яман сүз аннан да хәтәррәк каза китерә—тел кутырлый. Кече йомышны да чүгәләп башкару фарыз. Югыйсә, әгъзаңа шайтан иялөшә ди. Яхшылык, шәфкатьлелек, зурларны ихтирам итү—болар инде бәхеткә туры юл. Мансур сугыш-ызгышлардан, урлашу-

лардан, тәртипсезлекләрдән читтәрәк йөрде. Әле дә тәмәке тартмый, сүгенә белми.

Ә Кормашның бот буе малайларына чаклы якалашырга әзер. Армиядан ул октябрь азакларында гына котыла алды. Рәхмәт, директор да, Роно мөдире дә вәгъдәләрендә тордылар.

Кайтуга Җәмилә белән язылышып, бергә яши башладылар, хәтта туй-фәлән дә үткәреп тормадылар. Туган-тумачаны, дус-ишләрне дә Ләйсән тугач кына чакырдылар.

Эшкә чыгуының беренче көнендә үк директор аны кисәтеп куйды, балаларга да, укытучыларга да каты тор, таләпчән бул, йомшак агачны корт баса, диде.

Директор, мөгаен, Мансур килгәнче дә таләпчән булгандыр. Мәктәп чиста, пөхтә. Аның каты куллы хуҗа икәнлеге ишектән атлап керүгә сизелеп тора. Ләкин ул бернәрсәгә шаккатты: мәктәптә бөтен малайлар да диярлек тәмәке тарта икән. Фаҗига ләбаса бу! Директор алай санамый иде, күрәсең, әйткәч, жилкәләрен генә сикертеп куйды, янәсе, синең белән миннән генә калмаган.

Директорның бу сәер фәлсәфәсен Мансур кабул итмәде. Һәм ул мәктәптә тәмәкегә каршы чын мәгънәсендә көрәш башлап җибәрде. Тәмәкенең зыяны турында әдәбият, белешмә материаллар, күргәзмә әсбаплар туплады, класс җитәкчеләрен җыеп сөйләште. Мәсьәләне ата-аналар җыелышында да тикшерделәр. Ләкин, эш бик авырлык белән барды. Туалетларда тәмәке исе бетеп тормады. Дежур активистларны "сатлык җан" дип кыерсыталар иде. Ахры тәнәфес вакытларында Мансур үзе туалеттан-туалетка йөрде. Тартучылар да хәйләкәр: аларның да үз агентлары бар. Куркыныч янадымы, хәзер урыннарын алыштыралар. Инде качып, абзар-куралты тирәсендә пыскыталар. Тугызынчы класста укучы Муса исемле малай гына туалетта тартуын дәвам итте. Күрәләтә тарта. Мансур кергәндә дә папиросын авызыннан алмый. Әйткәч, иреннәрен кыйшайтып, синең миндә ни эшең бар дигәндәй, бәбәкләрен киерә.

—Әтиеңне чакырып сөйләшергә туры килер,—дип кисәтте аны Мансур.

Бу янау күп укытучыларның традицион хатасы. Укытучылар, гадәттә, көймәләре комга терәлгәндә шушы ысулны сайлыйлар. Стратегик яктан караганда ул фәкать тискәре нәтиҗә генә бирә. Ара тагын да киеренкеләнә.

—Әти безне ташлап яшь хатынга йортка керде,—диде Муса мыскыллы көлемсерәү белән,—аның миндә кайгысы юк.

Мансур аптырашта калды. Ачуланып хикмәт чыкмаячак, яхшылап сөйләшкәнне аңламый. Астан кисеп, өстән ямый бу абый дию дә ихтимал. Мәктәптән куарга гына да бит, юк, үзенә китереп сугачак, артыннан ялынып йөриячәксең.

Баксаң, аның педагогик арсеналы бик ярлы икән ич. Беренче селтәнүдә үк ярга килеп төртелде.

Муса, җә тагын нинди сүзең бар, дигән шикелле битараф кыяфәттә басып тора. Чибәр малай үзе, каһәр. Чем кара чәчле, кара кашлы. Сөйләшкәндә ияк очында чокыр хасил була. Бу аның кырыс йөзенә ниндидер мөлаемлык, йомшаклык өсти. Гәүдәсе төз, киемнәре дә килешле. Һич тә киребеткән малай актыгы, дип уйламассың. Башлы диләр үзен. Ләкин тырышмый, класста ишеткәне белән генә канәгатьләнә икән.

Көтмәгәндә Муса үзе сүз башлады.

—Сез миңа, абый, тәмәке зыянлы дисез, агулы дисез. Нигә соң алайса, врачлар тарта? Совхоз директоры Вәлихан абый да папиросын авызыннан төшерми. Киноларда да гел тарталар... Чөнки файдалы ул тәмәке. Тарткач, тынычланып китәсең.

Мансур Мусаны ышандыра алмады. Гомумән "Тәмәке" операциясе көткән нәтиҗәне бирмәде. Мусаның класс җитәкчесе Рәхимә Юнысова да юка иреннәрен бөрештереп: "Мансур Әмирҗанович, без контингент өчен кан түгәбез, ә сез таратасыз. Өч көн инде Мусаның дәрескә килгәне

юк",–дип, болай да әрнегән ярасына тоз салды. Бу аның, педагогикада син, энем, чыпчык баласы гына әле, дип тәҗрибәсезлегенә төрттерүе иде, билгеле.

Рәхимә Юнысова каты күнелле, үзсүзле укытучы. Ләкин мактаулы. Чөнки теләсә-нинди классны да тынлата ала. Мансур аны беренче көннән үк армиядагы хохол старшиналарга ошатты. Хохол старшина әмер биргәндә казарма тәрәзәләренең пыялалары чынлап тора хәтта. Рәхимәнең дә тавышы шундый. Ул коридордан үтеп киткәндә укучылар хәрбиләрчә үрә катып озатып калалар. Аның өчен иң мөһиме, тәртип. Дәресләрендә дә шундый ук солдафонлык. Китапта язылганны гына таләп итә, бер адым да читкә тайпылмый, һичнинди өстәмә мәгълүмат бирми. Дәлиле шулай ук саллы–дәреслек хөкүмәт тарафыннан расланганмы–расланган. Ә ул аны үти. Шулай булгач, бернинди дәгъва дә була алмый. Авызың каплана.

Мансур Мусаларга китте. Өйләре тау очында икән. Зур түгел, әмма коймаларына кадәр буяулы. Муса кар көри иде. Бүреген баш түбәсенә чөеп җибәргән, изүләре ачык, йөзенә алсу төс йөгергән. Мансурны күргәч, кулыннан көрәге төшеп китә язды, күзләре тасрайды.

–Эш килешә икән үзеңә, Муса,–диде Мансур,–җә, бир әле көрәгенне, мин дә тәнне язып алыйм.

Мансур пальтосын салып коймага элде дә, чалгы белән печән чапкандай селтәнә-селтәнә кар көри башлады. Төнлә белән генә яуган ап-ак кар әле тыгызланып өлгермәгән, бал кәрәзедәй купшакланып, кабарып тора. Күтәреп бәргәндә кар тәнкәләре кояш нурларында җемелдәп-җемелдәп китә, рәхәтлек биреп биткә сибелә. Кыш әле үз хокукларына кереп кенә килә. Аның әлеге кар бөртекләре шикелле пакь чагы. Шуңа күрә күнелләрдә шәфкатьле, матур хисләр генә уята. Әйтерсең лә, Мансур бу йортка тәртибе какшаган укучы артыннан түгел, кышның илаһи мизгелләре белән ләззәтләнергә килгән иде.

Аның дәртләнеп эшләгәнен Муса коймага терәлеп күзәтеп торды. Менә өйалды ишеге ачылды, идән сайгаклары шыгырдап китте. Мансур бу адымнарның хатын-кыз адымнары икәнен карамыйча да тойды. Әнисе булса кирәк, дип уйлады. Димәк, төп эшкә күчәргә вакыт. Ул көрәген көрткә кадап куйды да, шул тарафка борылды.

Чыннан да, күтәрмә башында ябык чырайлы, юка гәүдәле, зур шәлен муенына тыгызлап бәйләгән бер хатын басып тора иде.

–Исәнмесез, Хөмәйрә апа, мин Мусаның укытучысы булам,–диде Мансур.–Сөйләшергә дип килгән идем әле.

Хатынның тын юллары сырхаулы иде, ахры, сулышын еш-еш ала.

–Әйтәм мин аңа, энем, укы дим, ун класс бетермәгәннәрне хәзер армиягә дә алмыйлар дип әйтәм,–диде Хөмәйрә гыжылдыграк тавыш белән.

–Ярар инде, әни, син нәрсә?

Муса әнисенә үпкәле караш ташлады.

–Шул ЫСПТУ дигәннәре чыгырдан чыгара, шунда керәм дип жанны ашады чистый.

–Муса, сине яхшы математик диләр, минемчә, урта мәктәп кулаерак булыр иде. Аннан соң, икенче чирек башланды бит инде,–дип Мансур дипломатларча ерактанрак суктырып алды.

–Җыен мәктәптән куылган хөрәсән бит анда, шуларга иярмәкче.

–Әни...

–Әни, әни, нәрсә катып калдың, укытучы абыенны өйгә чакыр,–диде Хөмәйрә ютәл аша.

Муса әнисе алдында үзен мулла песие кебек тота иде. Мөгаен, тегесе улының тәмәке белән шаяруын да белмидер әле. Ихтирам итүме, куркумы?

Өй эче җыештырулы иде. Тиз генә самавырны яңартып, чәй табыны әзерләделәр. Мансур баш тартмады, чөнки аңа иркенләбрәк сөйләшергә,

ничек тә Мусаны мәктәпкә кайтарырга кирәк иде. Үзенең абруен ул шуның белән генә ныгытачак.

—Әтисе янында булса, алай трай тибеп йөрмәс иде дә сон, ташлап китте бит. Чирләшкә хатын ирләргә кирәк түгел шул ул. Югыйсә, чирне мин дә сорап алмадым,—дип үз хәлләрен сөйләп алды Хөмәйрә. Боларны Мансур белә иде инде. Алай да хәленә керергә тырышып, юату сүзләре әйтте. Ире ярдәменнән калдырмый ахры, бөтен жирләре житеш. Анын уйларын укыгандай хатын әйтеп куйды:

—Өйдәге бернәрсәгә дә тимәде, булдыклы, намуслы кеше ул үзе, нефтьче.

Мансур акрынлап әнгәмәне үзе теләгән сукмакка кертеп жибәрде. Белем турында, укыган кешенең мөмкинлекләре хакында гәпләштеләр. "Мин үзем дә төшеп калганнардан түгел идем,—диде Хөмәйрә,—укырга рәт кенә булмады. Һаман шул бер балык башы, ятимлек инде. Без дә әтисез үстек".

—Сон, Хөмәйрә апа, Мусаны нишләтәбез инде, почмакка бастырып куябызмы?—дип шаяртты Мансур.

—Анын өчен кайгырма, энем, иртәгә үзем житәкләп мәктәпкә илтәм. Күреп торырсыз, илтәм менә. Әнисенен итәгенә тагылып йөри дип көлсеннәр әле үзеннән.

Муса кайтарып сүз әйтмәде, көлемсерәп кенә куйды.

Китәргә жыенганда Мансур шкаф башындагы гармунны күреп алды.

—Муса, син гармунчы дамы әллә?—дип сорады.

Муса өчен әнисе жавап бирде.

—Бу хөрәсән ялкавыннан гармунда уйнау тагын, тузан жыеп ята шунда. Әтисе алып биргән ие.

Мансур гармунны кулына алып, күрүкләрен, төймәләрен тикшереп карады. Әйбәт гармун. Тулада эшләнгән. Ике рәтле хромка гармуны. Мансурга ошый бу тип гармуннар. Әле дә тартып жибәрде. Өй эченә моң йөгерде. Башта озын көйләр уйнады, аннан сон бию көйләренә күчте. Үзе уйный, үзе каш астыннан гына Мусаны күзәтә. Малайнын әле кашлары жыерылып менә, әле күпшәк иреннәре жәелеп-жәелеп китә. Музыкага битараф түгел димәк. Күзләрендә—көнләшү, кызыксыну, гажәпләнү. Ләкин үзенең бу халәтен күрсәтмәскә тырыша.

Кара син, нинди сихри моң тулып ята икән шушы кечкенә гармун эчендә?! Их, өйрәнәсе иде уйнарга, шаккаттырасы иде малайларны.

Боларын Мансур фаразлады. Бик ихтимал, бу минутта Мусанын күнелендә дә шундый уй-хыяллар бөреләнгәндер.

—Мәктәптә гармунчылар түгәрәге оештырып жибәрергә уйлыйм, теләгең булса, рәхим ит,—диде Мансур,—гармунын шәп, әрәм ятмасын.

Муса килешүен белдереп ияген кагып куйды.

Бу бәйгедә укытучы түгел, гармунчы жинде.

Ләкин иске дуслары Мусаны алай жинел генә ычкындырмадылар. Атна-ун көннән анын белән булган фажига бөтен Бистәне аякка бастырды. Кичен мәктәптән кайтуын саклап торып, бер аулак тыкрыкта Мусанын эченә пычак белән кадаганнар. Үләр дип курыкканнармы, башка бер сәбәп килеп чыкканмы, аны сырхауханәнен капка төбенә китереп ташлаганнар. Кышкы калын кием пычакны тоткарлаган, күрәсен, эчке әгъзаларына зур зыян килмәгән.

Бу хәбәрне ишетүгә, Мансур Муса янына барды. Йөзе кәгазь кебек ак иде малайнын. Аны күргәч, үз итеп елмайгандай итте.

—Бирешмә, Муса!—диде Мансур "рот—фронтлар"ча йодрыгын өскә күтәреп.—Ул хулиганнар тиешле жәзасын алыр.

Малай "юк" дигәндәй, башын чайкады. Ана бөтен Бистә кан бирде. Мансур исемлектә беренче иде.

Бер яманнын бер яхшысы, ди. Шул вакыйгадан сон Мусанын әтисе гаиләсенә кайтты. Әмма бу жинаятьне кем эшләгәнен таба алмадылар. Гаебен танучылар табылмады, ә Муса белмәмешкә салышты.

“Белмим, карангы иде, таный алмадым”,–дип тикшерүчеләргә шуннан ары бер кәлимә сүз әйтмәде. Ахры, эшне бер нәтиҗәсез ябарга мәҗбүр булдылар.

Мансур ике айлык укытучылык стажы белән зур мәктәпнең уку-укыту бүлеге мөдире булып китте. Ул ике ай арасында ике ел армия хезмәте ята. Җитмәсә, көтеп алдылар. Бу, әлбәттә, коллективта зур кызыксыну уятты. Төрлечә юрадылар. Башта Роно мөдиренең энесе икән дигән сүз таралды. Ләкин Мансурны күргәч, моның дөрес түгеллеген бер карауга аңладылар. Чөнки бөтенләй ошашмаганнар. Бере өрлектәй, икенчесе аның янында чебеш кенә. Аннан соң “җөнтәс кул”ны райкомнан эзләделәр. Анысы да барып чыкмагач, Казанга ябыштылар. Имеш, Мансурның якын туганы министрлыкта эшли икән.

Моның сәбәбе, югыйсә, бик гади иде: беренчедән, Җәмилә; икенчедән, директив органнарның рәсми булмаган күрсәтмәсе нигезендә җитәкчелеккә яшь ир-ат укытучыларны билгеләү мәгкуль күрелә иде. Ник дисәң, халык мәгарифен болай да хатын-кыз баскан. Ә бу хәлнең тискәре яклары шактый. Иң борчыганы – малайларда ир-атларга гына хас булган сыйфатларның акрынлап җуела баруы.

Мансур соңыннан да һаман сынау астында иде. Ул бер елга сузылды. Аның һәр сүзен иләк аша сөзәләр, ниндидер яшерен мәгънә эзлиләр. Ялгыш җибәрсә, куанышалар, янәсе, бездән бер артык җирең дә юк, борыныңны күтәрмәсәң дә була.

Мәктәп коллективы, гадәттә, төркемнәргә бүленүчән. Беренчесе, әлбәттә, директорны яклый торган төркем. Һәр коллективта шулай ук директор урынына ымсынучы кеше дә була. Ул йә завуч, йә элеккеге башлык. Аңлашылганча, аның да үз төркеме.

Кормаш мәктәбе бу яктан тыныч иде. Зыятдинов андый буза куптаручылардан күптән арынган. Мәктәптә аның сүзе сүз, вазифасы буенча аңа каршы торучы, аның урынына үрмәләргә теләүче юк. Булса да, бу фәкать буш хыял гына. Чөнки директорның абруе зур иде.

Ә Мансур әле тәпиләнеп кенә килә. Өстәвенә, чит кеше, җитәкчелек тәҗрибәсе дә юк. Кыскасы, Мансурга каршы төркем оеша. Эшне төптән уйлап, бик астыртын алып барганнар. Бу планны бары тик директор ярдәмендә генә тормышка ашырырга мөмкин икәнне алар, билгеле, яхшы белгән. Шуңа күрә иң элек үз якларына аны аударырга тырышканнар. Ә моның өчен саллы дәлилләрнең булуы шарт. Болар Мансурның һәр адымын күзәтеп, һәр сүзен теркәп барганнар. Эзләсәң, кер табыла инде ул. Җыйганнар.

Зыятдинов башта аны-моны сиздермәде. Тегеләрнең кымы басылгач кына әйтте. Вакытында тишкән булса, ихтимал, әйбәтрәк тә булган булыр иде дә бит, тынычлап эшләсен дигән, күрәсең.

Аңа каршы өч ирсез хатын берләшкән. Берсе–Дамирә исемле. Ире унынчы класста укучы бер кызны ияртеп, Малмыж якларына чыгып качкан. Шунлыктан ир-ат затын күрә алмый, бөтен дөньясына ачулы. Икенчесе карт кыз Нурсөя. Чаян кебек үзен-үзе ашый, кибеп беткән инде.

Өченчесе–Камилә. Кылыч борынлы, зур авызлы, ана үрдәкнеке кебек мимылдап торган зур артлы яшь хатын. Алар берара дус булып та йөрделәр, кунакка алыштылар. Ире нефтьче иде, җитәкче кеше. Бик шаталак кеше. Тартынмыйча кычкырып көлә белә иде. Рәхәт иде аның белән.

...Кышкы зәмһәрир салкын иде. Кырлачның котырынган чагы. Өй бүрәнәләре шыңгыр-шыңгыр килеп ярыла. Инде өченче көн тоташтан кырык градус салкын. Җиргә төшкәнче төкерек туңа. Һавага сыкы сылашкан, хәтта тамакка утыра.

Көн саен Татарстан радиосы сүзен, укулар булмый дип, башласа да мәктәпкә барыбер күзен җыртып бер-ике дистә укучы килә. Хәтта күрше авылдан да киләләр. Укытучыларның җан ачулары чыга.

Мансур укучыларны барлап килде дә, эшкә утырды. Камилә дә шунда иде. Нигәдер борчыла бу. Әле журнал актара, әле тәрәзә янына килеп баса, һич кенә дә тынычлана алмый. Нидер әйтмәкче булып, Мансурга да карап-карап ала. Ләкин кыймый ахрысы, ишекле-түрле йөрүен дәвам итә.

—Камилә, бер-бер хәл булдымы әллә?—дип сорады Мансур.

Камилә йомры жилкәләрен генә сикерткәләп куйды, жавап бирмәде.

Кисәк кенә телефон шалтырады. Камилә чебешкә һөжүм итүче карчыга шикелле бер ыргылуда өстәл янына килеп тә басты.

—Касыйм, бу синме, Касыйм?!

Камилә шунда ук сыгылып төште, куллары белән битен каплап, диванга ауды. Трубкада кемдер һаман сөйли иде әле.

—... Касыймны моргка алып киттеләр...

Мансур үзе дә югалып калды. Ана Камиләне юатырга кирәк, ярдәм итәргә. Ә ул әлеге кара хәбәрдән бөтенләй камыргә әйләнде. Укытучылар килеп кергәч кенә хәлгә керде.

Касыйм белән Камилә сүзгә килешкәннәр. Тегесе кунарга кайтмаган. Камиләнен шуна борчылуы булган икән. Ә Касыйм исә күрше авылда кәеф-сафа корып йөргән, салмыш килеш кайтырга чыккан. Куәте беткән, күрәсен, ярты юлда катып үлгән. Югыйсә, сызгырасы гына, минутында китереп житке-рерләр иде. Күрәчәк шулай инде, язганың була.

Камилә бик нык бетерешә, онытылып торырмын дип, берничә ай туган авылы Чыршылыга кайтып та эшләп йөрде. Анда да дәва таба алмагандыр инде, кире әйләнеп кайтты. Көнләшүе идеме, ул Мансурлардан ераклашты, хәтта Жәмилә белән дә ачылып сөйләшми башлады. Аны әлеге коргаксыган ачулы затлар үз канаты астына алды. Бергә-бергә күнел дә ачкалыйлар, дип сөйләделәр.

Директор белән уртак тел таба алмагач, тактикаларын үзгәрткән болар. Ничек тә Мансурны әхлакый сазлыкка кертеп батырырга. Ә аннан соң Зыятдинов үзеннән-үзе бирелергә мәжбүр булачак.

Соңгы вакытта Камилә Мансурга карата үзгәреп китте. Юк, кеше алдында ул элеккечә үк тәкәббер, һавалы, үзсүзле. Икәүдән-икәү калгач, чытыклана, кылтыклана, уфылдый. Кинаяле сүзләр әйткәли. Мансур аптырашта калды.

Кеше карбыз түгел шул, эчен ярып карап булмый. Берсендә кемнендер туган көнен билгеләп үтәргә жыенганнар иде. Нәрсәдер алырга дип укытучылар бүлмәсенә керде. Ул икегә бүленгән. Анын өстәле эчке якта. Ашыгыч иде, ут та яндырып тормады, актарына башлады. Шунда кемдер анын артыннан килеп кочаклады да кайнар иреннәре белән колагын, муенын, чәчләрен үбәргә тотынды.

Мансур чирканып китте, гүя өстенә бака сикерде.

Ул аны мышнавыннан таныды.

—Камилә?! Нишләвен бу?

—Мансур, аңлашыйк әле...

Камилә янә Мансурга таба тартылды.

—Чаманны белергә кирәк,—дип Мансур тизрәк чыгу ягына юнәлде.

—Китмәле...

Мансур ишек катында кемнәр беләндер чәкешә язды, әмма туктап тормады.

Бу хакта бер кешегә ләм-мим. Жәмилә, әнә, Гайшә өчен һаман колак итен ашый.

Ул Камиләнең әлеге ычкынуын хәмергә аударды, артыграк жибәргәннән дип уйлады. Гомумән, Камиләгә хатын-кыз буларак, битараф иде ул. Гадәттә, ир-ат андый шәрәфле ханымнарга кызыгып, ымсынып карый. Анарда исә Камилә бары үртәлү хисе генә уята иде.

Мөнәсәбәтләр акрынлап үз урынына утырды кебек. Камилә шырпыдай турыга катып, тәкәббер генә йөри. Шулай да бер көнне икенче сменада укулар тәгәлләнүгә, математика кабинетын карарга

чакырды бу. Чөнки иң яхшы класс-кабинетка конкурс игълан иткәннәр иде. Ә ул кабинетын яңабаштан җиһазларга кереште. Эшкә бик үҗәт үзе.

Мансур бернинди астыртын хәйлә дә көтмәде. Чөнки барысы да онытылган иде инде. Камилә дә бик җитди кыяфәт белән экспонатларын, күргәзмә әсбапларын күрсәтте, киңәшләр сорады. Шулай карый-карый кабинетның түренә барып җиттеләр.

Менә шунда башланды инде. Һич көтмәгәндә Камилә аның муенына сарылды: үбә, кочаклый, куллары бер аска төшә, бер өскә менә. Мансур да икеләнеп калды. Хатынның кайнар тыны аны да кузгатып җибәрде. Шушындый хисләр өермәсенә кайсы гына ир-егет каршы тора алыр икән? Сусаган күрәсең, ничек өзгәләнә. Әллә соң хәленә керергәме? Үпкән-кочкан, җилгә очкан ди. Сәвабы булыр... тол хатын бит...

Ләкин житешә алмый калды. Шулвакыт Камилә чәрелдәп кычкырып җибәрде:

—Коткарыгыз, көчлиләр!

Бер секунд эчендә Мансур йөз төрле халәт кичерде: янды, көйде, пеште, туңды, суынды, калтыранды. Күкләргә ашты, упкынга тәгәрәде...

—Беттем!

Ул инде Камиләнең мәкерен аңлап алган иде. Тик соң инде, эш үткән. Хәзер...

—Кем кемне көчли бит әле монда? Оятсыз икәнсең, Камилә. Тьфү! Укытучы исеме сиңа харам.

Бу—мәктәпнең завхозы Мөкаррәмә иде. Күрәсең, аларны шактыйдан күзәтеп торган. Завхоз түгел, ходай күктән индергән фәрештә! Мансур шатлыгыннан чак елап җибәрмәде.

Мөкаррәмә, чыннан да, фәрештә кебек саф, гадел хатын. Усаллыгы да бар. Әмма туры усал. Акны ак, караны кара дип, күзеңә бәреп әйтә. Шуңа күрә сүзе дә абруйлы.

Ул арада тыннары-көннәре бетеп, бүлмәгә Дамирә белән Нурсөя атылып керде.

—Кая, кем, нәрсә?

Кылт итеп Мансурның хәтеренә уй бәрде: теге вакытта да укытучылар бүлмәсе янында алар сак торган ләбаса! Мөкаррәмә бүлмәгә кермәгән булса, була иде мәгәр хәлләр.

—Бернәрсә дә юк, барысы да өзелде,—дип Камилә тегеләрне карашы белән өттереп алды. Шуның белән ул Мансурны күрәләтә батырырга йөрүләрен тулысынча таныды. Батырчылыгы җитте. Аннан соң сүзе белән кадалды:

—Бәхетленең көймәсе корыдан йөри ди. Анаңнан күлмәкле килеш тугансың икән, Мансур. Ирәймә, дөнья ул куласа, бер әйләнә, бер баса. Синең кебек әзергә-бәзер кешеләрне җаным сөйми. Күралмыйм!

—Кеше бәхете кешегә булмый,—диде Мөкаррәмә тыныч кына.— Үзең казыган базга үзең төшсәң ни әйтерсең?

—Ырлама, эт түгелсең. Күземнән югал! Барыгыз да! Кызлар, сез дә. Берәүне дә күрәсем килми.

Менә шулай кыл өстеннән тәмугка тәгәри язды Мансур. Камилә дөрес әйтә, бәхете бар икән. Мөкаррәмәнең нәкъ вакытында бүлмәгә керүе могҗиза ич! Алдан сөйләшеп куйганнар, әнә, оттырды. Ә ул судан коры чыкты.

Мөкаррәмә серне читкә чыгармады, вәгъдәсендә торды. Әлеге төркем дә таралды. Камилә төрмәдән кайткан бер кешегә кияүгә чыгып, Алабугага күченеп китте. Нурсөя дә яңа уку елында мәктәптә күренмәде. Дамирәнең генә китәр урыны да, мөмкинлеге дә юк иде. Ике балалы хатынны беркайда да көтеп тормыйлар шул.

Завуч урынына да үрмәли алмады...

* * *

Мондый тавыш-гаугалы педсоветның булганы юк иде әле. Бәйдән ычкындылар. Директор укытучыларны тырышлык белән генә тыеп торды. Әмма үзе канәгать иде. Житди күренергә тырышудан эчкә батып кергән яңаклары уйнаклап китә. Жәрәхәтле кулы исәненә орынып-орынып ала. Дулкынлана. Чөнки аның күптәнге хыялы, ниһаять, бүген өскә калкып чыкты. Мәктәпне рус-татар мәктәбенә әверелдерү аның инде төшләренә керә башлаган иде. Рус мәктәбендә эшләүче хатынының: "Татар мәктәбенең киләчәге юк",—дигән сүзләрен, рәсми шартларда булмаса да, тишкәләп куйгалый иде. Яна министр мона үзе юл ачты. Бер кулы белән татар мәктәпләренең абруен күтәрсә, икенчесе белән "ата-аналар" теләге дигән демагогик постулат нигезендә Зыятдинов ише житәкчеләргә мәктәпләрнең статусын үзгәртергә мөмкинлек тә бирде. Шул рәвешле саф татар авылларында рус мәктәпләре пәйда булды.

Жае да чыгып тора бит аның. Мәктәпне бик яхшы билгеләренә генә тәмамлаган Гүзәл Бәйрәмова дигән кыз коллектив исеменә хат юллаган. Казан университетының юридик бүлегенә гариза биргән иде ул. Беренче имтиханда ук "3"ле алган. Кыз бу шәхси уңышсызлыгын тулысы белән мәктәпкә, укытучыларга сылтый. Мине русча белмәү харап итте, дигән,ә сез тиешенчә өйрәтмәдегез, дигән, татар мәктәбе ныклы белем бирә алмый, дигән.

Директор жәрәхәтле кулы белән янә исәненә орынып алды да, тынлык урнашуга:

—Жә, нинди фикерләр, конкрет тәкъдимнәр бар?—диде.—Рәхим итегез.

Беренче булып рус теле укытучысы Фирая Сабировна күтәрелде.

—Мин, иптәшләр, рус теленә сәгатьләрне арттырырга кирәк дип саныйм,—диде ул зур яналык житкергәндәй.—Хәтерегездәдер, мин моны күптәннән тукып киләм. Минә сәгате сукты. Шул вакытта минем сүзләремә колак салган булсагыз, ак сакаллы карт була идек.

Көлештеләр. Аның шул һаман "ак сакаллы карт" булыр инде. Ул, әлбәттә, укыту челтәрен, программаларны үзгәртеп булмаганны бик яхшы белә. Алар министр тарафыннан расланa. Әмма гел шулай төрттереп кенә тора.

—Фирая Сабировна, ата казыгыз күкәй саламы, дип сораган кодагый кебегрәк сөйләшәсез сез,—дип урыныннан торып басты Рәхимә Юнысова,—рус теле болай да атнага тугызар сәгать керә ләбаса! Географиягә шуның өчтән берен генә бирсәләр дә, мин укучыларымнан Миклуха-Маклай ясап бетерер идем.

Тагын гөжләшеп алдылар.

—Педсоветны уенга әйләндермик әле, иптәшләр, мәсьәлә бик житди,—дип, директор карандашын су савытына бәргәләп алды да, немец теле укытучысы Әслах Галиуллинга ым какты. Тегесе күптәннән сөйләргә теләген белдереп, кулын күтәреп утыра иде. Салмак хәрәкәте, вәкарь белән генә сөйләүче бу киң карашлы укытучыны ихтирам итәләр иде коллективта. Ул сугыш вакытында фронтта тәржемәче булып эшләгән, кем әйтмешли, немец телен су кебек эчә. Дөнья хәлләрен жентекләп күзәтеп бара, күп укый. Нинди сорау белән генә мөрәжәгать итсәләр дә, жавапсыз калдырмас. Хәтта белмәгәнен дә, белмим, димәс. Үз-үзенә гашыйк кеше.

Ул, гадәтенчә, күзлеген салып, аны сөттәй ак кулъяулыгы белән иркенләп корытып торды, учы белән авызын каплап, ютәле булмаса да, ютәлләгәндәй итте һәм сөйләп китте.

—Мин үзем, иптәшләр, Гүзәлнең хатын артык дәрәжәдә шөбһәле димәс идем. Бу очраклы бер вакыйга, тормышта андый хәлләр булгалый инде ул. Әнә, һич уйламаганда, Төхфәтуллин медицина институтына кергән бит. Бу хакта авыз тутырып сөйләргә, мактанырга була. Югыйсә,

аттестатында “өчле”ләр дә бар иде. Гүзәлебезне без үзебез боздык, мактап боздык. Димәк, ул медаленә ышанарак төшкән.

Әслах Зөбәерович күзлегенең пыялаларына янә тынын өрде, янә аны кулъяулыгы белән озаклап корытты. Әйтерсең лә, моннан да мөһимрәк нәрсә юк иде. Директор түзмәде, “кыскарак тотыгыз”,–дип әйтергә мәҗбүр булды.

Галиуллин иреннәрен бүлтәйтеп директорга карады, янәсе, ул сөйли генә башлады ич.

–Сез кыскарак тотыгыз дисез дә соң, Мирза Кәбирович, үзегез әйтмешли, мәсьәләсе ифрат та җитди бит. Мин бу мәсьәләне Үзәк Комитет, хөкүмәтебезнең икътисадый сәясәте яссылыгында карарга кирәк, дип саныйм. Авыл хуҗалыгын текә күтәрү максатыннан берсеннән-берсе мөһимрәк карарлар кабул ителә. Мәктәп тә алардан читтә кала алмый. Һәм калырга тиеш тә түгел. Әнә, Чирмешән районындагы Кызыл юл мәктәбен тәмамлаучылар тулысы белән туган колхозларында эшкә калганнар. Комсомол-яшьләр бригадасы оештырып җибәргәннәр. Менә бу патриотизм! Ә без монда аерым бер укучының институтка үтә алмавына борчылып утырабыз. Кайтсын авылга, керсен фермага, саусын сыер! Чын комсомоллар шулай эшли.

Ә Фирая Сабировнага иярсәк, мәктәптә фәкать рус теле фәне генә калыр иде. Бу–абсурд...

–Бөек рус телен, Пушкин, Маяковскийлар телен мин соңгы сулышыма чаклы пропагандалаячакмын, Әслах әфәнде,–дип бүлдерде аны тегесе.

Галиулланың зур гәүдәсе судагы көймә шикелле чайкалып куйды.

–Сез миңа сәяси яла ягасыз, мин сезгә “әфәнде” түгел, иптәш Гыймадиева,–диде ул калтырануын баса алмыйча.–Мин ярлы крестьян нәселеннән. Мин... мин... мин сезне бу “әфәнде”гез өчен партия җыелышына куйдырачакмын!

Директор су савытына каләм кагу белән генә чикләнмәде, җәрәхәтле кулын күкрәгенә ышкый-ышкый торып ук басты. Ләкин физик Фәрдиев аңа сүз әйтергә ирек бирмәде.

–Нинди сабыр Әслах Зөбәеровичны да чыгырыннан чыгардык, иптәшләр,–дип төкерекләрен чәчте ул,–болай барса, йодрыклашып китүебез дә бик ихтимал. Ә мәсьәлә сукыр тиенгә дә тормый. Безнең авылда: “Татар теле Котылдык күперенә җиткәнче генә алып бара”,–дигән әйтем бар иде. Хәзер инде татар теле ишек алды капкасыннан да алып чыга алмый, иптәшләр. Шулай булгач, ничу аңа ябышып ятарга. Барыбер бетәчәк ул. Рус теленә күчәргә кирәк. Бетте-китте вәссәлам!

Бу сүзләрдән Мансур сискәнеп китте. Фәрдиев, билгеле, директорга ярарга тырыша. Алдан сөйләшеп-килешеп тә куйганнардар, бәлки. Югыйсә, үзенең рус теле бик тә чамалы, ипилек-тозлык та юк. Укытуы да рәтсез. Кайчандыр ялган аттестат белән Үзбәкстанда ике еллык укытучылар институты тәмамлаган. Бердәнбер таянычы – ялагайлык. Моны барысы да белә. Шуңа күрә, яратмасалар да, шикләнәләр. Чөнки ишеткәнен берсен директорга җиткереп бара. Гомумән, Кормашның үз укытучылары директорның авызына гына карап торалар. Ник дисәң, хуҗалыклары зур. Күп итеп мал асрыйлар. Белемнәрен күтәрү өстендә эшләргә вакытлары да калмый. Киресенчә, авыр физик хезмәттән соң мәктәптә ял итеп китәләр. Инде шул укытучылар туган авылларының буыннан-буынга килгән милли традицияләренә таш атмакчы.

Мансур укытучыларны күздән кичерде. Әнә, физкультура укытучысы Мөхәммәт Чанышев. Керпе энәләре шикелле тырпаеп торган чәчләрен сыпыргалап куя. Янында хатыны, химия укытучысы Зәйтүнә. Икесе дә Чувашиянең Батыр районы татарлары. Бик милли җанлы гаилә. Арча егете биолог Таһир Хисамов та шул камырдан изелгән. Күреп тора, бу сөйләшү Бөгелмәдән килеп-китеп йөрүче рус әдәбияты укытучысы Гөлнарага да ошамый. Бар андыйлар. Мансур белән Җәмилә кебек яңа буын педагоглар. Алтмышынчы еллар алып килгән яз һавасын иснәп

формалашкан шәхесләр. Фикердәшләр. Әлегә тынлап кына утыралар. Мансурның чыгышын көтәләр булыр, мөгаен. Директор шуна үрсәләнә. Чөнки белә, яшьләр үзләренчә уйлый, үзләренчә эшли. Алар азчылык тәшкил итсәләр дә, сүзләре үтә төшә. Сыер-сарыктан аерыла алмаган педагоглар белән укыту-тәрбия эшен заманча үзгәртеп кору, ай-һай, икеле. Шул ук вакытта үз сәясәтенә дә хилафлык китермәскә кирәк, дилбегәне кулдан ычкындыру, директорлык постыннан китү дигән сүз.

Ул арада Мөхәммәтнең керпе башы калыкты.

—Минем иптәш Фәрдиевка бер соравым бар иде, Мирза Кәбирович, мөмкинме? — диде ул үтә бер итагатьлелек белән. Тик бу итагатьлелек юрганы астында ниндидер сер яшеренгәнен барысы да төшенде. Чөнки Мөхәммәтнең сораулары чәче кебек үк чәнечкеле. Бушка тегермән әйләндерүчеләрне карап-карап утыра да, бер хикмәт чыгарып куя.

—Иптәш Фәрдиев, сез сталинист икәнсез, шулаймы?—дип мөрәҗәгать итте үзеннән алда чыгыш ясаган ораторга.

Фәрдиев ач тавык шикелле шунда ук жимгә үрелде.

—Сез уйлап сөйләшегез, Үзәк Комитет фаш иткән шәхесләр белән минем бернинди уртаклыгым да юк.

—Алай булгач, ни өчен Сталинның тәгълиматларын пропагандалыйсыз соң?

—Ялган бу, күрәләтә намуслы кешегә яла ягу.

—Мин алай димәс идем Фәрдиев абый. Менә сез киләчәктә бер генә тел калачак дидегез, ягъни бер генә милләт булачак. Бу бит Сталин теориясе. Үзәк Комитет тарафыннан фаш ителгән Сталин теориясе. Моның белән килешмәүче башка милләтләрне чеченнар, Кырым татарлары кебек сөргенгә сөрергәме? Барыбызга да Себердә урын житәр микән соң?

—Көн тәртибеннән читкә тайпылмыйк, иптәшләр,—дип директор тәртипкә чакырды.—Кемгә сүз бирик?

Бүлмәдә бермәлгә тынлык урнашты. Бигеннән ычкынган форточканың шыгыр-шыгыр килгән тавышы гына ишетелә. Мансур форточканы ябып килде. Укытучылар аны тыңларга җыенды. Ләкин Җәмилә алданрак өлгерде.

Мансурның Мәскәүдән бүләк итеп алып кайткан костюмын кигән. Кара төс аңа бик килешә. Төз, зифа гәүдәсе берьюлы асыл да, рәсми дә. Ирексездән күңелгә Дәрдмәндның шигъри юллары килә:

Буе зифа, йөзе күркәм, үзе яшь;
Күзе кара, озын керпек, каләм каш.

Мансур хатынын кочаклап үбүдән чак-чак кына үзен тыеп калды. Күрәсезме Җәмиләне дигәндәй, карашы белән бүлмәне йөреп чыкты. Ә укытучылар инде арыган. Кайсыдыр китап актара, дәфтәр тикшерә, икенчеләре әкрен генә гәпләшеп утыра. Фәрдиевнең башы түшенә авыпавып төшә. Сталин теорияләре инде онытылган, йокысын баса алмый интегә. Мансур аны типкәләп ташлар хәлгә житте.

Җәмилә сүзен башлады.

—Мин,—диде ул карлыкканрак тавыш белән,—кайберәүләрнең мәктәпне рус телле мәктәпкә әйләндерү турындагы ниятен зәгыйфь акыллы кешеләрнең саташуы белән генә чагыштыра алыр идем.

Халык шып булды. Фәрдиев та тураеп утырды. Күзләр директор ягына борылды. Чөнки Җәмиләнең чалгы пәке шикелле үткен сүзләре беренче чиратта директорны уеп ташлады. Ничек дип юрарга да белмәделәр. Ихтимал, өстәгеләрнең фикерен житкерәдер? Ире Мансур абруйлы кеше, аны министрлыкта да яхшы беләләр.

Зыятдинов үзе дә шактый ара тамагына тыгылган төенне йота алмый торды.

—Моның өчен,—дип дәвам итте сүзен Җәмилә,—иң элек беренче класска рус контингенты тупларга кирәк. Ләкин Бистәдә ике рус мәктәбе бар ич инде. Димәк, рус мәктәбе теориясе төшеп кала. Безнең мәктәп

өчен аның нигезе юк. Аннары мине Әслах Зөбәерович үзе укыткан укучыларын түбәнсетүе, кимсетүе гаҗәпкә калдырды. Бу—хыянәт!

—Җәмилә Нурулловна... сез.. ни...

—Әслах Зөбәерович, мин сезне тыныч кына тыңладым, бүлдермәгез, зинһар, фикеремне әйтеп бетерергә ирек бирегез.

—Дәвам итегез,—диде директор үзенең баш очындагы давылның икенче юнәлеш алуына сөенеп,—дәвам итегез.

—Ни өчен әле авыл баласы сыер тизәгендә генә казынырга тиеш? Юк, бу зур хата. Без авыл баласына юлны ябарга тиеш түгелбез. Укысыннар, институтларда, университетларда укысыннар. Фәндә, сәнгатьтә, мәдәнияттә үз урыннарын тапсыннар. Милли интеллигенциянең коесы —авыл. Кызганыч, татар әдәбияты бу мәсьәләдә, минемчә, ялгыш эзгә кереп китте. Роман-повестьларда укырга керә алмыйча төзелешләрдә кирпеч ташучы, тимер юллар сузучы, фермаларда эшләүче квалификациясез егет-кызлар мактала. Гүзәл Бәйрәмованың фаҗигасы—ул безнең дә фаҗига.

—Тәкъдимегезне әйтегез,—диде директор.

—Тәкъдимем шул: бүгенге хәлне исәпкә алып, югары классларда фәннәрне рус телендә укытуга күчәргә кирәк. Монысы реаль.

Мансур дәрес ишетәмме, ялгышмыйммы дип, Җәмиләгә күтәрелеп карады. Ә Җәмилә берни булмагандай тигез ак тешләрен күрсәтеп алды да, урынына утырды. Мансурның ачуыннан каны кайнап чыга язды.

—Төртмә, кода, үзем беләм, үлсәм дә, хак сүземне әйтеп үләм,—дигән мәкаль белән башлап җибәрде ул үзенең чыгышын.—Күреп торам, мин инде күпчелек тавышны җыя алмамдыр, мөгаен. Мин шәхсән татар баласы рус телен үзенең ана теле дәрәҗәсендә белергә тиеш дигән карашта торам. Алай гынамы, чит телләрдә дә иркен сөйләшә белергә тиеш әле ул. Тик моңа ирешү үз теленне типкегә чыгару, аны санга сукмау исәбенә башкарыла алмый. Телгә булган мөнәсәбәтеннән билгеләнә милләтнең абруе. Үзе ихтирам итмәгән телне башкалар ничек ихтирам итсен ди?

Мансур күп дәлилләр китерде, рус телен укытуны яхшырту буенча тәкъдимнәр кертте. Кагыйдә ятлауга, схоластикага нигезләнгән алым алга таба да уңыш китермәячәк, диде. Ләкин сүзе үтмәде. Педсовет икенче яртыеллыкта 8-10 классларда фәннәрне рус телендә укытуга күчәргә, дигән карар кабул итте.

Педсоветтан соң аны директор үзенә чакырды. Кәефе шәп. Кулларын бәрештерә-бәрештерә ишекле-түрле йөрештереп алды да, Мансурның алдына ук килеп басты.

—Син яшь кеше әле, Мансур,—диде ул әңгәмәнең рәсми булмавына ишарәләп,—сәләтең бар, абруең бар. Әмма син мондый карашларың белән бервакытта да максатыңа ирешә алмаячаксың. Милләтчелек чире бик куркыныч чир. Синнән зуррак абзыйларның да муенын сындырды ул. Сталин белән мин тулысынча килешәм; телибезме-теләмибезме, торабара вак телләр йотылачак. Никадәр тиз, шул кадәр яхшы. Чувашлар, марилар, удмуртлар, төньяк халыклары молодецлар. Алар инде рус мәктәпләре программасына күчкәннәр.

Мансурның күңелен төшенкелек хисләре биләп алды. Җәмилә булып Җәмилә дә иң соңгы минутта аңа арты белән борылды. Иң көлкесе шул, һәр икесе дә халык мәнфәгатьләре турында кайгыртабыз, дип уйлый. Чынлыкта исә бу татарга ясин чыгу белән бер ич инде.

—Бу хакта мин сезнең белән бәхәскә кереп тормыйм, Мирза Кәбирович,—диде ул директорның уңган чүпрәк кебек төссез күзләренә туп-туры карап,—милли мәсьәләдә безнең карашлар капма-каршы. Һәм, кызганыч, сезнең караштагылар күпчелекне тәшкил итә. Тик мин сезгә барыбер рәхмәтле, сез мине, бер белмәгән кешене, армиядән кайтканымны көтеп торып эшкә алдыгыз. Сезнең кул астында мин эшкә өйрәндем. Булдыра алганча үзем дә сезгә ярдәм итәргә тырыштым. Нәтиҗәләре дә булды, дип саныйм. Хәзер инде юлларыбыз аерылды. Сезнең бу

авантюрагыз аркасында русча да, татарча да белмәүчеләр туачак.

—Мансур Әмиржанович...

—Башлагач әйтеп бетерим инде, Мирза Кәбирович. Мин бу мәктәпкә төпләнү өчен килмәдем. Сез моны үзегез дә беләсез. Урыныгызга да дәгъва итмәдем. Китәр вакыт житте дип уйлыйм. Билгеле, уку елын тәмамлагач инде. Ләкин белеп торыгыз. Моны мин беренче булып сезгә әйтәм.

* * *

Мансур башына төшкән бу күңелсезлекләрне бик авыр кичерде. Институт белән араны өзде. Диссертациясен утка якмакчы иде дә, аңына килеп тукталып калды. Ашарга сорамый бит, ятсын шунда, сандыгының иң төбенә яшерде. Педсоветта сүзе үтмәве дә кәефенә бик нык сукты. Оят үлемнән яман, дип белеп әйткәннәр. Кеше арасында мәсхәрә ич! Барысы да аннан көлә, аның гайбәтен сата кебек тоела иде аңа.

Икенче караганда, ис китәрлек бернәрсә дә юк шикелле. Берәүнең дә тормышы тоташ бәхеттән, тоташ уңышлардан гына тормый ич. Әнә, Тукайны гына ал. Нинди генә михнәтләр күрмәгән аның башы?! Әмма бирешмәгән, максатына омтылган. 20-25 яшендә үк милләтебезнең горурлыгына әверелгән. Мондый сикәлтәләр аның тормышында киләчәктә дә булмас дип, жә, кем ышандыра ала?

Мансур акылы белән боларны яхшы аңлый. Яраткан шагыйре Тукайның шигъри юллары да хәтерендә: "Үткән эш кире кайтмый, үкен син, үл, ела". Димәк, аларны инде онытырга кирәк! Тик гарьлекне, оятны, кимсенүне, жан жирсүен диссертация кебек сандыкка бикләп куеп булмый икән шул. Хисне билбауга төйни алмыйсың. Ә ул хисле кеше. Шуның өстенә йомакай. Һәр күңелсезлек йөрәгенә бәрә. Чөнки Жәмилә кебек үк күңелендәгеп селкеп сала торганнардан түгел. Әмма сабырлык та туза икән. Шеш тә бит тула-тула да берзаман сытыла. Мансурның да эченә жыйган борчулары башын калкытты. Ул йоклый алмый башлады.

Шулай бер көнне кылт итеп жиде төн уртасында уянып китте. Элек тә була иде андый хәлләр. Бераз әйләнгәләп ятуга янә татлы йокыга чумар иде. Ә бу юлы күңеле тулы шом, курку. Житмәсә, идән астында нindидер бөжәк кыбырсына: керт-керт, керт-керт...

Бу хәл һәр төнне кабатлана башлады. Кич життеме, борчыла башлый, тиктомалдан үртәлә, бер кешене күрәсе килми. Үзе генә калырга да курка, әллә ни булыр сыман. Төн аның өчен чын мәгънәсендә жәзага әйләнде. Аз гына черем иткән арада да бастырылып бетә. Вакыт-вакыт йөрәге кага, игә килә алмыйча интегә. Тора-бара шуны аңлады, йокы килмәүдән түгел, куркудан йокы алмый икән аны. Йоклап китсә, әллә нәрсә булыр сыман. Хәзер ул үзе йокысын басарга жан-фәрман тырмаша. Бу жәһәттән балалык хатирәләре булыша. Төннәр буе шул хатирәләрне исенә төшереп ята. Балык каптырырга һәвәс иде ул. Аеурча олы балыкка йөри иде. Тирес корты кигезә дә кармагын төнгә куя. Кеше-фәлән күрмәсен өчен сабын кәс белән күмә.

Тирес кортына кызыл канат, опты кебек балыклар каба. Көндез аларны Мансур яр башыннан күзәтә. Кояшлы көнне кичке якта кызыл канатлар көтүләре белән су өстенә калкалар. Салмак кына койрыкларын селкеткәләп эленгән кер шикелле бер урында тибрәләләр. Балчык ыргытып куркытсаң да, бер-ике генә минутка югалып торалар, янә калкалар.

Мансур кармак салган көнне көтү белән бергә уяна. Шыпан-шыпан Сөн буена элдертә. Буш кул белән кайткан көннәре дә күп анысы. Балык та хәйләкәр бит, жимгә уптым-илаһи ябырылмый, ян-яктан гына капкалап сыйлана да, сыза.

Ә балык эләккән көнне Мансурның борын чөйдә. Бөтен авыл күрсен дип, юри балыгын эләктермәгә аса да, койрыгын жирдән өстерәтеп

кайта. Зур балык эләктергән, янәсе.

Бервакыт тирес кортына, ялгышыпмы, башка берәр сәбәп беләнме, чуртан да килеп капкан иде. Кармагының җебен тотып карауга, балык барлыгын тойды Мансур. Авыр, тыгыз, кыл җәя җебедәй тартылган. Мондый чакта йөрәк күкрәк читлеген ватып чыгардай булып тибенә. Күңелдә—шатлык, горурлык, масаю... тагын әллә нинди хисләр.

Мансур түземсезләнеп кармак җебен сава башлады. Беренче мәлне балык карышмады. Әмма су читенә җитәрәк дуларга керешмәсенме. Ул үзенең кармакка эләккәнен сизеп алган иде, күрәсең. Тормыш һәр җан иясенә кадерле. Ләкин балыкчы бу хакта уйламый. Анда аучылык азарты.

Менә Мансур балыкны күреп алды: саңаклары кош канаты кебек җәелгән, авызы киерелгән, күзләре—шар. Нәкъ аждаһа.

Куркуыннан аның кулыннан җебе ычкынып китте. Аждаһа шундук күздән югалды. Ул аңына килеп, янә кармагына ябышты. Тартыша торгач, кыл чуалып бетте. Шулай да балыкны өстерәп чыгарды. Өч килолы иде.

Чуртан шулай куркыныч булып каба икән.

Җәмилә йоклый. Төш күрә ахры, авыз эченнән нидер сөйләнә. Үзе әледән-әле әйләнгәли, карават пыржиналары шыгыр-шыгыр килеп куя. Моңа Мансурның җаны үртәлә.

Бераздан, ниһаять, барысы да тынды, идән астындагы таныш бөҗәкнең керт-керт иткән тавышы гына ишетелә. Ул бөҗәк Мансурның төнге дустына әверелгән иде инде. Шул керт-керт иткән тавыштан ничектер тынычланып китә.

Шулай тартышып ята-ята таң ата башлый. Мансурның инде йокы белән көрәшерлек хәле калмый, күзләре үзләреннән-үзләре йомыла. Әйтерең бармы, җәфа. Табибка барыр иде, кешедән ояла. Япь-яшь килеш нинди табибларга йөрү инде ул?

Мансур үзенең бу халәтен хатынына сиздермәскә тырышып карады, үтәр әле, дип ышанды. Сизмиме соң хатын-кыз? Җәмилә сизде, әлбәттә. Ләкин ул да аңа артык әһәмият бирмәде. Вакытлы җирсенүдер, житди нәрсә булса, үзе әйтер, дип уйлады. Җәмиләне күбрәк Мансурның битарафлыгы борчый иде. Чөнки салкынайды. Моны инде хатын-кыз күтәрә алмый. Шуңа күрә чарасын да күрә башлады. Ул аны "хатын-кызлар медицинасы" ярдәмендә дәваларга булды. Америка галимнәренең фикеренчә, бу гамәл организмнан бик күп сырхауларны куарга сәләтле икән. Нервы авыруларыннан аеруча файдалы ди.

Шулай беркөнне Җәмилә ятар алдыннан кече өстәлгә матур гына, җыйнак кына табын әзерләде.

—Әллә нигә бүген җаным бәйрәм тели, әйдә, булган-булсын, бәләкәй генә утырып алыйк әле,—диде һәм Мансурның ризалыгын да көтмичә рюмкаларга коньяк агызды.

—Төнгә каршы зыяны тимәсме соң?—дип шөбһәсен белдерде Мансур. Ул хәзер бар нәрсәдән дә шикләнә иде.

—Шундый таза чибәр егеткә нинди зыян ди ул? Менә хатыныңнан үрнәк ал!

Җәмилә гомерендә беренче мәртәбә рюмканы төбенә кадәр бушатты.

Шәраб тәненә җиңеллек биреп, кан тамырларына сеңде. Озак та үтми, текә таудан чаңгы шуганда гына кичерә торган халәте килде. Белми эчмиләр икән, нинди рәхәт, дип уйлады Җәмилә иренә елыша-елыша.

Җәмиләнең коткысын Мансур дәвам итәргә, "гөнаһ" тезгенен үз кулына алырга тиеш иде. Ләкин Җәмилә үзе кызып китте. Бармаклары иренең йөнтәс күкрәген капшаштырып алды да, түбәнгә шуыша-шуыша оҗмах җисеменә барып иреште...

—Мансур, җанашым, Мансур...

Мансур исә түмәр кебек, урыныннан кузгатырмын димә. Җәмилә аны төрлечә назлап-иркәләп үзен чишендерергә мәҗбүр итте. Шуннан соң гына уянды Мансур.

"Дәва" Җәмиләнең үзенә килеште. Йокы дигән юха елан аны башы-аягы белән йотты. Кайда ятканын да белмәде, иртәнгә чаклы ник бер уянып карасын?

Ә Мансур төшендә шәрә хатыннар белән саташты. Бер көтү хатын. Ят җирләрен чәбәкли-чәбәкли һәммәсе үзе янына чакыра. Кайберләре йодрык күрсәтә. Янапмы-яныйлар. Аннан, чыр-чу килеп, куып ук киттеләр. Йөгерә-йөгерә Мансурның хәле бетте, тыны кысылып, гыж-гыж килә башлады. Бер убыры, әнә, куып та җитте бугай инде, чабудан эләктереп алды...

—Кирәкми,—дип кычкырды Мансур җан ачуы белән,—мин теләмим!!!

—Алайса ниемә тагып йөрисең соң ул нәмәстәкәйне, алаша?

Җәмилә ич бу, дип уйлап алды Мансур, аның тавышы.

Ул арада ниндидер көчле кул аны җиргә егып салды.

—Җәмилә, кирәкми, Җәмилә...

Ярый әле бу мәхшәрдән уянып котылды Мансур, югыйсә йөрәге шартлап ярыла иде.

Шуннан соң керфек тә какмады. "Хатын-кыз медицинасы"ның ярдәме тимәде.

Шулай инде, бу дөньяда бернәрсә дә эзсез генә узмый. Һәммәсе — яхшысы да, яманы да йөрәктә үз тамгасын калдыра.

Укытучылар шаһит, ул Кормаш мәктәбен чын милли татар мәктәбе итү өчен тырышмады түгел, тырышты. Үзенә калса, нәрсәгәдер ирешелде, дип тә ышанып йөри иде. Ләкин бу чүлдәге мираж гына булган икән. Җил исүгә таралды да бетте. Бу ахыр чиктә татар мәктәбенен кризисы һәм шуны рәсми рәвештә тану дигән сүз иде. Мансур һәм аның шикелле меңнәрчә татар укытучыларының эшен санга сукмау дигән сүз иде.

Җәмиләгә ул бигрәк тә шуңа ачулы. Хәлбуки, аның фикерендә дә хаклык бар. Татар милли югары уку йортлары булмый торып, татар мәктәбенең абруен күтәрә алмыйсың. Татар мәктәпләрен саклап калуның бердәнбер юлы төгәл фәннәрне рус телендә укытуга күчү.

Педсовет та күз буяу өчен генә үткәрелгән икән. Мәсьәлә югары даирәләрдә җыелышка кадәр үк хәл ителгән булган. Укытучылар ирегенә куйсаң да, нәтиҗәсе шулай була иде. Татарны эт кебек бер-берсенә өстерү, әләккә этәрү, куркыту бернигә дә тормый. Шул сыйфатлары дәүләтчелекнең башына җиткән дә инде.

Мансур барыбер Җәмиләгә үпкәле иде. Инде хәтсездән ачылып сөйләшкәне юк. Ямьсез кыяфәттә төшкә керүе дә шул сәбәптәндер, ихтимал. Бөтен юанычы—кызы Ләйсән.

Ләйсән исле сабын тышында сурәтләнгән кызчыкны хәтерләтә. Шундый ук матур, шундый ук йомры, шундый ук итләч. Үбеп туймаслык. Тел бистәсе, сорау оясы. Аның өчен сырхау да юк, үпкә дә юк. "Юк" дигән сүз үзе дә юк. Тормышы шатлыктан гына гыйбарәт. Йөзенә төшкән күләгәләр дә шатлык күләгәләре генә.

Әле дә әтисе белән урам буйлап кайтып киләләр. Тун кигәч, Ләйсән аю баласына охшап калган. Табаннарын ялтыратып йөгерә генә. Юри-чари гына егылып та киткән була. Аннан соң хәйләкәр генә елмаеп, әтисенең күтәреп торгызганын көтеп ята.

—Кызым, кар йомарламы булып беттең бит инде, алай ярамый бит инде,—дип, кызын шелтәләп тә куя Мансур.

Ләйсән, гадәттәгечә, әтисенең җөмләләреннән үзенә ошаган сүзне кармагына эләктереп ала.

—Йомаглам? Нәгсә ул йомаглам, әтием?

—Йомаглам түгел, йомарлам. Кабатлале, йо-мар-лам.

—Йо-мар-р-р-лам.

Ләйсәннең сакаулыгы бетеп килә инде. Шулай да "р" авазын әле буташтыра. Тырышканда дөрес әйтә үзе.

—Әтием, нәр-р-сә ул йо-мар-р-р-лам?

Мансурның кашлары арасында буразна хасил булды. Ничек аңлаешлырак аңлатырга соң бу кәттәбикәгә?

–Йомарламмы? Йомарлам ул, кызым, нәрсәне булса да укмаштыру, кушу... әйтик менә син...

–Юк, әтием, юк, юк, юк. Мин йомаглам түгел. Йо-мар-р-р-лам ул май, белдеңме? Дәү әнием ясый аны сөттән.

–Сөттән түгел, сөт өстеннән,–дип төзәтте Мансур.

Ләйсәнне “йомарлам” кызыксындырмый иде инде. Чөнки ул көлтә койрыклы йөнтәс көчекне күреп алды һәм шуның артыннан йөгерде. Тегесенә уйнаучы гына кирәк. Чәр-чәр өреп, кызның бер алдына, бер артына төшә. Шунда ук кинәт кенә туктап, менә мин нинди усал, курык миннән дигәндәй, тешләрен ыржайтып, йоннарын кабартып, Ләйсәнгә карап тора. Ләйсән печтек тә курыкмый. Маэмайның башыннан сыйпый, иркәли. Тегесе усаллыгын онытып, бияләй шикелле зур теле белән Ләйсәннең кулын ялый.

Мансур көчек яныннан кызын өстерәп алып китте. Хәер, хуҗасы да янында гына булган икән, сызгырып җибәрүгә йөнтәс аның янына ыргылды.

–Әтием, без кайчан шундый бәләкәч алабыз инде,–дип Ләйсән шыңшырга ук кереште. Кирәк әйберсен ул еламсырап сорый. Чөнки белә, аны юатачаклар, теләген үтиячәкләр. Ләкин бу юлы Мансур коры торды. Әгәр тагын тәртипсезләнсәң, башка урамга алып чыкмыйм, диде.

Ләйсән шыңшуыннан туктады. Иреннәрен турсайтып берара тавышсыз гына барды. Тик шушындый матур, ямьле көндә сөйләшмичә түзеп була ди мени?

Ә көн матур иде. Аяз. Күк зәп-зәңгәр. Шул зәңгәрлек эченнән кояш елмая. Бу елмаю кар җәймәсенә асылташ булып ява.

Суык бабай да бүген усалланмый. Иркәләп кенә чеметкәли. Ләйсәннең бит очлары, әнә, алмаланып тора.

–Әтием, без кызыл маэмай алабыз, җәме?–дип кыз теге йөнтәсне тагын исенә төшерде. Бусы да хәйлә. Ерактан суктыра торган стратегик хәйлә. Ләкин әти кешегә бу алымнар инде таныш.

–Кызыл эт булмый,–дип кырт кисте ул.

–Ә нигә булмый?

–Йөдәтмә әле, булмагач булмый инде.

Ниһаять, өйләренә кайтып җиттеләр. Ләйсән икенче катка әтисеннән алданрак менеп җитте. Ишекне әнисе ачты. Билендә алъяпкыч, яулыгын үзенә бер кәкитлек белән баш очына гына элеп куйган. Плитә тирәсендә кайнаша иде, шуңа күрә йөзе алсу төскә кергән.

–Әйдәгез, бик вакытлы кайттыгыз, бәлешем өлгерде,–дип елмаеп каршы алды ул якыннарын.

–Әнием, минем буяулагым кайда?–дип сорады Ләйсән чишенгән арада.

–Башта ашыйбыз, бар кулларыңны юу, рәсем соңыннан,–диде Җәмилә.

Ләйсән мыштым гына йокы бүлмәсенә элдертте. Анда аның үзенә яраклы өстәле, урындыгы бар. Уенчыклары да шунда, кәгазь-дәфтәрләре дә. Менә ул ашыга-ашыга кулына кылкаләм алды да, борынын тарткалый-тарткалый нидер ясарга тотынды.

Аш бүлмәсеннән әнисенең тавышы ишетелде.

–Ләйсән, мин сиңа нәрсә әйттем, җә, тиз бул, кулларыңны юу.

–Хәз-ер-р-р!

Бераздан ул ясаган сурәтен кулына тотып кухняга чыкты.

–Әтием, кар-р-р-а, кызыл эт! Буйыйсың да, ул кызыл эт була да куя.

Ләйсән кетер-кетер көлде. Ул үзенең сүзе өстен чыгуга чиксез шат иде. Ашаганда да тынмады. Әле ярый Ләйсәнем бар, дип сөенеп куйды Җәмилә, көне буе бер сүзгә зар булып утырыр иде.

Ләйсәннен дә башына шушы уй кергән иде.

—Әтием, телең урамда калдымы әллә?—дип Мансурга текәлде.

—Теленә салынма, маэмаенны урлап китәрләр,—диде Мансур.

Аштан соң Ләйсәннән Яна ел бәйрәменә өйрәнгән шигырьләрен сөйләтеп карадылар. Тәтелди генә. Ә иң яратканы Такташ шигыре:

Урамнар бүген сөенгән,
Ап-ак карга киенгән.
Ләйлә чанасын өстерәп,
Чыгып китте өеннән.

Инде Ләйсән хужа роленә керде.

Баг күнелле лек бөтен дөньяда, баг бег ямь бүген.
Нәгсәдән бу?—Мин беләм: бәйгәм бүген, бәйгәм бүген!

—Хәзег театг уйный, диде Ләйсән.—Әнием син пгинсиса буласың, әтием—пгинс. Мин—Каши. Бик усал ул Каши. Пгинсалагны углый. Каганггыга ябып куя. Әнием, син кугыкма, җәме, мин юги генә, җәме.

Ләйсән йөзен куркыныч рәвешкә кертеп, уылдый-уылдый әнисе тирәсендә әйләнде дә, өстерәп алып китеп почмакка бастырып куйды.

—Әтием, син принс бит, принсисаны эзлә. Мин Каши. Без сугышабыз. Әйдә, әйдә, менә шулай. Күрдеңме усал Кашины җиңдең. Ул инде юк, һавага очты. Ура, принсисаны коткардың. Ни карап торасың инде, әтием, принсисаны кочагыңа ал. Кочакла, кочакла. Ә хәзер үп. Табышкач үбешәләр инде. Оялма, әтием, мин күзләремне йомам. Менә кара, бернәрсә күрмим.

Нишләмәк кирәк, принц принцессаны кочаклап үбәргә тиеш. Әкияте шулай.

Мансур әкияткә буйсынды. Җәмиләнең күзләреннән яшь коелды. Үзе елмая, үзе елый, кояшлы яңгыр кебек.

—Әнием, мин юри-чари гына бит,—дип Ләйсән аларның ике арасына килеп керде. Ул "р" авазын бертоткарлыксыз әйтә башлаган иде. Тик моны үзе дә, әти-әнисе дә сизмәде.

Мансур тагын төнен саташып уткәрде. Имеш, хатыны Җәмилә, кызы Ләйсән белән нинди дер тау өстендә йөриләр. Аста диңгез котырына. Ак башлы каракучкыл дулкыннар ыңгыраша-ыңгыраша киләләр дә, таш кыяга килеп сугылалар. Тау дер килеп селкенә. Хәзер ишелеп төшәр сыман. Ләйсән елый, әтием, мин Кашидан куркам, китик моннан дип ялвара. Кая китәсең? Юл юк. Шунда иләмсез зур канатлары белән күкне аждаһа каплады. Ахырзаман шушы икән, дигән уй кадалды Мансурның башына. Ул да булмады, аждаһа Ләйсән белән Җәмиләне эләктереп алды. Мансур аның артыннан ташланды. Тик аждаһаны куып житеп буламыни? Ялгызы кыя очында басып калды.

Ә диңгез кайный. Тауга шундый зур дулкын китереп бәрде ки, чигенгәндә үзе белән Мансурны да суырып алды.

—Коткарыгыз!

Кемдер аны күтәреп алды. Караса, Җәмилә.

Җәмилә аны, чыннан да, тынычландырырга тырыша иде. Нарасыен иркәләгән яшь ана кебек чәчләрен сыйпый-сыйпый күзләреннән, бит очларыннан, иреннәреннән үпте.

Мансур боларны тоймады. Ул әле һаман ярымсаташу хәлендә иде. Инде уяндым гына дигәндә күзләре йомылып китә дә янә диңгез чоңгылына тәгәри. Җәмилә торып утны яндыргач кына җайга килде.

—Һәр нәрсәне болай йөрәгең аша үткәрмәскә тырыш инде Мансур,—диде Җәмилә,—диссертацияне дә сипләргә булыр дип уйлыйм, юньле житәкче генә табасы. Мәктәптәге үзгәрешләр дә шулай ук синең белән миннән генә тормый, бөтен республика шул юлдан бара. Миңа да юкка үпкәлисең. Мин сине саклап калу өчен тырыштым. Педсоветта миннән

алда сөйләгән булсаң, үзеңә дошманнар гына җыя идең. Татарны татар итәр өчен министрның да көче җитми әле анда. Тырышып карады ич инде. Партиядән узып ни майтарсын? Без дә шул хәлдә.

—Диссертация, тераң мәктәп дип күпме шаулады...

—Хәзергә боларның барысын да башыңнан чыгарып ташла. Сиңа дөньяңны онытып ял итәргә кирәк.

—Нинди ял ди ул, Җәмилә!

—Тиздән каникул житә. Отпуск исәбенә атна-ун көн ял алып була ич инде. Тотабыз да Сөн буена элдертәбез. Кышын да шулай матур микән ул Түбән Сөн?

—Ул һәрвакытта да матур, Җәмилә.

* * *

Аэропортта халык күп иде. Эче кеше, тышы кеше. Күрәсең, гадәттәгечә, һава шартлары чабудан тота. Бездә шулай бит, игенне вакытында җыеп алмасалар да, сөт кимесә дә, төзелеш акрын барса да шул каешланып беткән сәбәпкә, янгырга-карга сылтыйлар. Уңышка ирешкән очракта да һава шартларын кыстырмый калмыйлар. Монысы инде мактану, шапырыну. Янәсе, яңгыр бабай ничек кенә аяк чалмасын, без аны күтәреп салдык. Табигать-ананың теле юк, шуннан файдаланалар. Тик ул барыбер үзенекен эшли, сорап тормый. Яңгырын да яудыра, кирәк икән—карын. Гарасатын-давылын да өрдереп ала, Җирнең үзен дә селкеткәли. Җиһанга ул гына хуҗа. Аэропорттагы кешеләр, билгеле, бу хакта уйламыйлар, аларга барырга, кайтырга, китәргә кирәк.

Мансур тынчыган күл шикелле исле халык дәрьясын күздән кичерде дә, Җәмилә белән Ләйсәнне бер почмакта калдырып, этешә-төртешә билет кассалары урнашкан якка үтте. Анда да чуалышып беткән чират. Кешеләр йончып, тирләп-пешеп беткәннәр. Усал эт шикелле ырылдарга гына торалар. Касса тәрәзәсе янына гомумән дә үтеп булмый, ботарлап ташларга әзерләр.

—Мүкләк сыер, кая төртеләсең болай,—дип берсе Мансурның якасыннан алды,—без монда бер тәүлек интегәбез, ә ул б...

—Мин сорыйм гына,—диде Мансур акланган дай. Ул иртән телефон аша белешкән иде. Бөгелмә—Мөслим—Актаныш маршруты ачык, билетлар да бар, дигәннәр иде.

—Һы, сорыйм гына, имеш, синең кебек сораучылар әнә күпме, вокзал тулы.

—Сыптырып җибәр, нәрсә ул нахал белән тел кашып торасың?—дип киңәш бирде икенчесе.

Чират хәрәкәткә килде. Койрыктагылар әлеге тавыш-гауганы үзләренчә кабул итте, ахры. Кайсыдыр:

—Билет саталар!—дип кычкырды. Китте тарткалаш, китте бакырыш. Әле ярый репродуктордан чираттагы игълан яңгырады, югыйсә бу болганышның фаҗига белән бетүе дә бик ихтимал иде.

—Казанга, Мәскәүгә, Куйбышевка очу һава шартларының начар булуы сәбәпле, тагын ике сәгатькә соңартыла. Уфадан, Чиләбедән, Свердловскидан әлегә мәгълүмат юк...

Репродуктор чәнечкеле сүзләрен чәчте-чәчте дә, тынып калды. Кешеләр сүгенә-сүгенә элекке урыннарына кайттылар. Көтмәгәндә репродуктордан яңа игълан сибелде:

—Якын арадагы маршрутлар ачык. Мөслимгә, Минзәләгә, Актанышка очучы пассажирларның регистрациягә үтүен сорыйбыз, билетлар да сатыла.

Мансур бернәрсәгә карамый касса авызына ыргылды.

—Әй, сытасың бит, аю,—дип сукранды олырак яшьтәге бер хатын.

—Бәхетлеңең көймәсе дә корыдан йөри шул аның, килүенә кайчан, инде китеп тә бара.

—Нәчәлниктер әле, аларга кайда да юл ачык.

Мансур мыек астыннан гына елмаеп куйды. Аның инде күптәннән үзен болай жинел тойганы юк иде. Булса була бит, вокзал тулы халык, ә ул гүя Искәндәр гаскәрибаш: килде, жинде, китте.

—Булды бу, кадерлеләрем,—дип ул хатынын, кызын берьюлы кочаклап алды,—киттек Сәрвәрне эзләргә!

—Кем ул Сәрвәр, әтием?—диде Ләйсән як-якка карангалап.

—Ария бу, кызым. Композитор Жәүдәт Фәйзинең "Башмагым" комедиясеннән.

Башмак, башмак, башмак, башмак,
Кемнәр йөри икән ташлап;
Син дә минеке булырсың,
Шушы вакыйгадан башлап.

Ләйсәннең башында секунд эчендә биниһая күп сорау туды. Тик алар сүнеп калдылар. Чөнки пассажирларны очу кырына чакырган әмер яңгырады.

Бөгелмә аэропорты ачык жирдә, жил уртасында утыра. Анда дымык көннәрдә дә буран уйный. Жилбикә саксызрак адәмнәрнең баш киемнәрен дә очыртып алып киткәли. Кош-кортларга бүләк, алар аннан оя кора.

Жирле пассажирларның абруе жирле дәрәжәдә генә икән. Зур очкычларга кешеләрне аэропорт янында ук утырталар, хажәте чыкса автобус та бирәләр. "Кукурузник" дигән чикерткәләр әллә кайда, еракта, ындыр артына ук кунаклаган булсалар да, тәпи-тәпи барасы. Бара-бара күзләре күгәреп бетте. Әллә нинди жимерек сарайлар, канатлары каерылган аэропланнар, гаражлар, тимер-томыр өемнәре аша узасы.

Ләйсән инде арыды, шыншый ук башлады. Мансур аны кулына алды. Берсендә—бала, икенчесендә—чемодан. Алда, ниһаять, очкыч күренде. Жилбикә аңа да тынгылык бирми, кибәргә эленгән кер шикелле дер-дер калтырата тегене.

Очкыч янында берничә кеше кайнаша иде. Араларында хатын-кыз да бар. Башлык, күрәсең, янындагыларга ярсып-ярсып нидер аңлата.

—Пассажирларны утыртырга мөмкинме?—дип сорады озата килүче кыз.

Әлеге хатын (ул очучы икән) кызны күзләре белән бораулап алды да:

—Самолетны полосага чыгарырга машинаң бармы соң?—дип сорауга сорау белән жавап кайтарды.

—Алайса мин пассажирларны кире алып китәм,—диде дежур кыз аның дорфалыгына игътибар да итмичә—самолетны полосага алып чыгу минем вазифага керми.

Пассажир дигән хокуксыз бәндәләр каз көтүедәй каңгылдашып алдылар.

—Житәрең!—дип кычкырды очучы,—минем үземә дә Минзәләгә кайтырга кирәк, әнием авырып ята.

Аэроплан янындагылар тагын гәпләшеп алдылар. Шуннан соң очучы:

—Балалы хатыннар салонга кереп утырыгыз, калганнар белән самолетны полосага этеп чыгарабыз,—дип әмер бирде.

Бу калтырча да мәктәп машинасы кебек икән, дип уйлап алды Мансур. Аны да урам буйлап этеп кабызалар. Балалар, шул исәптән Жәмилә дә, салон эченә уздылар. Салон дигәне таракан ташлаган өйне хәтерләтә иде. Салкын, жыештырылмаган, идәндә әллә нинди капчыклар, приборлар аунап ята. Утыргычлары да калай икән. Шыр ялангач, берничәсенең генә япкычы бар. Алары да киезләнеп беткән.

Ләйсән тиктормас тәрәзәдән Мансурны күреп алган икән.

—Кәрәле, кара, анда әтием,—дип Жәмиләнең жиңнәреннән тарткалап алды. Мансур да кызын шәйләп алган иде, елмаеп кулын болгады.

—Дәү әнигә барып життекмени инде?—дип сорады Ләйсән.

—Нигә алай дисең, кызым?

–Әтиемнең авызы менә-ә-ә болай. — Кыз куллары белән колакларын капшап алды. Бу аның, әтиемнең авызы колагына житкән, дигәнне аңлатуы иде.

Ул арада очкычны күтәрелү мәйданына сөйрәп китерделәр. Анда жил хужа иде. Бетон плитәләр арасына кереп поскан кар бөртекләрен пран-заран китереп йөри. Әле аларны бөтерелдерә-бөтерелдерә күккә индерә, әле кыр буйлап куып алып китә. Шыксыз бушлыкның да үз матурлыгы бар икән.

Аэропланга иң соңгы кеше булып очучы хатын үзе керде. Кунак табынындагы шикелле капма-каршы утырышкан пассажирларны күздән кичерде дә:

–Нәрсә, чүп-чар арасында утырасыз, әйдәгез әле, тиз генә жыештырып алыйк,–диде.–Геологлар чүпләгән, кичтән аларны алып кайткан идем.

Бергәләшеп салонны жыештырып алдылар.

–Апа, син Сәрвәрме әллә?–дип сорады аннан Ләйсән һич уйламаганда. Әнисе аның кабыргасына төрткәләп алды, тик кенә утыр янәсе. Ләкин әйтеләсе әйтелгән иде инде. Очучының йөзендәге ясалма кырыслыгын юып төшерделәрмени, ак тешләрен күрсәтеп елмаеп жибәрде. Була бит шундый кешеләр, житди вакытта алар бер рәвештә, елмайганда бөтенләй башка затка әйләнәләр дә куялар.

–Юк, үскәнем, мин Сәрвәр түгел, исемем Мәдинә минем. Кызым –Алсу. Ул синнән зуррак, яренгә укырга керәчәк. Ә үзеннең исемең ничек соң?

–Ләйсән.

–Исемең дә үзең кебек бик матур икән, сылукай. Кая барасыз соң болай күбәүләп?

–Дәү әни янына.

–Киттек алайса, дәү әниең көтә-көтә көтек булып беткәндер инде.

Мәдинә тыштан тупас булып күренсә дә, бик мөлаем хатын икән. Һәм бик яхшы очучы. Аэроплан үз биеклеген алганчы гына чайкалгалады. Аннан тынычланды. Тигез асфальт юлдан элдерткән зиннәтле машина диярсең, селкенми дә. Мөслимгә кайтучы бер әби баштарак ян-якка карарга да батырчылык итмичә авыз эченнән пыш-пыш догаларын укып барган иде дә, ул-бу сизелмәгәч, түгәрәк тәрәзәгә дә күз салгалый башлады.

Тора-бара һава да ачылды. Очкыч өстендә асылынып торган болытлар арасыннан кояш елмайды. Авыллар, урманнар, таулар уенчык шәһәрчек кебек. Теләсәң тотып кара, урыннарын алыштыр, үзеңчә үзгәрт. Аларны үрмәкүч жепселләредәй юллар чолтәре чорнап алган. Машиналар тызбыз чаба. Йөк төягән олаулар күренә. Лупа астындагы сыман бәләкәйләр. Свифт үзенең данлыклы “Гулливерның сәяхәте” әсәрен язганда, мөгаен, жирне һавадан күзәткәндер. Югыйсә, шундый ук төгәллеккә ирешә алмас иде.

Ләйсән бертуктаусыз тәтелди. Аның әле очкычка беренче мәртәбә утыруы.

–Әтием, кара, машиналар кеп-кечкенә, безнеке зур, әйеме?

–Әтием без аска ничек төшәрбез икән инде, баскыч юк бит.

Аэроплан нindидер каты нәрсәгә бәрелгәндәй калтыранып китте. Әби янә күзләрен йомды, догаларына керешге. Ләйсәннең дә күзләре түгәрәкләнде.

–Курыкма, кызым,–дип Мансур Ләйсәнне кысыбрак тотты.– Мөслимгә килеп життек, самолет түбән төшә башлады.

Мөслимдә әлеге догалы әбине генә калдырдылар. Әби Мәдинәнең аркасыннан кагып, зур рәхмәтләр укыды, теләкләр теләде.

Минзәләдән соң Мансурлар да үзләре генә калды. Актаныш халкы, күрәсең, кышын өйдә утыруны мәгъкулрәк күрә.

Дөресе дә шулай. Элек-электән юл йөрергә күнекмәгән Актаныш халкы. Түбән Сөндә бер мәртәбә дә авылдан чыгып карамаган, хәтта

пароход та күрмәгән әбиләр бар. Хәлбуки, авыл Сөн белән Агыйдел тамагына урнашкан. Җәй чорында таң алдыннан халыкны пароход тавышы уята. Ә поезд? Анысы бөтенләй җәһәннәм астында. 70 чакрым, кунатөнә барырга кирәк. Камбарка дигән станца. Удмурт ягы, ят, кире як. Анда йөрүче дә юк.

Актаныш төбәген чит дөнья белән су юлы гына тоташтырып тора. Су юлының исә гомере кыска. Район үзәгенә аэроплан оча башлауга да ике генә ел әле. Ана шулай ук ышаныч аз. Бигрәк тә кышын. Чалт аяз көннәрдә дә тотрыклыклар чыгып кына тора, чөнки аэродромның исеме генә бар. Узган ел Мансур кунакка килгән әнисен Казан аша озаткан иде. Мал-туарларым, кош-кортларым, дип бик ашыккан иде әнисе. Кеше фаразлый, Аллаһы тәгалә гамәлли дигәндәй, әнисе Казан аэропортында бер атна утырган.

Шуңа күрә актанышлылар юл йөрергә һәвәс түгел. Цивилизация мәгънәсендә юл монда гомумән юк. Сукмак бар, юл юк. Сөн аркылы чыксаң, келтертәп торган юл. Күтәртелгән, таш җәелгән. Фермаларына кадәр барып житә. Ләкин бу Башкортостан. Азык-төлек, чәй-шикәр өчен дә халык Башкортка чыга.

Мансурларны каршы алырга килгән ат та ун чакырым араны ике сәгать ярым кайтты. Юлга шактый көрт салган иде. Әнисе ике толып хәстәрләп җибәргән. Аның толыбы да музей хәзинәсе хәзер, калса шул Актаныш якларында гына калгандыр инде.

Мансур толып кимәде. Каршы алырга килгән абзый белән ат артыннан җәяүләп кайттылар.

Аның каравы монда табигать дөнья яралгандагыча сакланган. Бөгелмә яклары белән чагыштырганда җир белән күк аермасы. Анда адым саен скважина, адым саен электр баганасы. Көне-төне газ факеллары яна. Бу тирә-як мохитны пычратып кына калмый, миллиардларны кара сөремгә әйләндерә. Шул ук вакытта янәшәдәге авыллар газсыз интегә. Чөнки барысы да Мәскәү кулында. Мәскәүнең кулы исә үз ягына гына кәкре.

Һавасы саф, чиста, пакь. Кар сөттәй ак. Кылтык егетләрнең хром итеге кебек, баскан саен шыгырдап тора.

Ләйсән арыган иде инде, толып эчендә эреп йоклап та китте. Кайткач та уянмады. Шуңа күрә үзләре дә озын-озак юанмадылар, юрган астына керделәр.

* * *

Мансурның күнеленә балачакны хәтерләтүче нииндидер саф, аһәңле, моңлы тавыш иңде. Сихри, жылы, йомшак, ләззәтле тавыш. Ул аның жанын, тәнен, рухын берьюлы биләп алды. Бишектә тибрәлгәндәй тибрәлде. Өнме бу, төшме, йоклыймы ул, уяумы? Өн булса да, төш булса да, ул бу халәтенең озак, бик озак дәвам итүен генә теләи. Нинди риясыз рәхәтлек! Югыйсә, дөньяның яме, яктылыгы тоныклана башлаган иде ич.

Шулай да нинди илаһи тавыш соң бу? Ирексездән Мансурның күзләре ачылды. Башта ул үзенең кайдалыгын аңышмый торды. Мич янында кайнашучы бик кадерле затның таныш чалымнарын абайлап алгач кына, һәммәсенә төшенде. "Әнкәй, әнкәем",–дип пышылдады аның иреннәре. Инде чынлап торып уянды, карашы белән өй эчен айкап чыкты. Әнә, түшәмдә балачактан таныш рәсем. Дөресрәге, түшәм тактасында уелып калган ботак эзе. Үзен белә-белгәннән бирле йокыдан уянуга күзләре шул сурәткә текәлә иде. Бер караганда, мылтык аскан, кылыч тоткан атлы гаскәригә ошый, икенче вакытта дию пәриен аяк астына салып таптаган Камыр батырны хәтерләтә. Үсә төшкәч, борынына ис керә башлагач, ул чишмә ярында озын толымнарын тарап утыручы гүзәл туташка әверелде. Әкияти сурәт булып чыкты бу ботак эзе, хыялда нинди уй йөрсә, шул рәвешне ала. Инде әнә хәзер кызы Ләйсәнгә

ошаган, “чанасын өстерәп чыгып бара өеннән”.

Күзләре түшәмдә булса, колак төбендә әлеге сихри тавыш яңгырап тора. Самовар ич бу! И, жанаш! Әле дә элеккечә ыспай, чиста, матур икәнсең. Элеккечә үк иртәләрен өй эчен моңлы жырың белән тутырасың икән. Рәхмәт сиңа!

Мәдинә улының уянуын сизеп алган иде инде. Янына килеп утырды, юрганын рәтләде, сөеп чәчләреннән сыйпады. Мансурның балачактагы шикелле әнисенең куенына кереп елышасы килде. Их, татлы да була иде соң әни куенындагы йокы!

Мансур әнисенең кулларыннан алды. Бу кулларның һәр уемы, һәр сызыгы, һәр төере таныш аңа. Һәр ике учын да аркылыга өч сызык кисеп уза. Уртадагысын гомер сызыгы, дия иде әбисе. Буйдан-буйга чыга икән, димәк, озак яшисең. Әнисенең дә гомер сызыгы буйдан-буйга чыга. Аллаһы боерса, гомере озын булыр.

Табигый сурәтләрдән тыш, көндәлек авыр физик хезмәт тә аның кулларына үз билгеләрен салган. Менә бу баш бармак белән имән бармак арасындагы жөй арыш урганда урак кискән эз. Салкын тиюдән куркып, элек яшь бозауны өйдә имезәләр иде. Берсендә сыер көйсезләнеп, мөгезе белән әнисенең беләген ярды. Ул эз дә исән-сау.

Кытыршы, жөйле, эзле булсалар да, бу куллар Париж чибәркәйләренең сөяркәләр генә назлый торган нәфис кулларыннан бик күпкә шәфкатьлерәк, мәрхәмәтлерәк. Элек-электән татар хатын-кызларының кулы дөньяны тоткан.

Жә, ходай, нинди газиз бу куллар! Бала жиһанга килүен белдереп, әнисенең мәрхәмәтле кулларында беренче авазын сала. Әнисе аны куллары белән күкрәгенә кысып, шифалы сөтен имезә. Шушы ышанычлы кулларга таянып бу кечкенә кеше тәүге адымын атлый. Үсеп, канат какканда да, әнисе яулык очы белән яшен сөртә-сөртә аны кул болгап озатып кала.

Иң кадерле әнкәемнең
Эшчән, житез куллары.
Жир йөзендә аннан матур,
Аннан йомшак кул бармы?

Шагыйрьнең бу риторик соравына һич икеләнмичә: “Юк!”,—дип кенә жавап бирергә мөмкин.

Ана белән бала озак кына бер-берсенә карашып утырдылар. Мәдинәнең күзләреннән ике бөртек яшь сытылып чыкты. Улы моңа хафаланмады. Чөнки белә, бу—шатлыктан, очрашу шатлыгыннан. Шуңа күрә ул аларга кагылмады. Шатлыкны жуярга ярыймы соң?

Әнисе стенага эленгән фоторәсемгә ишарә итте. Бу—Мансурның әтисе Әмиржан. Тоныкланып беткән инде. Суслонгер дигән каһәрле урында төшерелгән сурәт. Фронтка жибәрер алдыннан Идел буе республикаларыннан, өлкәләреннән алынган солдатларны иң элек шунда интектергәннәр. Ачлык, чир-сырхау, бет-борча—шулар өстенә командирларның тупаслыгы, дорфалыгы.

Әле дә бу сурәт бар. Чөнки Башкортостан якларында бернечә ел мөгаллимлек иткәннән соң Түбән Сөнгә күченеп кайтканда әйберләрен елга бөтереп алган. Китаплары, язу-сызулары да аккан. Бу фото әтисенең бердәнбер ядкаре.

Мансурны әтисенә ошаган диләр. Озынчарак йөз, тар маңгай, иртә сирәгәйгән чәч, тәкәббер ияк. Бик чибәр дип әйтеп булмый, билгеле. Аның урынына буй-сын, гәүдә ясап куйган кебек. Төз, мәһабәт, горур. Дәү әтисе тирә-якта уңганлыгы белән дан тоткан. Аның турында хәзер дә: “Һиммәте тау тишәр иде”,—дип сөйлиләр. Тик совет властена андый алтын куллы тырыш кешеләр кирәкмәгән. Йорт-жирләрен, мал-туарларын талап алып, үзләрен сөргенгә сөргәннәр. Әкрәм карт бу хәлләрне алдан сизенгән, күрәсең, улларын Башкорттагы ерак туганнарына озаткан.

Күрекленең башы барыбер бүрекле инде, балалар анда да жаен тапканнар. Әмиржан педтехникум бетергән, Әбелхан урманчы белгечлеге алган. Калганнары да ким-хур түгел, барысы да белем эстәгән.

Совет власте Әкрам картның нәсел-нәсәбәсен ничек кенә мәсхәрә итмәсен, ир туганнар барысы да шул власть өчен башын салган. Мансур хәзер әтисе белән бер яшьтә. Кулак малае укытучы Әмиржан 28 яшендә һәлак булган. Күмелгән урының гына белүче юк...

–Улым, торсагыд да ярый инде, самаурым жырлый, әнә, хәдер бер-ике таба төплекәй пешереп алам,–диде әнисе.

Жәмилә дә уянган икән.

–Һай, серләштегез дә соң, колакларым чыңлый башлады,–дип көлде.

–Каенананың сүде бер инде аның, Жәмиләкәем, киленнең яманатын сату,–диде Мәдинә.

–Арт алмасына кояш төшкәнче йокы бүскән киленне сөйләми соң,–дип шаяртты Мансур.

–Жәмиләкәем, булмаса, бар, юынып ал, уманник кәбәрткәдә, суы да жылы.

–Дәү әни, нәрсә ул кәбәртка?–дип учлары белән күзләрен уа-уа Ләйсән дә торып утырды.

–И, бәбкәччәем, уяндыңмы, үсепләр беткәнсең бит инде, и-и, күр инде, клубка чыгарлык дур кыд булгансың бит,–дип сөйләнә-сөйләнә Мәдинә оныгын күкрәгенә кысты.–Нәмәләр белән генә сыйлаем икән тәтәй кыдымны.

–Дәү әни, авызыңдагы ипиеңне йот башта, аннан сөйләшерсең,–дип шаккаттырды Ләйсән әбисен.–Кыд түгел, кыз, кыз! Белденме?

–И, бәбкәччәем, беднең телебед шулай өтек инде, нишләем соң? Кыдыл бодау дип ирештерә бедне Калан кешеләре.

–Үзеңне бел, сорау букчасы,–диде Мансур,–әле кайчан гына гагылдый идең, оныттыңмы әллә?

Ләйсән әтисенең сүзенә игътибар итмәде, үзенекен такылдады:

–Дәү әнием, мин сине сөйләшергә өйрәтермен, жәме?

–Ярар, бәбкәччәем, ярар, үрәтерсен.

–Дәү әни, мин чыршы бәйрәмендә күбәләк булып киендем, шигырьләр сөйләдем. Сиңа да сөйләп күрсәтимме?

–Сүлә, бәбкәччәем, сүлә.

Кырга ак кардан
Юрган ябылган.
Кыш язга чаклы
Йокыга талган.

Ашагач-эчкәч, Мансур белән Жәмилә, авылны урап кайтыйк әле дип, урамга чыгып киттеләр.

–Дәү әни, урлашып кына сандыгыңны актарабыз хәзер, жәме?–диде Ләйсән.

–Эшләрне бетерәек әле, кыдым, чормадан балан бүкәне алып төшеп эретергә куяеык. Балан бәлешен әтәң бик ярата. Ипи дә идәсе бар, май ядасы...

Өйалдыннан чормага баскыч куелган. Ләкин бауга тотынып менәсе. Зурлар өчен кыенлыгы юк та, баланың тәгәрәп төшүе бар.

Мәдинә ничегрәк итәргә соң дип, баш ватып торган арада Ләйсән инде маймыл шикелле өскә үрмәли иде. "Егыла күрмә",–дип Мәдинә дә аның артыннан ашыкты. Бергәләшеп алар башта чолан өстенә, аннан чормага менеп життеләр.

Ләйсән берара кая барып бәрелергә белмичә як-якка каранып торды. Бу аның өчен бөтенләй яңа дөнья иде, иске-москы, узган заман патшалыгы.

Татар өенең чормасы, дөрестән дә, үзе бер музей ул. Авыл халкы яраксызга калган әйберләрен дә чүплеккә чыгарып ташларга ашыкмый.

Кирәге тияр әле дип, җыеп бара. Ул әйберләрнең урыны–чорма. Нәрсәгә генә тап булмыйсың анда? Ярык казан, иләккә әйләнгән күмер чүлмәге, сапсыз кисәү агачы, каптыргычы сынган табагач, черек туку станы, көя кисеп бетергән толып, тишек чабата–тагын әллә нәрсәләр...

Боларның берсе дә Ләйсән күргән-белгән әйберләр түгел. Шуңа күрә кызыксынып күзәтә. Беренче булып аның игътибарын бер түгәрәк түмәр җәлеп итте.

–Ярма ташы ул, кыдым,–дип таныштырды дәү әнисе.

–Нәрсә соң ул ярма ташы?

–Ярма ярып ботка пешерә иек,–диде Мәдинә.

–Дәү әнием, минем дә ботка ашыйсым килә.

–Пешерербед, бәбкәчләем, ярмага кытлык юк, аллага шөкер.

–Миңа ярма ташының боткасы кирәк.

–Әтәңә әйтерсең, минем кулымнан килә торган нәмә түгел ул хәдер.

Ләйсән әтисен көтәргә булды. Чөнки монда әле башка әйберләр дә күзне кыздырып тора. Әйтик, менә бу маэмайныкы кебек тумпак борынлы сырлы нәмәстә.

–Туданга батасың, кагылма ул бәләккә,–дип кисәтте Мәдинә.

–Дәү әни, кара, мин аны күтәрә дә алам әле. Оһ-һо-һо!

–Күтәрмәскә теге, үтүкне дә күтәрмәгәч...

Ләйсән гаҗәпләнеп әбисенә карап алды.

–Һи, дәү әни, шундый үтүк була мени?

–Монда аның күмер салып кыддыра торганы да бар әле. Менә. Капкачын ачып эченә утлы күмер тутырасын да, үтүкләйсең. И-и, бар ие интеккән чаклар. Сугыш кына чыга күрмәсен. Дөнья күдгә күренеп рәтләнә. Әнә бит ярапланга утырып, сәгать эчендә кайтып та җиттегед.

–Бусысы комган,–диде Ләйсән,–мин беләм. Өйдә янасы да бар, әйеме, дәү әни?

–Мөселман өендә комгансыд ярамай, кыдым, җәен кайткач, бисмилла догасын үрәткән ием, онытмадыңмы соң әле?

–Дога? Нинди дога?

–Әгүде биллаһим минәшайтан irражим...

–Ә-ә, беләм, беләм. Әнием дә белә. Без әппәр дә итәбез әле. Әтием көлә.

–Һы, кара син аны, мулла нәселеннән икәнен оныткан икән, шилма малай. Бабаң Әмирҗан да бик гыйлем кеше ие. Искечәне дә, яңачаны да су күек кенә эчә ие. Әткәсе, минем кайнатам Әкрам картның туганы Әхмәтҗан абдый сәүит вакытында да хәдрәт булып торды әле. Халык бик ярата ие. Себергә сөреп кенә башын ашадылар. Бу турыда җәелеп сүләргә ярамай хәдергесе вакытта, бәбкәччәем, сүд уңаеннан гына әйтүем, нәсел-нәсәбеңне белеп үс диюем. Әтәңә авылда укыганда гелән "кулак калдыгы", дип каныктылар. Бирешмәде, укуы белән алдырды, рәхмәт төшкере.

Бригадир булып эшләгәндә үдемнең дә теңкәгә тиделәр. Бер көнчеле наруш крандас башына бөрмәкәй белән борчак яшергән дә, сәүит персидәтеленә чаккан. Басу капкасы төбендә саклап торып тентеделәр. Шундук милитсягә алып төшеп киттеләр. Төрмәдә ике төн кундырдылар, исәркәем. И, шундагы өдгәләнүләрем!? Үдемнән бигрәк балаларым өчен кайгырдым, бер кичтә чәчләремә чал керде. Нахакка бит. Ярай әле, теге денседнең крандас тирәсенә чуалуын хатыннар күреп торган. Шулар коткарды, жаныкайларым. Районга явит белән төштеләр...

–Дәү әни, мин анламыйм, син нәмәкәй сөйлисен?

–Инде син дә бедненчә сүләшә башладыңмы әллә? Әтән-инән ачуланыр, "нәмәкәй" монда гына ярай ул.

–"Нәмәкәй" матур, дәү әни, мин яратам.

–Ул сүдләрне мин, кыдым, үд-үдемә генә сүләем. Кайчак искә төшеп, йөрәкләрем сыкрап китә. Хөкүмәт хәдер генә йомшарды ул. И,

каты чаклары бар ие, дер селкетеп тота ие.

Мәдинә аркылы әртәгә эленгән балан бүкәнен үрелеп кулына алды. Ике-өч бөртек балан түшәм балчыгына тәгәрәде. Ләйсән аларны учына салды. Ни өчендер колагына китереп тынлап та карады, телен тигезде. Ул көткәнчә булмады ахырысы: "Тәмсез",—дип йөзен чытты.

—Бәлеш эчендә тәмләнә ул, бәбкәччәем.

Ләйсәнне өйдә дә ачышлар көтә иде. Багып баксаң, ипи башта пластилин шикелле була икән ич! Аны да кул белән әвәлиләр, йомшарталар икән. Ләйсәннең чын пластилины күп. Ул алардан курчаклар, маэмайлар, мәчеләр ясый. Юлпычы юк менә. Дәү әнисенеке бар. Көймә кебек ул. Кечерәк кенә. Онны шуңа сала. Аннан соң иләккә коя, шап-шоп китереп суккалый. Кызык!

Камырлар песи балалары кебек ояларына кереп яттылар. Дәү әнисе янып торган кузларны мич авызына тартып өйде дә: "Кыдым, берәр таба гына көләчә пешереп алаем әле үдеңә",—диде. Табада май чыжылдый башлады. Дәү әнисе түгәрәк камырларны шунда тондырды. Күп тә үтми, шар сыман кабарынып бәләкәй ипиләр мендәр өстенә ятты. Әкияттәге күмәч шикелле, хәзер тәгәрәп китәрләр төсле. Әмма Ләйсәнне ошаттылар булса кирәк, тәгәрәмәделәр. Ул аларны майга мана-мана ашады. Бик тәмле була икән кайнар көләчә. Аларның олы авызлы миче юк шул. Әнисе дә пешерер иде. Газ мичендә гөбәдия, өчпочмак, бәлеш кенә пешә.

—Әтәңнәр кайтып житкәнче майны да ядып куяеык әле,—диде Мәдинә мичне томалап, ипиләрне урнаштыргач.—Бәләкәй чакта әтәң әйрән ярата ие.

—Минем әнием дә ярата, мин дә яратам,—диде кыз авызларын бүлтәйтеп.—Әтәң дә, әтәң, без кая?

Мәдинәнең кулындагы табасы чак идәнгә төшеп ярылмады. Ул оныгын кочагына алып, чуп та чуп үпте.

—Бәбкәччәем минем, аралап әйтүем түгел бер дә. Надан инде мин шулай, башсыд. Әнкәңне дә бик яратам, үд кыдларым күек, сине яратуымның иге дә чиге дә юк, гомеркәйләрең генә одын булсын. Каян шулай барысын да белеп бетерәсеңдер?

Мәдинә май язганда Ләйсән атлы казак шикелле аның янында басып торды. Үзе дә язып карады. Тик "май таягы" авыр икән, шундук кулбашы талды. Дәү әнисе, әнә, бер кулы белән дә ничек гөбердәтә.

Май төште. Мәдинә гөбене зур мискә бушатты. Әйрән өстенә сапсары май кисәкләре калкып чыкты. Ул аларны ике кулы белән чып та чоп китереп әвәләде.

—Йомарлам,—диде Ләйсән урамда әтисе белән булган әңгәмәне хәтеренә төшереп,—әтием мине "йомарлам" ди. Мин ничек "йомарлам" булыйм ди инде? Май ул "йомарлам", әйеме, дәү әни?

—Ни ылтара, ни пылтара, иләс-миләс чумара икән әтәң, кыдым, ә?

—Нәмәкәй дисең, дәү әни, мин аңламыйм.

—Менә монысын аңлыйсыңмы?

Саескан сарымай китерде,
Тургай туңмай китерде.
Чыпчык килеп өләште,
Ләйсән кыдым көнләште.

—Дәү әни, син нәмә, мин көнләшмим. Мин чыпчыкларны яратам. Әйдә, үзләрен май белән сыйлыйк.

—Күдләре сукыраер.

—Мин ашыйм, минеке сукыраймый бит. Әнә, кара! Нигә аларныкы сукырая?

—Сиңа, бәбкәччәем, җавап табып бетерә торган түгел. Булмаса, мал-туарларны караштырып керәек әле. Әтәңнәр дә батты. Кайтса, чебен күек ябышалар шуңа.

Ләйсән дәү әнисе белән ишек алдына чыкты.
Ул бик бәхетле иде.

* * *

Мансур белән Ләйсән шау-гөр килеп чаңгы шуарга чыгып киттеләр. Тавышлары әле бик озак ишетелеп торды. Җәмилә аларны тәрәзәдән карап калды. Мәдинә, гадәтенчә, учак тирәсендә чуала. Тырышып-тырышып казан төбе кыра. Катык оетырга дип сөт кайнаткан иде. Озаграк торган, көебрәк киткән. Бәләкәй чакта балалары касмакка чират торыр иде. Бу кортлысы борылып та карамый. Дөньялар үзгәрде шул, элек печән өстендә иң алдынгы чабучыга гына эләгә иде ул казан төбе кыру.

Җәмилә әле һаман тәрәзәгә капланган. Мәдинә үзенә сиздерми генә киленен күзәтеп торды. Иркәрәк анысы, тик бик ипле, ихтирамлы. Олыны олы, кечене кече итә белә. Мин укытучы дип кылтаймый. Авылныкылар әнә, әллә кем булып йөриләр, хан кызлары диярсең. Үдебеднең мәктәпкә кайтып эшләсәләр дә бик әйбәт булыр ие дә бит, тыңламайлар. Кала тирәсеннән китәселәре килмәйдер инде.

Җәмиләнең күзләре әле дә тәрәзәдә.

—Кыдым, нигә алай боектың, үпкәләшмәгәнседдер бит?—дип сорарга мәҗбүр булды Мәдинә.

—Юк, әнкәй, нинди үпкәләшү ди ул, кайтканыбызга сөенеп бетә алмыйм. Ләйсәнебез күбәләк шикелле очып кына йөри. Мансур өчен генә борчылам.

Мәдинә кулларын алъяпкыч итәгенә сөртә-сөртә килене янына килеп басканын сизми дә калды.

—Мансурга ни булды, кыдым, бер-бер чире бармы әллә?

—Начар йоклый ул, әнкәй, төне буе саташып чыга.

Мәдинә морҗа янындагы урындык читенә килеп чүмәште.

—И-и, аман бетмәгән икән, ходаем, — диде авыр сулыш алып, — бәләкәйдән куркак булды инде. Уттан коты алына ие, бәбкәччәем. Шулай бервакыт уракчылар янына аппарганыем. Аны аш пешерүче янында калдырып, үдем басуга кереп киттем. Урап килсәм, исәркәем, арба астына кереп поскан да йоммай түгеп утыра. "Нәмә булды?"—димен. "Ут, ут чыга",—диеп пешекче яккан учакка төртеп күрсәтә. Уттан әле дә куркамы диеп, сорармын дигән ием әле.

—Мина, төнлә убыр утларын күзәтергә ярата идем, дип мактанган була.

—Белмәем, Җәмилә, анысы үскәчрәк булгандыр.

Саташуы да Актаныштa укыганда калды. Көн дә ун чакырымны йөреп укыды бит. Кар димәй, янгыр димәй, чыгып китә. Бер көн дә укуын калдырмады. Берсендә буран чыгып, Шырлык күперендә адашкан, бәбкәччәем. Шуннан соң бик одак саташты. Беткәндер дигән ием инде мин аны, бетмәгән икән.

—Нинди урын соң ул Шырлык күпере дигәнегез?

—Бик хикмәтле урын ул, Җәмиләкәем. Өч-дүрт елга бер чорсызланып ала. Ул гел язгы ташу гайрәтле булган елга туры килә. Иван атлы явыз патша Кадан ханлыгын пран-даран китергән чакта бер иш керәстиәннәр качып киткәннәр дә, Сөн буена килеп төпләнгәннәр. Ул чагында бу урыннарда кара урман шаулап утырган. Урманны кисеп йорт-җир тергедгәннәр, бушаган урынны чистартып чәчүлек җире көйләгәннәр. Елгаларга күпер салганнар. Шырлык елгасына да салып куйганнар андый күперне.

Авылда гаиләсе белән Корбангали атлы бик саран бер бәндә яшәгән. Гөлшәһидә исемле бик сылу кыдлары булган ди боларның. Гөлшәһидә яраткан егетенә вәгъдә биргән, сиңа чыгармын, диеп. Әтәсе кыдын тыңламаган, саранлыгына көч килеп, тоткан да күрше авыл кешесенә никахлаган. Кыдны авылдан алып киткәннәр. Шырлык күперенә житкәч,

теләк теләгән Гөлшәһидә, шушында жир йотсын ие, диеп. Аллаһы ишеткән аның теләген. Шунда туйны жир йоткан. Шуларнын жаннары өрәккә әйләнеп кешеләргә дыян сала башлаган: алаштыралар, чирләтәләр.

Минем сугышта үлгән Миңнәхмәт агаем да очраткан аларны, сөләй ие. Районнан йон теттереп кайтып килә икән. Сонлаган. Күпер янында өч кеше басып тора дие. "Сед кем, кая барасыд? – диеп сораган агаем. Тегеләр дәшмәгәннәр. Курыккан Миңнәхмәт агаем, шәп-шәп атлап үтеп киткән. Бара-бара бу, ә күпер өстендә тагын шул өч кеше басып тора дие. Удып киткән ием бит инде бу күперне, диеп уйлай икән. Шулай өч-дүрт тапкыр кабатлангач кына хәлне төшенеп алган. Кемнәндер, курыкмаска кирәк, сүгенергә кирәк, дигәнен ишеткәне булган. "Курыкмаем, курыкмаем, өермә жиле өреп кит, маржа күтенә кереп кит",–диеп такмакларга тотынган. Юк, файдасы тимәгән, тегеләр китмәй дие. Аятелкөрси догасын укыгач кына күддән югалганнар.

–Хәзер дә очрыймы соң ул өрәкләр, әнкәй?

–Сирәк булса да күренгәли диләр. Шау-шуны яратмай ди алар. Хәдер көне-төне машина чаба бит, юл буш тормай.

–Мансурны әйтәм, бик курыккандыр, жанашым.

–Курыкмаенча, төн уртасында бит ул.

–Куркуны кире кайтарып була икән дип ишеткәнем бар иде, әнкәй, дөресме икән?

–Миңнәхмәт агаемны әйттем бит инде. Ул да саташа башлаган ие. Тегеләргә өшкертеп бик күп ридык илтте, ачу сакламасыннар диеп. Аны өрәкләр котырынган вакытта, жиде төн уртасында илтергә дие.

Мансурныкын әйтәм, әлегә кадәр үч тоталар икән, мәлгуньнар. Бәхилләтмәй ярамас, Жәмиләкәем. Яп-яшь килеш сырхауланып йөрергә тагы...

–Икәүләп барсак кына инде.

–Юк, кыдым, өрәкләрнең ачуы төшкән кеше үде барып бәхилләтергә дие.

* * *

Мансур башта бот чабып көлде. "Атом, электроника заманында, кеше галәм кинлекләренә сәяхәт кылган фән-техника революциясе чорында нинди ырым-шырым ди ул, юк белән башымны әйләндермәгез, ишетә-нитә калсалар, мина көн бетәчәк",–дип теше-тырнагы белән каршы торды.

–Табиблардан файда тимәде бит,–дип үгетләвен дәвам итте Жәмилә.

–Димәк, чир юк. Булмаган чирне ничек тапсыннар соң алар?

–Йокламау чир булмыйча нәрсә соң ул?

Моржа янындагы урындыгында ир белән хатынның сүзенә кушылмаган атлы булып бәйләм бәйләп утырган Мәдинә, аллан сөйләшеп-килешеп куелганча, бәйләмен кучкарга куйды да, улы янына килеп утырды.

– Мансур, улым, моның бер гаебе дә юк. Бодык, сихер ише чирләрне брачлар белмәй ул. Синең чирең жан чире, брачлар әгъзаны гына дәвалай. Карышма, барып кайт, эт тә белмәс.

Ризалаштырдылар тәки. Моннан дистә ел булган вакыйгалар кино кадрларыдай янә Мансурның күңеленнән узды.

Дөя күзе шикелле чәтрәннәп торган төн иде. Ай күзләрне чагылдырырлык якты иде. Ишелеп-ишелеп йолдызлар атыла. Дымык. Салам селкетерлек тә жил исми. Әйтерсең лә, Жир шары әйләнүеннән туктаган. Үтә жете төсләргә манчылган бу төн гадәти дә, гадәти дә түгел. Агачлардан, читән-коймалардан төшкән күләгәләр тирә-якка шом тарата. Ул күләгәләр эчендә нинди-дер куркыныч зат күзәтеп тора сыман.

Мансур төнлә юл йөрергә күнеккән иде инде. Кара бураннарда да кире борылып кайтканын хәтерләми. Ә бүген йөрәге пошына. Чөнки

кайда, ни өчен барганын белеп бара. Очрармы ул өрәкләр, юкмы, барыбер шикләндерә.

Бу шикләрен басу өчен Мансур айга багып, шигырь сөйли башлады.

Ай—ялгызның сердәше,
Уйчыларның уйдашы,
Гыйшыкларның мондашы,
Юлчыларның юлдашы...

Ул колхозның алма бакчасына килеп җитте. Анда каравыл йорты бар. Гадәттә, элек юлаучылар шунда җыела иде. Болар башлыча урта мәктәп укучылары, РТСка ремонт мәшәкатьләре белән йөрүче тракторчылар, йомышчылар була иде.

Укучылар дигәч тә, Түбән Сөннән алар икәү генә иде. Шәйхулла белән ул—Мансур. Шәйхулла чирләшкә малай. Ике көннең берендә генә бара. Анда да юньле-потлы укымый. Башкорт ягыннан чыгып укучылар фатирда тора. Атнага бер генә кайтып киләләр. Күпчелек ялгызы гына йөри иде Мансур. Юлдашлары ай, йолдызлар. Ул күк җисемнәре белән дуслашып бетте. Алар аны атнага алты мәртәбә Актанышка кадәр озатып куялар. Кар-буранда да ул аларның кайдалыгын сизеп тора иде.

Инде ай-йолдызларга карап, һава торышының ничек буласын да чамалый башлаган иде. Әйтик, яңа ай урагының очлары нәзек күренсә, салкынны көт. Ай кырын туса—буранга. Җидегән йолдыз карасу төскә керә икән, көн бозылачак. Йолдызлар "куерса", җылырак киен, суык бабай чабуын ычкындырыр.

Йолдызлар арасыннан иң яратканы—Тимерказык, Җидегән йолдыз, Иләк йолдыз. Тимерказыкның Җидегәнгә караган башында үзгәрәк төстә ике йолдыз бар. Берсе Акбүзат, икенчесе—Күкбүзат. Матур йолдызлар. Исемнәре дә күркәм.

Тимерказыкка карап, диңгездәгечә җиһанның якларын билгеләргә була. Чөнки ул һаман Котып өстендә асылынып тора. Урынын үзгәртми. Шуңа күрә аны күкнең аркасы дип тә йөртәләр.

Ә теге көнне барысы да элеккечә иде. Күк гөмбәзен күзәтә-күзәтә менә ул Шырлык күперенә дә килеп җитте. Күпер—ярты юл. Аннан соң чакрымнар кимүгә бара. Үр менгәч, РТС утлары да күренә башлый.

...Күпер янында искәртмәстән нииндидер өермә күтәрелде. Мансур ян-ягына карангаларга да өлгермәде, чиный-чиный аңа бер эт килеп сарылды. Ныклабрак караса—Актырнак!

—Актырнак, Актырнак,—дип Мансур этенең башыннан сыйпамакчы итте. Әмма эт читкә ыргылды. Шунда гына аңа ис керде. Актырнакны соң узган кыш бүреләр ботарлап ташлады ич! Ләкин ул уйларын уйлап бетерә алмады, кемнеңдер үзенә текәлеп карап торуын сизде. Ике-өч кенә адымда бер кеше басып тора иде. Кулын изәп сүзсез генә үзе янына чакыра. Ә Мансур кузгала алмый, аяклары—боз. Тагын эт тавышы ишетелде. Ул үзен-үзе белешмичә этен чакырырга кереште.

—Актырнак, Актырнак!

Аның каршында янә теге сүзсез адәм калыкты. Һаман кулын изи. Мансур атлап китте. Теге кеше атлый, ул атлый. Шунда ул сорасы итте:

—Кем син, кая алып барасың мине?

Ләм-мим. Кылт итеп Мансурның хәтеренә әбисенең сүзләре килеп төште. Җен-пәриләргә юлыксаң, Аятелкөрсине укып, тирә-ягыңа түгәрәк сызык сыз дия иде. Аңа шул дога ярдәмгә килде. Түгәрәк сызык сызып, үзе шуның эчендә калды.

Күз ачып йомганчы буран басылды, күктә йолдызлар кабынды, ай елмайды.

Шушы хәлләрдән соң ул төннәрен саташа башлады. Әмма табибларга мөрәҗәгать итмәде. Уналты-унҗиде яшьлек егет зарланып йөри димени? Җитмәсә, күңелендә гыйшык уты кабынган чак иде. Авылга Алабуга

институтын тәмамлаган Галия исемле кыз укытучы булып килгән иде. Бөтен егетләр гашыйк иде ана. Мансур да гашыйклар арасында. Тик кыз берәүне дә якын җибәрмәде, һавалы иде. Укытучы ич! Ләкин ана карап, Мансурның хисләре сүнмәде. Яшерен яратуның да үз ләззәте, үз сихере бар. Хыял канатларында мәхәббәт дингезенең нәкъ уртасында кайныйсың. Җилкенәсең, аның исерткеч хәмереннән авыз итәсең...

Нинди эчкерсезлек, нинди беркатлылык!? Хәер, тиле булмаса, яшьлек яшьлек була димени? Егет халкы хисләрәк була шул. Мәхәббәт фәрештәсе иң элек егетләрнең җилкәсенә куна. Шуңа күрә тилелек тә алардан ерак йөрми. Чөнки ходай ир-атны мәхәббәт колы итеп яраткан. Нәзберек, нәфис, асыл аты алган кыз затларыбыз мәхәббәттә ир-егетләребезгә караганда күпкә гамәлиерәк. Алар танышканда ук дөньяви максат куеп, киләчәкне күздә тотып таныша.

Мәхәббәт горурлыкны кабул итми диләр. Әмма хатын-кыз һәрвакыт хисне горурлык белән алмаштырырга омтыла. Мәхәббәт өчен, ярату өчен хатын-кыз үзен корбан итми. Мәхәббәт өчен үз-үзенә кул салучылар да ир-егетләр.

Галия дә үзеннән шактый өлкәнрәк кешегә чыкты. Сайлаганы инде тормышта да ныклы урынын тапкан, матди ягы да хәл ителгән. Югары урында эшли.

Мансур гыйшкы аркасында Такташ белән мавыгып китте. Шагыйрьнең мәхәббәт лирикасын аркылыга-буйга буйлады. Саташкан кеше шикелле юлда кычкырып шигырь сөйләп йөри иде.

Мәхәббәт ул үзе иске нәрсә,
Ләкин һәрбер йөрәк аны яңарта.
Тиле яшьлек ярты гомерен бирә
Аның хисләрендә янарга.

...Күпергә инде ерак калмады. Мансур уйларыннан бүленеп, якягына карангалап алды. Тын. Бернинди ят тавыш ишетелми. Һәммәсе үз урынында. Йолдызлар да, ай да. Хәтта күпере дә шул ук. Тик барыбер шикләндерә. Менә хәзер чиный-чиный Актырнак килеп чыгар сыман. Теге телсез адәм дә шунда гына сагалап тора кебек.

Шул чактагы шикелле көтелмәгәндә башы әйләнеп китте Мансурның. Йөзенә салкынча җил китереп бәрде, мизгел эчендә тирә-як томан белән капланды. Килделәр!

Мансур бөтен ихтыяр көчен учына җыйды. Аңа ничек тә үзен кулында тотарга, курку хисен басарга кирәк. Чөнки ул бу очрашуга үзе теләп, үз иреге белән килде, ирек бирүләрен үтенергә килде.

Берара телсез адәмнең шәүләсе күренеп киткәндәй тоелды. Актырнакның чинавы да ишетелде кебек. Мансур Аятелкөрси догасын укып, алып килгән ризыкларын кар өстенә куйды да билен турайтты. Җиңел, рәхәт булып китте. Ул Аллаһы Тәгаләнең мәрхәмәте белән тәненә сихәт килгән Әйүп пәйгамбәр хәлендә иде. Гүя анадан янадан туды.

Өрәге аны таныды! Килде! Тик бу юлы ул хушлашу өчен, аны тынычлыкта калдыру өчен килде!

Икенче көнне Мансур авыл клубында концерт бирде. Аның бик күптәннән болай рухланып, бирелеп, ләззәтләнеп уйнаганы да, җырлаганы да юк иде. Тамаша кылып утырган һәр авылдашына җыр багышлады.

Җәмилә дә, әнисе дә куанышып-шатланышып тыңладылар. Кызы Ләйсән сәхнәгә йөгереп менеп әтисен кочаклап ук алды.

Гаиләгә бәхет кайтты.

* * *

1970 елның язы дәррәү килде. Ике-өч көн эчендә ерганаклар, уйсулыклар, үзәннәр кар суы белән тулды. Тау битләре йөзен ачты. Зәй ярларыннан чыкты, боз калыкты. Тик кузгалырга гына өлгермәде, кинәт

салкыннар китереп бәрде. Аръяк болынына җәелгән су дингезе боз элпәсе белән капланды. Мәктәп ярыннан караганда бөтен җир өсте пыяла җәелгән кебек күренә.

Укучыларны язгы каникулга, гадәттә, ташуга карап чыгаралар. Чөнки мәктәпкә якын-тирәдәге авыллардан да килеп укыйлар. Алдавыч яз бу яктан да исәп-хисапны бозды: каникул башлануга, юл төште.

Мансур белән директор шушы манзараны күзәтеп, яр буенда басып торалар. Зыятдиновның чытык йөзе борчулы күренә. Мансур аны кызганып куйды.

—Бәлкем, каникулны өзеп торыргадыр, Мирза Кәбирович,—диде ул аның хәленә керергә тырышып.

Ә директорның башында бөтенләй башка уй икән.

—Тагын кабатлагыз әле, Җәмилә Нурулловна нәрсәләр әйтте,—диде.

—Муса Сәлахов өч турны да яхшы узды, беренче урынга чыгарга ике генә балл җитмәде,—диде.

—Беренче урында кем икән?

—Казандагы математика юнәлешендәге мәктәп укучысы ди.

Директорның салкын күзләренә җылы йөгерде.

Җәмилә Казанга математика буенча республика олимпиадасына районнан бер төркем укучыларны алып киткән иде. Муса да шулар арасында. Тернәкләнеп китте бит малай. Мансур аны күз уңыннан төшермәде. Әти-әнисе белән дә дуслашып беттеләр. Ара-тирә кунак булып, мунча да кереп кайткалыйлар.

Муса гармунда алдыра алмады. Әмма математикадан талантлы иде. Җәмилә аны шәхси программа нигезендә укытты. Һәм менә нәтиҗәсе. Муса авиация институтына керергә, конструктор булырга хыяллана иде. Үзен исемлеккә теркәп тә куйганнар. Унынчыны әле бетермәгән, инде студент! Мондый бәхет санаулы кешеләргә генә тәти.

—Үзегезнең планнар үзгәрмәдеме соң?

Зыятдинов Мансурга күз кырые белән генә карап алды.

Менә нәрсә борчый икән директорны? Мансур аның кичерешләрен әле хәзер генә аңлап алды. Борчуы һич тә каникулның уңайсыз вакытка туры килүендә түгел икән. Иң сәләтле укытучыларын югалтуына кайгыра икән. Кайгырырлык та шул. Исем-даны бөтен республикага таралган физкультура укытучысы Мөхәммәт Чанышевны Әлмәт спорт техникумына кодалыйлар. Ризалашты. Физика укытучысы Адлер Сафин аспирантурага хәзерләнә. Рус әдәбияты укытучысы Луиза Борһанова Бөгелмәсенә кайтырга җыена. Мансурларның язмышы да ачыкланып килә. Чаллының татар мәктәбендә директор урыны бушый икән. Бу вариант барып чыкмаган очракта да, эш табылачак, диделәр. РОНО мөдире Азат Харисов бик нык ышандыра. Ул да диссертация артыннан йөри, шул сукмакта дуслашып киткәннәр иде.

Чаллыда автомобиль заводы кору турында шаулаша башладылар. ГЭС төзелеше дә шактый кузгатып җибәргән иде бу ком бураны эчендә утыручы аулак шәһәрчекне. Димәк, киләчәге зур.

Мансур шулар турында уйлап алды. Ә директор җавап көтеп, тавыштынсыз гына басып тора бирде. Әйе, соңгы ике-өч ел эчендә мәктәпнең абруе шактый үскән иде шул. Шушы яшь коллективны тотып калуда директорга стратегик сиземләү җитмәде, урынын югалту ихтималы турындагы икеләнүләре өстен чыкты. Мал-туар, хуҗалык мәшәкатьләренә кереп баткан ялагай укытучылар белән бу дәрәҗәне саклап булмаячак, әлбәттә.

—Китү хакында мин сезгә теге педсоветтан соң ук әйткән идем ич инде, Мирза Кәбирович,—диде Мансур.

—Ул чакта барыбыз да кирәгеннән артык хискә бирелгән идек димме?

—Ялгышасыз, Мирза Кәбирович, ул мәсьәлә минем өчен бик

принципиаль мәсьәлә. Сезнен карашны тотсак, татар мәктәбенә кабер казырга гына туры киләчәк.

—Мин дәүләт кешесе, рәсми сәясәтне якларга бурычлымын. Тагын бер тапкыр кабатлыйм, сезгә дә үз карашларыгызны чәчеп йөрмәскә киңәш итәр идем, киләчәк планнарыгызга киртә булуы бар.

Әңгәмә шушы урында өзелде, директорны чакырып алдылар.

Үз халкыңны яраткан өчен, аның киләчәк язмышын кайгырткан өчен Себер китәргә дә мөмкин ич, әй. Зыятдиновның шуна ишарә итүе. Утыз жиденче ел түгел анысы, Себергә үк олактырмаслар. Әмма, директор әйтмешли, юлына киртә салачаклар. Төпченә башласалар, нәсел жепләрен дә селкеп ташлаячаклар, билгеле. Бу кисәтү, һичшиксез, урынлы.

Мансур директор белән сөйләшкәндә үк су буенда соскыч белән балык тотучы кешене күзәтеп торган иде. Озын кунычлы резин итек кигән, кунычлары бот төбенә житеп тора. Соскычын тирәнгә кертеп батыра да, боз арасыннан сөзеп югары күтәрә. Балыклары да күренгәли.

Балык дигәндә, Мансур үзе дә сәпәрәй кеше. Кечкенәдән балыкка йөреп үсте. Дөрес, Агыйдел — Сөн буйларындагы балык бөтенләй башка, затлы балык. Ләкин балык жене кагылган кешегә балыгыннан бигрәк мәзәге кыйммәтрәк ич аның.

Малай вакытта Мансурлар Сөн кузгалганда үз эшләре белән яр читен айкыйлар иде. Балыкның иләс-миләс чагы. Озын, караңгы, ялыктыргыч кыш аларны да мингерәүләтә. Язга таба боз астында кислород азая. Шуңа күрә бөтенләй хәлсезләнәләр. Һич түзәрлекләре калмагач, борыннарын бәке авызына төртәләр. Балык күпләп һәлак булмасын өчен, зур күлләрдә махсус озынча бәкеләр тишелә иде. Балыкны саклыйлар иде. Хәзер генә ул ерткычларча кыралар.

Мансур балыкчы янына килде. Мәктәпнең хужалык мөдире Муллый икән.

—Көн бозылды, балык төпкә ятты,—диде ул,—юкны бушка әвәләү генә.

—Сусаклагычта ничек икән?

—Анда зур корал кирәк.

—Рөхсәт тә итмиләрдер әле.

Мансур астыртын гына елмаеп алды. Чөнки Муллыйның кем икәнлегең бик яхшы белә. Куркып-өркеп йөрүчеләрдән түгел. Кышын рөхсәтсез-нисез пошый да аткалый диләр.

—Иртәгә Казаннан Жәмилә кайтасы, бераз балык юнәтеп булмасмы дигән идем,—диде Мансур,—синең монда мәчелек кенә икән.

Жәмилә балык ярата. Авылда сеңлесе Кларaның кияве Васил белән бергә туры килсәләр, зуррак балык башын чиратка салалар иде.

Муллыйның йөнтәс кашлары жыерылды, бит тамырлары тартышып куйды.

—Мәчелек кенә дип син мине бөтенләй бетереп ташладың бит әле, Мансур дус,—диде ул үпкәләвен белдереп,—юк, алай булмый ул...

—Дөресе шулай булгач, ни дим соң?

—Алайса сөйләшү болай, кичкә яхшыларын фатирыгызга үзем кертеп чыгармын,—диде Муллый һәм китеп тә барды. Аның: "Һы, кара син аны, мәчелек кенә, имеш",—дип мыгырданганын Мансур ишетеп торды. Серкәсе су күтәрми икән, дип уйлады ул, мин-минлеге үзенә күрә генә түгел.

Мәктәптә ул шактый юанды. Ә кайтса, күзенә күренәме дип тора, өй янында аны бабасы Нурулла көтеп тора иде. Гадәттәгечә, биштәрен аскан, шарфы күкрәгенә жыерылып төшкән. Әрле-бирле йөренә. Тагын ни булды икән инде? Чөнки Нурулла йомышсыз йөрмәс, аның һаман саен ниндидер ашыгыч мәшәкате чыгып тора. Булмаса, уйлап таба. Тормышы шуңа көйләнгән. Житмешенче дистәне түгәрәкләп килүче кеше димәссең.

—Нихәл, бабай, нинди жилләр ташлады?—дип күреште Мансур.

—Да-а, канәт, Әлмәткә базарга килгәнием, күреп цыгыйм дидем.

—Базарың ундымы соң?

—Да-а, вак-төяк, йөз штук цалгы алдым. Кәрәмнәргә кертеп калдырдым.

Киявенен сорау бирәсен белгәнгә күрә Нурулла тиз генә өстәп тә куйды.

—Пецән вакытында хакы ике-өц тапкыр арта анын. Мунца түбәсенә шифер кирәк бит. Җәйгә өлгертәсие.

Мансур барысын да аңлады. Йөз чалгы дигәне чын авантюра, үзенең бәһасен күтәрү өчен генә. Сүзе хак булган очракта да мәгънәсез гамәл. Чөнки авыл кибетләрендә чалгы—үтмәс товар, анын белән буа буарлык. Килүенең төп сәбәбе, чыннан да, шифердер, мөгаен. Бераз жылынып алгач, ул аны тишәчәк әле. Шифер юнәтеп бир әле, кияү, диячәк, акчасын рәтләнгәч түләрмен, диячәк. Ул моны акча сорамаячакларын белеп әйтә. Шуңа күрә ышанычы зур. Мансур инде анын хәйләсен сүз башлауга тотып ала.

Хатын-кыз булмаган оя—ташландык оя. Бер атна эчендә Мансурларның фатиры да жанын, жылысын, рухын югалтты. Болай караганда, барысы да урынында кебек. Тәртип, һәр нәрсә ялт итеп тора. Гадәттә, кинофильмнарда әлеге ятимлекне юылмаган савыт-саба өемен күрсәтеп дәлилилләр. Янәсе, күрегез, ир-ат нинди булдыксыз, артыннан жыя да белми. Мансур бу категориягә керми. Тулай торакта яшәгән студент урын-жирне дә жыештыра белә, бәрәңгесен дә әрчи, ашарына да пешерә, хатын-кыз жилкәсенә генә салынып ятмый. Шулай да өйне өй итеп тотучы зат барыбер хатын-кыз. Аннан башка йортның коты кача.

Ләйсәнне дә алырга вакыт житеп килә икән. Бакча унайлы, күршедә генә. Кызы аны киенеп-ясанып көтеп тора иде инде. Бабаң килде, дигәч бик сөенде. Килем-китемне бик ярата үзе.

Урамда Муллый очрады. Кулында кәржин. Авызы ерык.

—Менә мәчегезгә күчтәнәч,—дип кәржинен Мансурга сузды.

—Гафу ит, Муллый абый, телемнән уйламыйчарак ычкынды, синең кебек олы балыкчыны кимсетә торган сүз әйтелде,—диде Мансур.—Әйдә, өйгә керәбез, үпкә-сүткәлерне дә юып төшерербез.

—Юк, юк, булмаганны,—дип Муллый кулларын чәбәләде,—ашыгам, мине көтеп торалар анда. Бигәйбә.

—Башка вакытта алайса.

—Үз кешеләр бит, ничек тә бер шартын китерербез әле.

Балыгы шактый күренә. Молодец, вәгъдәсендә тора белә икән, дип куанды Мансур, Җәмилә сөенер инде.

Балыклары күп кенә түгел, эре дә иде Муллыйның. Симездер үзләре. Хәлбуки, елга балыгы кышны авыр үткәрә, уылдык туплаганчы әле аңа шактый вакыт кирәк. Күрәсең, нефть зилзиләсе мутан кошкортлар белән бергә, мутан балыклар да тудырган.

Ләкин сәбәбе бик гади булып чыкты. Эчләре тулы суалчан. Авыру балыклар. Бу да нефть бәләсе. Суга кислота, тоз эремәләре әләгүдән барлыкка килә торган сырхау.

Муллый боларны белә, билгеле. Мәгәр мут кеше икән. Тәки "мәчелек"нең үчен кайтарды. Сиам песие белән бер икән, ачуын алмыйча тынычланмый. Дәгъва дә белдерә алмыйсың, белмәдем генә, диячәк. Әле ул урлап тотылган балык бит!

—Нәстә булды, канәт, кемне сүгәсең?—дип Нурулла кухняга чыкты.

—Әнә, теге жүнсез авыру балыклар китергән.

—Пешкәц зыяны юк анын, кияү, хафаланма бер дә.

—Күрәләтә авыру балык ашап булмый ич инде.

Нурулла шалкандай шома башын кыңгыр салып, уйланып торды. Күренеп тора, ниндидер план кора. Ул үзе дә Муллый сынары.

—Да-а, канәт, авыру балыкны пажалый ярамыйдар шул ашарга,—дип, Нурулла кәржинне кулына алды. Мансур аңа карап куйды. Ләкин сүз әйтмәде.

Ишектә Ләйсәннең чәчби башы күренде.

—Бабакай, мульти-пульти, тиз бул,—дип ашыктырды бабасын.

— Туктатып тор, кызым, мин балыкларны гына түгеп керәм.

Ләйсән көлеп җибәрде.

—Син нәрсә, бабакай, мульти-пульти машина түгел ич ул туктатырга. Теликны сүндерсәң дә туктамый ул.

Нурислам өйдән чыгуга, туп-туры ашамлыклар кибете янына титаклады. Көндез ул анда картка-сарткаларның сату сатып торганнарын күргән иде. Шунда барып басты. Вәкарь белән генә тамагын кыргалап, як-ягына каранып алды да:

—Кемгә балык, балык сатам!—дип сөрән салды.—Әле генә тотылган эсбижи балык. Карагыз, куйрыклары селкенә. Ул җайлап кына уң аягы белән кәрҗингә кагылып алды.

Алыш-бирештә иң мөһиме, тәвәкәллек. Авызыңны ачарга куркып торсаң, хикмәт чыкмасы көн кебек ачык.

Акча бездә кеп тегел,
Кирәгенә жук тегел,
Килә тора, китә тора.
Кирәгенә житә тора.

—Балык, дарым бирәм, кем беренце?

Үткән-сүткән аның янына җыелды. Мондый тамаша һаман булып тормый.

—Йөгәненнән ычкынма, бабай, милиция колагыңны борыр,—дип кисәтте берсе.

—Төкерә ул милициягә, шулаймы, бабай?

Нуруллага ничек тә тизрәк балыкны җилгәрергә кирәк.

— Балык, эсбижи балык...

Кемдер хакы белән кызыксынды. Китте сатулаш.

Озын буйлы, ак чырайлы бер яшь кеше бәхәскә нокта куйды.

—Хакыннан тормыйм, кәрҗине-ние белән алам,—дип картка акча төртте.

Йөз-кыяфәте, килеш-килбәте күркәм иде сатып алучының, киемнәре дә ыспай. Бер-бер түрә булырга тиеш бу, дип сөенде Нурулла. Шуңа күрә акчасын санап тормады, йомарлаган килеш кенә кесәсенә шудырды.

Кәефе шәп иде бабакайның. Һич уйламаганда, тешен ерып керде бит бу акча, унган юлга чыккан икән, шиферы да булып куймагае әле. Бер тәгәрәсә, тәгәри ул арба...

Шушындый хозур күтәренкелек белән Нурулла киереп фатирның ишеген ачты һәм катып та калды. Аннан соң, ишекне буташтырдым ахры, дип артына чигенде. Мансурны күргәч кенә икеләнеп калды. Теге ыспай егет тә шунда. Янәшәсендә каратут йөзле чибәр хатын.

—Әйдүк, сәүдәгәр, түргә уз,—дип иреннәрен кыйшайтты Мансур.

Каптым, дип шыр җибәрде Нурулла, барысы да очты, шифер да...

—Бик булган сатучы икәнсең, кода бабай,—дип ыспай егет аның җилкәсеннән кагып куйды,—сайрый гына, алмас җиреннән алырсың.

—Йөрешмәгәч шулай була ул,—дип чибәр хатын да сүзгә кушылды,—адәм тәганәсе, коданны таныма инде.

Нурулла кергәнче бик житди сөйләшү булганга ошый. Кунаклар аны яклый ахры, Мансурның гына күзеннән очкыннар чәчелә. Киявен мондый хәлдә беренче күрүе иде. Үзе дә инде, нәфсесен тыя алмады... Анысы шулай инде шулаен, шартлап торган эре балыкларны ничек чүплеккә түкмәк кирәк? Ризык ич!

—Суалчанлы балык белән кешеләр агуланса, ни килеп чыгасын уйлап карарга иде, бабай,—дип сукрануында булды Мансур,—өйрәнгәнсең шалтай-балтай йөрергә, үгез үлсә—ит, арба ватылса—утын.

—Ярар инде, абый, баш ватылып күз чыкмаган. Кая ул безгә, пәйгамбәрләрнең дә аяклары тайгалый, ди.

Чибәр хатын, рәхмәт төшкере, һаман аны яклап маташа.

—Әйдә, кода бабай, танышыйк,—дип кулын сузды чибәр егет,—мин Васил булам, менә бу сылукайның ире.

—Мин Клара,—диде яшь хатын,—киявеңнең бертуган сеңлесе. Лениногорскида яшибез.

—Җәмилә апа кайтуына кучтәнәчнең кәттәсен алдым дип сөенгән идем, булмады,—дип офтанды Васил.

* * *

Икенче көнне җыйнаулашып аэропортка Җәмилә белән Мусаны каршы алырга бардылар. Нурулла канәт, минем һәр сәгатем йөз тәңкә тора, дип Әлмәт базарына тайды.

Мансур башта Җәмиләне танымыйча торды. Артистка! Алсу Гайнуллиналарың бер якта торсын. Хатынының Казанда язгы киемнәр юнәтәсен бик яхшы белә иде, югыйсә. Бергәләп сөйләшеп хәл кылдылар. Әмма Мансур бу яңаруны болай ук күз алдына китермәгән иде.

Язбикә үзе дә хатын-кызга Зөһрә сылуның затлы шәлен яба. Хатын-кыз күзгә күренеп нурлана, мөлаемлана, чибәрләнә, атлау-йөрүләре үк үзгәрә. Бөреле агачтай эче-тышы мәхәббәт суты белән тула. Ә зәвыклы кием бу гүзәллекне купшы ефәккә төрә.

Җәмиләнең өстендә чия төсле пальто. Буй-сынына сыланып тора. Муенында озын ак шарф. Атлаган саен жилфер-жилфер килә.

Тимер капка ачылуга, Ләйсән әнисенең кочагына атылды. Шундук яңалыкларны да житкерә башлады.

—Әтием бабакайны ачуланды. Васил абый сиңа балык алган иде. Клара апа чыгарып түкте...

—Җитәр, әләкче, безгә дә ирек бир,—дип Мансур Җәмиләне үбеп алды, Мусаның кулларын кысты.

—Котлыйм, Муса! Бик шатмын. Бөтен мәктәп сине көтә.

—Җәмилә апага рәхмәт,—диде Муса.

—Булдырды Муса, бик күп мактанчыкларның борынына чиртте, —диде Җәмилә.—Бу хакта иркенләп сөйләшербез әле. Өйгә кайтыйк, кунаклар да бар икән.

—Без кичә кунак булдык инде, Җәмилә апа, кайтып баруыбыз, үзеңне юл уңаеннан котларга дип кенә сугылган идек,—диде Клара.

Ирләр машина янында кайнашкан арада Клара жингәсен читкәрәк алып китте. Чыш-пыш килеп гәпләшеп тордылар. Әлбәттә, кием турында. Клара ательеда эшли, модельер, кием-салымның рәтен белә. Тик башкала модасы башкала модасы шул инде. Ихтыяҗ булгач, модасы да камилләшеп кенә тора. Мода белән бергә модельер үзе дә үсә. Монда андый шартлар юк. Нефтьчеләр киемгә талымлы түгел. Чыдам булсын, җылы булсын — башкасы аларны әллә ни кызыксындырмый.

Клара зарларын бушаткан арада Лениногорск автобусы кузгала ук башлады. Чак-чак өлгерделәр. Икенче рейсны көтәргә кала иде. Алар һәрвакыт шулай. Пошмаслар. Соңгы чиккә кадәр юаналар да, автобус китеп бара. Янә кунарга калалар. Шуна күрә сеңелләрен озатып жибәрмичә Мансур машинасын кабызмады. Инде менә үзләре генә калды. Ләйсән әнисенең алдыннан төшеп тә карамый. "Сиам игезәкләре булдыгыз тәки",—дип мыскыллап көлде Мансур. Бәхәсләшергә дисәң, Ләйсән ясап куйган кебек. Әтисенең сүзенә күзләре тасрайды.

—Юк, әтием,—диде ул төкерекләрен йота-йота,—әнием әнә нинди дәү, мин кечкенә. Кара, кара, үлчәп кара.

—Үзең мин дәү үстем дигән буласың,—дип ирештерде Мансур кызын.

Ләйсән хәйләкәр төлке кебек, көймәсе комга терәлгән вакытта шундук сүзне икенчегә борып жибәрә. Мусага борылды да:

—Муса син әниеңә нинди бүләк алдың?—диде.

— Муса түгел, Муса абый, — дип төзәтте аны Җәмилә.

—Мин үзем бүләк,—диде Муса.

—Мин дә бүләк,—дип элэктереп алды кызчык егетнен бу сүзләрен. Көлештеләр.

Ләйсән кич буе әнисенең итәгенә ышкылып йөрде. Мансур аны берничә тапкыр яткырырга тырышып карады. Тынламый, сезнең белән йоклыйм, ди. Ахыры сүзен сүз итте. Үзе бик тиз йокыга талды. Мансур аны ятагына күчереп салды.

Бу төн бәхетле гаиләнең Кадер киче кебек йолдызлы төне булды. Ул инде башка бервакытта да кабатланмаячак. Тәкъдир аларның язмыш дәфтәренә үзенең ачы тамгасын суккан инде.

* * *

Мусаның олимпиадада урын алуы Җәмиләгә дә дан китерде. Газеталарда аның турында мәкаләләр басылып чыкты. Докладларда аның исемен телгә ала башладылар. РОНО аның эш алымына багышлап, методик бюллетень чыгарды. Бездә шулай бит ул, мактасалар күккә чөяләр, яман телгә эләксән, изеп ташлыйлар.

Җәмилә талантлы укытучы иде. Ихтимал, математиканы фән буларак, аннан тирәнрәк тә, төплерәк тә белүче укытучылар бардыр. Әмма шул белгәненне балаларга җиткерү, аларда кызыксыну уяту, мөстәкыйль эзләнүгә этәрү сәләте һәр белгечкә дә бирелмәгән. Бу инде мөгаллимлек таланты. Ләкин яртысы гына. Мәсьәләнең тагын бер мөһим ягы бар. Монысы укучыларның күңеленә сукмак салу. Яраткан укытучының гына фәнен ярата лар. Абруй мәктәп укытучысы өчен төп шарт. Мансурга, мәсәлән, абруй жыр-монга һәвәслеге аша килде. Җәмилә гимнастика, бию осталыгы белән үзенә каратты.

Укучылар белән уртак тел таба белү, аларны үзең белән тиң күрү, гаделлек...—әлеге сыйфатлар укытучының шәхси образын тудыра.

Сүз дә юк, укытучыга балалар куйган билге һәрвакытта да житәкчеләр, түрәләр куйган билге белән туры килеп бетми. Әйтик, өстәгеләрнең Җәмиләгә дә дәгъвасы бар. Мәсәлән, яшьләр газетасына биргән интервьюсы РОНО мөдиренә ошамаган. Искиткеч рәсми, эче-тышы идеология белән тулган бу түрә дәрескә керсә, Пифагор теоремасыннан да марксизм тәгълиматын эзләнә башлый.

—Җәмилә Нурулловна, сез совет педагогикасының асылын аңламыйсыз икән ич,—диде ул зур хафа белән,—гажәпләнәм, бу фикерегезне редакция ничек үткәрде икән?

—Нинди фикер, Ризван Сабирович?

—Совет илендә, Җәмилә Нурулловна, сәләтсез, талантсыз балалар юк. Аларның һәрберсе математиканы да, химияне дә, гуманитар фәннәрне дә үзләштерергә сәләтле. Өйрәтә белергә генә кирәк. Ә сез бу сәләт аерым укучыларга гына бирелә дип тәкърарлыйсыз.

Җәмилә мөдиргә каршы төште.

—Ишле талант була алмый, Ризван Сабирович, бу күптән исбат ителгән хакыйкать ич инде. Берәүләргә төгәл фәннәр жиңел бирелә, икенчеләргә гуманитар фәннәр...

—Сезнең кандидатураны "Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре" исеменә тәкъдим итәбез дип исәпләп тора идек, Җәмилә Нурулловна,—диде мөдир бәхәскә кермичә, —белегез, әлеге интервьюның тискәре роль уйнавы да бар.

Җәмилә өчен бу яңа хәбәр түгел иде. Казанда чагында ук шәкертләре беренче—өченче урынга чыккан мөгаллимнәр мактаулы исемгә тәкъдим ителәчәк, дип әйткәннәр иде. Мөдир, күрәсең, аны үз инициативасы итеп күрсәтмәкче була. Шул ук вакытта өстеннән жаваплылыкны да төшереп куя. Янәсе, андый-мондый хәл килеп туса, гаеп фәкать үзегездә генә.

Мөдирнең каркылдавы рас килде. Ләкин ул кисәткән яктан түгел.

Җәмиләнең кандидатурасын мактаулы исемгә тәкъдим итү җыелышы мәктәптә тыныч та, тиз дә узды. Министрлык кушуы буенча дигәч, хәл ителгән инде, диделәр. Ләкин бу ялган тынычлык кына булган икән. Берәр атна уздымы-юкмы, Сабиров РОНОга чакыртып алды. Мөдир аны каршысына утыртты да, озак кына чекрәеп карап торды. Шуннан соң гына дәүләткүләм бик әһәмиятле сер чишкәндәй: "Җәмилә Нурулловна, сезгә тиз арада партиягә керергә кирәк",—дип пышылдады.

Җәмилә телсез калды. Чөнки ул бу чакыртуның сәбәпләрен ачыкларга тырышып, әллә нинди фаразларга бирелде. Тик РОНО мөдиренең аны партиягә кодалау турындагы уй башына да кереп карамады. Бу—бер. Икенчедән, укытучыларны анда бик алырга да тормыйлар әле. Мәктәптә, әнә, теләүчеләрне чиратка куйдылар хәзер. Моның өчен башта нефтьчеләр, төзүчеләр, колхозчылардан биш кешене партиягә җитәкләп алып килергә тиешсең. Ә алар атлыгып тормый. Гади халыкка моның кирәге юк. Партия ул югарыга үрмәләүчеләр өчен зарур. Җәмиләнең исә андый ниятләре юк. Мансурының канаты астында тыныч кына, назланып кына, үз кадерен үзе белеп кенә яшәү, балалар тәрбияләү—менә шул аның шәхси тормышына куйган максаты. Эшен белә, ярата—тагын ни кирәк?

—Ризван Сабирович, мин әлегә бернәрсә дә аңламыйм,—диде Җәмилә гаепле кеше сыман. Чөнки тегесе һаман күзен алмый карап тора иде.

Ябыктыр үзе, яңаклары эчкә батып кергән. Күлмәк якасыннан озын муены гына шакаеп тора. Бакчадагы карачкы инде. Җәмилә ирексездән, ничек моңа хатын чыкты икән, дип уйлап куйды.

Мөдир теле белән кибешкән иреннәрен ялмап алды.

— Аңламасагыз, хәзер аңлатам. Шәһәр комитетына сезнең мәктәптән имзасыз шикаять җибәргәннәр. Җәмилә Әмиржанованы мактаулы исемгә тәкъдим итү белән килешә алмыйбыз, дигәннәр. Эш стажының азлыгы белән килешкән очракта да, партиясез укытучыны шулай мәртәбәләү КПССка тап төшерү булыр иде, дигәннәр. Коллективта лаеклы партиецлар аннан башка да күп, дигәннәр. Шикаятькә имза куймауның сәбәбен дә аңлатканнар. Ире завуч, белсә, безне эзәрлекләячәк, дигәннәр. Горком миннән аңлатма таләп итә. Так што... Ә партия киләчәк өчен...

Җәмилә урынынннан сикереп торды.

—Минем ул исемне сорап гариза биргәнем юк, Ризван Сабирович!

Шул сүзләрне сиптерде дә, шак-шок басып кабинеттан да чыгып китте.

Сабиров аптырап басып калды. Нишләргә соң аңа? Ул ике ут арасында. Бер якта—министрлык, икенче якта—горком. Кичә министрлыктан шалтыратып кисәттеләр, документларыгыз ике көннән министр өстәлендә булырга тиеш, диделәр. Верховный Советка үзебез тапшырабыз, диделәр. Актив җыелышы булмакчы икән, министр шунда үзе бүләкләрне тапшырмакчы ди. Шуңа ашыктыралар.

Шуннан соң ук аны горком инструкторы чакыртып алды. Бик төксе сөйләште. Әмиржанова документларына секретарь кул куймаячак, мәсьәләне ачыклап, чара күрегез, диде.

Әлегә секретарь Казанда. Сабиров аны көтә. Җәмиләне чакыртуының сәбәбе шул, әлеге дә баягы, үз өстеннән җаваплылыкны төшерү. Чөнки бу эш министр белән бәйле. Югыйсә, төкермәс тә иде, беткән ди анда Әмиржановалар. Министрның тәкъдимен үткәрә алмасаң, эшең белән дә саубуллашуың ихтимал.

Телефон челтерәвеннән Сабиров дерт итеп китте. Кызыл телефон. Горкомнан!

—Ризван Сабирович, Әмиржанованың документларын хәзер үк горкомга китерегез,—дип әмер бирде әлеге инструктор.

—Шикаять мөнәсәбәтендәме?—дип сорады мөдир.

—Нинди шикаять? Намуслы кешегә пычрак атучы ул бушкуыкларның

үзләрен фаш итәргә кирәк. Укытучылар арасында тәрбия эше начар куелган. РОНО бу җәһәттән пассивлык күрсәтә.

Халык мәгарифе хезмәткәрләренен төбәк киңәшмәсенә хәзерлек йөзеннән өлкә комитетыннан райкомнарга, горкомнарга күрсәтмә килеп төшкән иде. Анда олимпиада, бүләкләү мәсьәләләре дә чагылыш тапкан иде. Инструктор партия колы, нәрсә кушсалар, ул шуны үтәргә тиеш.

—Ни бит...—үзегез,—дип мыгырданды Сабиров моннан ике генә сәгать элек булган әңгәмәне исенә төшереп.

—Секретарь документларыгызны көтә!

* * *

Төбәк киңәшмәсе Әлмәттә узды. Нефтьчеләр сараенда. Җәмиләне президиумга сайладылар. Кара костюмнан. Ак кофтасының челтәрле якасы аз гына ачык. Калын толымнары баш чүмеченә урап куелган.

Башкалардан үзенең өстенлеген тойган хатын-кыз—бәхетле хатын-кыз. Бу аңа мөлаемлык кенә түгел, ышаныч, тәкәбберлек тә өсти. Мондый хатын-кыз теләсә-нинди ир-атны да үз кубызына биетә ала. Җәмилә шундый иде бүген.

Президиумнан бөтен зал күренә. Ул карашы белән таныш йөзләрне эзләде. Берән-сәрән күренәләр. Көнләшсеннәр, әйдә! Хәер, олимпиадада Муса бүләкле урынга чыкмаган булса, үзе дә йөзләгән, меңләгән укытучылар шикелле үк күләгәдә калган булыр иде. Министр тәвәккәл кеше икән, сүзендә тора белә. Яшьләрне күтәрергә тырыша. Бу исем белән дә күпме мәрәкә булды. Өмете өзелгән иде инде. Ә хәзер, әнә, президиумда утыра.

Җәмилә игътибарын трибунага юнәлтте. Анда кулларын болгый-болгый төп шикелле бер юан кеше сөйли иде. Җилпенепме-җилпенә. Аякларының очларына баскан, гуя очып китәргә җыена. Оратор Америка империализмының тетмәсен тетә иде. Тик бу тема Җәмиләне кызыксындырмый. Методик секцияләр буласы. Профессиональ сүз шунда булачак. Ул үзе дә чыгыш ясарга җыена.

Уйлары элекке эзгә төште. Чөнки Гайшә исемле сабакташын абайлап алган иде. Йөзе кара янган, күзләре белән ашап бетерер иде. Моңа шатланды гына Җәмилә. Ник дисән, алар арасында инде күптән кара шәүлә ята. Дусты Мөнирәнең егетен үзенә каратмакчы булып йөргән иде Гайшә. Бозылу шуннан башланды. Төскә-биткә матур үзе. Буе озын, зифа. Кара чәчле, кара кашлы. Әйбәт киенә. Чын ясау татар кызы. Тик бер-ике озатуга егетләр читләшәләр иде. Соңыннан, авызы сасы, дип гайбәтен саталар. Шунадыр инде, исле майга коена гына иде. Кеше арасын бозарга бик маһир. Теге вакытта кибеттә чират тора-тора бер банкы балын күтәрешеп кайткан өчен Мансурны да шул сәбәпле утлы табага бастырган иде. Шуннан соң Гайшә озак та тормады Әлмәткә күченеп китте.

Җәмилә министрга елмаеп нидер әйтте. Министр да аңа елмаеп җавап бирде. Үзе астыртын гына Гайшәне күзәтте. Бөтенләй бөгелеп төште бит. Җәмилә аңа карап үзенә бер канәгатьләнү кичерде.

Һай, бу хатын-кызны!?

Мактаулы исем турында таныклык тапшырганда Гайшә күренми иде инде.

Кичен ресторанда банкет уздырдылар. Җәмилә бу мәҗлестә дә каш астында күз булды. Түбәтәй аслары чыланган мәгариф түрәләре бертуктаусыз биергә чакырдылар. Башта бу хәлгә Мансурның саруы кайнаган иде дә, аннан кул селтәде. Кан кызган, күңел дә күкнең җиденче катында. Һаман "ярамый" кысасында әвәләнгән укытучы халкына бераз йөгәннән ычкынып алса да гөнаһ булмастыр ла.

Хезмәт ит тә мактан, уйнап-көл дә шатлан. Кымын куймадылар мәҗлестә катнашучылар. Биеделәр, җырладылар, шаярдылар, көлделәр.

Телләре дә, үзләре дә тозактан ычкынды.

—Мин нинди бәхетле,—дип Җәмилә иренең муенына асылынды. Алар урамда иде инде.

—Эгоист син, Җәмилә, Сальери сынары. Ә мине кая куясың?

—Теләсәң нәрсә әйт, мин бүген эгоист! Күрдеңме, хатыныңны уч төбендә генә йөрттеләр...

—Җәмилә, тукта! Тоясыңмы күктән моң иңә. Тыңла, тыңла! Ташкын булып иңә.

—Бар дөнья шатлык диңгезенә чумган, Мансур!

—Ә ул диңгезнең уртасында без... Тыңла!

Гөлләремнең ал чәчәге,
Таң нурында балкыды.
Мәңге сүнмәс, һич сүрелмәс
Сөюемнең ялкыны.
Ай ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.

* * *

Төрле кешегә бәхет төрле вакытта килә. Берәүләр аны балачакта кичерә. Икенчеләргә яшьлектә елмая ул. Гомер уртасына да туры килә. Картлык бәхете үзе бер хозурлык. Бәгъзеләрнең бәхет кошлары исә бу дөньядан киткәч кенә куна. Андый бәхет тә бар. Мәхәббәтне бәхеткә саный кайберәүләр. Әйе, мәхәббәт илаһи хис. Тик чын мәхәббәт бервакытта да бәхетле тәмамланмый. Ул бик тиз янып бетә.

Шулай, бәхет тә, мәхәббәт тә озын гомерле була алмый. Аларны теләк, тырышлык белән генә дә озынайтырмын димә. Бу — тәкъдир. Ә тәкъдир кешегә буйсынмый. Бәндә сөйләр, тәкъдир көләр, ди.

Мансурлар яшь әле. Аларның тәкъдир, җан, әҗәл турында уйлый торган чаклары түгел, гөнаһ җыя торган чаклары. Тормышлары башланып кына килә. Алда ал җилкәнле ак кораб. Ул сине теләгән вакытыңда Хыял дигән гүзәл утрауга очыртып кына илтеп куя. Хыял яшьлекнең аерылгысыз юлдашы. Ул аңа зур өметләр баглый, чын күңеленнән ышана, барысы да тормышка ашар сыман тоела. Хыялның хәмер кебек алдавыч агу булуын аңлау өчен тетрәнүләр кичерергә кирәк шул. Мансур да инде күрәсен күреп, югалтасын югалтып бетергәч кенә маңгайга язылган язмышны тир белән бергә сыпырып төшерү мөмкин түгел икәненә төшенде. Бәндәнең тәдбире (чарасы) Алланың тәкъдиреннән уза алмый икән.

Әлеге тәгъбирне балачакта ишеткән иде. Шулар барысы бергә бүгенгедәй күз алдына килеп басты. Әбисе Шәмсебәдәр бик тәкъва зат иде. Һәр дини бәйрәмдә бер мосафир мулла куна килеп Коръән укыр иде. Затлы, абруйлы нәселдән дип сөйлиләр иде ул мулла турында. Революциядән соң сөргенгә сөргәннәр. Архангел урманнарында агач аударган. Хәзер мосафир булып йөри. Өлкән яшьтә булса да, бик мәһабәт күренә. Затлы нәселдән дигәне хактыр, күрәсең. Тавышы да шул затлылыкка тиң иде. Йомшак тавыш, күгәрчен гөрелдегедәй гөр-гөр килеп тора. Пәйгамбәрләрнең тәрҗемәи хәлләрен аның кебек мавыктыргыч итеп сөйләүчене Мансур башка очратмады. Дөрес, ул әкият итеп кабул итә иде аларны. Көймәдә тибрәлгәндәй тыңлый-тыңлый йоклап киткәнен сизми дә кала иде.

Юк, мулла "әкият" кенә сөйләми иде, билгеле. Әнә, әлеге тәгъбир шул вакытта күңеленә кереп калган ич. Димәк, сендерерлек итеп җиткерә белгән мулла абзый.

Ул Ризаэддин Фәхреддин, Шиһап Мәржани, Муса Бигиевларны еш телгә ала иде. Бу дин әһелләре искелеккә ябышып ятучы кара кадимчеләрдән радикал карашлары белән аерылып тора. Боларны Мансур

сонынннан белде. Муллабыз шулар кыйбласын тоткандыр, мөгаен. Югыйсә, дин турында хатын-кыз белән гәп корып утырмас иде.

Бервакыт әбисе кемнедер яклап: "Язмыштан узмыш юк, шулай язгандыр инде",—дигән иде. Муллага бу ошамады.

—Үзеннең булдыксызлыгыңны язмышка ягарга ярамый, килен,—дип үзенчә тәкрарларга кереште.—Әҗәлдән башка бар нәрсәгә дә чара бар. Язмышка сылтау итеп дөнья гамәлләрендә кимчелек кылу үзе бер гөнаһ. Һәрбер кеше үз кулыннан килгән кадәр эш эшләргә, байлык вә һөнәр һәм сәнәгать тугрыларында милләтнең күтәрелүенә ярдәм кыларга тиешле.

Әбисе исә:

—Хәзрәт, бу сүзләрегезне ахирәт мөнәсәбәтендә ничек анларга соң?—дип, килешеп бетмәвен белдерде.

—Ахирәт сәгадәте дөньяны ташлауда түгел, килен, бәлки ахирәтне һәм дә дөньяны бәрабәр алып баруда. Аллаһының төп биләмәсе—җан, рухият. Кешене ризык йөртә, тәкъдир соңгы юлга озата.

Мансур бу теологик фәлсәфәнең мәгънәсен үзе башыннан үткән тетрәндергеч хәлләрдән соң төшенде. Гади дә, анлаешлы да: яшәү—әҗәт, үлем—бурыч. Соңгысыннан котылу юк. Ә марксизм бу шәхес өчен бик тә зарури мәсьәләләрне уратып кына уза, белмәмешкә салыша. Хәлбуки, яшәүнең асылы нәкъ менә шуннан гыйбарәт тә.

Әлегә аларны ризык йөртә. Әмма язмыш яшене җир тетрәве шикелле уйламаганда-көтмәгәндә китереп суга икән...

Җәмиләнең бервакытта да сәламәтлегенә зарланганы булмады. Хәтта томау төшкәнен дә хәтерләми. Грипп котырынган чорларда мәктәптә математиклар арасында еш кына бер үзе калгалый иде. Классларны куша-куша берьюлы дүртәр сыйныфта дәрес үткәргәне бар. Спорт белән шөгыльләнә, һәр иртәдә салкын су белән коена. Нәсел-нәсәбе таза. Ул да сәламәтлегеннән риза булмаса, тавык көләр.

—Әтинең кабыргасы корычтан коелган булган,—дип шаярта иде үзе. Һәм...

Елга бер мәртәбә укытучыларның үпкәләрен рентген нурлары белән яктыртып алалар иде. Үпкә авыруы йокмы, балаларга зыян салырлык түгелме?

Бу юлы хатын-кызларны гинекологка да керттеләр. Гинеколог институттан соң беренче елын гына эшли иде әле. Яшь. Җәмилә табибәнең озаклап тикшерүен, җентекләп сорашуын тәҗрибәсезлегенә сылтады. Аны бу минутта кызыкайның туфлие кызыксындыра иде. Очлы башлы "лодочка" дип йөртелә торган яна фасонлы түфлиләр. Хатын-кызларның хыялы. Кибетләргә килеп житми алар, түрә бичәләре базада ук үзара бүлешеп бетерәләр. Җәмилә дә бик кызыга иде. Шуңа күрә түзмәде: "Түфлиләрегез бик килешле",—дип комплимент та әйтте. Анын уенча, кыз ачылып китеп, бу модалы аяк киемен кайдан алуы турында сөйләргә тиеш иде. Әмма ул тикшерүен дәвам итте. "Авырту сизмисезме?—" дип Җәмиләнең күкрәгенә баса-баса интектереп бетерде. Өстәл янына барып утыргач, зур зәңгәр күзләре белән Җәмиләгә текәлеп:

—Сез абортка еш йөрисезме?—дип кызыксынды.

Җәмиләнең сагыз кебек ябышкан бу кызга чын-чынлап ачуы чыкты.

—Шәхеснамәмнән карагыз, ясаткан булсам, анда теркәлгәндер,—диде дорфа гына.

—Шәхеснамәгездә андый язу юк, бәлки, башка урында...

—Теркәлмәгән икән, димәк, юк!

Җәмилә табибка дөресен әйтергә базмады. Чөнки моннан бер ел элек Әлмәттә танышлары аша яшертен генә бер аборт ясаткан иде. Ул аны Мансурга әйтмичә эшләде. Чөнки Мансур рөхсәт итмәячәк, инде шактыйдан Ләйсәнгә энекәш кирәк, дип колак итен ашый иде. Ә ул икенче баланы бер урында ныклап төпләнгәч кенә табармын, дип ниятләнеп йөри.

—Сезнең сул як күкрәгегездә төер бар,—диде табибә,—менә юллама, Бөгелмәдә яхшылап тикшертергә кирәк...

Күкрәктәге төерне табибә сыйпап алуда ук тоемлап алган иде. Шуңа күрә пациент белән житди булырга тырышты. Күкрәктәге төер бик куркыныч нәрсә. Чынлыкта ул яман шешнең башлануы дигән сүз. Моны инде белмәгән хатын-кыз юктыр да, мөгаен. Уттан курыккандай куркалар бу сырхаудан. Җәмиләнең дә сыгылып төшүен, күз яшьләрен көткән иде ул. Ни гаҗәп, пациент бу мәгълүматны кирәгеннән артык тыныч кабул итте.

—Иртәгә Бөгелмәгә барасым бар, сугылып чыгармын,—дип юлламаны алды да, хушлашмыйча да бүлмәдән чыгып китте.

Табибә авыр сулап куйды. Беләсеңме икән, чибәр апа, алда үзеңне нинди газаплар көткәнен? Кызганам мин сине, әмма ярдәм итә алмыйм. Шулай ук турысын әйтергә дә хакым юк. Болай да үземне дөрес тотмадым ахырысы, көләчрәк булырга кирәк иде. Бәлкем әле борчылырга да кирәкмидер? Күкрәктә гади шешләр дә була. Анализсыз аны тәгаен гына билгели алмыйсың.

* * *

Җәмилә табибәнең сүзләренә ышанмады. Сөйли шунда, чикерткә, институтны танышлык белән бетергән берәр түрә кызыдыр әле, дип үз-үзен юатты. Чир иң элек кешенең йөзенә чыга ул. Сызлана, кәефсезләнә. Ә аның бернинди дәгъвасы да юк. Җир шарын йөгереп әйләнергә дә көче бар әле аның.

Ул юл уңаенда кибеткә кереп, белгән сатучылары аша чыгарылыш кичәсенә күлмәк тектерү өчен тукыма алды. Алданрак хәзерләнү хәерлерәк.

—Җәмилә, сез һаман шат күңелле, көлеп-елмаеп кына йөрисез. Сезнең бернинди борчуларыгыз да юктыр, әйеме?—диде сатучы хатын соклануын яшермичә,—күз генә тимәсен. Фатир алсак, алла боерса, мин дә шулай авыз ерып кына йөрер идем.

—Андый шарт куйма, Алсу, фатирдан соң, белеп торам, әпититегез икеләтә артачак. Машина дия башларсыз, дача...

—И-и, көлдермәгез әле, Җәмилә, машиналык акчабыз булса, Казанда йорт салып керер идек.

—Менә-менә, әйттем бит. Казаннан соң Мәскәү...

Сатучылар чырык-чырык көлештеләр.

Җәмилә ничек кенә битараф булырга тырышмасын, шеш турындагы уй сукыр чебен кебек барыбер үзенә керер тишек таба иде. Кичкә таба ул аны тулысы белән үз кочагына алды. Ашарга пешергәндә дә, дәрескә хәзерләнгәндә дә, телевизор караганда да әлеге хафа тынгы бирмәде. Өйдәгеләргә сиздерәсе килми. Бөгелмәдә тикшерелеп, тәмам тынычлангач кына кызык итеп сөйләрмен дип өметләнә иде.

Мансур гыр-гыр килеп йоклый. Чалкан төшкән икән, борылып яткач кына тынды. Ләйсән үз бүлмәсендә. Ачык ишектән аның да мыш-мыш килүе ишетелеп тора.

Җәмилә балкон ишеге янына килеп басты. Алар яшәгән йорт Бистәнең нәкъ үзәгендә. Каршыда гына түгәрәк мәйдан. Мәйдан уртасында Ленин һәйкәле. Җәен ул аллы-гөлле чәчәкләргә күмелеп утыра. Шунда ук чуеннан коелган озын утыргычлар тезелешеп киткән. Бистә халкы бәйрәмнәрдә шушында җыела. Ак колонналы мәдәният сарае мәйданга купшылык, затлылык өсти. Ә хәзер, утлары сүнгәч, ташландык кораб сыман моңаеп, күңелсезләнеп калган. Җәмилә шау-шуга, ыгы-зыгыга, яктылыкка күнеккән. Шуңа күрә бу җансыз төнге бушлык аңа авыр тәэсир итте, күңелендәге шик-шөбһәләрне яңа көч белән кузгатып җибәрде.

Ул маңгаен салкын пыялага тигезде, ә иләнгә тып-тып итеп күз яшьләре тамды...

Кинәт тәрәзә пыялалары зыңгылдый башлады. Мәйданга су эчәргә килүче җәнлекләр сыман тезелешеп автобуслар килеп керде. Вахта автобуслары. Иңнәренә әбәт капчыклары аскан нефтьчеләр шау-гөр килеп җиргә коелды. Димәк, сәгать төнге бер. Смена ни сәбәпледер җиде төн уртасында алышына. Әлеге җанлылык Җәмиләне авыр уйларыннан йолкып алды һәм ул Мансур өстендәге юрганны иплән кенә каерып, аның җылы гәүдәсенә елышты.

* * *

Бөгелмәдә Җәмиләне хастаханәгә салдылар.

—Сезне ныклап карарга кирәк, ике-өч көн эчендә бөтен анализларны үткәрербез, үзегез үк рәхмәт әйтерсез,—диде ана табиб.—Борчылмагыз, бу гадәти процедура. Кайчан да булса бер тикшерелергә кирәк бит инде. Күренеп тора, сезнең табибларга мөрәҗәгать иткәнегез булмаган.

Ир-ат гинекологларны өнәп бетерми иде Җәмилә. Дөресрәге, аңламый ул аларны, ни дип саф хатын-кыз шөгыленә тыкшынырга инде? Хәер, алай дисәң, кайбер хатын-кызлар ир-ат гинекологларга чират баса.

Бөгелмәдә Җәмиләне дә ир затындагы гинеколог кабул итте. Яһүд. Японнарны европалылар белән бутап булмаган шикелле ул да башка бер милләт кешесенә дә ошамаган. Өстәвенә, симез. Ак купшак йөзе дердер килә.

Әмма Шарон Моисеевичның бу килбәтсезлеге авызын ачып сүз әйтүгә юкка чыкты. Сөйләшкәндә аның йөзе бөтенләй үзгәрә: матурлана, җыйнаклана, мөлаемлана. Сүзләрен сәйлән кебек тезә генә. Чәчәннәрен бер якта торсын.

Җәмилә үзенең хастаханәгә керүен хәбәр иткәч, Мансурның кулыннан телефон трубкасы төшеп китә язды.

—Ни булды, машина бәрдермәгәндер бит?—дип гасабиланды.

—Борчылма, барысы да әйбәт, килгәч сөйләрмен,—диде Җәмилә тыныч булырга тырышып.

—Барысы да әйбәт булгач, нигә анда барып эләктең соң,—дип төпченде Мансур.

—Әйттем ич инде, килгәч сөйләшербез дип.

Мансур Җәмилә сораган әйберләрне зур сумкага тутырды да, машинасын кабызып, Бөгелмәгә элдертте. Ләйсәнне бакчадан аласы бар, вакытында урап кайтырга кирәк. Ашыгу бәласе, аэропорт борылышында аны ГАИ инспекторы туктатты.

—Документларыгызны күрсәтегез,—диде ул эре генә.—Сез тизлек режимын боздыгыз.

—Гафу итегез, иптәш лейтенант, хатын больницада ята, шуның янына ашыга идем,—дип акланды Мансур.

—Документларыгыз!

Мансурның документлары тәртиптә иде, әлбәттә. Тик аны бу коры таякка тоттырсаң, кесәсенә салып куюы да ихтимал. Аннан имтихан биреп йөрергә туры киләчәк. Әмма югалтуларсыз гына котылырга иде бит. Нindидер хәйлә кирәк, бәхәс эшне катлауландырачак кына.

—Иптәш лейтенант безнең мәктәптә юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмәләр үткәрергә кирәк иде, белгеч таба алмыйбыз. Сез аны, минa калса, булдыра алыр идегез,—диде Мансур үзенең бу табышына зур өметләр баглап.

Лейтенантның вәкарь өчен генә үстерелгән сирәк мыегы тартышыптартышып алды, ул ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Мондый мәсьәлә юлда хәл ителми. Әмма кызыктыргыч. Үзе дә әле генә парта арасыннан чыкты, югыйсә. Булдыра алыр идеме икән?

—Сез мәктәптә эшлисезмени?—дип сорады ул Мансурдан.

—Мин завуч,—диде Мансур,—бу рәсми тәкъдим. Ә юл кагыйдәләрен бозуга килгәндә, сез закон кешесе, гадел хөкем кылырсыз, дип ышанам.

—Рөхсәт бирерләрме икән соң?—диде инспектор икеләнебрәк.

—Анысына борчылмагыз, башлыгыгыз белән үзем сөйләшермен,—диде Мансур,—рөхсәт бирмичә, яшь буынның язмышы турында кайгырту бит бу.

—Безне училищеда да шулай өйрәттеләр.

Мансур инспекторның исем-фамилиясен язып алды. Исеме Фәнил икән, Газизов. Азнакай егете. Язын-көзен инспекторлар болай да мәктәптә әңгәмәләр уздыралар. Быел Фәнил үткәрсен соң. Танышлыкның да файдасы тими калмас.

—Хатыныгызны көттермәгез, абый, борчылыр,—диде Фәнил.—Сак йөрегез.

Шөбһәләнү белән башланган юл мәрәкәсе көтелмәгәнчә уңышлы тәгәлләнде. Мансурның кәефе күтәрелеп китте. Күнелен тырнап торган җәрәхәте дә сулкылдаудан туктады кебек. Хафаланырлык та шул, семинарга киткән җиреннән хатының сырхауханәгә эләксен әле. Бу бит гомерендә чир күреп карамаган Җәмилә! Әйтми генә булыр, мөгаен имгәнгәндер. Ничә мәртәбә кисәткәне бар, алай тугарылып чапма дип. Тыңламый, ут өертә, машина дими, юл дими элдертә генә.

Вестюбильдә үзен көтеп торучы Җәмиләне күргәч, Мансурның йөрәге иркен сулыш белән тибә башлады.

—Куркыттың да соң, ә?—дип аны үбеп алды.—Нишләп ятасың монда, әйдә, җыен кайтабыз!

—Бераз сагынызгыз әле, юкса кадеремне белми башладыгыз...

Җәмилә башын иренең күкрәгенә терәде.

—Ни булды соң, җанаш, телгәләмә йөрәгемне, әйт инде,—дип Мансур хатынын кочагына кертте.

Күңел тулы вакытта аны ерып җибәрү өчен салам селкетү дә җитә. Шушы гадәти генә сүзләр дә Җәмиләнең йөрәген җебетте дә ташлады. Аның үзен тыярлык көче юк иде инде.

—Минем сул күкрәгемдә төер таптылар, Мансур...

Мансур бу хәбәрнең ни дәрҗәдә хәвефле икәнен әлегә төшенеп җитмәде. Җитди булырга тиеш, Җәмилә юкка-барга чәүчәләнә торганнардан түгел. Шуңа күрә аңа хәзер иң дөрес тактиканы сайларга кирәк. Ул Җәмиләгә чир баткагына, өметсезлек сазлыгына кереп батарга ирек бирмәскә тиеш.

—Шул төер өчен яшь түгәбезмени әле без?—дигән булды Мансур ваемсыз һәм шук күренергә тырышып.—Беләсең килсә, шул төер кети-кети итеп минем күңелне котыртып тора да инде.

Җәмилә дәшмәде. Мансур ничек тә аны елмайтырга тырышты. Тисә—таякка, тимәсә ботакка дигәндәй, бер мәзәк тә сөйләп алды. Ләкин файдасы тимәде, хатыны дорфа сүзләр белән сүгеп ташлады. Бераздан гына кайтып төште.

—Гафу ит, Мансур, боларны мин түгел, күңелемә кереп оялаган шикләрем әйттерә,—диде.

Мансур форсаттан файдаланып калырга ашыкты.

—Син ничек уйлыйсың, җанаш, ул шик дигән кортны оясыннан куып чыгарсак, үпкәләмәсме икән?

—Дөрес әйтәсең, Мансур, җебеп төштем чистый, боламыкка әйләндем...

Сүзне икенчегә борырга кирәк иде.

—Укытучыларга ни әйтим соң, сораячаклар бит,—дип сорады Мансур.

—Алда шунда берәр нәрсә...

Мансур ут төрткәндәй юри кабынып киткән булды.

—Нинди алдашу ди ул? Син авыру түгел! Кызыксынучыларга да шулай диярмен. Ә аяк таю ише вак-төякләр булыштыра инде ул. Шулай бит?

—Шулай, Мансур, ә хәзер бар кайт, Ләйсән борчыла башлар.

Шарон Моисеевич та Мансур тактикасын тәкрарлады. Әмма ул,

тәжрибәле табиб буларак, ялганын бик оста итеп хаклык төргәгенә төрә белә иде. Бу һич тә аның гаебе түгел, моны шундый ук ялганга корылган совет медицина этикеты дигән нәрсә таләп итә. Янәсе, сырхауны тынычландыралар, аны чир стрессыннан саклыйлар, гуманлык күрсәтәләр.

Ул дөреслек пәрдәсенен бер читен генә булса да ачарга карар итте. Чөнки Җәмиләнен чәчәк аткан вакыты гына. Әле ана яшәргә дә яшәргә, балалар табарга... Тик сырхау сайланып тормый шул ул. Бу чибәр ханымны урап узса да яхшы буласы булган да бит. Юк, инде агулы угын китереп кадаган. Моннан котылу чарасы да әлегә табылмаган. Аны тоткарларга гына мөмкин. Бу ягы кешенен үзеннән тора. Бер үк авырудан кайберәүләр ике-өч айдан гүргә керә. Бәгъзеләре дистә елларга суза. Хәтта бөтенләй башка сырхаудан дөнья куя.

—Сезгә операция ясатырга кинәш итәр идем,—диде Шарон Моисеевич.

Җәмиләнен эчендә нидер өзелеп төшкән сыман булды. Әмма табиб аны карашыннан ычкындырмады. Табибнын күзләреннән, әйтерсен лә, гөнаһсыз, саф-чиста сабый үзе карап тора иде. Йомшак, эчкерсез, мөлаем. Җәмиләнен эчендәге өзелеп төшкән теге нәрсәсе кире урынына беректе. Куркуы басылды.

—Борчылмагыз, зинһар, операция дип авыз тутырып әйткәч тә, ул төерне алу колак алмасын тишү кебек кенә...

Табиб үзенен ялганыннан үзе уңайсызланып китте. Нервыларым какшый башлаган ахрысы, дип кашларын җыерды, болай ярамый, үзенне кулда тотарга кирәк.

Җәмилә ризалык белдереп башын селекте.

—Һәм операцияне Казанда ясатырга кирәк,—дип дәвам итте табиб, —анда белгечләр күчлерәк. Дөрес, андый операцияне мин үзем дә ясыйм, пациентларым әле дә рәхмәтле. Тик мәсьәләнен эстетик ягы да бар бит әле. Сез яшь, чибәр. Күкрәк алмаларыгыз, әнә, кызларныкы шикелле... Аңлыйсыздыр, шәт...

—Шулай бик ашыгычмыни?—дип сорады Җәмилә,—минем чыгарылыш классым бар, имтиханнар...

Шарон Моисеевич башын артка чөеп бермәлгә хәрәкәтсез калды. Ул мультфильмнар герое Чипполинога ошап китте. Җәмилә көлеп җибәрүдән иреннәрен кысып кына тыелып калды.

—Татарларда чирен яшергән үлгән, дигән бик акыллы әйтем бар,— дип аңлату эшләрен дәвам итте ул,—әмма бу өлешчә генә дөрес.

—Кан коссан да, белгертмә, дип әйтергә телисезме, Шарон Моисеевич?

—Мин аны бу мәгънәдә тәкрарламыйм. Хикмәт шунда, кайбер кешегә чир ошап китә. Дәваланасы урынга такылдык саескан кебек теләсә-кемгә тәмләп-тәмләп сырхавы хакында сөйләп йөри башлый, үзен жәлләтергә тели. Чирне һич тә әләмгә әверелдерергә ярамый. Киресенчә, аннан арыну мәслихәт.

—Тынычлана аласыз, Шарон Моисеевич, мин Бөекбритания королевасына караганда да горуррак.

*Ахыры киләсе санда*

# ШИГЪРИЯТ



## Илсөяр Иксанова

### Ә БӘХЕТНЕ... САКЛАУ КИРӘК ИКӘН...

### Мәхәббәт

Мәхәббәт безне бар иткән:
Каннан—кан, җаннан—җан иткән.

Мәхәббәт безне яр иткән.
Җандашына пар иткән.

Җаннарга сүнмәс утлы хис тулган,
Каннан—кан булып,
Җаннан—җан туган.

Мәхәббәт аны да яр итәр,
Үзенең тиңенә пар итәр.

Җаннан—җан,
Каннан—кан итәр,
Яшәүне мәңгегә бар итәр.

Мәхәббәт җаннарны күбәләк иткән,
Дөньяны түгәрәк иткән,
Мә—хәб—бәт!

* * *

Әллә соңлап,
Әллә нәкъ вакытында,
Очраштык та
Киттек җитәкләшеп.
«Әйдә безнең белән бергә!»—диеп
Уятмакчы идем җилне дәшеп...

Кирәк түгел ул гайбәтче җилләр,
Дөньяларга сөйләр хәбәреңне.
Белми торсын әле беркем минем
Ничек сөюемне хәләлемне!

Әллә соңлап,
Әллә нәкъ вакытында
Очраштык та
Киттек әле бергә.
Һәм иярде безгә бер фәрештә,
Сезнең белән барам, диеп мин дә.

Шундый нәни матур бер фәрештә
Илһам салып торды бөтен эштә;
Йоклап калган ул гайбәтче җилләр
Ни дип бәя бирер бу күренешкә?

Әллә соңлап, әллә нәкъ вакытында
Очраштык та...
киттек әле менә.
Сөюемне сиңа тапшырырга
Җитеп бетмәс кебек гомер генә...

## Сентябрь

Сарылы-яшелле агачлар,
Агачлар яшелле-сарылы.
Җәйләрнең күзләргә атлавы,
Нишләптер, йөрәккә кагылды.

Сап-сары яфрак шикелле
Өзелеп төшәр күк бу йөрәк.
Ямь-яшел тойгылар леперди—
Без җилдән көчлерәк, көчлерәк.

Яшелле-сарылы фасыл бу,
Бу фасыл сарылы-яшелле.
Күзләрнең түренә агылган
Болытка яшердем яшемне.

Кемнәрне юатыр,
Кемнәрне
Үртәр дә елатыр ул болыт.
Әлегә тойгылар талпына
Сарылы-яшелле моң булып.

* * *

Мин синсез дә, бәлки, яшәр идем
Җирдә син барлыкны белмәсәм.
Яшен булып, бәлки, яшьнәр идем,
Елак яңгыр булып эндәшәм.
Үпкәләрем йөрәгемә йотып
Кочагыңа килеп сыенам.
Башны текә тотып йөрер идем
Син булмасаң әгәр...
Син булган!

## Бердәнберем

Син минем бердәнберем бит,
Беренчем син,
бер генәм.
Төшләреңә керер өчен
Төннәреңә йөгерәм.

Тыннарым белән тын гына
Чәчләреңә кагылам.
Сагынам,
Алсу моң булып
Таңнарыңа сарылам.

Таңнар булып сызылам да
Көннәр булып сузылам.
Елгаларның яры якын,
Елгаларга кызыгам.

## Илдарым

Тагын бер кат гомер бирсә Ходай,
Сиңа бирсә гомер
тагын берне,
Кай ярларга язмыш ташласа да
Эзләр идем сине,
Бары сине!

Мин яшәгән тарафларга чабып,
Сулуларың тыннарыңа кабып
Әверелсәң әгәр бер учакка,
Офык ялкынында сине танып,
Ак күбәләк булып канат кагып,
Мин ташланыр идем ут-кочакка.
Тагын бер кат гомер бирсә Ходай,
Тагын бер кат бу дөньяга килсәк,
Киек казлар,
безгә юл сабыгыз
Табышалмый адашыплар йөрсәк!

* * *

Синсез язлар язмыни соң,
Синсез көзләр көзмени?
Чит-ятларга соклансак та
Читләр безгә үзмени.

Йолдызларга кем сокланмый,
Кем карамый күкләргә!?
Таянырлык таллар кирәк
Хыялларга җитәргә.

Синсез көннәр аязмыни,
Синсез язлар язмыни.
Йөрәгемне бирдем сиңа,
Йөрәк кенә азмыни?

* * *

Үрти-үрти үрсәләнгән җаным,
Күзләр яңгыр сибә күземә.
Тәрәзәмә кунма, сары яфрак,
Болай да бит бәгырь өзелә.

Тышта юеш,
салкын,
ул караңгы!
Йөргәнме көз безгә үч саклап...
Син ялгызың юлда,
Туңасыңдыр...
Күлмәгеңне яттым кочаклап.

* * *

Китсәм куркам,
Югалтырмын сине...
Калсам,
үзем югалырмын кебек.
Сүзсез генә син аңласаң икән—
Сүзләр нәрсә—
Сүзләр бары күбек.

Ап-ак күбек,
Ап-ак ташкын булып
Дулкын ярсуларын күмеп тора.
Бер әрнүсез синнән китәм дисәм...
Күзләреңдә сыным күренеп тора.

## Курку

Үтәр көннән куркам.
Мине сөйгән
Соңгы көнең булса ни эшләрмен?
Көтеп торса юлда бер-бер хәвеф,
Йә мәкере явыз кешеләрнең.

Туар көннән куркам.
Мине сөймәс
Көнең булып килсә,
Мин үләрмен.
Алып китсә сине ялган назлар,
Соңгы сүзем итеп ни диярмен?

Синнән куркам,
Үз-үземнән куркам,
Зурлыгыннан куркам мәхәббәтнең,
Сүзсез генә карыйм күзләреңә
Күзләреңә карап нәрсә әйтим?

Син сүзсез дә барсын аңлыйсың бит,
Куркасың бит син дә бу бәхеттән.
Бәхетсезлек китми куганда да,
Ә бәхетне саклау кирәк икән...

*1993—1998, 13 август.*

❋



# Фәүзия Солтан

## Мәңгелектә, якты бу аланда...

Ямьле язда
Беренче яшел яфракларга елмайганда,
Төпсез күктә эреп беткән
Җиңел канат-кошка карап хәйран калганда—
Бер сәер хис, ямансу хис чолгап ала.
«Яшьлек узды» дигән уй бар җанда.

Килер язлар—килә алмам бу аланга:
Тузганаклар, зәңгәр чәчәк үсәр анда.
Шыбырдатып коеп яңгыр явып үтәр.
Салават күпере күктән нурлар сибәр.
Аллы-гөлле күбәләкләр очар анда.

Күпме йөрәкләргә кояш тулыр,
Якты булыр. Күңелләрдә, бәйрәм булыр.
Уйлап шулай, сагышларым таралалар.
Гүя аларны ак болытлар үзенә алалар.

... Йөз елдан соң, кабат туып булса иде.
Яшь үләнне, чык тамчысын күрсәң иде:
Кырмыскага тими үтеп, гашыйкларны сискәндерми,
Урманның саф һавасыннан исергәнче йөрсәң иде.
Әйтсәң иде:
—Оялмагыз, пар гашыйклар!
Бу урында мин дә булдым.
Хәзер мин—кош. Күктәге бер болыт мин...

Кошкайларым, чит итмәгез.
Сезнең белән мин дә сайрыйм.
Зәңгәр күкне, җирне-суны һәм кояшны мактап җырлыйм.
Ялгызлык бар урман ешлыгында,
Сагышларым шатлыктан да татлы миңа...

---

Фәүзия СОЛТАН—*«Учларымда җиләк» исемле китап авторы. Журналыбызда беренче тапкыр басыла.*

Киләчәккә теләк-фатихамны әйтеп китәм:
—Бездән соң да Җир йөзендә
Чәчәк атып җимеш бирсен һәр үсемлек.
Яшелләнсен урман-кырлар,
Агачларда кош сайрасын.
Яшьнәсеннәр яшеннәр гел яшь-яшь күктә.
Җир йөзендә җыр җырлансын—һич тынмасын.
Гәүдәм агач булып үсеп чыккач,
Җыр тыңлармын. Тик—җырларга кеше булсын,
Кешеләр гел җырласын!

## Оныта алмадым

Кар эрегәндә, җылы назлы җил искәндә,
Йөрәк язга тартылганда,
Язның назын сагынганда—
Күрдем сине.
Ак кардагы эзләреңә дулкынланып мин карадым.
Шул мизгелдән инде тынычлыгым җуйдым—таба алмадым.

Язның болын чәчәгедәй саф көнендә күрдем сине.
Бер күрүдә бик күптәннән таныш диеп сиздем сине.
Ак кардагы эзләреңә дулкынланып мин карадым.
Шул мизгелдән күзләреңнән күземне ала алмадым. Ала алмадым.

Юллар буйлап яз йөргәндә, боз киткәндә күрдем сине.
Көн бер якты, бер караңгы—еладым йә көлдем инде.
Ак кардагы эзләреңә дулкынланып мин карадым,
Шул мизгелдән инде сине оныта алмадым, оныта алмадым...

* * *

Җавапсыз мәхәббәт каршында баш имә!
Ялынма! Тезләнмә! Сер бирмә!
Дәрвиштәй ирекле, горур бул—
Ялынып ул килсен үзеңә!
Җавапсыз мәхәббәт каршында баш җуйма!

## Сиңа тагын ни кирәк?

Мин сине хуҗам дип саныйм—
  Сиңа тагын ни кирәк?
Җырларымны сиңа җырлыйм—
Сиңа тагын ни кирәк?
Яшьлегемне сиңа бирдем—
  Сиңа тагын ни кирәк?

Беләсең бит, коллар хисе көчле була—
Өзелә богау, җимерелә таш диварлар.
Тар ярлардан бәреп чыккан елгалардай
Ямьле, киң һәм якты юл табалар алар.
Ә мин—бер кол. Синең колың.

Син булганда нигә кирәк миңа ирек?
Син әйтсәң мин юкка чыгам. Йә—дан алам.
Син булмасаң—яшәү бетәр кебек.

Мин бит сиңа тугрылыклы—
Сиңа тагын ни кирәк?
Мин бит сиңа берекәнмен—
Сиңа тагын ни кирәк?
Мәхәббәтнең чагылышы—чуар, төрле төстә.
Миңа ул—тик синең исемең!
Сиңа тагын ни кирәк?!

## Дүртъюллыклар

* * *

Кайнар хисләр чагыладыр йөзләреңдә.
Ямьле дөнья. Якты гомер. Гүзәл мин дә!
Бәхетле мин. Язмыш сине биргән миңа.
Озаккамы? Ансын бары Хода белә.

* * *

Аякларым җиргә басып атлаганда,
Күк йөзеннән күзләр йолдыз санаганда,
Давылларны, ташкыннарны җиңәрмен күк
Җир йөзендә син булганга. Син булганда!

* * *

Кар салкыны кердеме соң күңелемә?
Пыскыйм. Көйрим. Үтеп бара гомер менә.
Бер карашың—ут карашың җитәр кебек.
Сүнгән йөрәк кабат дөрләп китәр кебек.

* * *

Һич кичереп булмый икән хыянәтне,
Судан алып язмыш утларга салса да.
Сөенеч тә, шатлыклар да баса алмый.
Сызлый күңел. Әрни яра. Йөрәк яна.

* * *

Әйттең миңа:—Шигырьләрең ник ямансу?
Сөенерлек, күңеллерәк сүзләр кирәк!
Язар өчен шатлык тулы сөю хисен,
Күзләремә һаман сине күзләү кирәк...

## ПУБЛИЦИСТИКА

**Әгъдәс Борһанов**

# РОССИЯ ҖӘМГЫЯТЕНЕҢ КРИЗИС ЧЫГАНАГЫ

«ЧЫГАНАК» сүзен яздым да, уйлап куйдым: «кризис сәбәпләре» дип язарга да булгандыр, мөгаен. Әмма «чыганак» сүзе әйтергә теләгән фикеремне төгәлрәк-тулырак аңлата шикелле. «Чишмә, чишмә башы» дигән мәгънәләре дә бар бит әле бу сүзнең. Әйе, нәкъ менә— чишмә башы!

Россия җәмгыятенең бүгенге хәле, Россия тарихының барлык үткәненә үк бәйле булмаса да, аның «чишмә башы» Петр Беренче патшалык иткән чорларга барып тоташа. Петр Беренче галәмәт зур хәрбиләштерелгән дәүләткә нигез сала, шуның белән асылда бөтен дворяннар катлавын үз эченә алган, көннән-көн ишәя-үрчи баручы, чикләнмәгән хакимлеккә ия дәүләт бюрократиясен тудыра. Бу бигрәк тә хәрбиләр арасында, югары һәм урта идарәче даирәләр арасында нык сизелә. Нәкъ менә шул дәүләт бюрократиясе— түрәләр соңыннан һәм икътисадның, һәм дәүләтнең, һәм бөтен җәмгыятьнең үсеш юлларын, аның юнәлешен билгели. Россиянең алгарыш-үсешенә 1861 елгы крестьян реформасының йогынтысы,— нигездә тискәре йогынтысы!— гаять зур. Ул реформа, беренчедән, ким дигәндә ярты гасырга соңга калып ясала, икенчедән, аның концепциясе, нигезе үк дөрес булмый. Крестьяннарның иң уңдырышлы җирләрен кишәрлекләп алпавытларга бүлеп бирү, крестьяннарның үзидарәсендәге җир община җире булып калган очракта, аның өчен түләп бетерә алмаслык зур бәяләр кую, крестьяннарның җиргә хосусый милекче булу хокукларын кире кагу илдә киңәя барган революцион процессны туктатып кала алмый, алай гына да түгел, киресенчә, аның көчәеп китүенә этәргеч көнә була. Димәк, реформа үзенең максатына ирешә алмый кала. Крестьяннарны крепостнойлыктан азат итеп, аларга ирек бирү шартлары, Көнбатыш Европадагыдан аермалы буларак, Россиядә крестьяннардан күпсанлы урта буржуаз сыйныф оештыруга киртә була, аны соңыннан Столыпин реформасы белән дә төзәтеп, юлга салып булмый. Сәбәпләре шул ук: ул соңга калып башкарыла, алпавытлар мәнфәгатен яклый, крестьяннар файдасына булмый. Реформа, революцион тетрәнүләрнең башлануын вакытлыча чигереп торса да, бары тик халык язмышы өчен тагын да начаррак булган, ә революцияләр өчен иң уңайлырак вакытка гына чигереп тора. Чөнки бу чорда инде азатлык хәрәкәтендә марксистик-ленинчыл тәгълимат җиңеп чыга, ул Россиянең яңа тарихында

күрелмәгәнчә озакка сузылган большевистик диктатура урнаштыра.

1917 елгы вакыйгалар һәм аннан соңгы еллардагы большевистик хакимият дәвере Россиядә Петр Беренче нигезләгән дәүләтчелекнең үсеше үзенең соңгы чигенә—финишка килеп терәлгәнен искәртә кебек. Җәмгыятьтәге тарихи күләмдә әһәмиятле кризисның чыганагы—аның башлануы да, сәбәпләре дә нәкъ менә шул чордан башлап бербөтен булып укмаша. 1917 елның октябрендә Россия дәүләте, әзлекле рәвештә тулысынча бюрократлашып бетеп, халык тормышкөнкүрешенең барлык якларын, аның яшәешен үзенә буйсындырып һәм,—иң мөһиме!—милли байлыкларга бердәнбер монополист хуҗа булып, үз яшәешенең дә соңгы хәлиткеч чорына аяк басты. Хәзер без Россия дәүләтчелегенең үлем алдыннан тартышуында— агониясендә, аның тарихының юкка чыгып, бетеп барган дәверендә турыдан-туры катнашучылар булып калабыз.

Дәүләтнең үсеш-алгарышындагы элгәрләребездән буыннан-буынга күчеп килә торган тәртип бозылу бетүгә йөз тоткан бу соңгы чорга килеп керүнең иң төп билгесе булды.

Диалектиканың кире кагуны кире кагу канунын бөтенләй исәпкә алмыйча, алгарыш-тәрәккыятнең элгәрге нигез ташлары булган ысул-карашларны кирәкмәгәнгә кире кагып, аларны бозып аңлату, аерым алганда, Россия җәмгыятенең тәрәккыяте милексез ярлы сыйныфның хосусый милекче байлар сыйныфына каршы көрәше белән билгеләнә, дип раслау шуның ачык мисалыдыр. Ә чынлыкта исә һәркайда бар дөньяда—ул тәрәккыят милекнең мал-мөлкәтле сыйныфлар арасында хәрәкәт итүе һәм төрле сыйныфларның үзара хезмәттәшлеге белән билгеләнә.

Марксизмда, бигрәк тә аның варисы булган ленинизмда волюнтаризм, ягъни үзең теләгәнчә генә эш итү өстенлек ала. Бу аның, үзенә уңай чакта кулланып та, кирәге булмаганда читкә тибәрелүче, тискәре ягы белән әйләндерелгән диалектикасында ачык чагыла. Бирәдә хаталарның төп асылы шунда ки, эчке каршылыклар тышкы каршылыклар белән бергә буташтырыла, соңгылары гына үсеш-алгарышны тәэмин итә дип исәпләнелә. Хакыйкатьтә исә һәр нәрсә (күренеш, сыйныф) үзлегеннән үсешкә сәләтле, шул сыйфатка ия булмаган бер нәрсә дә, күренеш тә, сыйныфлар да юк, чөнки алар эчке каршылыклы, ул каршылыкларны чишү үз эчләрендәге процесслар барышында хәл ителә. Әгәр шундый чишелеш булмаса,—ө мондый хәлнең каршылыклар юкка чыккан очракта булуы мөмкин,—ул чагында яшәү сәләте югала һәм тышкы тыкшынулар белән юкка чыгарыла, ягъни көрәштә үзара бер-берсен юк итү һәм «өченче көчнең» җиңүе белән тәгәлләнә. Укучым гафу итсен, артык фәлсәфиләштереп-фәнниләштереп әйтелде шикелле. Әмма бу—диалектика законы. Димәк, милекнең артуы-ишәюе аның хәрәкәттә булуы, милекчеләр сыйныфының үзара ярышыкөндәшлеге—конкуренциясе аркасында барлыкка килә. Әгәр ул конкуренция милекнең азчылык кулында тупланауына—монополизациягә китерсә, ул вакытта милекнең хәрәкәте туктатыла, торгынлык—стагнация башлана. Ә милексез пролетарийлар сафы бөлгенлеккә төшкән милекчеләр хисабына тулылана бара, милекчеләргә дошман сыйныфның көчәюе килеп чыга. Пролетарийлар сыйныфы үзлегеннән генә үсеш ала алмый, аңарда җәмгыятьтә тоткан урынын—статусын үзгәртерлек каршылыклар юк, аның язмышы—исән калу өчен көрәш, иң әйбәт дигән очракта да, бары тик үзен пролетариат сыйныфында саклап калу, ә күбесенчә—хәерчелеккә төшеп бөтенләй люмпенлашу. Азмыкүпме хәллерәк һәм эшлекле-булдыклырак крестьяннар арасыннан буржуазия сыйныфы үсеп чыккан булса, сыйныф буларак пролетариат үзеннән өстәрәк торган сыйныфка күчә-күтәрелә алмый, аның хәрәкәте бары тик түбән тәгәрәүгә генә дучар ителгән. Җәмгыятьтә тормыш төбенә төшә-төшә, пролетариат революционерлар өчен табышка әверелә.

аны милекчеләргә һәм, әгәр дә җәмгыять демократик юл белән милекне халыкка бүлеп-таратып бирмәсә, гомумән, милеккә-байлыкка каршы революцион көрәшкә күтәрә.

Егерменче гасыр башындагы өч рус революциясенең һәм аннан соңгы еллардан башлап бүгенгә кадәр хөкем сөргән рәтсезлек-чарасызлыкның башлангыч сәбәпләре булып хаким сыйныфның— дәүләт бюрократиясенең күпчелек халыкка хосусый милек принцибын кире кагуы, милли байлыкны җәмгыятьнең бик аз өлешенә генә,— кагыйдә буларак, карак өлешенә,—казна байлыгы бетсә түгел ич!— тиешле дип санавы тора. Хаким сыйныфның канына сеңгән инде бу. Башында самодержавный патша торган дәүләт бюрократиясенә— империячел фикерле түрәләргә халык бары тик яулап алу сугышлары өчен генә кирәк. Мал-мөлкәте, җире булмаган кара халык, әлбәттә, беренче чакыру белән үк яуга барырга, башка халыкларны буйсындырып, җирләрен басып алырга, таларга әзер торган. Ә инде сугышларда имгәтелгән гарип-гораба, ятимнәр, толлар язмышы җәмгыять өстенә йөкләтелгән, түрәләрнең аларда эше булмаган. Табигый ки, мондый сәясәт мәңгелек була алмый. Халыкны күп гасырлар буена милектән мәхрүм итеп, аны бөлгенлеккә тоту социаль тотрыксызлыкка китерде. Хезрчелектән башы чыкмаган халык байлар сыйныфын дошман итеп күреп, хосусый милеккә, мал-мөлкәткә гомумән нәфрәт белән яши башлады. Шундый шартларда Россия халкы хакимияткә каршы күп тапкырлар көрәшкә күтәрелде, әмма нәтиҗәсе куанырлык булмады. «Бетмәс-төкәнмәс рус революция-контрреволюцияләре йөзъеллыгы» дип аталырлык егерменче гасыр башына халык тәмам таланган хәлдә һәм чиксез үч-ачу белән аяк басты.

Октябрь революциясе җиңгәннән соң, Россия халыклары бер начар җәмгыятьтә яшәүдән икенчесенә генә күчтеләр. Милек, мал-мөлкәт мәсьәләсендә халыкның бөтенесе диярлек бер хәлдә калды, ул милектән бөтенләй мәхрүм ителде. Матди яктан тәэмин ителгән булып өлеге дә баягы түрәләр— номенклатура гына калды, күпчелек исә кызганыч гомер сөрергә дучар булды. «Тимер пәрдә» белән томаланган булганлыктан, бу халык үзенең тормыш-көнкүрешен башкаларныкы белән чагыштыра алмый һәм шунлыктан мул-рәхәт тормышның нәрсә икәнен дә белми, үзенең хезрчелеген аңламый килде. Большевиклар, җәмгыятьнең байлар-ярлыларга бүленүен инкарь итеп, киләчәктә,—әмма хәзер үк, үзләре хакимлек иткәндә үк түгел!— һәркем иркен-рәхәт тормышта яшәр, дигән шигарь-лозунг күтәрсәләр дә, чынлыкта барыбызны да хезрчелеккә тигезләүгә генә сәләтле булып чыктылар. Виктор Черномырдин әйтмешли: «Бер бүлмәгә керәбез дип, икенчесенә барып кердек.» Пушкинның замандашы декабрист Петр Чаадаев язганча: «Без алга барабыз, әмма максатка илтми торган сызык буйлап, кыек юнәлештә.» Россиянең гомерлек бәласе шул: чын-асыл хәлне бик азлар гына белә-аңлый иде һәм андыйларны идарәче даирәләр «акылдан язганнар» яки «хыянәтчеләр» дип кенә тамгалап килде.

Коммунизм— коммунистик бюрократиянең диктатурасы ул. Егерменче гасырда кайбер илләрдә җиңеп чыккан коммунизм үз тәгълиматчыларының әүвәлгә хыялый-утопик яки «фәнни-коммунистик» карашларына бер яктан гына туры килә иде: ул, икътисадны дәүләткә буйсындырып, кешенең иҗтимагый һәм шәхси тормышын да «дәүләтләштерде». Нәкъ менә шуның аркасында югары әхлаклы, гадел, кешелекле җәмгыять—коммунистик строй дигәннәре тормышка ашмады да инде. Аны төзү өлеге дә баягы пролетариат диктатурасының дәүләте тарафыннан башкарылырга тиеш иде. Әмма, тышкы дошманнардан саклану һәм җәмгыятьтәге социаль каршылыкларны киметү вазифаларын үтәүче гадәти дәүләтләрдән аермалы буларак, «пролеталар» (ә чынлыкта—комбюрократлар) дәүләте, милли байлыкларга тулысынча

хуҗа булып алгач, Сталин әйткәнчә, «хуҗалык-оештыру һәм мәдәни-тәрбияви» вазифаларны да башкарырга хокуклы булып чыкты. Ягъни ул һәртөрле хокуктан мәхрүм ителгән җәмгыять өстеннән хакимлек итә башлады. Ә бит ул үзе җәмгыятькә хезмәт итәргә, аның сайлап куелган хакимияте алдында хисап бирергә һәм җәмгыять тарафыннан тәрбияләнергә тиеш. Үсеш-алгарышның бердәнбер чын хуҗасы булган милекчеләр сыйныфын юк итеп, аның вазифаларын үзенә алган дәүләт «ялган хуҗа» булды һәм, үсеш алгарыш урынына, бөтенләй кире нәтиҗәләргә китерде.

Социаль гаделлек принципларын тормышка ашырабыз, дигән булып, дәүләт хезмәт ияләренең керем-табышларын һәм куллану ихтыяҗларын тигезләү юлына басты. Нәтиҗәләре аяныч...

Алгарыш-тәрәккыятнең асылы кешеләрнең бөтенесенең дә бертөрле булуында түгел, ә аларның бер-берсеннән аерылып торуында, алар арасында хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне тәэмин итәрлек талантлы шәхесләр булуда. Бары тик шул нигездә генә җәмгыять тормышының барлык тармакларында үсеш-алгарыш була ала. Керем-табышларны һәм куллану ихтыяҗын көчләп тигезләү зур сәләтләргә ия кешеләрнең дә үз сәләтләрен файдалану теләгән бөтенләй юкка чыгара—алар да башкаларга тигезләнә башлыйлар. Нигә бушка көч түгәргә? Нәтиҗәдә—җәмгыять үсешенең торгынлыгы. Бу хәл «ялган хуҗаларның» халык хуҗалыгын туздырулары, әрәм-шәрәм итүләре белән, «үзләренекен үзләре» урлаучы караклары һәм вакытлы түрәләренең акылсыз гамәлләре белән тагын да катлауландырыла-тирәнәйтелә. Шул рәвешле, котылгысыз фаҗига— халык үзенең килечәгеннән мәхрүм ителә. Әле бит шуның өстенә җитмәсә, бу әрәмтамак-сорыкорт комбюрократ сыйныф, «хезмәт ияләренең интернациональ теләктәшлеге» дигән шигарь-лозунг белән, бөтен дөньяда хакимлек итәргә дәгъва кыла. Болай да тормыш дәрәҗәсе түбән халыкка зыян китереп, шул максатлар өчен гаять зур дәүләт чыгымнары сарыф итә. Табигый ки, мондый дәүләт башка иҗтимагый мөнәсәбәтләргә нигезләнгән һәм башкача хуҗалык итүче дәүләтләр белән ярыша алмый. Аның тормышка ашмас уй-теләкләренең нигезе булган хәрби көчләре хәлсезләнә-какшый, халыкның имин тормышын азмы-күпме адәм рәтле тәэмин итәргә мөмкинлеге калмый, социаль киеренкелек үсә һәм диктаторлар хакимлегенә куркыныч яный башлый. Бу дәүләт әле күпмедер вакыт үзенең икътисадый ныгыту-үстерү мәсьәләсен ГУЛАГлары, колхозлар, кешелексез канун-законнары белән, халыкның чиксез арзан кол хезмәте һәм миллионнарча тоткыннарның бөтенләй түләүсез хезмәте белән хәл итеп килә ала. Әмма гомергә алай дәвам итә алмый бит. Ә ул арада капиталистик илләр үсеш-алгарышта шундый сикерешләр ясый ки, кайбер усал телләр әйтмешли, коммунистик дәүләтләр «мәңгелеккә» артта калалар. Коммунизм, алгарыш субъекты булган милекчеләрсез җәмгыять төзергә тырышып, аны «ялган хуҗа»—дәүләт белән алыштырып, җиңелүгә дучар була. Коммунизм—тормышка ашмас хыял ул. Социаль гаделлек мәсьәләләрен хәл итү башка юнәлештә булырга тиеш. Ул да булса— төше-үзәге милекче урта сыйныф булган гражданнар җәмгыяте төзү. Ә дәүләт шул җәмгыятьтә үзенең табигатенә хас эш-гамәл белән шөгыльләнә: халыкның эчке һәм тышкы иминлеген саклый, аңа үз тормышын үзе теләгәнчә алып барырга комачауламый. Хакимият белән шәхес арасындагы мөнәсәбәтләрнең төп асылы— кешенең уңай эшчәнлегенә комачауламауда. Без хәзер, бәлки, Россиянең менә шундый бөтенләй яңа төр хакимиятле дәүләтчелегенең бик авыр газаплар белән туып килүенә шаһитлардыр. Бәлки, ул дәүләт асылда демократик көнбатыш дәүләтләреннән әллә ни аерылып та тормас. Россия җәмгыятенең гасырларга сузылган кризистан чыгу юлы шулдыр. Бирсен ходай!

* * *

ЖӘМГЫЯТЕБЕЗНЕҢ кризис чыганагы, аның «чишмә башы» да, сәбәпләре дә— Россиягә хас дәүләтчелегебездә. В. И. Ленинның бөтен нәрсәне үзенә буйсындырган бюрократизмлы, үлемгә дучар ителгән дәүләт төзүе турында үзе үк фараз кылган күрәзәчелеге расланды. Кызганыч ки, моны аңлау һәм шулай ук социализмга карата булган карашларын тамырдан үзгәртү аңа бик соңлап, үләр алдыннан гына килде. Ул вакытта инде ул үстергән партия-дәүләт номенклатурасы хаким сыйныф булып өлгереп җиткән, ә Ленин үзе, авыру сәбәпле, көчен югалткан, бары тик «теше коелган арыслан» булып кына калган иде. Үлеменнән соң озак та үтмәде, ул «тудырган балалар» да: дәүләтне демократик-халыкчан итәргә бердәнбер чын сәләтле НЭП (яңа икътисади сәясәт) һәм НЭП белән берлектә җидешәр чакрымлы адымнар белән үсеп килүче кооператив төзелеш тә «үлде». Аларны Сталин «үтерде». Бу гарип дәүләтчелекне бары тик бюрократияне хакимлектән сөреп төшереп кенә юк итәргә мөмкин, аны тик гражданнар җәмгыяте генә башкарып чыга ала. Әмма гражданнар җәмгыяте төзергә халыкның үзенең эчке көче-җегәре калмады. Соңгы еллардагы уйланмаган, акылсыз реформалар аны бөтенләй хәлсезләндерде. Барысын да яңадан булдырырга, күтәрергә кирәк. Моны кем эшләр? Мәсьәләләрнең мәсьәләсе дә менә шунда!

Минем моңа мондыйрак җавабым бар: тоталитарлыктан котылган бер генә дәүләт тә, хәтта үзендә демократик юнәлешле дәүләт эшлеклеләренә һәм күпсанлы милекчеләр сыйныфына таянырлык социаль җирлеге булган очракта да, читтән ярдәм алмыйча, үзлегеннән генә гражданнар җәмгыяте төзергә сәләтле түгел. Аларда гражданнар җәмгыяте һәм демократик дәүләт оештыру җиңүчеләр күзәтчелегендә, алар булышлыгы белән барган. Бездә исә ни милекчеләр сыйныфы юк, ни көн таләпләренә җавап бирерлек лидер-юлбашчылар юк һәм безнең эчке эшләребезгә читтән турыдан-туры йогынты ясаучылар да юк—хәлебез менә шуның белән дә катлаулана. Менә шушы хәлләр һәм халыкның тормышында сизелерлек үзгәрешләрне өстән торып ясауны көтү гадәте безне дәүләтебезгә генә өмет итәргә этәрә. Без шулай тәрбияләнгән, шулай өйрәтелгән. Аңлашыла ки, хәзерге дәүләт аппаратына түгел, ә башында интеллектуаль сәләтле һәм әхлаклы, демократик карашлы, халыкара демократиянең һәрьяклап хәлиткеч булышлыгына һәм әлегә хәлсез булган үз демократиябезгә дә таянган күренекле лидер-юлбашчы торган дәүләт аппаратына өметләнергә кала. Шундый дәүләт, башкалар белән бердәмлектә-дуслыкта, үзебезнең хәзерге идарәче түрәләрнең һәм оппозициядәге номенклатураның да каршылыгын җимерә-җимерә, милекчеләрнең урта сыйныфын булдыруны тизләтә алыр иде.

Ничек итеп безгә тыныч юл белән шундый дәүләт төзергә соң? Монысы мәсьәләләрнең икенче мәсьәләсе. Минем бу сорауга анык кына җавабым юк. Бәлки, халыкара демократия бу мәсьәләне чишүгә якынлашып киләдер. Ул бит әнә коммунизмның котырынып азып китүен үз өендә генә түгел, социалистик лагерь илләрендә дә чикләү чараларын таба алды. Салкын сугыш шартларында социалистик лагерьны ярышка чакырып, милекне халыкка бирү һәм демократияне үстерү юлы белән халыкның имин, иркен-мул тормышын тәэмин итү ярышында отты бит. Хәзер дә шундый чараларны таба килә. Мин бары тик моның йөздән бер мөмкинлек булганын гына әйтергә телим. Аны тормышка ашыру өчен рус халкын бөекдержавачыл-шовинистик психологиясеннән, империя синдромыннан арындырырга кирәк. Ә ул әле җитмәсә хосусый милекчелеккә каршы коммунистик дошманлык белән дә агуланган. Евгений Евтушенко әйтә бит: «Я—босяк, но—русак!»—ди. Юкса, акрынлап булса да тернәкләнеп килүче

демократияне буарга, аны һәрьяклап тоткарларга тырыша-тырыша, коммунистик үткәнебезнең «бөеклеген» ГУЛАГлары-ниләре белән кире кайтармакчы булып, һаман да яман белән яхшының бетмәс-төкәнмәс көрәш сазлыгында,—ә анда безне шул ук коммунистлар этә-төртә кертмәкче!—быкырдап тик ятарбызмы? Әлбәттә, коммунистларның бу көчәнүләре өметсез, чөнки, бердән, халыкның азмы-күпме дәрәҗәдә күзе ачылды, ул инде каршы торырлык булып өлгерер, җитте, икенчедән, публицист Виктор Ерофеев язганча: «Соңгы ярты гасыр эчендә дөнья артык кечерәеп калды. Яңа технологияләр дә, дөньядагы яңа вәзгыять тә безгә теләсә нәрсә эшләргә мөмкинлек бирмәячәк. Шулай булгач, коммунистлар тәкъдим итә торган вариант, үзенең әхлаксызлыгыннан тыш, тормышка ашмас хыялый да әле. Без инде барлык цивилизацияле дөньяны куркытып-өркетеп торырдай әлекке супердержава була алмаячакбыз» *(«Будь здоров» журналы. Мәскәү, 1999 ел, 4 сан, 100 биттән тәрҗемә).* Бу «географик һәм технологик» сәбәпләргә сәяси-психологик сәбәпләрне дә өстик. Икенче бөтендөнья сугышы сабаклары, аерым алганда, «кечкенәрәк явызлык» дип, әле фашизм, әле коммунизм ягына авышу, нәтиҗәдә—вакыты җиткәч аларның «зур явызлыкка» әверелүен (ә ул котылгысыз!) күрү—менә бу ачы тәҗрибә халыкара демократия өчен эзсез үтмәде. Ниһаять, нинди генә явызлыкны да якларга ярамаганлыгын, аның тешләрен бөтен кешелек дөньясына куркыныч янарлык булып үсеп җиткәнче үк тамыры-ние белән йолкып алырга кирәклеген аңладылар.

Шунысын да кисәтеп кую кирәктер, Россиянең «ни алга, ни артка» булган бүгенге хәле озак дәвам итәргә мөмкин. Әмма «ничек кенә үрелсә дә, бауның очы була». Ләкин нинди «оч» бит—анысы билгесез.

Дәүләт хакимияте үзара ызгыш-талашлардан арына алмый, аерым төркемнәргә таркалу, төрле партияләр-хәрәкәтләр калкып чыгу, иң югарыда утырган түрәләрнең дә чикләнмәгән җинаятьчел даирәләргә тартылу-укмашулары дәвам итә. Илдә үсеш-алгарыш субъекты— милекче урта сыйныф юк, аның вазифаларын җинаятьчел олигархлар (милли байлыкны үз кулларына төшергән һәм сәяси-икътисади хакимлеккә омтылучы Чубайс, Березовский, Гусинский һ. б. кебекләр) һәм бюрократ түрәләр башкарган булып кылана. Милли идея юк, аны күп чәйнәлгән «самодержавие, православие һәм халыкчанлык» дигән формулага алмаштырмакчы булалар. Анда да, Никита Михалков әйтмешли, «баш хәрефтән язылырга тиешле милли сыйфат—милләтне батырлыкларга өндәүче көнчелек» белән буташтырып алыштырмакчылар. Ул «батырлыкларның» ни-нәрсә икәне безгә бик яхшы мәгълүм! Юлбашчылар урынында—һәртөрле дәрәҗәле дә, дәрәҗәсез дә шарлатаннар-бушбугазлар. Халык шомда, менә-менә фетнә-гыйсьян башланыр шикелле. Берденбер юаныч—Россия тарихындагы бу болганчык чуалыш өченчесе һәм ул да үзенең өченче әйләнешендә инде. Руслар: «Бог любит троицу»,—диләр, ягъни: «Алла өчлекне ярата». Димәк, бу галәмәтнең соңы якындыр. Әгәр дә хәзерге хакимият үткәнгә кайтуны булдырмый кала алса, үткәнне сагынып хыялланучылар белән хәзерге кебек кети-кети уйнамыйча, киресенчә, аларның халыкка дошман булган асылын фаш итеп, коммунистик мирасның тамырына чапса, хәзерге кебек кыланып кына калмыйча, җәмгыять һәм дәүләтне дөнья цивилизациясе юнәлешендә хәрәкәт итәргә чын-чынлап оештырса—менә шул чагында Тарих Галиҗәнапләре бу режимның күп кенә гөнаһларын да гафу итәр иде, бәлки.

Без хакыйкать мизгеленә якынлашабыз. Аны абайламый калмасак иде. Иске гадәтебез буенча, яңадан да «максатка илтми торган сызык буйлап, кыек юнәлештә» китеп бармасак иде.

*Май, 1999 ел.*

# ШИГЪРИЯТ



## Рөстәм Мингалим

### ЯНА-ЯНА КИТКӘН ТОРНАЛАР...

I

Моннан бик еракта, арттa, күп кышлар һәм җәйләр артында бер көн бар. Ул көнне бүгенге ай да күрми, кояш та яктыртмый. Ул көн өстендә инде катлам-катлам яңа кышлар, язлар, җәйләр, көзләр. Яңа юллар, шәһәрләр...

**Менә шул ерак көндә Эльза үзенә хас булмаганча җитди иде. Миңа ул моны сиздермәскә тырышты. Хәер, бәлки, Эльза холкы белән гел җитди кеше булгандыр. Гел миңа моны сиздермәскә тырышкандыр, минем әле җитдилектән ерак икәнемне сизеп шулай эшләгәндер... Булыр да?!**

Сез, кешеләр, гел учаклар кебек,
төрле уйлар сездә дөрлиләр.
Шуңа күрә генә дөнья якты—
якты көннәр, өйләр һәм илләр.
Әле, бәлки, Кояш яктылыгын
сезнең янулардан аладыр.
Яна сездә шатлык, кайгы, сагыш,
ә дөньяга болар бар да бер.
... Мин дә янам,
сезнең кебек янам!—
йолдызларда шуның яктысы.
Бу язганым гади бер хикәят,
ләкин ул да гомер чаткысы.

II

Нигәдер?
Белмим мин,
белмим мин—
нигәдер,
дусларга «Бер яшь кыз
сөям» дип сөйләдем.

Кич белән, киенеп,
киткәндә тораклан,
әйттем мин дусларга,
барам, дип, еракка.
Әйттем мин, барам, дип,
сөйгәнем янына.
Гел әйттем, янәсе,
мин аны сагынам.

Ә чыны—ул яши
торакның каршында.
Сагыну уе да—
юк кебек башымда.
Барам да кагылам
туп-туры ишеккә.
... Бер ел кагылам,
ике ел кагылам
шул таныш ишеккә.
Шылт итеп келәсе
ачылуын ишетәм.

Көннәрдән бер көнне
уздым да өенә,
нигәдер ашыктым
«Сагындым» диярргә.
Эльзаның җавабы
кагылды йөземә:
—«Сагынып килмәдең,
Алдыйсың?!
Йә, нигә?
Ни өчен алдарга?!
Ярамый алдарга!
Мин сине аңладым,
алдарга кирәкми!
... Кыен тик аңлавы
үземнең йөрәкне.
Бик кыен аңлавы
үзеңнең йөрәкне.

Киттең бит
килмим дип.
Яңадан ник килдең?»

Кыен шул аңлавы
үзеңнең йөрәкне!
Мин чынлап аңламыйм,
аңларга кирәкме?
Сагынмый килдемме?
Сагынып килдемме?
Төшми һич хәтергә—
килмим, дип әйттемме?
Белмим мин,
белмим мин—
яңадан ник килдем?
Тик шуны беләм мин,
ул үзе сөйләде:
ватылган гаилә,
онтылган сөйгәнен.
... Тәрәздә пәрдәләр—
ап-аклар, ап-аклар!
Зәңгәрсу халаты—
сап-сары шакмаклар.
Аягы очына—
чүәге эленгән.
Сулышы ешлыгын—
түшләре сөйлиләр.
Эльзаны шигырьгә
күчер дә куй аны.
Чәчләре кап-кара,
ямь-яшел диваны.
Диваны артына
чәчләре таралган.
Өстәлдә көзгесе,
кулында тарагы.

Тукта!
Ни сөйли соң
аның зур күзләре?!
Ул миннән башкарак,
ул миннән үзгәрәк:
шактый ук олырак,
шактый ук сипкелле,
еш кына елмая—
ул дөнья шикелле.
Шуңадыр ул миңа
бетмәде ошап та.
Шуңа бит мин аны
киталмыйм ташлап та.

Бүген ни сөйли соң
аның зур күзләре?!
...............
Әллә ул үзгәрде?
Әллә мин үзгәрдем?
Әллә без—үзгәрдек?

Әнә шул, еракта гы, инде табылмаска югалган кечкенә алтын тәңкә кебек түгәрәк көндә... Эльза озак сүзсез торды. Мин, әкрен генә ниндидер көй сызгырынып, бүлмәдә йөрдем. Бу кечкенә бүлмә җир хәтле зур тоелды миңа ул чакта. Әйтерсең җирнең бер як читендә—мин, икенче читендә—Эльза. Мин аны күрәм, таныйм. Башка көннәрдә ул болай җитди түгел иде. Әнә, чын Эльза—стенадагы фоторәсемендә... Ул анда шат, бәхетле.

Күптән төшкән фотосурәте ул аның.

Мин һаман әкрен генә сызгырындым. Сызгырынуым бөтенләй үк мәгънәсез түгел иде, анда минем уй—мондыйрак мәгънәдәге җырлар бар иде:

Аклы күлмәк, аклы күлмәк
иңнәремә тар инде.
Сөйгән яры тиң түгел, дип
сөйләүчеләр бар инде.

Таулар биек, таулар биек,
тау өстендә учагым.
Дошман көнләшерлек ярлар
табала торган чагым.

Күлләрендә, күлләрендә
балыклар уйный икән.
Минем уйлар чуалганда,
ул ниләр уйлый икән?

Шунда кинәт Эльза елмайды. Стенадагы фоторәсеменә охшап калды. Ул әле гомерендә бер тапкыр да кайгы кичермәгән кызчык кебек иде. Мин сызгырынган шаян көйгә Эльза җыр башлады:

Ал итә алыр идем лә,
гөл итә алыр идем.
Ятлар сүзен санга суга,
ялгызы калыр инде.

Яулыгыма яңгыр тиде,
кибәр әле киптергәч.
Үптермәсәм, «сөйми» диде,
«азган» диде, үптергәч.

Өстәлемдә ике сәгать,
икесе дә туктаган...

Эльза—җырлаудан туктады. Үзе һаман елмаеп миңа карап тора иде. Ул хәзер тәмамламаган, узган очрашуыбызда мин җырлаган бу җырның ахырын:

«Онтылгач та бергә йөргән, искә төшәр йоклаган»—дигән юлларын мин сызгырынып тәмамладым. Аннан тәрәзәгә карап алдым. Көн әле якты. Урамда кызыл көз.

—Син җил кебек!—диде миңа Эльза шунда. Мин эндәшмәдем. Ул тулып торган кызыл иреннәрен түгәрәкләде дә сузып кына сызгырып куйды:

—Җил тавышы киләме?—диде.

Мин эндәшмәдем. Тик чынлап та миңа аның сызгыруыннан кышкы җил авазы ишетелде. Тәнемә салкын таралган кебек булды. Тәрәз артындагы көз тәэсире бугай, дип уйладым.

—Син ми-нем җы-лы кояш-лы кө-нем идең!—диде Эльза. Мин җылынып киттем. Ләкин эндәшмәдем.

—Син салкынайдың,—диде Эльза.

Мин эндәшмәдем.

—Син бик салкынайдың! Мин китәм!—диде ул.

—Кая китәсең?—дидем мин.

—Торналар киткән якка,—диде ул шаярган да һәм шаярмаган да кебек.—Торналар белән китәм,—диде өстәп.

—Димәк, очасың?—дидем.

—Очам!—диде Эльза.

—Торналар кайтачак бит,—дидем мин.

—Мин кайтмаячакмын,—диде Эльза.

Мин көлдем.

—Шатланасыңмы?—диде ул.

—Ә шәһәр... Бу шәһәргә синнән башка... Аңа синсез күңелсез булыр,—дидем мин.

Эльза, урыныннан кузгалып, өстәле янына килде. Бераз вакыт көзгесенә карап торды. Аннан миңа таба борылып:

—Мин шәһәрне сиңа калдырам. Син кара, аңа күңелсез булмасын!—диде. Әллә миннән көлүеме? Ялваруымы бу? Үкенүеме? Тавышында—мең төсле мәгънә. Ләкин бу сөйләшүнең асылы миңа аңлашылып җитми иде. Шаяра бугай, дип уйладым эчемнән. Тагын көлдем.

### III

Ул шаярмаган.

Ул китте.

Хәбәрләшмәдек... Соңрак... Соңрак аны мин гел искә алдым. «Торналар киткән якка китәм!» дигән иде. Шул чакта көлгәнем өчен мин аңардан бик оялдым, гафу үтенәсем килде... Аңа бәхетләр теләдем. Ә ул кайларда икән? Инде мин күпме юллар уздым, күп яшәдем. Аны очратканым юк... Җир бүген минем өчен әйтерсең кайчандыр мин белгән Эльзаның бердәнбер тәрәзәне ап-ак пәрдә корылган бүлмәсе кебек кечкенә. Ә Эльза күренми. «Торналар киткән якка китәм» диде... Ул көн артта, моннан еракта, яңа кышлар, язлар, җәйләр, көзләр астына күмелгән. Ул көнне бүгенге ай да, кояш та яктыртмый.

Хәзерге юллардан заманның авыр машиналары узганда, җир дерелди, күптән күмелгән көн калтыранып куя: мин шуны һәрвакыт бөтен тәнем белән сизәм. «Торналар киткән якка китәм!»—дигән иде.

Без, кешеләр, бер-беребезгә охшаш,
хисләр төрле, әмма...
дөрлиләр.
Шуңа күрә генә дөнья якты,
якты көннәр, өйләр һәм илләр.
Янып йөри бездә сагынулар,
башта әллә нинди моңнар бар.
... Әллә нигә
бу елларда
гел төшемә керә
кызыл көзләр,
яна-яна киткән торналар.



# Рәшит Гатауллин

## ҖӘЙ БЕЛӘН КЫШ АРАСЫНДА

* * *

Дулкыннар, яшел дулкыннар...
Диңгездәй яшел чирәм.
Яшел дулкыннар—бары тик
Диңгездә генә, дисәм,—
Алдымда үлән диңгезе,
Теләсәң колачлап йөз.
Теләсәң ялан тәпи йөр—
Диңгез ул, яшел диңгез.
Яшел үләнне аралап
Чык төшкән болыннардан
Балачагым хыяллары
Йөгерә кем узардан.
Яшел хыяллар гомерне
Күтәреп барыр кебек.
Йөгерер дә... Дулкын эчендә
Югалып калыр кебек.

* * *

Китәр булгач, фани дөньяга Хак
Ник тудырган адәм баласын?!
Туу, яшәү... Аннан тагын китү—
Бу дөньяга хәйран каласың.
Акырып елап, урын-җирне тырнап
Яшәү өчен ту да... кит инде.
Бу дөньяның кануннарын мәңге
Аңламамдыр, ахры, мин тиле.
Галәм—мәңгелек, ди. Шулай булгач,
Мәңгелектер—җәннәт, җәһәннәм.
Димәк, мин дә мәңгелектә калам—
Хәтта
Җәһәннәмгә хөкем ителсәм дә—
Аерылмыйм галәм-җиһаннан!

## Ә мин карлар көримен

Кар көрим җилгә кушылып,
Әйтерсең лә үчем бар.
Баш очымда каргалар да,
Тирә-юнем кар да кар.
Кар көрим көрәкне селтәп,
Җил тагын өеп тора.
Җилкенәм. Ә ник соң җанда
Нидер оеп утыра?
Эзләрне, тирәннән казып,
Кизәнеп ыргытамын.
Үчем бармыни кышларга?
Көрәккә тотынганмын?
Мин авыл кешесе. Кары,
Көрәге күптән таныш.
Язларны «ташлап», үткәннән
Китү булдымы ялгыш?
... Көрә, көрәмә,—кар, еллар
Эзеңне күмеп бара.
Җәйләргә, яшел җәйләргә
Гел ерагая ара...
Мин гүя килер җәй, кышлар
Арасында йөримен.
Яусын карлар, купсын буран—
Яшим... Карлар көримен.

## Ак болытлар ага

*Нәселебезнең соңгы аксакалы*
*Хәтмулла абзыйга*

Кабатлана болыт. Әйтерсең лә
Туган якка китеп барышы:
Яңгыр булып кырларыма явар,
Болытлардан явар—сагышым.
Кабатланып аккан шул болытлар
Хәтер җебе булып сузыла.
Өермәләр булып күтәрер дә,
Алып китәр... Кулың суз гына.
Кул сузымы ара гына бары,
Булырмы соң кабат кайтулар?
Беләм, кабатланмас мизгелләр бар,
Мәңгелеккә илтер—бар юллар...
... Кулларыңны кашларыңа куеп
Күзәтәсең болыт агышын.—
Алардан тик күләгәләр кала,
Күләгәләр... Үтеп барышлый!
Күләгәләр. Җанда күләгәләр...
Күләгәләр калка хәтердә.
Һәм аларны күмеп өмет калка,
Өметләр бит мәңге тереләр.—
Барысы да: үткән, кайтканнар да
Хәтер буйлап узар тагын да...
Кабатланып ак болытлар ага,
Ак болытлар... туган ягыма.

* * *

Күлмәгең синең ак иде,
Әле дә каралмаган.
... Әллә еллар читләп үткән—
Бер сиңа кагылмаган.
Чәчләрең дә, кашларың да,
Елмаюың да таныш.
Кара уйлар кермәгәндер,
Кагылмагандыр сагыш.
Һаман да элекке кебек
Күзең дә ачык, зәңгәр.
Элекке дә... карашыңда
Дулкыннар тынган мәгәр:
Әллә инде керфекләрең
Бөгелгән кебек бераз...
Чайкалыр да, әллә ниләр
Түгелер кебек тора.

## Кайтам әле

Кагылып та, сугылып та
Үскән җир!.. Кайтам әле.
Читләрдә «шиңгән» җилкәмне
Бераз турайтам әле.
Туган ягым, тагын синдә,
Их, кунак булам әле.
Бер акыл иясе кебек
Бик тыйнак булам әле.
Сагынганнары да бардыр,
Танымаганнар да күп.
Азмыни туган җиреннән
Аерылган—минем күк—
Бәхет эзләп, шөһрәт эзләп,
Язмыш куып, дан куып.
Әллә алдан, әллә соңлап
Узган юллар—сузылып.
Мин бәхет тә, дан-шөһрәт тә
Эзләмәдем... Хәзер соң.
Сагышларым үзе тапты,
Аз булмады шатлыгым...
Кунак булып килмим сиңа,
Туган җир!—кайтам әле.
Читләрдә «шиңгән» җилкәмне
Синдә турайтам әле.

*1999. Башкортостан.*

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# ТУКСАНЫНЧЫ ЕЛЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Кешелек җәмгыяте өчен гаять мәгънәле дата—2000 нче ел якынлашып килә. Бу дата тормышыбызның төрле тармаклары турында җитди уйлануларга этәрә, үткән чорга нәтиҗәләр ясауны, киләчәк елларга күз салуны сорый.

Шул уңайдан "Казан утлары" журналы редакциясе язучыларга һәм киң катлам укучыларга, әдәбият сөючеләргә гасырыбызны йомгаклаучы туксанынчы еллар әдәбияты турында түбәндәге сораулар белән мөрәҗәгать итә:

**—Соңгы ун-унбиш елда басылган кайсы әсәрләрне (проза, поэзия, драматургия, публицистика) әдәбиятыбыз казанышы дип саныйсыз? Ни өчен?**

**—Сезнеңчә, туксанынчы еллар татар әдәбиятында нинди уңай сыйфатлар бар? Ә кайсы яклар Сезгә ошап җитми? Киләсе гасырга Сез кайсы әсәрләрне алып керер идегез һәм татар әдәбиятында нинди сыйфатларның өстенлек алуын теләр идегез?**

**—Әдипнең җәмгыятьтәге урынын киләсе гасырда ничек итеп күз алдына китерәсез?**

## Галимҗан Гыйльманов:

Әлбәттә, соңгы ун-унбиш елда да татар әдәбиятының казанышы булырдай әсәрләр иҗат ителгән. «Перестройка» дигән халыкара исем астында тарихка күчеп барган дәвер бусагасында ук Мәхмүт Хәсәнов үзенең «Язгы ажаган» роман-эпопеясы белән дөнья шаулаткан иде. Чынлап та, яз башында уйнаган ажаган яктысы кебек булды ул әсәр рухи тормышыбыз өчен. Татарның горур холкын, шул ук вакытта аянычлы язмышын һәм драматик язмышын бу кадәр киң масштабта һәм психологик тирәнлектә айкап сурәтләгән башка берәр әсәр булды микән соңгы ун-унбиш елда? Кайчандыр Мәхмүт Галәү башкарган эшне Мәхмүт ага чынга ашырды. Татарны уятты. Аны тезләнгән җиреннән торырга, башын калкытырга мәҗбүр итте. Чыннан да, мөһаҗирлек кылу, дөнья гизеп, күчеп яки сөрелеп йөрү—татарның канында, язмышында шул. М. Хәсәнов халкыбызның бу миссиясен әдәби калыпка гына салып калмады, татарны берләштерү максатына хезмәт иттерде. Безгә юк белән баш катырасы түгел, бүген көн тәртибенә чыккан милли мәсьәләкне, милли идеяне «Язгы ажаган» герое Иргали агай сүзләреннән генә эзләргә кирәк.

Шуны да искәртәсем килә: әдәбиятчылар, тәнкыйтьчеләр романның зурлыгын, егәрлеген, актуальлеген, бер сүз белән әйткәндә, миллилеген тойса́лар да, бу хакта күп язсалар да, аңа чын, дөрес һәм тирән анализ биргән, әсәрнең поэтикасын, композициясен, образларын төпле итеп аңлаткан язмалар күренмәде. Әдәби тәнкыйтьтә азмы-күпме каләм тибрәткән кеше өчен «Язгы ажаган» әллә ни катлаулы

түгел. М. Галәү «Мөһаҗирләр»ендәге кебек, үзәктә—«Совет иле» дигән тегермәндә тартылып ятучы өч туган язмышы. Башка вакыйгалар, башка каһарманнар, ничек кенә булмасын, шушы «өчлек»кә, күп очракта бу өчлекнең үзәк персонажына—Газигә, аның язмышына килеп тоташалар.

М. Хәсәнов әсәрен укыган һәр кеше икеләнмичә әйтер: «Романның үзәк каһарманы Иргали»,—дияр. Ахыр чиктә, ул хаклы булыр. Парадокс шунда: язучы бу әсәрендә классик әдәбият гыйлеме таләпләре ягыннан аклап булмаслык композицион төгәлсезлек җибәргән—ул төп конфликтны, төп драма үстерелешен үзәк герой (Гази) белән бәйләмәгән, ә бәлки, Газинең сөйгән кызы Гөлүсәнең атасы—Иргали образының эволюциясе аша ачып салган. Шул рәвешле, композицион бөтенлекне ватып-җимереп читкә чыгып киткән иң гади персонаж үзәк каһарманга әверелгән. Ул каһарман-образ булып кына калмаган, милли бәйсезлек, рухи ныклык, халыкчан характер, ниһаять, хәтер символына кадәр үскән.

Әлбәттә, романның кайбер сюжет борылышларында мотивлаштыру (дәлил) һәм иҗади логика шактый зәгыйфь. Шул ук Иргалинең тормышын күтәрүе, баеп китүе аның үз характерыннан, үз мөмкинлекләреннән килеп чыкмый. Ахыр чиктә, бу мөһим дә түгел. Романның үзәгендә—язмыш мәсьәләсе, сынау һәм бу сынауны җиңү өчен мөһим булган рухи ныклык мәсьәләсе.

М. Хәсәнов тагын бер тапкыр раслап күрсәтте: иҗатта кануннар бик шартлы; догмага, аксиомага җиткерелгән иҗат алымнары, композицион принциплар белән чын, асыл иҗатның берниндн уртаклыгы да юк. Димәк, XX гасыр ахырында композиция, образ, стиль мәсьәләләренә кабат әйләнеп кайтырга, аны янабаштан, бу юлы инде заман таләпләренә яраклы рәвештә хәл итәргә тиешбез. Һәр яктан төгәл, камил, гармоник композиция янсә шома, төзек стиль яисә билгеле бер логикага гына буйсынган образлар—әсәрләр дә хәзер үзмаксат түгел. Мондый караш дөньяви әдәбиятка 20-30 еллап элек керә башлаган иде. Безгә аның җиле әлеге дә баягы «Перестройка» китереп җиткерде.

Туксанынчы еллар казанышы булырдай әсәрләр шактый икән әле. И. Салаховның «Колыма хикәяләре», Ф. Садриевнең «Таң җиле», Г. Тавлинның «Афәт» романнарын шундый әсәрләр рәтенә кертер идем. М. Мәһдиевнең «Бәхилләшү»е—шулай ук казаныш. Яшьрәклрдән Р. Сибәтнең «Исабәт», З. Хәкимнең «Гөнаһ», Ф. Әмәкнең «Гөлҗиһан» әсәрләре шулай ук вакыйга буларак кабул ителде. М. Хәбибуллинның тарихи романнарын да бүгенге әдәбиятыбыз казанышы дияр идем. Туфан Миңнуллин драматургиясе дә—горурлыгыбыз, казанышыбыз.

Яңа заман яңа каһарман көтә. М. Хәсәновның Иргалие—язмыш каһарманы, күпмедер дәрәҗәдә—гасыр каһарманы иде. Ә менә бүгенге көн—XX гасыр ахырындагы татар тормышы сәхнәсенә менгән каһарман-герой—кем ул? Аның шөгыле, тәртибе, холкы нинди? Уй-фикер офыклары, ният-хыялы, омтылышлары кая кадәр китә? Милли рухы ныклы, гомумән, милли хис-тойгысы бармы аның?

Минемчә, чын мәгънәсендә безнең чор көзгесе булырлык әдәби персонаж иҗат ителмәгән әле. Әмма бу юнәлештә ике кызыклы омтылыш булды. Аларның берсен 80 елларда ук Р. Мөхәммәдиев үзенең «Кенәри читлек кошы» романында Арслан Сәхипович образы аша сурәтләп күрсәтте. Икенче омтылыш ун елдан соң Т. Галиуллинның «Тәүбә» һәм «Элмәк» романнары герое Сәет Сакманов образында күренде. Нигездә ике язучы да безнең чор героен шактый ышандырырлык итеп сурәтләделәр. Иң мөһиме, бу әдипләрнең фикер сөреше өр-яңа иде. Бер журналга биргән җавабында Р. Мөхәммәдиев бу фикер юнәлешен үзе үк әйтеп бирде. «Кенәри—читлек кошы» романының уңай герое кем?—дип сорасалар: «Арслан Сәхипович»,—дип җаваплыйм, дигән иде ул. Бераз шаяртыбрак әйтелгән бу сүздә хак дөреслек бар, минемчә. Чөнки уңай герой, тискәре герой дигән төшенчәләр гасыр ахырында чынлап та көлке тоела башлады. Ә бит дөнья әдәбиятында бу күптән шулай инде.

Булмый ул андый геройлар—уңай гына яки тискәре генә... Без бу дәресне 100-150 ел элек үттек, ләкин әле һаман төшенеп җитә алганыбыз юк. Кеше бар. Заман бар. Язмыш бар. Милләт бар. Әлбәттә, мәхәббәт бар. Шушы берничә төшенчә бер төенгә бәйләнгән җирдә каһарман-герой туа. Нишлисең, XX гасыр ахырында татар җирлегендә иң гыйбрәтле каһарман булып Сәет Сакмановлар, Арслан Сәхипович тора. Моның өчен Т. Галиуллинны яисә Р. Мөхәммәдиевне гаепләп булмый. Яшәешебез шундый, заманыбызның чагылышы шундый. Үзебез ямьсез булгач,

күзгене гаепләп булмый, җәмәгать. Шулай да, мин үзебезне ямьсез генә дә диярга ашыкмас идем. Әлеге дә баягы, унай герой—тискәре герой мәсьәләсе инде бу.

Югарыда телгә алынган романнарның сәнгатьчә эшләнеше хакында сүз кузгатмыйм. Алар хакында күп мактаулар, шулай ук күп бәхәсләр булды. Шуны гына кабат искәртәм: Р. Мөхәммәдиев тә, Т. Галиуллин да бүгенге чор каһарманын тудырдылар, аны дөнья гизәргә чыгарып җибәрделәр. Бу каһарман татарның горурлыгы булырмы, әллә ояты булырмы—анысы икенче мәсьәлә, киләчәк күрсәтер.

Соңгы ун-унбиш елда дөнья күргән әсәрләрне күздән кичергәндә күңелдән һаман бер уй китми: бу вакыт аралыгында татарны дөньяга күтәреп күрсәтерлек әсәр язылмады шикелле. Татарның әдәби портреты тумый калды. Ч. Айтматов кыргызлар өчен әллә кайчан эшләп куйган эш бездә эшләнмәде. Милләтебезнең бөтен үткәнен, бүгенгесен, рухын, йоласын, холкын, бәхетен-бәхетсезлеген, кыскасы, бөтен язмышын, дөнья каршындагы бөек миссиясен сурәтләп күрсәтүче мөһим роман-эпопея язылмады. Сүз дә юк, аның чалымнарын Ә. Еникинең «Соңгы китап», А. Гыйләҗевнең «Йәгез, бер дога!», Г. Ахуновның «Идел кызы» романнарында, әлбәттә, М. Хәсәновның «Язгы ажаган»ында, Х. Камаловның «Түләнмәгән күз яше» әсәрендә, М. Галиевнең «Нигез»ендә, «Догалы еллар»ында, Р. Мөхәммәдиевнең «Сират күпере»ндә, М. Хуҗин, Ә. Гаффар, Ф. Садриев, Ә. Баян, Н. Гыйматдинова әсәрләрендә очратып куанган идек. Әмма тулы, бөтен һәм берәгәйле әсәрне күтәп ала алмадык. Чын «гасыр романы» язылмады...

Туксанынчы еллар татар әдәбиятында көчәеп киткән тенденцияләргә килгәндә, тарихилык белән бәйле сыйфатларның алгы планга чыгуы күренә. Бу бигрәк тә чәчмә әдәбиятта шулай. Тарихи роман жанры—татар прозасының йөрәгенә әверелде. Бу юнәлештә активлыгын һич киметмәгән Н. Фәттахка М. Хәбибуллин, Р. Батулла, Ж. Рәхимов, Ф. Латыйфи, З. Зәйнуллин, яшьрәкләрдән Р. Зәйдулла, Хәйдәр, З. Мәхмүди, Л. Зөлкарнәй килеп кушылдылар. Алар арасында иң активы, әлбәттә, Мөсәгыйть Хәбибуллин иде. Ел саен диярлек бер роман бирең барган бу әдип үз иҗат офыкларын, димәк, татар дөньясын да, Аттилла дәверенә кадәр киңәйтте.

Әлбәттә, тарихилыкны «тарихи роман», «тарихи әсәр» дип кенә аңларга ярамый. Тарихилык рухы, хәтер рухы, милли рух күпчелек чәчмә һәм тезмә әсәрләрдә, шулай ук драма жанрында (Т. Миңнуллинның «Шәҗәрә»се генә ни тора!) төп аһәң-интонацияне билгеләде; бу чорда әдәбият күгендә күтәрелгән төп символлар да шанлы да, кайгылы да тарихыбыздан алынды. Тарихилыкның уптым көчәюе, әлбәттә, иң элек милли үзаңның көчәюе, рухи мирасыбызга игътибарның артуы белән бәйләнгән иде. Халкыбызга «Идегәй» белән Исхакыйның кайтуы, Мөхәммәдьяр белән Кандалыйның яңа югарылыкка күтәрелүе, милли язма әдәбиятның офыклары, Кол Галидә генә тукталып калмыйча, С. Бакыргани һәм Ә. Ясәви иҗатларына кадәр киңәюе, ике томлык «Татар поэзиясе антологиясе» һәм биш томлык «Татар әдәбияты тарихы» басылып чыгу, ниһаять, «Татар мифлары» томнарының басыла башлавы—боларның барысы да татар әдәбиятында һәм мәдәниятендә тарихилыкның үсешенә импульс бирделәр. Тарихилыкның идея эчтәлеген җөмһүриятебездәге суверенитет марафоны билгеләде.

Соңгы ун-унбиш елда татар әдәбиятында күзәтелгән тагын бер матур күренеш—символизмга табан хәрәкәтнең көчәюе. Гомумиләштерүнең дәрәҗәсе үсте, образларның мәгънәви мөмкинлекләре артты, әдәби образ, образ булып кына калмыйча, фәлсәфи дәрәҗәгә күтәрелде, символик мәгънәгә ия булып, шуның белән, борынгылыктагы милли кодлар системасын яңартуга, кабат тудыруга хезмәт итә башлады. Бүгенге милли яңарыш чорында бу да бик мөһим иде.

Символ балладик фикерләү алымы прозага да, поэзиягә дә, драматургиягә дә бердәй үтеп керде. Прозада ул М. Юныс, М. Галиев, Ә. Гаффар, З. Мәхмүди, Р. Зәйдулла, Р. Сибат, З. Хәким әсәрләрендә аеруча нык чагылыш тапса, шигърияттә нигездә Ркаил—Ләис—Газинур—Ләбиб буынында, бигрәк тә Газинур иҗатында төп иҗат алымына әверелде. Яшьрәкләрдән Р. Сүлти белән И. Иксанова әсәрләрендә дә бу алым нык тамырланды. Т. Миңнуллинның атаклы Әлмәндәр—Әҗәл көрәшеннән башланган бу күренеш туксанынчы еллар драматургиясендә тагын да тирәнәйде, Туфан абыйга, З. Хәким үзенең «Кишер басуы» белән килеп кушылды.

Символик—образлылыкның югары дәрәҗәсе, ә образлылык—әдәбиятның нигез ташы. Бу—аксиома. Шикләнмичә әйтергә мөмкин: татар әдәбияты 90 елларда яңа

сыйфат баскычына күтәрелде, билгеле бер мәгънәдә дөньяви орбитага чыкты, чөнки символик иҗат дөнья әдәбиятында күпкә элгәрерәк тернәкләнгән иде. Дөресен генә әйткәндә, мондый иҗат алымы безнең өчен дә яңалык түгел. Гасыр башындагы символизм күренешенә әлегә кадәр күз йомып киләбез. Дәрдемәнд, С. Рәмиев, Ш. Бабич, Һ. Такташ, Г. Рәхим, соңрак Х. Туфан, Ә. Фәйзи иҗатларын кая куябыз? Габдрахман Сәгъдинең «Символизм турында» дигән монографик хезмәтен кая куябыз? Ул инде әллә кайчан символизмның төрки-татар әдәбият өчен иң кулай иҗат алымы булуын исбатлап күрсәткән иде. Без гасыр ахырында үз асылыбызга кайттык. Шул гына.

90 еллар татар әдәбиятындагы тагын бер уңай тенденция итеп психологик һәм аналитик иҗатның көчәюен күрсәтер идем. Шул ук М. Галиев, М. Хуҗин, Н. Гыйматдинова иҗатындагы, яшьрәкләрдән Ф. Әмәк, Н. Акмал, Хәйдәр, З. Мәхмүди, Ф. Яхин әсәрләрендәге үзәк каһарманнар эчке кичерешләренең тирәнлеге һәм киеренкелеге белән җәлеп итәләр. Иң мөһим үзгәреш шунда: иҗтимагый-сәяси, социаль психология бөтенләй диярлек юкка чыкты, аларга алмашка кеше психологиясе, гуманлылык һәм вөҗдан психологиясе килде. Катлаулы «җан диалектикасы» аша иманга ирешү—күп әсәрләрнең эчтәлеген һәм мәгънәсен билгеләде. Моңа тагын милли рух тынгысызлыгын һәм, әлбәттә, һәркемгә якын, кадерле мәхәббәт кичерешләрен өстәргә кирәктер.

Психологик иҗатка күңел баглаган язучыларның һәркайсы үзенчә кызык. М. Галиевтә ул аналитик фикерләү аша бара, еш кына җинелчә, җор ирония белән өртелгән була. М. Хуҗинда—җитди кичерешле, еш кына фәлсәфә белән ныгытылган, әмма мөлаем лирик чигенешләрдән дә азат булмаган психологизм. Н. Гыйматдиновада магик, табигый башлангыч көчле, ул юри кешенең иң авыр, хәсрәтле һәм инрәүле кылларын чиртә. Ф. Әмәктә—кичерешләр җылы, якты, әмма елатырлык дәрәҗәдә нечкә, халыкчан. Ф. Яхин йоланы, авыл психологиясен яхшы белә. З. Мәхмүди берьюлы берничә психилогик агымда иҗат итә, аның уй-фикеренә, кичерешенә, сурәт-образына бер укуда төшенеп җитеп тә булмый, чөнки ул кичерешләренең офыгын еш кына билгеләп тә тормый. Хәйдәр белән Н. Акмалда шагыйрьлек ташып тора, чәчмә әсәрләрендә дә алар бу язмыштан китә алмый изаланалар...

Татар прозасында мемуар жанрның активлашып китүен дә кайсы яклаптыр шушы психологик тенденция белән бәйләргә кирәктер. Соңгы ун-унбиш елда өлкән әдипләр, бер сүздә булып, гасыр дәвамында кичергәннәрен яздылар. Ләкин бу очракта да бер-берсен кабатлау булмады. Ә. Еникидә «(«Соңгы китап») милли, кайчакта социаль-психологик башлангыч алга чыкса, А. Гыйләҗевта («Йәгез, бер дога!») психологизм фәлфәси гомумиләштерүләр аша тормышка ашты. Г. Тавлинның «Афәт»ендә, И. Салаховның «Колыма хикәяләре»ндә сәяси режим иләгенә эләккән кеше кичерешләре алгы планга чыккан. В. Нуруллин үз кичергәннәрен әдәбиләштереп (гомумиләштереп) сурәтли, әмма, А. Гыйләҗевтан аермалы буларак, аның фикер сөреше, кичерешләр дулкыны өстәрәк ята, һәм ул күп очракта рәнҗү катыш үпкәгә кайтып кала. Ф. Бәйрәмованың, А. Хәлимнең публицистик прозасындагы ялкынлы һәм сугышчан психологизм хакында да күп язырга булыр иде. Бу да татар прозасы өчен яңалык булды. М. Мәһдиев иҗаты татар укучысы өчен яңалык түгел, әмма аның мәңгелеккә китәр алдыннан язып калдырган мемуарлары психологик һәм фәлсәфи тирәнлеге белән дә, халыкчан аһәңе белән дә Ә. Еники, А. Гыйләҗев иҗатына тиң.

Чәчмә әдәбиятта тагын бер сөенечле күренеш: жанрлар төрләнде, аларның күптөрле формалары һәм вариацияләре барлыкка килде. М. Галиевнең гыйбрәтле лирик һәм ироник кыйссалары, З. Мәхмүдинең лирик-фантастик повестьлары, Ф. Латыйфи белән Р. Якушның тарихи-фантастик әсәрләре, З. Зәйнуллинның хәрби Ф. Яхинның дини прозасы, роман-портертлар (Р. Мөхәммәдиев—«Сират күпере», К. Миңлебаев—«Бакый» һ. б.), З. Фәтхетдинов белән М. Насыйбуллинның детектив әдәбияты, К. Тимбикова, М. Маликоваларның хатын-кызлар күңеле генә тудыра ала торган шәфкатьлелек тәгълиматы—боларның барысы да соңгы чор әдәбиятыбыздагы жанр казанышлары булырга хаклы.

Соңгы ун-унбиш елда шигърияттәге үзгәрешләр кызык һәм гыйбрәтле. Чәчмә әдәбият уңаеннан югарыда телгә алынган барлык тенденцияләр дә шигърияттә үз чагылышын тапты. Шул ук тарихилыкны алыйк. Ә. Рәшитовның тарихи поэмалары—

безнең чорның казанышы түгел мени?! Мин бу фикеремне М. Әгъләмов поэмалары, Зөлфәт балладалары белән ныгытып, сипләп куяр идем. Мәрхүм Рәшит Әхмәтҗанов иҗаты бүген дә милләт йөрәген әрнетеп, сызлатып тора...

Иң элек шуны әйтергә кирәк: 60 елларда әдәбият мәйданына гөрләп килеп кергән шагыйрьләр үз егәрлекләрен югалтмыйча, шигърият дилбегәсен кулларында нык тоттылар. М. Әгъләмов белән Зөлфәт бу чорның йөзек кашы булды. И. Юзеев, Ш. Галиев, Г. Афзал, Роб. Әхмәтҗанов, Ф. Яруллин һ. б. өлкән шагыйрьләр, остазлар рәтенә күчеп, басылыбрак иҗат итә башладылар. Роберт Миңнуллин үзенчәлекле шагыйрь булып житеште. Лирикада, жыр жанрында һәм балалар шигъриятендә бердәй унышлы эшләү аны халык арасында иң танылган шагыйрьләрнең берсе итеп куйды. Бу елларда әдипнең иҗади кредосы да халыкчанлык һәм туган нигезгә тугрылык булды. Ркаил—Ләис—Газинур—Ләбиб буыны да ныклап аякка басты. Мәйданның тап уртасына чыкты. Әмма 90 еллар уртасында бу буын кинәт пассивлашты, алардан Ләбиб белән Газинур гына сайлаган юлларыннан тайпылмадылар. Ләис белән Ркаил соңгы вакытта проза ягына еш карыйлар, дөресен генә әйткәндә, алардан менә дигән прозаик та чыгачак. Әмма Ркаил белән Ләиснең шигърияттән китүе дә татар поэзиясе өчен югалту булыр иде.

«Ркаилләр буыны» йомшаруга, алардан бушап калган урынга икенче бер шигъри буын урнашып алды. Юк, шул алардан соң килүче яшь иҗатчылар буыны түгел. Бик кызык хәл: 70 елларда тернәкләнеп, 80 еллар башында юкка чыккан шигъри буын 90 елларда «уянып», «терелеп», «үсеп» китте. 90 еллар казанышы булырдай исемнәр бар иде бу «иске» яна агымда: Шәүкәт Гаделша, Илдар Хөсни, Фәиз Зөлкарнәй, Салих Маннапов, Габделнур Сәлимов, Асия Минһажева, Фәйрүзә Мөслимова, Фәния Габидуллина, Флюра Низамова... Мин үзем дә шул буыннан, шуна күрә аның гыйбрәтле тарихын бик яхшы беләм. Хәзер сер түгел: 70 елларда татар шигъриятe яңа үсеш баскычына күтәрелергә тиеш иде. Иҗади үсеш логикасы шуны сорый иде. Моның өчен бөтен шартлар бар иде. Дөресен генә әйткәндә, 60 елларда башланган шигъри яңарышның дәвам итүе, көчәюе иде бу. Гыйбрәт тә шунда: Р. Фәйзуллин—Р. Харислар буыныннан соң, 70 еллар башында ук дәррәү килеп чыккан М. Әгъләмов белән Зөлфәтне, аз гына соңрак Р. Миңнуллин белән Ф. Сафинны партия номенклатурасы (совет режимы) мәйданга чыгарып җибәрергә мәҗбүр булды. Әмма алар артыннан килүче Шәүкәт, Нияз, Флюра, Илдар, Фәйрүзә, Рафис һәм башка яшь каләм ияләренә бөтенләй диярлек нәшрият, редакция ишекләре ябылды. Язучылар берлегенә керү авырлашты. Аларның кайберләре, хәтта, суд, КГБ басымына дучар булды. Үз унышларыннан башлары әйләнгән өлкәнрәк буыннар да бу яшь төркемгә әллә ни игътибар бирмәде. Нәтиҗә бик тә аянычлы: «Әллүки» иҗат берләшмәсеннән күтәрелеп, олы әдәбият ишеге төбенә килеп баскан унбишләп исемнән ике генә исем—Нияз Акмал белән Рафис Корбан гына шигърият агымына эләгеп китә алды. Аларның Язучылар берлегенә, профессиональ әдәбиятка керүләре, беренче китапларын ничек бастырулары хакында үзе бер кыйсса язарга мөмкин булыр иде.

Бу буынны «йокыдан» милли хәрәкәт уятты. Бигрәк тә И. Хөсни (авыр туфрагы җиңел булсын) шушы милли кузгалышның үзәгендә кайнады, берничә ел эчендә басмага берничә жыентык әзерләде. Кызганыч, без үз каләмдәшебезне саклап кала алмадык. 70 елларда күнеленә ясалган җәрәхәтне төзәтә алмыйча бу дөньядан китте ул. Үләр алдыннан гына нәшриятка тапшырырга җыенган, дөнья күрми калган кульязмасы, әгәр басыла калса, 90 еллар татар шигъриятенең казанышы булыр иде. Минем моңа иманым камил. Соңгы еллар шигъриятенең икенче бер унышы—Шәүкәт Гаделша (Сибгатуллин) иҗаты. Себер урманнарыннан «адашып» килеп чыккан һәм милләт тамырына мәңгелеккә берегеп калган бу кызыклы шәхес шулай ук тиз арада ике жыентык бастырып чыгарды һәм шигърияттәге халыкчанлыкка, милли рухка яңа сулыш өрде. Ул борынгылыктан килүче саллы образ-символларны, аһәң-интонацияне кулланып, безне кешелек асылыбызга, табигый бишегебезгә кайтарырга омтылды.

Ниһаять, Фәиз Зөлкарнәй белән Салих Маннапов иҗатлары. Алар кайсы яклаптыр бер-берсенә охшаган да. Бәлки, фәлсәфи фикер тирәнлеге беләндер. Аналитик фикерләү алымнары беләндер. Шул ук вакытта алар—бер-берсенә бөтенләй охшамаган үзенчәлекле каләм ияләре дә. Фәизнең үз шигъри дөньясы, шигъри

офыклары, шигъри тарафлары бар иде. Аның шигырьләренә ягылып калган фикри һәм метафорик тирәнлекне киләчәктә анларга тырышачаклар әле. Ә менә Салих Маннаповның шигърияте́ндәге аналитик фикерләү алымнары жылы, мөлаем лирик аһән, халыкчан рух белән өртелгән.

Габделнур Сәлимовтан да олы иҗат өмет итәбез. «Аргамак», «Идел» журналларында дөнья күргән әсәрләре буенча да шикләнми әйтергә мөмкин—бу шагыйрьдә иманга тартылган татар кешесенең йөрәк тибеше, җан инрәве ишетелә...

90 елларда татар шигърияте күзгә күренеп яшәрде. Ана әллә каян гына бер төркем «мәктәп шагыйрьләре» килеп кушылды. Укучыга Энже Авзалова, Лиана Әмирханова, Гөлназ Гарипова, Луиза Янсуар, Гүзәл Исхаковаларның исемнәре мәгълүм булды. Алар да—милли кузгалыш җимеше.

Милли кузгалыш инде исемнәре дөньяга мәгълүм шагыйрьләр иҗатына да яңа төсмерләр бирде. Соңгы ун елда Харрас Әюп шигъриятебез казанышы булырдай милли, халыкчан лирик шагыйрь булып үсте... Рәшит Әхмәтҗанов та татарның горурлыгы, юк, җан-бәгыре кебек шәхес булып җитешкән иде... Хәтта «мәхәббәт шагыйре» Рәдиф Гаташ та актуаль лирикага каләм манып алды... Ренат Харисның соңгы чор иҗаты, бигрәк тә мәхәббәт лирикасы шагыйрьнең үзен генә түгел, татар шигъриятен дә яңа баскычка күтәрде... Равил Фәйзуллин иҗатындагы фикер һәм хис гармониясе тагы да җетерәк милли төсләргә баеды... Хатын-кыз шагыйрәләр арасында лидер барлыкка килде—Лена Шагыйрьҗан. Аның үтә дә милли шигърияте күп ир-ат шагыйрьләргә үрнәк булырлык. «Күңел шагыйрәсе» Фирая Зиятдинова да халык проблемаларына еш мөрәҗәгать итә башлады. Илсөяр Иксановада Сажидә апа Сөләйманова иҗаты чалымнары төсмерләнә...

Бездә «җырчы-шагыйрьләр» дигән «шигъри сыйныф» барлыкка килде. Аның башында Тукай бүләгенә ия булган Гөлшат Зәйнашева тора... Районнарда яшәп иҗат итүче шагыйрьләр дә сынатмады. Аларның барысы да үз төбәкләрендә милли хәрәкәттә актив катнашты, татар мәнфәгате өчен җанын да, бәгырен дә җәлләмәде. Менә алар: Нур Әхмәдиев, Илдус Гыйләҗев, Фәйрүзә Исмәгыйлова, Вәзих Фатыйхов, Рафаил Газизов, Рәшит Шиһапов, Мөхәммәт Мирза, Дамир Гарифуллин һ. б. Шулай ук Рәмис Аймәт, Танчулпан, Чулпан Зариф иҗаты йөзендә дә өр-яңа шигъри буын тернәкләнеп килә...

Соңгы ун-унбиш елда балалар әдәбияты да җанланды, үсте. Бу әдәби тарафта да кызыклы үзгәрешләр барды. Бу чорда балалар әдәбиятында төп фигуралар булып Халыкара Андерсен Дипломына ия әдипләр—Ш. Галиев белән Р. Миннуллин тордылар. Г. Сабитов киткәч, проза ятимләнеп калды. Шулай да Л. Ихсанова, Н. Әхмәдиев, Ж. Дәрзаман, Ф. Яруллин, Р. Хафизова, С. Сәүбанова, Л. Гыймадиева, Р. Зәйдулла, Ф. Яхин, И. Диндаров, Н. Сәйяр, А. Гыймадиев бу юнәлешне матур гына дәвам иттеләр.

Балалар драматургиясендә кызыклы үзгәрешләр бара. Монда да яңа исемнәр: Р. Корбан, Ш. Фәхретдинов, Гафур Каюмов, Х. Җәләл һ. б.

Кыскасы, әдәбиятның кайсы өлкәсен генә алып карасак та, матур үзгәреш, янарыш күрергә мөмкин. Бу, әлбәттә, яшәешебез, теләк-омтылышларыбыз белән турыдан-туры бәйләнгән. Тормыш мәгънәсе җан асрауга гына кайтып кала икән, бервакытта да олы әдәбиятка ирешә алмаячакбыз, талантларыбызны, казанышларыбызны да әрәм-шәрәм итеп бетерәчәкбез. Ә моның өчен күп кирәкми—милли тоемны югалту да җитә. Ничек тә милли рухыбызны югалтмаска иде безгә? XXI гасырда милли рухы булган әдәбиятлар гына исән калачак, милли идеясе булган халык кына яшәячәк. Язучыларның миссиясе дә заманның шушы үзенчәлегеннән чыгып билгеләнергә тиеш. Бу хакта без бүген үк уйлана башласак иде!

*Үткен мәсьәлә*

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬНЕ НИЧЕК «ТЕРЕЛТЕРГӘ?»

***Әдәбиятыбызның тәнкыйть жанрында эшләрнең торышы язучыларны гына түгел, ә күп санлы укучыларны, әдәбият сөючеләрне дә борчый. Бу хакта күпләр уйлана торгандыр. Эшне җанландыру буенча аерым тәкъдимнәр дә бардыр. Әнә шуларны ачыклау нияте белән редакция кайбер язучыларга мөрәҗәгать итте. Түбәндә аларның җавапларын урнаштырабыз.***



**Аяз Гыйләҗев:**

—Татар әдәбиятында әдәби тәнкыйть жанрын заман таләп иткән югарылыкка күтәрү ниятенә керешәбез икән, иң элек безгә кадрлар мәсьәләсен хәл итәргә кирәк булачак. Әдәбиятның гаять тә зур көч, үтә дә нечкә хасият икәнен аңлап эш итүче тәнкыйтьчеләребез бармы безнең? Басылып чыккан бик кызыклы әсәрләрне тулы мәгънәсендә һәм тирәннән, нечкәләп аңлый, тоя, кичерә аламы алар? Әгәр дә алай түгел икән—нишләп? Ни өчен безнең бу тармагыбызга без көткән, без теләгән кешеләр—башка жанрлардагы шикелле шулай ук талантлы каләм ияләре килми? Моның сәбәбе, сере нәрсәдә? Бу тармакка да талантлар килсен өчен хәзер нинди оештыру чаралары күрергә кирәк? Минемчә, менә шушы мәсьәләне бик конкрет хәл итәр вакыт килеп җитте.

Милләтебездә талантлы егетләр тумый тормыйдыр. Безгә бары тик тәнкыйтькә сәләтле егетләрне вакытында күреп алырга, аларны дәртләндерергә, иҗади ярдәм итәргә һәм бигрәк тә мөһиме: аларның яңа, кыю фикерләреннән куркып калмаска кирәк! Яшь тәнкыйтьчеләрнең канатларын кисмәскә кирәк!

Әнә шулай эшләсәк кенә зур әдәбиятыбыз янәшәсендә зур тәнкыйть барлыкка килер! Без үзебез тырышмасак, нәрсәнедер үзгәртмәсәк, көч куймасак—бер әйбер дә үзеннән үзе генә хәл ителмәс!

**Рафаэль Мостафин:**



—Әдәби тәнкыйть үссен өчен Язучылар берлегендә эшләрне җанландырып җибәрү кирәк. Андагы атмосфераны иҗади итү сорала. Төрле темаларга әдәби дискуссияләр, бәхәсләр, фикер алышулар, яңа әсәр тикшерүләр, аерым авторларның иҗади хисап бирүләре—менә болар барысы да әдәби тәнкыйть фикерен уятуга, аны җанландыруга

ярдәм итә ич. Әнә шундый сөйләшүләр һәм үзара бәхәсләр вакытында иҗатчы шәхесләрнең фикри дөньялары үсә һәм киңәя, язучы күңелендә яңа әсәрләр өчен кызыклы орлыклар, идеялар барлыкка килә. Авторларның рухи дөньясы байый, зиһене чарлана, акылы үсеш өчен яңа стимул ала.

Минемчә, без хәзерге демократик тормыш биргән бик күп мөмкинлекләрдән файдалана белмибез. Шуңа күрә әдәби тәнкыйть тә чын-чыннан үсеп, җанланып китә алмый.

Әлеге бәхәсләрне, дискуссияләрне оештыруда әдәби басмаларыбыз да активрак роль уйнарга тиеш дип саныйм.



**Марс Шабаев:**

—Оештыру эшләре бик кирәк, әлбәттә. Ләкин «тормышны өйләндерүче чыгыр башка» дигәндәй, бу мәсьәләдә дә без матди якка килеп чыгабыз. Иң төптә, иң үзәктә шул ятканын аңларга тиеш булабыз. Әдәби тәнкыйтьне үстерик дисәк—иң башта аңа түләүне арттырырга кирәк! Һич югында рецензия жанрына гына булса да түләү зуррак булырга тиеш. Югыйсә, күләмгә карап кына каләм хакы түләгәндә, кем инде рецензия язып утырсын? Аңа бит күпме көч куярга кирәк, никадәр вакыт сатарга кирәк! Билгеле ич инде: әгәр дә куелган зур хезмәт матди яктан акланмаса—ул эш бүтән эшләнми башлый, сүрелә. Безнең тәнкыйть тә әнә шул хәлдә.

**Зәки Зәйнуллин:**



—Басылып чыккан әсәрләр турында җыйналып сөйләшүләр, фикер алышулар кирәк. Менә, мисал өчен, берәү минем иҗат хакында гел әйбәт яктан гына уйлап йөри, ди. Ә икенче берәү, киресенчә, анда кимчелекләрне күбрәк күрергә мөмкин. Дөреслек кайда икәнен ничек белергә? Әлбәттә инде, бергә җыелып сөйләшә-сөйләшә, үзара бәхәсләшә-бәхәсләшә! Әнә шулай эшләгәндә генә чын хакыйкать ачыкланачак дип уйлыйм. Әле алай гына да түгел—андый сөйләшүләр вакытында бүтән кызыклы фикерләр дә, әдәбият һәм иҗат процессы турында яңа һәм кызыклы, гыйбрәтле күзәтүләр дә әйтеләчәк. Боларның һәммәсе тулаем иҗат эшебезгә ярдәм итәчәк. Яшь иҗатчыларга бигрәк тә булышачак бу.



**Роберт Әхмәтҗанов:**

—Безнең әдәбиятыбызда бик кызыклы, талантлы каләм белән язылган әсәрләр туа тора. Менә шулар турында конкрет сүз йөртү җитми. Поэзия тармагын гына алып карасак та, аның үзе эчендә әллә ничә жанр бар бит әле: поэмалар, балладалар, газәлләр, сонетлар... Әле генә санап үтелгән менә шушы жанрлар хакында аерым алып, эченә кереп, бар хасияттән тирән аңлап һәм укучыга да аңлатып язылган әдәби тәнкыйть мәкаләсе инде күптәннән күренгәне юк... Әллә инде алай язардай кешеләребез дә юкмы безнең? Күбесе фамилияләр саный-саный, өстән генә йөгереп үтәргә күнегеп киткәнме әллә?

Поэзия әсәрләре турында бигрәк тә әчкә кереп, нечкә тоем һәм матур тел белән язылган әдәби тәнкыйть әсәрләрен,—әйе, әйе, чын-чыннан әсәртердәй язмаларны—укыйсы килә! Ә коры һәм салкын мәкаләләр, буталчык фикерләр җыелмасын түгел!

## Мөдәррис Әгъләмов:



—Тәнкыйтьне үстерәбез дисәгез, журналда иң яхшы рецензияләргә конкурс оештырыгыз! Ләкин ул әдәби әсәрләргә, әдәби китапларга гына булсын. Файдасы тими калмас. Бездә каләмле кешеләр байтак бит әле. Аларда әдәби тәнкыйть белән кызыксынуын яңадан уятасы гына бар.

Аннан соң, кулыннан килердәй авторларга кызыклы эшләр кушыгыз. Аларга заказ биреп яздырыгыз! Әлбәттә, тиешле түләвен дә кызганмыйча.

## Мөдәррис Вәлиев:



—Минемчә, иң мөһиме—тәнкыйтьне кирәксенү, аның кирәклеген аңлау булырга тиеш. Ансыз үсеш була алмавын аңларга кирәк. Тәнкыйтьнең үсеш катализаторы, үсеш стимулы икәнен төшенергә тиешбез. Бу фикер безнең иҗади берлегебезгә дә, тулаем җәмгыятькә дә карый. Тәнкыйтьнең исән, тере булуы—җәмгыятьнең сәламәтлеген, аның дөрес юлдан баруын күрсәтеп тора. Шуңа күрә безгә иң башта тәнкыйтьнең статусын күтәрергә кирәк. Аның абруен үстерергә.

## Мансур Вәли:



—Элегрәк «Яңа әсәр укыгач...» дигән рубрика матбугатта еш кына күренә иде. Кызыклы хикәя, яисә шигырь бәйләме, яисә инде повесть басылганнан соң тиз генә арада аның турында оператив фикер бастыру ул—бик тә дөрес, бик тә кирәкле эш иде. Чөнки болай эшләгәндә әлеге әсәрнең эчтәлеге, байлыгы тирәнрәк, ныграк үзләштерелә. Ул укучыга да ярдәм итә. Бүтән иҗат кешеләренә дә мәсьәләнең яңа якларын ачу белән стимул һәм дәрт бирә андый язмалар. Республика газеталары, бигрәк тә әдәби басмалар, менә шуңа да игътибар бирсеннәр иде.

❋

*Тарих*

**Равил Фәхретдинов**
тарих фәннәре докторы

# КАЗАН ХАНЛЫГЫ

Заманында бөтен Евразиянең иң зур дәүләтләреннән саналган Алтын Урда XV йөзнең 20-30 елларында, төрле тарихи сәбәпләр аркасында, яшәешенең тәмам җимерелү чорына керә. Аның башкаласы Сарай шәһәрендә зур низаг, хакимият өчен соңгы көрәш башлана. Әүвәл Сәедәхмәт атлы бер ханзадә (Алтын Урданың кодрәтле ханы Туктамышның оныгы) дәүләтнең ханы Олуг Мөхәммәткә каршы күтәрелеп чыга һәм бу эштә аны Мәскәү кенәзе Василий II яклый. Ул да булмый, әлегрәк Алтын Урдага атаклы Идегәй тарафыннан хан итеп куелган Тимеркотлыкның оныгы Кече Мөхәммәт Сарай тәхете өчен яңа көрәш башлый, Олуг Мөхәммәткә каршы яу белән китә. Җитмәсә, ханның гаскәр башлыгы, шул ук Идегәйнең улы Нәүрүз хуҗасына хыянәт итә һәм гаскәренең иң зур өлеше белән Кече Мөхәммәткә кушыла. Шушы берләштерелгән көчкә каршы тора алмаячагын аңлаган Олуг Мөхәммәт төньякка күчеп китәргә мәҗбүр була.

Башта Олуг Мөхәммәтнең үзе хакында кечкенә генә бер белешмә биреп үтик. Ул Туктамыш хан белән бер нәселдән: бөек Чыңгыз ханның улы, Алтын Урда ханнары нәселенә нигез салган Җучиның унөченче улы Тукай-Тимер токымыннан, Туктамышның өченче буын туганнан туганы Әчкеле Хәсәннең улы. Олуг Мөхәммәт Алтын Урда белән 1421 елдан 1438 елга кадәр, ягъни унҗиде ел идарә итә, дәүләтнең элекке куәтен торгызу эшенә зур көч куя: аңа хәтле үк инде Җаек буе, Себер, Харәзем Алтын Урдадан аерылып чыксалар да, хан дәүләтнең иң зур өлешен, ягъни Иделдән алып, Кырымга хәтле булган Ак Урданы үз кул астына берләштерә. Шул чордан калган тарихи язмаларда Олуг Мөхәммәт Алтын Урданы кулында тотып торучы кодрәтле хан дип атала.

Әмма, югарыда әйтелгәнчә, Сарай хакимияте өчен соңгы зур көрәш башланып, Олуг Мөхәммәт 1438 елның көзендә күченеп китә. Ул үзенең уллары һәм калган гаскәре белән Үкә (Ока) елгасы буендагы Белев дигән урыс шәһәре янына барып чыга, ә ул шәһәр Алтын Урда биләмәсендә була. Василий II ханга каршы зур гаскәр җибәрә, әмма Олуг Мөхәммәт аны тар-мар итә. Бер елдан хан Мәскәүне камый, ләкин ала алмыйча кире чигенә һәм Түбән Новгородка килеп, аның иске өлешендә урнаша. Ә аның элек-электән кечерәк бер мөселман шәһәрчеге булуы мәгълүм. 1445 елның җәендә Олуг Мөхәммәт үзенең уллары Мәхмүтәк белән Якубны Василий II гә каршы яуга җибәрә. Яклар Суздаль шәһәре янында очрашалар, татарлар урыс гаскәрен тар-мар итәләр, хәтта бөек кенәзнең үзен әсир итеп, "Нижний"га, әтиләре янына алып кайталар.

Шул ук елның август ахырында Олуг Мөхәммәт Кормыш шәһәрчегенә килә (ул ныгытма хәзерге Чувашстан җирендә урнашкан була). Октябрь башында хан Василий II не иреккә җибәрә һәм Казанга юнәлә. «Казан тарихы» исемле күпләргә мәгълүм урыс язмасында ханның шул вакытта, юлда олы улы Мәхмүтәк тарафыннан үтерелүе хакында әйтелә. Гәрчә башка чыганакларда андый мәгълүматның теркәлү очрагы юк. Ләкин, чыннан да, Олуг Мөхәммәтнең исеме шуннан соң бер генә тарихи чыганакта да искә алынмый. Үтерелгәнме ул, әллә үз үлеме белән вафат булганмы—бу хәл әлегә

кадәр билгесез булып кала бирә. Мәхмүтәк энеләре һәм әтисенең гаскәре белән килеп, Казанны ала, аның бие Галибине үтереп, Казан тәхетенә утыра. Менә шуннан яңа олы дәүләткә—Җучи нәселеннән булган хан җитәкчелегендәге Казан ханлыгына нигез салына. Бу тарихи вакыйга 1445 елның 1 нче, яңа стиль белән 14 нче октябрендә була.

Олуг Мөхәммәт исә, рәсми рәвештә Казан ханы булмаса да, аның исемен Казан тарихыннан аерып карап булмый. Ул—Казан ханнарының нәселенә нигез салган кеше. Һәм шул яңа дәүләтнең барлыкка килүе, әлбәттә, Алтын Урданың соңгы ханы Олуг Мөхәммәтнең төньякка килеп чыгуы һәм аның җитәкчелегендә барган мәгълүм тарихи вакыйгалар белән бәйле. Җитмәсә, аның токымы Казан ханлыгы белән бу дәүләтнең беренче—тотрыклы һәм куәтле чорында идарә иткән.

Казан ханлыгы Урта Иделдә гаять зур мәйданны биләп торган. Көнчыгыш чиге Урал тауларына барып җиткән һәм Себер ханлыгы белән тоташкан. Көньякта Нугай Урдасының киң далалары җәелеп киткән һәм анда, табигый ки, төгәл генә чик булмаган—даланы әле бу, әле теге як бер дәрәҗәдә диярлек файдаланган. Көнбатыш чик төгаен билгеле: урыс биләмәләре белән ике арада Сура елгасы аккан, ә инде төньяктагы җирләр Нократ һәм Кама елгаларының урта агымы киңлекләрендә тайга яннарына кадәр сузылган булган.

Казан дәүләте ул чорның күренекле мәмләкәтләреннән берсе. Монда халыкның укымышлы затлары туплана, әдәбият, сәнгать чәчәк ата. Һәр шәһәрдә мәктәп-мәдрәсәләр гөрләп эшли. Китап күчереп язу, хаттатлык сәнгате иң югары кимәлгә ирешә.

Дәүләтнең төп халкы—татарлар. Алардан башка, Казанга буйсынып күрше чуаш, мари, мукшы, удмурдт һәм башкортлар яшәгәннәр. Ханлыкның үзәк җирләре—мәшһүр Казан арты һәм Иделнең көнбатышындагы Тау ягы. Башкаласы—Казан, кечерәк шәһәр һәм ныгытмалары: Арча, Алат, Иске Казан, Чаллы, Алабуга, Лаеш, Мамадыш, Тәтеш, Җөри, Таңгачы. Соңыннан, 1552 елда Казан урыс тарафыннан яулап алынгач, Мәскәү соборында торган нотыгында Явыз Иван (Иван Грозный) Казан җиренең 30 шәһәр һәм кальгакирмәнен алганлыгы хакында әйтә. Аларның күбесе шул вакытта җимерелгән, ул урыннарда урыс шәһәрләре һәм авыллары барлыкка килгән—кайберләренең исемнәрен әле генә телгә алдык.

Казан яулап алынып 13-15 ел үткәч, Мәскәү хөкүмәте тарафыннан төзелгән исәпкә алу кенәгәләрендә Казан ханлыгы җирендәге 700 татар авылы теркәп куелган—шуларның иң зур күпчелеге—биш йөзе Казан артына кагылышлы (йөз иллесе Тау ягында). Бу җирләрдә, бигрәк тә, Ашыт һәм Казан суы буйларында, Казан ханлыгы чорыннан калган язулы ташлар бик еш очрый. Бүгенге көнгә сакланган җитмешкә якын борынгы каберлектә йөз илледән артык шундый таш мәгълүм. Байтагы «олуг-солтан» («солтан әлгали»—ханнар нәселеннән килүче затларны шулай атаганнар), би, морза, бикә, бикәч, шулай ук шәехләр каберенә куелган әлеге ташлар халкыбыз тарихының, аның теле һәм таш кисү-бизәкләү сәнгатенең бәһа биреп бетергесез, кадерле ядкарьләре булып саналалар.

Казан ханлыгының, бигрәк тә әлеге шул Казан артының җирләре хакында, аларның гаҗәеп матур, бай булганлыгы, авылларның күплеге, йортларның төзеклеге турында шул җирләрне заманында үз күзләре белән күргән кешеләр таң калып язганнар. Һәм юкка гына урыс дворян идеологы Иван Пересветов Явыз Иванга җибәргән хатларында Казан ханлыгын «җәннәт җире» дип атамаган, юкка гына аны тизрәк яулап алырга чакырмаган.

Әлбәттә, шундый бәрәкәтле җирдә урнашкан Казан ханлыгының икътисады, аның хуҗалык төрләре—игенчелек, терлекчелек, сәүдә һәм һөнәрчелек зур үсеш алган. Җир мул уңыш биргән, урман-дала дөньясына хас булган бөтен культуралар да игелгән. Җир биләүнең, тарханлыкның нигезен Алтын Урда чорыннан килүче сөюргаллык хокукы тәшкил иткән—бу хакта Ибраһим һәм Сәхибгәрәй ханнарның бүгенге көнгә кадәр сакланып калган ярлыкларында ачык әйтелгән.

Мал-туар үрчетү, терлек асрау, бигрәк тә җылкы көтүләре тоту, игенчелек, сунарчылык, бал җыю, Идел, Кама һәм аларга коючы суларда күпләп балык, шул исәптән кыйммәтле мәрсин балыклары тоту хуҗалык итүнең төп төрләреннән санала. Һөнәрчелекнең ул чор өчен мәгълүм барлык төрләре дә Казанда зур үсеш ала. Төзелеш-архитектура эшләре дисеңме, зәркән (ювелир) сәнгате, корал эшләү дисеңме, гомумән, тимерчелек, агач эше, күн эшкәртү, тукучылык, затлы һәм гади савыт-саба ясау—боларның һәммәсенең Болгар һәм Алтын Урда чорларыннан килүче төпле нигезе, тотрыклы традициясе бар.

Татар дөньясының зур бер өлеше булган Казан ханлыгын, аның башкаласы Казан шәһәрен шул ук татарның канына сеңгән сәүдәсез, алыш-бирешсез һич кенә дә күз алдына китереп булмый. Дәүләтнең башлангыч чорыннан, ягъни XV йөз уртасыннан ук инде Казан дөньяның шактый гына илләре белән алып барылган транзит сәүдәсенең үзәге буларак мәгълүм. Итил, Болгар, Сарайлардан килүче бу бай традиция дә бик тотрыклы була һәм дәүләт яшәешенең соңгы елларына кадәр диярлек дәвам итә. Бу халыкара сәүдәнең географиясе шулай ук бик киң: көнбатышта дөньякүләм мәшһүр диңгезчелек һәм сәүдә үзәге булган Фландриядән алып көнчыгышта Фарсыга кадәр.

Дәүләт белән идарә итү һәм иҗтимагый төзелешнең нигезе Алтын Урдага барып тоташа. Шул ук Җучи нәселеннән булган хан (бер генә татар ханлыгында да җучилылардан башка династия юк—мин моңа аерым басым ясап әйтәм!), хан карамагындагы диван, аның да иң күренекле һәм Себердән алып Кырымга хәтле булган бөтен татар дөньясы өчен хас атаклы карачыбиләр токымы. Ягъни Ширин, Барын, Аргын, Кыпчак кавеме. Бер яктан, Алтын Урда, икенче яктан, Казан һәм Кырым ханнарының ярлыклары буенча мәгълүм булган идарәче даирәләр, аларның һәртөрле ярдәмче-хезмәтчеләре, бүгенге тел белән әйтсәк, дәүләт чиновниклары, шул ук җыем-салым төрләре. Әлбәттә, кайбер вазифалар, керем белән чыгым, хокук һәм бурыч төрләренең кайберләре гамәлдән төшеп калган, алар урынына яңалары да туган. Әмма нигез, система Алтын Урдадагыча сакланган.

Шундый ук сүзләрне хәрби эш, гаскәр төре хакында да әйтеп булыр иде. Дөрес, Казан ханлыгында Болгар дәүләте хәрби сәнгатенең мөһим билгеләре дә булган, мәсәлән, крепость-кирмәннәр һәм ныгытмалар төзү эше. Ләкин бу Казан ханлыгының Болгар белән географик якынлыгына, ягъни аларның төньяктагы урман-дала җирләрендә утыруларына бәйле. Шул ук географик мохиттагы Урыс дәүләтенең крепость-ныгытмалар төзү системасы да Болгар белән Казанныкыннан әлләни аерылмый.

Урта гасырларга хас булган барлык салкын корал төрләреннән тыш, Казан ханлыгында инде утлы корал куллану хакында мәгълүматлар тагын да тулырак. Бу чорда Казанда инде туплар гамәлдә була, ләкин аларның, ягъни татар тупларының 1552 елда гәрселдәмәвенең аянычлы сәбәбе бар—ул сатлыкҗан Шаһгалинең касәфәтенә бәйле. Казаннан киткәндә хыянәтче хан дары мичкәләренә су агызып китә.

Ханлыкның башкаласы Казан каласы үзенең матурлыгы, төзеклеге, тышкы күренешенең үзенчәлеге белән илгизәр-сәяхәтчеләрдә һәм сәүдәгәрләрдә онытылмас тәэсирләр калдырган. Тау башына салынган зур хан сарае һәм зиннәтле ташпулатлар, биек-биек манаралы Җамигъ мәчет, мәхәллә саен айларын күккә чөйгән башка мәчетләр, үзәнлектә яшеллеккә күмелеп утырган бистәләр, шуларның һәммәсен бер шәһәр итеп әйләндереп алган, әле тауга күтәрелеп, әле иңкүлеккә төшеп сузылган шәһәр курасы, ягъни ныгытма-стенасы, аның биек хәрби машлары һәм киң, атаклы капкалары, шулар аркылы узып, еракларга сузылган Кырым, Нугай, Төмән юллары, ул олы юллардан узган сәүдә кәрваннары Казан каласына, аның тирә-юненә кабатланмас матурлык биргәннәр. Бер яктан тезелешеп киткән Кабан күлләре, икенче яктан бормаланып аккан Казан суы, ә арырак җәелеп яткан киң Идел белән әйләндереп алынган борынгы Казан ераклардан бик матур булып күренеп торган.

Казан ханлыгының матди, бигрәк тә рухи мәдәнияте хакында инде

шактый язылды. Мин, тарихчы-археолог буларак, үзем якын белгән өлкә—матди культура буенча ике генә мәсьәлә хакында кыскача әйтмәкче булам. Казан ханлыгы чорыннан Казан шәһәрендә берни дә сакланып калмаган, барлык булган корылма-биналар 1552 елда яныл-җимерелеп беткәннәр дигән фикер озак еллар дәвамында фәндә өстенлек итеп килде. Ләкин бу ышандырмый иде, дәлилсез иде. Озак тикшеренүләр һәм эзләнүләрдән соң, бу фикер белән килешә алмаган бер даирә урыс һәм татар галимнәре Казан кремлендә сакланып калган берничә архитектура истәлегенең татар чорына караганлыкларын исбат иттеләр.

Шуларның берсе—риваять-легендаларга кергән, бәет-мөнәҗәтләрдә әйтелгән, татар халкының ханбикәсе, милли батыры исемен йөртүче мәшһүр Сөембикә манарасы. Үзенең архитектурасы, төзелеш алымнары, бизәкләү ысуллары буенча, бу атаклы корылма нәкъ менә милли сәнгатьнең үзенчәлекле дә, ачык та истәлеге, һәйкәле булып санала. 1990 елда бу гүзәл манара өстенә ай куелды, дөресрәге, әүвәлдә булган ай торгызылды, гасырлардан килгән гадәт буенча, татар халкы ел саен манара янына Коръән укырга йөри, шунда җыелып Хәтер көнен үткәрә башлады.

Бүгенге Казан кремлендә татар чорыннан сакланып калган икенче истәлек—Нурали мәчете бинасы. XVI йөзнең атаклы карачы-бие, Казан ханнарының якын киңәшчесе һәм ярдәмчесе, хөкүмәт башлыгы Нурали Ширин исемен йөрткән бу мәчет, Казан яулап алынгач башта корал склады, аннан «Введение» чиркәвенә әйләндерелә, ә 1854 елда Дворцовая церковь исеме белән урыс-православие архитектурасы стилендә реставрацияләп куела. Гомумән, Казан кремлендә бүгенгәчә сакланган XVI йөз таш архитектура истәлекләренең башкалары да җентекләп, чын профессиональ тикшерүне көтеп яталар. Казан кремлен реставрацияләү, аның тарихи йөзен саклау мәсьәләсе шул чор тарихы буенча белгечләр белән берлектә эшләүне таләп итә!

Казан ханлыгының тышкы сәясәте Евразиянең шактый гына илләре белән тыгыз бәйләнешне эченә алса, Урыс дәүләте белән булган мөнәсәбәтләр тарихта аерым урын тота. Бу тарих ае-елы, кайчакта көне-сәгате белән дә билгеле булган өчен генә түгел, ә иң мөһиме, дөресрәге, иң аянычы—бу мөнәсәбәтләрнең ахыр чиктә татарның дәүләтчелеге югалуга китерүдә, халкыбызның язмышын фаҗигага дучар итүдә. Бу тарих—бик тә катлаулы һәм четерекле, дөньякүләм вакыйгаларга, атаклы шәхесләргә ифрат бай, шул ук вакытта, җан өшеткеч, үзәкләрне өзгеч тарих. Әлбәттә, аның хакында кыска гына язмада тулы мәгълүмат бирү мөмкин дә түгел. Шуңа күрә, без ул тарихның төп дәверләренә һәм иң зур вакыйгаларына гына тукталырбыз, иң олуг вә иң фаҗигале шәхесләре белән генә танышырбыз.

Казан ханлыгы яшәвенең башлангыч чоры, Мәхмүтәк идарә иткән егерме ел (1445-1465), нигездә, тыныч үткән. Кайбер чыганаклардан күренгәнчә, Мәскәү алдында Казанның абруе зур булган. Хәтта, Василий II не азат иткән өчен урыс татарга контрибуция түләп торган. Бөек кенәз белән бергә шул чакта Мәскәүгә 500 татар килә, алар башкалада һәм бүтән шәһәрләрдә төрле идарә эшләренә куелалар. Кайбер урыс шәһәрләрендә мәчетләр дә төзелә башлый. Казан ханлыгының Мәхмүтәк чоры бу дәүләтнең оешу, ныклап торып аякка басу, икътисадының, сәяси һәм хәрби куәтенең ныгу, үсеш чоры ул.

Бу күтәрелеш дәвере Мәхмүтәкнең кече улы Ибраһим тәхеттә утырганда да дәвам итә (1467-1479; ике арада кыска гына вакыт Ибраһимның абыйсы Хәлил хан булып ала, әмма ул үлеп китә). Ибраһим Казанның иң кодрәтле ханнарыннан һәм ул, дәүләтнең тотрыклылыгын, көч-куәтен арттыруда зур уңышларга ирешә. Гомумән, Мәхмүтәк һәм Ибраһим ханнар идарә иткән утыз биш еллык дәвер татар халкы һәм аның дәүләтчелеге тарихында иң якты чорларның берсе. Ибраһим хан идарәсенең соңгы елларында Урыс дәүләтенең экспанционистик омтылышлары башланса да, хан аларга лаеклы каршылык күрсәтеп торган. Мәскәүнең андый сәясәте Василий II үлгәч тәхеткә утырган улы Иван III исеме белән бәйле. Урыс дәүләте белән кырык ике ел идарә иткән бу талантлы, әмма рәхимсез дәүләт эшлеклесе булган кенәзнең

эшчәнлеге башка дәүләтләрнең эчке эшләренә турыдан-туры тыкшыну юлы белән алып барыла башлый. Һәм бу сәясәт Казан ханлыгына карата мөнәсәбәттә үзенең бөтен асылы һәм мәкере белән гәүдәләнеш таба.

Иван III Казанга 7 тапкыр яу оештыра, соңгысы, 1487 елдагысы, Казанны вакытлыча алу белән тәмамлана. Бу походларның баштагылары, әле Казан тәхетендә Ибраһим хан утырганда, урыс өчен бик тә уңышсыз тәмамлана. Мәсәлән, 1469 елда Казанга ике юл белән—Идел буйлап һәм төньяктан әйләнеп килгән Мәскәү гаскәрен татарлар бер-бер артлы камап алып, тар-мар итәләр. Су юлы белән килгәнен хан үзе флотилиясе белән каршылый һәм урысның тетмәсен тетә.

Ибраһимнан соң хан булып калган олы улы Илһам (1479-1487) әтисенең сәясәтен дәвам иттерә. Моны ошатмаган Иван III Казанга берсе артыннан берсе походлар оештыра. Соңгысы, ягъни 1487 елдагысы нәтиҗәсендә Казан алына, ләкин ханлык бетерелми, аның каравы Илһамны, аның әнисен, хатынын һәм ике энесен—Мәликтаһир белән Ходайголны әсирлеккә алып китеп, Вологда җиренә сөргенгә сөрәләр. Илһам үзе, әниләре Фатыйма, Мәликтаһир тиздән шунда үләләр, Ходайголны һәм Мәликтаһирның ике улын чукындыралар. Ходайгол Петр Ибрагимович исеме белән Иван III гә хезмәт итәргә мәҗбүр була, хәтта аны бөек кенәзнең сеңлесенә өйләндерәләр. Кабере билгеле—Мәскәү кремленең Архангель соборында, урысның бөек кенәзләре һәм патшаларының каберләре белән янәшә.

Ибраһим хан белән аның икенче хатыны, атаклы Нурсолтанның өч баласы була: уллары Мөхәммәтәмин белән Габделлатыйф, кызлары Гәүһәршад. 1487 елда тәхеткә Мөхәммәтәмин утыртыла, ул 1496 елга кадәр идарә итә, һәм шуннан Казан өстеннән Мәскәү протектораты башлана. Бу сәяси бәйлелеккә Казанның Шәрык «партия»се чик куярга тырышып карый, Мөхәммәтәминне тәхеттән төшереп, аның урынына Себер ханзадәсе Мамукны чакыралар. Әмма бер ел узуга аннан да ваз кичәләр. Шәрык фиркасының башлыгы Киләхмәт Мәскәү ягына күчә. Аның яңа хуҗалары Казан тәхетенә Габделлатыйфны утырталар, тик яңа хөкемдар аларга буйсынмый, Казанның мөстәкыйльлек сәясәтен үткәрә башлый. Аңа бу эштә әнисе Нурсолтанның йогынтысы көчле була. Чөнки Нурсолтан Ибраһим хан үлгәч, Кырым ханы Миңлегәрәйгә кияүгә чыга, аның улы Габделлатыйф, Мөхәммәтәминнән үзгә буларак, Кырымда әнисе янында тәрбияләнә. Мөхәммәтәмин исә, Казан ханы булганчы, Мәскәү янындагы Звенигород шәһәре белән идарә итә.

1502 елда Иван III тарафыннан җибәрелгән урыс илчелеге, сатлыкҗан Киләхмәт булышлыгы белән Габделлатыйфны тәхеттән төшереп, Мәскәүгә озата (Киләхмәт Казан хөкүмәтенең башлыгы була). Тәхеткә яңадан Мөхәммәтәмин утыртыла. Ләкин урыс кенәзләренең көткәне акланмый, яңа ханның сәяси һәм дәүләт эшчәнлеге бөтенләй үзгәрә, ул Казанның бәйсезлеге өчен көрәш юлына баса. Мөхәммәтәмин бик җентекләп сугышка әзерләнә, моны Мәскәү дә, ялчысы Киләхмәт тә сизми калалар. Җитмәсә, авыру Иван III соңгы көннәрен кичерә, анда инде Казан кайгысы булмый һәм ул 1505 елда үлә. Бер елдан соң аның улы, Мәскәүнең бөек кенәзе Василий III Казанга флотилиядән һәм коры җир гаскәреннән торган 100 меңлек армия җибәрә, әмма Мөхәммәтәмин аны 25 июнь көнне Казан янында тәмам тар-мар китерә. Кайбер чыганакларда күрсәтелгәнчә, урыс гаскәреннән бары тик 7 мең кеше генә исән кала.

Әмма хан үзенең шундый зур җиңүен ныклап беркетеп куя алмый. Аның шуннан соңгы тормышы чагыштырмача тыныч үтә һәм ул 1518 елда 48 яшендә үлеп китә. Аның үлеме белән Олуг Мөхәммәт буыны өзелә; шуннан бер генә ел элек сөргендә Габделлатыйфны да үтергән булалар.

Тәхеткә кемне утырту мәсьәләсе тагын көн тәртибенә килеп баса. Дөрес, әле ул вакытта Ибраһимның кызы Гәүһәршад, хәтта Нурсолтан үзе дә исән булалар, җитмәсә Миңлегәрәй, ягъни Нурсолтанның ире, үлеп китә. Димәк, ханбикә Кырымнан Казанга кайта алган булыр иде. Ләкин татар дөньясында дәүләт башына хатын-кыз җәмгатен кую гадәте булмаган.

Нурсолтанның Кырымда Миңлегәрәйдән Мөхәммәтгәрәй белән

Сәхибгәрәй атлы ике улы була (кайбер тарихчылар аларны ханбикәнең үги уллары дип атыйлар.). Олысы үзенең энесе, ягъни Сәхибгәрәйне, Казан ханы итеп куярга дип Василий III гә мөрәҗәгать итә, тик Мәскәү кенәзе моңа риза булмый, ул Кырым-Казан берлегеннән курка. 1519 елда Казан тәхетенә Мәскәүдә урыс тәрбиясе алган Касыйм ханзадәсе, 13 яшьлек Шаһгали утыртыла. Тышкы кыяфәте белән дә бик ямьсез, хәтта җирәнгеч, Мәскәү марионеткасы булган бу адәмне Казан кабул итә алмый—ул монда өч тапкыр хан итеп куела, өчесендә дә татарлар аны куып җибәрәләр. Ул хәтта Мәскәү яклы татарлар өчен дә күңел кайтаргыч бер кеше була.

1521 елдан 1549 елга кадәрге чорда Казан тәхетенә вакыты-вакыты белән Шаһгали һәм аның энесе Җангали утыргалап алсалар да (соңгысы, дәүләт эшенә җинаять иткәне өчен, казанлылар тарафыннан җәзалап үтерелә), алар ханлыкның үсүе, мөстәкыйльлеге өчен тарихта калырлык бернинди эш тә майтара алмыйлар. Бу чор—җучилыларның, ягъни Кырымдагы Гәрәйләр нәселеннән булган Сәхибгәрәй һәм аның туганының улы Сафагәрәй идарә иткән заман буларак тарихи әһәмияткә ия. Казан, ниһаять, Мәскәү йогынтысыннан аерылып, кабат мөстәкыйльлеккә аяк атлый. Дәүләт иркенләбрәк сулыш ала, ныгый, көчәя. Бу юнәлештә Сафагәрәй хан үткәргән сәясәт, аның максатчан эшчәнлеге бик тә нәтиҗәле була. Ул, мәсәлән, Казанның мәйданын зурайта, аның халкы шактыйга арта, шәһәрнең хәрби ныгытмалары яңартыла, Мәскәүнең 1524, 1530 һәм 1545 елгы походлары кире кагыла.

Сафагәрәй, ни сәбәптәндер, 1549 елда үлеп китә һәм шуннан соңгы фаҗигале вакыйгалар күпләргә мәгълүм: хан итеп Сафагәрәйнең ике яшьлек улы Үтәмешгәрәйне куялар, аның өчен әнисе Сөембикә идарә итеп тора, ләкин аларның икесен дә 1551 елда Мәскәүгә әсирлеккә алып китәләр. Шунда Үтәмеш Александр исеме белән чукындырыла, 1564 елда 18 яшендә үлеп китә; кабере Петр Ибраһимович, ягъни Ходайголныкы, һәм урыс патшаларыныкы белән янәшә—кремльнең Архангель соборында. Сөембикәне көчләп әшәке затка, инде Казаннан соң Касыйм ханы булган Шаһгалигә бирәләр, гомере шунда бәхетсезлектә өзелә, кабере төгәл билгеле түгел.

Урыс гаскәре 1549 һәм 1550 елларның кыш һәм яз айларында яшь патша Иван Грозный җитәкчелегендә Казанга ике поход ясый, ләкин алар уңышсыз тәмамланалар. Шуннан соң Казан ханлыгын яулап алуның генераль планы эшләнә, аны төзүдә Мәскәүнең дәүләт һәм хәрби җитәкчеләре, һәртөрле сугыш чукмарлары, чит ил белгечләре-минерлар, хәтта Казанның хәрби-саклау эшләре белән яхшы таныш булган кайбер сатлыкҗан татарлар да катнаша.

1551 елның май-июнь айларында Зөя елгасы тамагында урыс Свияжск крепосте төзеп куя. Бу әйбер Казан өчен көтелмәгәндә, аның «борын төбендә» эшләнә: булачак крепостьның һәр корылмасын, һәр бүрәнә һәм тактасын җентекләп эшләп, җайлап, башта Углич шәһәре янында корып карыйлар һәм сүтеп, билгеләр куеп, Идел буйлап булачак урынга китерәләр. Егерме сигез көн эчендә корып та куялар. Казан ханлыгының көнбатыш өлеше—Тау ягы, шулай итеп, җайлы гына Урыс дәүләте кул астында торып кала. Казан гаять мөһим бер икътисадый өлкәдән, тупланачак гаскәрнең зур гына өлешеннән, уңайлы, стратегик ноктадан мәхрүм була. Бер елдан соң, 1552 елның июнь аенда, яңа төзелгән стрелецлар полклары белән тулыландырылган, хәрби туплар белән баетылган йөз илле мең кешелек урыс армиясе Явыз Иван җитәкчелегендә Казанга юнәлә. Свияжскига тоткарлыксыз килеп җитеп, ярты ай чамасы ял итеп һәм сугышка хәзерлек үтеп, урыс гаскәре 23 август көнне Казанны камап ала.

Шул ук көнне татарлар дошманның алгы сафларына каршы беренче һөҗүмнәрен ясап карыйлар, әмма урысларның чагыштыргысыз күп санлы булуы сәбәпле уңай нәтиҗәгә ирешә алмыйлар. Берничә көн үткәч, урыс армиясенең Горбатый-Шуйский исемле кенәз җитәкчелегендәге зур берләшмәсе татарларның шәһәр янындагы Явыш һәм Япанча биләр оештырган иреклеләр гаскәрен (ополчениесен) җиңелүгә дучар итә. Икенче бер урыс полкы сугыша-сугыша Арчага кадәр барып җитә һәм аннан, зур табышлар

тәяп, күп санлы әсирләр алып кайта. Ул әсирләрне шәһәр ныгытмалары каршындагы казыкларга бәйләп куеп, казанлыларны урысларга бирелергә өндәргә мәҗбүр итәләр.

Казан тирәли боҗра торган саен кысыла бара һәм шәһәргә керү юллары булган Хан һәм Арча капкалары янындагы ныгытмаларның өзелү куркынычы туа. Стеналар шартлатыла, әмма шәһәрне саклаучылар ул өзеклекне тиз генә төзәтеп куялар. 5 октябрьдә Нурали манарасы астыннан үтеп берданбер исән калган чишмәгә бара торган җир асты юлы да шартлатыла. Камалыштагылар суны Черек күлдән алырга мәҗбүр булалар. Нәтиҗәдә, шәһәрдә эчәк авырулары башлана. 30 сентябрьдә дошман явы Арча капкасы янында тагын шәһәр стенасын шартлата, казанлылар аны тиз арада ямап куялар, урысларны шәһәргә кертмиләр. Явыз Иван бер-бер артлы илчеләр җибәрә, казанлыларның бирелүен таләп итә. Әмма шәһәрне яклаучылар аларның барысын да кире кагалар, Казанны, туган җирне соңгы тамчы каннарына кадәр сакларга ант итәләр.

2 октябрьдә Казанга соңгы һөҗүм билгеләнә. Башта шәһәрне туплардан утка тоталар. Ул төнне берәү дә йокламый, каланы саклаучылар дошман белән соңгы, хәлиткеч сугышка әзерләнә, ә камаучылар һөҗүмгә сигнал көтә. Менә таң алдыннан Аталык һәм Нугай капкалары янында бер үк вакытта коточкыч ике шартлау гөрселди—анда дары тутырылган барысы кырык сигез мичкә шартлатыла. Шәһәр ныгытмалары, ике яктан киң аралык ясап, ишелеп төшә. Коточкыч зур сугыш башлана. Ләкин сан ягыннан өстенлек дошман ягында була, һәм ул камалыштагыларны әкренләп кысрыклый, чигендерә башлый. Һәр урам, һәр йорт өчен аяусыз көрәш дәвам итә. Инде бер як та өстен чыга алмый башлагач, Явыз Иван үзенең резервта калдырган зур полкын татарлар өстенә ташлый, шәһәрне саклаучылар чигенә-чигенә Кремльгә керәләр.

Шунда соңгы бәрелеш була. Шәһәрне саклаучыларның башында Ядкәр хан һәм сәет Кол Шәриф торалар. Ул каһарманнарча һәлак була, көн уртасы җиткәндә ханны әсирлеккә алалар. Хан сараеның ишегалды соңгы терәк, соңгы таяныч урынына әверелә, исән калган ун меңлек гаскәр иңгә-иң торып көрәшә. Һич көтмәгәндә Хан сараеннан хатын-кызлар алга чыгып баса, әмма дошман аларны да аяп тормый. Соңгы алты мең чамасы татар Кремль буеннан Казан суына таба камалышны өзеп чыга ала, тик алар кенәз Курбский берләшмәсенең яңа көчләренә килеп төртеләләр. Татарларның бик аз өлеше генә кабат камалудан котылып елганы кичә һәм куе урман эченә юл ала...

Шәһәр эчендә чын мәгънәсендә суеш башлана. Урыс тарихи чыганакларында ("Царственная книга", Никон һ. б. елъязмалар, "Сказание о царстве Казанском") язылганча, ир-атны кырып бетерәләр, ә хатын-кызларны һәм бала-чаганы урыс гаскәренә бирәләр. Татар каны мөлдерәп ага, мәетләр аша үтеп йөргесез була. Кремль янындагы Казан суы ярлары, чокыр-чакыр, ныгытма тирәләре өем-өем мәет белән тула. Өемнәрнең биеклеге кайбер җирдә шәһәр ныгытмаларының өстенә кадәр җитә. Көндезге сәгать өчтә атка атланып, Иван Грозный шәһәргә керә, аның өчен көч-хәл белән Нурали капкасыннан Хан сараена кадәрге йөз адымлык юлны мәетләрдән арындыралар.

Казан алына, Казан ханлыгы яшәүдән туктый. Казанның соңгы ханы Ядкәр ханны Мәскәүгә алып китәләр һәм Самсон исеме биреп, чукындыралар. Хөкүмәт һәм гаскәр, бөтен дәүләт оешмалары юк ителә. Казан белән идарә итү өчен Мәскәү наместнигы итеп Горбатый-Шуйский куела. Ләкин татарлар һәм Казан ханлыгының башка халыклары бәйсезлек өчен, дәүләтне торгызу өчен көрәш башлыйлар һәм ул азатлык көрәше Рәсәй империясе эчендә гасырлар буе дәвам итә.

*Нәкый Исәнбәтнең тууына 100 ел*

# Нәкый Исәнбәт

# МӘКАЛЬЛӘРЕБЕЗ ТУРЫНДА



***Нәкый Исәнбәт төрки-татар дөньясының XX гасырдагы иң күренекле шәхесләреннән берсе дип саналырга лаек. Мәгълүм хакыйкать: тарихта якты эз калдырган затлар, гадәттә, күпкырлы талантка ия булалар. Нәкый Исәнбәт тә шундыйлардан. Ул—драматург («Хуҗа Насретдин», «Миркәй белән Айсылу», «Һиҗрәт», «Гөлҗамал» һәм башка дистәләгән пьесаларын искә төшерик), ул—шагыйрь (халыкта популяр «Уракчы кыз», «Син сазыңны уйнадың», «Бормалы су», «Илкәем» кебек җырларын хәтерлик), ул—балалар язучысы («Куян маҗаралары», «Ни өчен ни булган, яки утыз ялган», «Нәниләр шатлана», «Балалар дөньясы» кебек китапларын янәдән укып карыйк), ул—тәрҗемәче («Бакчасарай фонтаны», «Полтава», «Таш фонтан», «Гамлет», «Король Лир», «Акыллылык бәласе» кебек җитди әсәрләрнең татарча басмаларын онытмыйк)... Әмма, безгә калса, Нәкый Исәнбәт, беренче чиратта, энциклопедик белемгә ия бөек галим. Татар халкының тел, әдәбият хәзинәләрен җыю, барлау, гыйльми өйрәнү һәм аларны системага салып, бастырып чыгару өлкәсендә армый-талмый эшләгән бүтән әдип бездә хәзергә юк әле. Аның өйрәнелгән иҗат мирасы гына да 30 томнан артып китә. Хөкүмәтебез карары нигезендә аны инде быел ук чыгара башлау күздә тотыла.***

***Әдип тарафыннан әзерләнгән илле меңнән артык берәмлектән торган фразеологик сүзлек, күләмле «Татар халык табышмаклары» һәм балалар фольклоры җыентыклары үзләренең тулылыгы-киңлеге, авторның һәр жанрга биргән гыйльми-тарихи аңлатмалары белән татар халкы авыз иҗатын өйрәнү юлында фән ирешкән беренче фундаменталь хезмәтләр булып саналалар. Шулар арасында, безнеңчә, иң күренеклесе һәм саллысы - кырык меңгә якын берәмлекне үз эченә алган калын-калын (һәр том 35 табак чамасы!) өч томлык «Татар халык мәкальләре». Бу өч томлык безнең үлмәс хәзинәбез, милли байлыгыбыз. Әдипнең бу томнарга язган әтрафлы кереш сүзе - үзе бер олуг академик хезмәт.***

***«Татар халык мәкальләре» моннан кырык еллар элек (1958) дөнья күргән иде. Хәзер ул томлыклар сирәк очрый торган басмаларга әверелде, хәзерге яшь буын бу титаник хезмәт белән бөтенләй таныш түгел диярлек. Шуларны истә тотып, бөек әдипнең тууына 100 ел тулу алдыннан аның әлеге томлыкларга язган кереш сүзен журналыбызда бастырып чыгарырга булдык. Шунсын да әйтеп узыйк: бу хезмәт китап булып басылып чыкканнан соң Нәкый ага үзе керткән төзәтмәләр һәм өстәмәләр белән дә баетылды.***

***РЕДАКЦИЯ.***

## Беренче башлам

### Мәкальләрнең халыкларда гомуми һәм бәхәсле яклары

Мәкальләр дигәч тә күңелгә бер-бер артлы шундый сораулар килә: алар нәрсә? Нинди әсәрләр? Ничек туа һәм нәрсәгә хезмәт итәләр? Аларның нинди дә булса милли үзенчәлекләре, шигъри кыйммәтләре бармы яки

һәммә халыкларда да уртак-гомуми нәрсәләр генәме? Татар халык мәкальләренең тарихы ничек? Бездә нинди мәкальләр бар? Тема яки эчтәлекләре нидән гыйбарәт? Аларны мондый китап итеп җыеп чыгарырлык нинди әһәмиятләре, тормышта нинди рольләре бар? һ. б.

Шундый яки шуңа охшашлы сорауларга кем дә булса җавап эзләп, бездә китап һәм матбугат актарса, күп соравы җавапсыз калачак. Дөрес, дәреслекләрдә яки кайбер фольклор җыентыкларында мәкальләр турында ара-тирә сүзләр очрый, ләкин алар да, тәрҗемә юлы белән, каяндыр алып әйтелгән гомуми сүзләр булып, татар мәкальләреннән күп булса шуңа бер-ике мисал китереп үтүдән гыйбарәт. Бу исә безнең мәкальләрнең төп табигатен һәм үзенчәлекләрен ачыклау булмыйча, башка халык мәкальләрендә табылган кайбер үзенчәлекләрне безнеке белән дә раслау, аларга шәкел-иллюстрация бирү булып кала. Әмма инде югарыда бирелгән сорауларга килсәк, алар бездән мәкальләр хакында тулырак һәм житдирәк җавап көтәләр. Моның өчен әлегә чаклы бездә чыккан кечкенә һәм бер-ике генә бөртек мәкаль җыентыгы, йә булмаса аларга карата язылган бер-ике битлек аңлатма бирү генә җитми. Шуның өчен дә укучы бездән мәкальләрне махсус һәм киңрәк яктырткан хезмәт сорап килә. Билгеле, андый зур хезмәтләр бездә тел-фольклор галимнәре тарафыннан язылырга тиеш һәм языла да булыр. Ләкин, ни өчендер, әлегә хәтле ул эшләр мәйданда күренмәде. Мин дә үз ягымнан, халкыбызда булган шул хаҗәтне үтәү юлында бер адым булсын дип, кулымда җыелган мәкальләрне чыгара торырга булдым.

Бу китапны төзегәндә, миңа югарыдагы сорауларны үзалдыма кат-кат куярга, мәкальләр өстендә уйланырга, кайбер күзәтү-тикшерүләр дә ясарга туры килде. Мин шул уйларымны укучылар белән бүлешмәкче булдым.

Бирелә тик шул нәрсә яхшы аңлашылсын: монда әйтеләчәк фикерләрем монарчы мәкаль турында булган ниндидер гыйльми теорияләрне аңлату, йә булмаса, алар югарылыгыннан торып, безнең мәкальләргә гомуми анализ ясарга омтылуым түгел, болар тик эш барышында минем башымда туган фикерләр генә. Мин мәкальләр буенча үземдә туган сорауларга җаваплар эзлим, укучыларым белән дә шуларны бүлешмәкче булам. Шунлыктан монда төрле сорау-җаваплар да күп очрар. Мондый язылыш ниндидер академик тәртипләргә, гыйльми стильләргә, ихтимал, бер дә туры да килмәс. Хәер, монда аның кирәге дә юк һәм миннән аны таләп тә итмәсләр. Бу ниндидер гыйльми диссертация түгел, эзләнүләр генә. Аларны мин үз исемемнән генә сөйләргә хакым булганга, бу хезмәттә "без" яки "безнеңчә" дигән олы сүзләр кулланудан да тартындым. Шулай булгач, ни өчен бирелә төрле гыйльми цитаталар, өземтәләр китерелмәүгә һәм һәртөрле гыйльми атамаларны аз куллануыма укучыларым, шаять, гаҗәпсенмәсләр. Аерым санап күрсәтерлек библиография дә юк. Берничә мәкаль китабы булса, алар сүз рәтендә күрсәтеп үтелде.

Шулай итеп, монда язылганнар бер һәвәскәрнең хосусый карашлары, алар практикадан туганнар. Бәлки шуңа күрә дә монда укучылар өчен кайбер яңарак фикерләр дә табылыр. Арада бәлки ялгыш һәм житешсезлекләр дә күп булыр, алар хакында тәнкыйтьчеләребез күрсәтерләр һәм төзәтешергә ярдәм итәрләр. Дөрес табылганнары файдага калыр.

## Мәкаль дип нәрсәгә әйтелә?

Дөньяда телсез яки җырсыз-моңсыз халык булмаган кебек, мәкальсез халык та юктыр дип уйлыйм, һәрбер халык сүз арасында мәкальләр кыстырырга ярата, үз теленең аның белән бизи, төзи. Һәркайда, һәр халыкта үз мәкальләренә хөрмәт бар, аларга ышану, таяну бар. Безнең халыкта да шундый ук хәл: татар сөйләшкәндә сүз арасында, урынына карап, фикерне куәтләү өчен кыска гына һәм килешле генә итеп, хикмәтле бер мәкаль әйтеп куя. Ул моны әйтеп җибәргәнен кайчак үзе дә сизми кала. Шуның белән безнең халкыбыз арасында да саны әлегә хәтле беленмәгән күп төрле мәкальләр йөри.

Нәрсә соң ул мәкаль? Безгә кардәш төрки халыкларның кайберләре аны

*борынгылар сүзе,* кайберләре—*аталар сүзе, картлар сүзе* дип атыйлар, чувашларда *ваттисем калани*—картлардан калган сүз дип йөртәләр. Бездә дә Хуҗа Вәдигъ үзенең бер җыентыгының тышында “мәкальләр” дигәч, шуның астында ук “Борынгылар әйткән сүзләр” дип куйган. Халыкның үзендә дә:—*Борынгылар әйткән сүз китапның эчендә булмаса, тышында да түгел,*—дигән мәкаль йөри. Ягъни, мәкальне китапка язылмаган дип җиңелгә санама, читләп үтмә, барыбер ул, мөкатдәс китап сүзе хөкемендә. Шулай ук картлар сүзе дип йөртү дә бар: —*Картлар сүзен капка җый;*—*Картлар әйткән буш булмый;*—*Картлар сүзен капчыкка, яшьләрнекен янчыкка,*—диләр. Болардан мәкальләрнең, тәҗрибә һәм хикмәт җимеше буларак, хәтердә җыелып сакланырга тиешле булган бер хәзинә итеп каралуы аңлашыла. Һәм халык аны шулай үзенең хәтер капчыгында гасырлар буе саклап килгән дә. Яшьләр сүзе көндәлек әйләнештә йөргән акча шикелле янчыкта йөрсә, ул җитмәгәндә һәрвакыт теге хикмәтле хәтер капчыгын ачып, андагы запасны ходка җибәрергә кирәк булган.

“Мәкаль” сүзе безгә гарәпчәдән кергән. Аның мәгънәсе—урынлы сүз яки тиешле урынында әйтелгән сүз була. Гарәпләр: “Ликелли мәканин мәкаль”—һәр урынга лаек мәкаль бар,—диләр. Мәдрәсә шәкертләре гарәп сүзен үчекләргә оста булганга, алар бу сүзгә пародия ясап, татар сүзләре ялгап:—*Ликелли мәканин мәкаль, вә ликелли урманин чакал,*—дигәннәр, һәр урынга мәкаль булса, һәр урманга чакал бар,—дигәнгә туры килә*. Мәкаль сүзе дә безгә күптән үк кергән булса кирәк, ул иске язмаларда да очрый. Башкортлар да, казакълар да “мәкаль” дип йөртәләр. Шул рәвешле, мәкаль сүзе дә бездә язма әдәбият һәм соңыннан җыентыклар аша халыкка нык таралып, үзенең кыскалыгы белән инде тәмам телебезгә кереп урнашкан һәм шул сүзнең—үзе белән дә мәкальләр барлыкка килгән:—*Мәкаль сакалдан олырак,*—дигәннән мәкальнең яшь һәм тәҗрибә ягыннан һәрбер картка караганда да озынрак гомерле һәм хөрмәтлерәк саналуы аңлашыла. Яки:—*Сүз күрке мәкаль, ир күрке сакал,*—диләр. Сакал халыкта ирлек һәм куәт билгесе булса, бу мәкальнең безгә инде сүзнең мәгънәсе мәкаль белән мәһабәт һәм куәтле булуы, шулай ук, “күрке” дигәннән мәкальнең сүзгә шигъри ямь-тәм, матурлык бирүе аңлашыла. Шулай итеп, дөньяда сакалсыз халык булмаган кебек, мәкальсез тел дә юк. Ул—телнең шартыннан булган гомуми һәм зарур әйбер. Ул бик күп яклы. Шуның өстенә, тумышы белән тарихи да ул, кулланышы белән бүгенге дә ул.

Шулай да була: менә бу җыентык кебек бер китапны ачасың, аерым мәкальләргә күзең төшә:—*Үз өем алтын бишек, кеше өе утә тишек;* яки:—*Тел минеке, сүз мирнеке, дигән.* Укыйсың, карыйсың—болай әллә нәрсә дә юк кебек. Мәгънәсе дә хикмәтсез генә, төзелеше дә гади, берсендә шәхси үз өен мактый, икенчесе бөтенләй аңлашылмый, корама. Шундый мәгънәсез корамаларны “җәүһәр” дип белеп китабына җыеп бастырган кешесенә аптырыйсың. Ләкин син шундый корамаларны берәр сүз барган җирдә, практикада ничек әйтелгәнен, аның анда нинди мәгънәләр хасил иткәнен тыңлап кара!

Әйтик, авылда җыелыш. Клуб хакында сүз бара. Телгә оста бер агай сүз ала да артта гына басып сөйли башлый:—Безнең клуб турында ни әйтәсең? Аның хәле мәгълүм инде, *ачык та тишек, тәрәзә дә ишек.* Ул бик тыныч яши, *төнлегеннән җил өрми, ишегеннән кеше керми.* Бигрәк тә анда безнең председатель керми. Нигә керсен? Аның—үз өе *алтын бишек, кеше өе утә тишек,*—ди. Җыелыш гөр итә. Бар да түрдәге председательгә карый, көлә башлый. Председатель сискәнә, кызара, графин кагып җыелышны, аннан да бигрәк теге ачы мәкальләр кыстыручы агайны тәртипкә чакыра. Ләкин сөйләүче агай аптырамый, унайсыз хәлдән чыгу өчен тагын мәкальгә ябыша:—Нигә көлешәсез? Ялгыш әйттемме әллә? Бер дә гаеп итмәгез: *Тел минеке, сүз мирнеке,*—дип куя. Шуның белән баягы сүзләре үз шәхси фикере генә булмыйча, гомуми фикер икәнен тагын бер мәкаль белән ныгытып, үз өстеннән җаваплылыкны төшерә һәм шуның белән тагын да ныграк тозлап куя.

---

* Бу мәкальне Мөхәммәт Шакир Салихов үзенең беренче татар мәкальләре җыентыгы булган китабының хәтта тышына ук язып бастырган. Карагыз: *Табышмаклар һәм мәкальләр, 1880.*

Бу мисаллардан шуны аңлыйбыз: болай карауга мәкальнең хикмәте аңлашылса да, аның актив мәгънәсе һәм роле тормышта кулланган вакытта ачыла, аннары аны кем һәм нинди максат белән әйтүенә карап мәгънәсе авыша, төрлечә юралыш таба икән. Чөнки аларны бу агай бу очракта клуб һәм председательгә карата үзенә бер мәгънәдә кулланса, икенче урында, икенче максат белән әйтелгәндә, шул ук мәкальләр икенче юнәлеш һәм мәгънә табачаклар. Шулай булгач, бая китаптан укып караганда, бу мәкальләрнең ничектер, бәйләнешсез, хәтта берникадәр аңлаешсыз сыман тоелуы хәзер аңлашыла: без аларны тормыштан аерып, ялангач, абстракт бер төшенчә хәлендә кәгазь өстендә генә караганбыз икән. Димәк, мәкаль үзенең конкрет мәгънәсен һәм актив кулланышын сөйләмдә таба, ул анда тормыш куйган берәр сорауга җавап булып төшә, нине дә булса раслый, таныклык бирә, ышандыра яки кире кага. Үзен генә алганда төссез, хәтта кайчагында сай булып күренгән кайбер мәкаль дә җанлы сөйләмдә тапкыр һәм тирән икәнен ачып җибәрә. Чөнки ул үзе дә сөйләү телендә туган һәм авыз әсәре булып әйтелер өчен телдә яши.

Аннары бу агайның мәкальгә таянганда: *Тел минеке, сүз мирнеке,*—дип әйтүендә тагын бер хикмәт бар: ул шуның белән безгә мәкальнең практикада ничек һәм ни өчен кулланылуын, халык ни өчен анар таянуын әйтеп бирә: *тел минеке* дигәннең мәгънәсе—мин телем өчен җавап бирәм, әмма мәкаль халыкныкы, ул халыкның күмәк фикере, тормышта сыналган, кагыйдә хөкеменә кергән дәлил, шуның өчен уртак хакыйкать буларак, син дә, мин дә аңа таянабыз, ул мирнеке, ягъни җәмәгать фикере, шулай булгач, мин аны әйткәнгә син дә үпкәләмә, кабул ит, дигән сүзе була.

Димәк, мәкальдә күпчелек аны үзенеке иттереп таныта торган бер хасият бар. Бу гомумхалык өчен уртак булган хасият мәкальнең мәгънәсе тирән, формасы ритмик яки башкача булуында гына түгел, бәлки анда салынган идея халык тарафыннан хакыйкать яки берәр дәлил, кагыйдә дип танылган булуыннан да килә. Аннан соң кайбер аерым мәкаль болай карауга бигүк мәгънәле һәм матур булып күренмәсә дә, аның тик тормыш мөгамәләсендә һәм сөйләмдә үзенең конкрет мәгънәсен һәм кулланышын таба икәнен дә шул ук мисалдан күрербез.

Тагын мисалга түбәндәге мәкальләрне алыйк:—*Акчаны юлдан тапсаң да санап ал;—Кунак кадере өч көн;—Туй тиешленеке, бәйрәм барчаныкы;—Ит табыш, тураганда бер кабыш;—Атны йөгәненнән башка сатмыйлар;—Ир йоласы өчкә чаклы;—Юрганыңа карап аягыңны суз;—Качып китсәң дә чәчеп кит;—Ашаган җиренә мал да кайта* һәм башкалар. Мондый мәкальләр тормышның кагыйдәсе итеп тотыла, халык шуңа карап үзенең мөгамәләсен үлчи, һәм шулай итеп мәкальләр халык тормышының уртак бер кагыйдәле, уртак бер гореф-гадәтле булуына һәм уртак бер рухта саклануына нык кына ярдәм итәләр.

Яки шундый мәкальләрне алып карыйк:—*һәркемнең бармагы үзенә кәкре;—Бармаклар да тигез түгел;—Күз—дәрья;—Җил исми кура селкенми;—Кояш та тапсыз түгел;—Чыбык учлаган җирдән сынмый;—Тымызык күлдә корт үйный;—Үзе егылган еламас;—Кайта чапкан яу яман, кайтып килгән кыз яман* һ. б. Мондый мәкальләр тормышта төрле очракларда нәрсәдән булса да аклану яки гаепләү шикелле урыннарда дәлил урынында яки бер хөкем йөртү урынында китереләләр. Билгеле, мәкальнең уртак бер кагыйдә, дәлил яки хөкем дәрәҗәсенә ирешүе өчен, тормыш тәҗрибәсе нигезендә туып, күп сыналган һәм халык аны һичшиксез дөрес дип ышанган булырга тиеш. Мондый мәкальләрнең кайберләре турыдан-туры тәҗрибә уртаклашу яки киңәш йөзеннән, бер дә читләтеп-нитеп тормыйча, турыдан-туры бер генә мәгънәдә дә әйтеләләр. Мәсәлән, тәҗрибә уртаклашуга:—*Микула житми җәй булмый, Микула житми кыш булмый;—Иртә аязмаса, кич аязмас;—Арыш чәчсәң, кәлгә чәч;—Кәзге бозның кәзге калынлыгына ышан, язгы бозның ястык калынлыгына да ышанма,*—кебекләр. Киңәш яки үгет-нәсихәт йөзеннән:—*Юлга* чыксаң, юлдашың үзеңнән яхшы булсын;—Йөз тәңкәлек атың булса, мең тәңкәлек чыбыркың булсын,—кебекләр.

Халык тормышта шундый кагыйдә, дәлил яки киңәш бирерлек белемнәрне, билгеле, мәктәптә яки университетларда укып өйрәнмәгән, мондый мәкальләр халыкның ачы тәҗрибәсеннән туган. Ләкин мәкальләрнең турыдан-туры тәҗрибә яки сынау аңлатмый торганнары да күп, алар читләтеп әйтү, берәр мисал,

охшаш китерү рәвешендә кулланылалар. Мәсәлән:—Этнең баласы эчендә өрә;—Дингез баштан болгана;—Дуңгызның башын табакка куйсаң, тәгәрәп төшәр;—Убыр китте, урыны калды;—Йөргән таш шомарыр, ятсан таш мүкләнер;—Туйдан тукмак та калмый;—Яман хатыннан дию пәрие качкан һ.б. Билгеле, мондый образлы мисаллар турыдан-туры табигать һәм тормыш сынауларыннан туарга яки тумаска да мөмкин. Шунлыктан мәкальләрнең төрле борынгы ышанулардан, әкият-мәсәлләрдән яки хорафат калдыкларыннан барлыкка килгәннәре дә күп. Күп мәкальләр турыдан-туры үз мәгънәләрендә алынмыйча, төрле башка мәгънәләр өчен мисал булып йөриләр. Әйтик, бер эшне җупләү, яклау яки мыскыл итү төсендә дә, бер эштән кисәтү, шелтә рәвешендә дә, үкенү, әрнү һәм башка хисләрне тәгъбир итү яки шул ук кагыйдә, дәлил шикелле урыннарда да алар китерелә алалар.

Шулай итеп, ничек кенә булмасын, мәкаль нигездә сүзгә дәлил, тормышта кагыйдә йә киңәш һәм шул ук вакыт телдә тапкыр әйтелгән гүзәл бер мисал булып та килә. Мәкальләрнең кайберләре шулай үз мәгънәсендә әйтелүе, икенче берләренең читләтелгән икенчел мәгънәләргә ия булуы, мисаллыгы, шулай ук аның тагын шигъри сурәтләмә—образларга, ритм-рифмаларга байлыгы бездә бөтенләй диярлек тикшерелмәгәнгә, ул якларына алда аерым-аерым тукталырга туры киләчәк.

Мәкаль кыска һәм тирән мәгънәле булганга, аны халык хикмәте дип атау барлык халык фольклорында бик таралган. Моннан ике мең ярым ел элек Аристотельнең мәкальләрне үзеннән күп мең еллар борынгы философларның әсәрләреннән калма өзекләр булып, шулар грекларга килеп җиткәннәр, мәкальләр булмаса, борынгы халык хикмәтләре безгә килеп җитмәгән булыр иде, бу фәлсәфә-хикмәт әсәрләре борынгы халыклар белән бергә югалган булыр иде дип әйткән сүзләрендә дә мәкальләргә карата иң борынгы халык хикмәте дигән караш ята. Мәкальнең халык хикмәте булуга бүгенге көндә дә каршы килүчеләр юк.

Ләкин моңа карап, аны кайчандыр билгесез заманнарда әйтелгән үзгәрмәс һәм мәңгелек хакыйкатьләр дип әйтеп булмый. Мәкальнең төп көче дә аның мәңгелегендә,—дип нәтиҗә ясаучы кайбер галимнәр төрле ялгыш теорияләр тудыруга кадәр барып җиттеләр.

Мәкальнең зур көче, баягы агай мисалыннан күренүенчә, аның халык массасы фикере һәм таянычы булуында. Аның бу көче көнкүрештә искиткеч күп сыналган. Һәр халыкның мәкале үзенчә. Менә шулардан мәкальнең иң зур күпчелеге һәр халыкның үз иҗтимагый-тарихи тормыш тәҗрибәләреннән һәм ышануларыннан, аның үз теленең иҗат һәм сурәтләмә мөмкинлекләренә таянып барлыкка килгәнлеге аңлашыла. Аның кайчан туа башлаганы билгесез, авторлары исемсез, шулай ук аның әле дә туудан туктаганы юк. Тормыш һәм халык яшәгән җирдә аның тумавы мөмкин дә түгел: чөнки кеше үз табигате буенча шагыйрь, үзе тәҗрибә һәм иҗат иясе. Шунлыктан мәкаль башлап ялгыз кеше авызыннан әйтелсә дә, һәр уңышлы иҗатны әләктереп алучы халык аны телендә саклый, тагын да шомарта, чөнки аны гомуми мәгънәгә күтәрүче халык үзе бөек шагыйрь, үзе тормышны иҗат итүче бөек даһи ул.



*Нәкый Исәнбәт Казанның Галиев училищесы укучылары белән. 1916 елның кышы.*

Халкыбызның мәкальгә ата-баба хикмәте дип каравы, аңа таянып килүе бик табигый хәл. Шушы гасырга хәтле патша хөкүмәте аңа гәзит-журнал чыгарырга, әдәбиятын, фәнен, театрын, сәнгатен булдырырга рөхсәт итмәгән, үз телендә

китабы, гыйлеме аз, законы булмаган халык ата-баба тәҗрибәсенә, аның мәкальләренә таянмыйча нишләсен, ничек яши алсын? Гарәптән килгән диншәригать китаплары татар халкының гореф-гадәт һәм йолаларына, тормышына, шулай ук Россиядәге гомумзакон статьяларына күп яктан туры килеп бетмәгән, шуның өчен *булса* кирәк, бездә мәкальләрнең тормыштагы роле аеруча көчле булган.

Ләкин ата-баба хикмәте дигәннән, мәкальләр шулай төрле заманнар, төрле иҗтимагый катлаулар фикере булгач, аны мәңгелек үзгәрмәс хакыйкать дип карарга бигрәк тә туры килми. Тормыш төрле заманда төрлечә булып үзгәрә торгач, күп кенә борынгы мәкальләр дә терлечәрәк үзгәрмичә яки хәтта телдән үк төшеп калмыйча хәлләре юк. Дөрес, шундый мәкальләр дә бар, моннан мең еллар элек ничек әйтсәләр, бүген дә шулай әйтелә бирәләр, аларның бер сүзләре дә үзгәрмәгән, катып калган. (Моны без алдагы мисаллардан да күрербез.) Җәмгыять исә шул көе калмаган, халык буыннан-буынга үзгәрә килгән. Шунлыктан мәкальләрнең үзендә тирән хикмәт һәм мәгънә яки сурәтләмәле гүзәл бер мисал ятса да, аларның һәр сүзе дә бүгенге көн өчен чын хакыйкать дип алдан ук кырт кисеп куярга ярамый. *Көн итәргә көндәш яхшы,*—дигән икән, уйлап карарга кирәк, яхшы микән? Кем күзлегеннән яхшы?—*Килен кеше—ким кеше* дигәннәр, шулай микән? Гомумән кимме, әллә каенана күзлегеннәнме? Шундый патриархаллык карашлары, бигрәк тә байлык-ярлылык кебек сыйнфый карашларны чагылдырган мәкальләр арасында, бүгенге көн өчен хикмәте искергән яки хәзерге карашларга туры килмәгәннәрен дә очратып була. Шуна да карамастан, андый мәкальләрнең дә күпләре бүген дә телдән төшмиләр, беренчел мәгънәләре белән булмый икән, икенчел мәгънәләре яки берәр яктан мисал булуга яраулары белән яши бирәләр. Кыскасы, мәкальләр үзләренең темалары, эчтәлек һәм формалары белән дә бик бай һәм бәхәсле булып, анда кузгалган мәсьәләләрне безгә дә аерым-аерым карарга туры киләчәк.

Күп кенә мәкальләр турыдан-туры әйтелгән мәгънәне генә белдермиләр. Өстән караганда бу мәкаль нинди дә булса фикерне яклап киңәш бирә дип уйлыйсың, ә ул аны сиңа ирония белән әйтеп, киресенчә аңларга кирәк икәнен үз сизгерлегенә тапшырган булып чыга. Кыскасы, мәкальләрне куллана белү яки аңлауда акыл белән эш итәргә кирәк. Димәк, мәкаль үзе шулай бик кечкенә булса да, күпьяклы, үзенчәлекле һәм хикмәтле нәрсә.

Билгеле, мәкальләрне иҗат итүдә җәмгыятьтә күпчелек хасил иткән хезмәт ияләре иң зур рольне уйнаганнар. Мәкальләрдә башлыча алар карашы, алар тәҗрибәсе һәм алар шигъри хыялы чагылган. Аларның гомуми мәгънәгә ия булулары һәм халык хикмәте дип йөртелүнең төп сере дә шунда.

Мәкальне билгели торган төп сызыклар әнә шулар. Шулай булса да авыз әдәбияты иҗатында мәкаль хәтле төрле бәхәскә сәбәп булган башка жанр табуы бик авыр. Мәкаль турында борынгы греклар, кытайлар, һиндләр, румлылар язганнар. Соңгы йөзләрдә төрле юнәлеш һәм ысуллар белән эш итүче галимнәр озак тикшерүләр ясап, калын-калын китаплар барлыкка китергәннәр. Ләкин бу хакта бәхәсләр әле дә беткәне юк. Шунлыктан монда биреләчәк бу билгеләмәгә безгә алда тагын кабат-кабат кайтырга туры киләчәк.

Кайбер нәтиҗәләргә килик. Димәк, мәкальләрне мәгънә ягыннан ике төркемгә бүлеп була: алар йә туры мәгънәсендә, йә читләтеп, киная белән әйтеләләр.

Туры мәгънәсендәге мәкальләр, күбесенчә, үгет-киңәш бирү, яки чынбарлыктан алынган мөһим бер күзәтмә, кагыйдә урынында әйтеләләр:—*Кеше ышанмастай сүзне чын булса да сөйләмә:—Тиз эшлә дә тиз аша;—Сыйлы көнең сыер белән;—Картлык шатлык түгел;—Иртә аязмаса, кич аязмас;—Эшләмәгән ашамас;—Арыш чәчсәң, көлгә чәч* һ. б.

Мондыйларны беренчел, ягъни турыдан-туры мәгънәсендә әйтелгән дияргә туры килә.

Кинаяле мәкальләр чынбарлыктан алынган берәр шигъри мисал төсендә читләтеп әйтеләләр:—*Алма агачыннан ерак төшми; —Асыл кош—аягыннан;—Ярык кашык авыз ерта;—Эт күзе төтен белмәс;—Юрганына карап аягың суз;—Күз—дәрья;—Дүрт аяклы хайван да сөртенә* һ. б.

Болары—икенчел, ягъни читләтелгән мәгънәле мәкальләр.

Шулай булуга карамастан, мәкальләр бары тик читләтелгән, кинаяле, күчемле мәгънәдә була дип кенә аңлатулар әле дә еш очрый. Димәк ки, мәкальне болай чикләү дөрес түгел. Монда әйтелгәнчә, аларның икенчел мәгънәдәгеләре белән беррәттән, туры мәгънәдәгеләре яки файдалы бер күзәтмә рәвешендә әйтелгәннәре дә күп булганга, аларны мәкаль түгел дип сызып ташларга ярамый. Тик монда "күзәтмә" дигәннән, аны да безгә фольклор жанрларыннан берсе булган сынамышлар (приметы) белән чуалтып аңларга да ярамый...

Җыйнап әйткәндә, мәкаль нәрсә дигәнгә шундый билгеләмә биреп була:

Сөйләшкәндә сүзгә ямь һәм куәт бирү өчен, көнкүрештә күп сыналган дәлил яки шигъри бер мисал урынында әйтеп йөртелә торган, кыска, ләкин гомуми бер тирән мәгънәне эченә алган төгәл җөмләле халык хикмәте әсәрләре мәкаль дип әйтелә.

Мәкальләрнең ничек килеп чыгуы, башка халыкларныкы белән уртак һәм гомуми булып-булмавы да, күпме борынгы булуы да, мәгънә белән форма бәйләнешләре дә шигырь яки проза булып-булмаулары һәм башка күп төрле үзенчәлекләре дә—болар һәркайсы да өстән-өстән генә булса да күз йөгертеп чыгуны, кайберләренә аерым-аерым тукталуны таләп итәләр.

Соңгы егерме биш ел эчендә бездә мәкаль белән беррәттән әйтем дигән бер сүз үзенә мәйдан алды. Ул мәкаль дигән сүздән бер дә калмый,—*Тәтәй бара, мин дә барам* дигән кебек, һәркайда "Мәкальләр һәм әйтемнәр" булып йөри. Хәтта хәзер болар икесе бер үк төрдән булган сүзләрме, бер үк жанрмы, мәгънәдәшме, түгелме— яхшылап белер хәл дә юк. Бу хәл мәкальнең бездә жанр буларак та әлегә хәтле яхшылап аерылмаган булуын күрсәтә. Кыскасы, безнең мәкальләребез әлегәчә аз җыелган, ныклап тикшерелмәгән һәм өйрәнелмәгән булганлыктан, аларның бәхәсле һәм ачыклап үтәргә тиешле яклары шулхәтле күп ки, монда шуларның кайберләренә тукталырга туры киләчәк.

## Мәкальләрдә иҗтимагый формация һәм сыйнфый бүленешләр чагылу мәсьәләсе

Тарихи үсеш ягыннан татар халкы да башкалар кичергән төрле иҗтимагый формацияләр баскычын үткән, димәк, ул да үз юлында сыйнфый каршылыклар, төрле алмашынулар тарихын башыннан кичергән. Бу әһәмиятле яклар аның бер ише мәкальләрендә чагылмыйча калмаган. Шул рәвешле, без алар арасында коллык, патриархаллык, феодаллык, капитализм чорларын чагылдырган, алардагы кол, хан, би, бай, ярлы дигән кебек, төрле сыйнфый бүленешләргә бәйләнешле мәкальләрне күп очратабыз. Мәкальләргә бары сыйнфый бүленешләр күзлегеннән карарга һәм классификацияне дә шул күзлектән чыгып кына ясарга кирәк дигән карашларга тукталып үтик. Бу карашлар түбәндәгедән гыйбарәт:

Мәкаль тарихи. Тарих исә сыйныфлар көрәшеннән тора. Сыйныфлар тарихының, һәммә халыкларда да билгеле бер тәртибе бар: һәркайсында, әйтик, борынгы патриархаллык соңында феодаллык, капитализм, социализм формацияләре бер-бер артлы килә, киресенчә түгел. Инде халыклар бар да шулай бер үк төрле иҗтимагый баскычлар кичерә торган булгач, мәкальләре дә шул формацияләрне чагылдыру ягыннан бер үк эчтәлектә, бер үк ихтыяҗларны үтәгән булып чыгалар. Шуңа күрә, алар жанр ягыннан да, мәгънәләре буенча да барлык халыклар өчен дә уртак нәрсәләр итеп кенә каралырга тиешләр. Дөрес, тел ягыннан аермалары бар, ләкин мәгънәсе, жанры һәм шулай ук тел-бизәк чаралары (троплар) да һәммә халыклар өчен уртак булгач, тел аерымлыгының монда ул хәтле ни әһәмияте бар? Ул монда күбрәген тәрҗемә теле шикелле арадашлык ролен генә үти. Алыйк мона мисалга акча дигән әйберне: бер халыкта, аның исеме сум дип, икенчесендә доллар яки ф у н т с т е р л и н г дип йөртелсә дә, сумны долларга яки киресенчә алыштырганда, аңа карап акчаның асылы үзгәрми, кыйммәте шул ук кала. Шуның кебек, татарның берәр мәкалендә хан дип, урыста царь, французда король дип әйтелүенә карап кына аның төптә феодализм чорыныкы булуы, бу

сүзләрнең дә монархлар турында булуы үзгәрми. Димәк, монда эш исемдә түгел, телдә дә түгел, алары тышкы як кына. Кыскасы, бу хәл безгә мәкальләрне иҗтимагый формацияләр күренеше итеп кенә карарга тулы мөмкинлек бирә. Шуның белән без аларны һәммә халыклар өчен дә уртак һәм гомуми планда карый алабыз. Шуның аркасында, аларны өйрәнү һәм төрләргә бүлү, классификация ясаудан да җиңел эш юк. Бары тик шул формацияләр буенча аларны социаль, тарихи чорларга бүләргә дә тәртипкә тезеп чыгарга гына кала. Бу—бердәнбер фәнни, материалистик һәм марксистик юл...

Мәкальләрнең килеп чыгуын, мәгънәсен, иҗтимагый ролен, кыйммәтен, кирәк яки кирәкмәслеген *саф* сыйнфый күзлектән генә карап бәяләргә һәм аларны формацияләргә бүлеп теркәргә дигән карашның теоретик нигезләре шул. Мәсьәлә бик ачык: сыйныфлар һәм формацияләр... Шуның белән бу теория кайберәүләр өчен баштанаяк гыйльми нигезле һәм шул ук вакыт заманача бик революцион булып күренгән булса, һич тә гаҗәп түгел. Ләкин бу теорияне мәкальләргә карата шул килеш китереп кую үзе марксизмны бик вульгар һәм механистик схемалар корамасы итеп аңлау өчен һәм куллану икәнен төшенәсе авыр түгел.

Ни өчен? Чөнки бу теориячә мәкаль үзе конкрет бер күренеш итеп алынмый, ул монда гомумән иҗтимагый формацияләрнең кайбер өстәмә материалы итеп кенә карала. Аннары монда формацияләр дә аерым бер халыктан тыш гомуми бер хәл итеп кенә алына. Әйтик, бу теория буенча, бер мәкальне капитализм формациясенеке дип кенә алабыз икән, ул кирәк французныкы булсын, кирәк урысныкы яки татарныкы булсын, аермасыз рәвештә чоры, формациясе белән бар да бер үк категория һәм картотекада торырга тиеш була. Шул рәвешле, бу теория белән эзлекле барганда, һәрбер халыкның үз иҗаты, үз мәкале булуның урыны да, әһәмияте дә калмый, күп булса, культурада алдарак саналган бер халыктан әлбәттә "артта" калганына механик рәвештә күчә торган товар яки акча шикелле алмашып йөри торган әйбер булып кала. Шулай ук биредә мәкальләрнең иҗат һәм сәнгать әсәре буларак үзенчәлекләре (үз спецификалары) булуы да бетә, күп булса, алар гомумән җәмгыять тарихы өчен диаграмма шәкелләре шикелле бирәр аңлатма иллюстрация әйбере итеп кенә китерелә алалар. Әгәр бу теорияне тагын да эзлеклерәк дәвам иттерергә кирәк булса, монда аерым халыкның мәкале генә түгел, аның үз тарихы булуы яки үз язмышын үзе тудыруы да, хәтта ул халыкның үзенең булып-булмавының да әһәмияте юк. Аның өчен формация генә бар. Әмма формациягә туры килә торган халык урыс булды ни дә, немец булды ни, яки икесе дә булмады ни—барыбер. Чөнки бу схемада формация—халык өчен яшәми, халык үзе формация өчен генә яши. Аерым халык картотека өчен бүген мисалга кирәк икән, ул языла, кирәкми икән, сызып ташлана. Шуның белән, монда алынганча, формация үзе дә гомуми бер абстракт төшенчә генә булып аңлашыла.

Аерым халыкларның иҗат һәм сәнгате булуын инкарь иткән яки булган иҗатларын алдан әзерләнгән гомуми схемаларга шулай көчләп куып кертүгә корылган мондый теориянең, билгеле, сәнгатьнең үзе һәм диалектик материализм методы белән һич уртаклыгы юк.

Мәкальләрне саф сыйнфый бүленеш һәм формацияләр билгесе итеп карау, һәм хәтта икесен дә берүк нәрсә итеп бергә бутап йөртүләр, өлешчә, хәзер дә очраштыргалый әле. Билгеле, мондый вульгарлаштыру хәзер турыдан-туры мәкаль билгеләмәсе итеп алынмый, мондый очракта ул бераз икенче киемгә төрелә: хәзер мәкаль билгесенә иң элек социаль тәҗрибә мәсьәләсе алга куелып, сыйнфыйлык яклары шуңа ялгап кына бирелә, шуннан өченче рәткә мәкальләрдә троп, аллегория дигәндәй кайбер шигъри элемент булуына берничә мисал бирелә дә шуның белән барлык үзенчәлекләре әйтелде дип исәпләнелә...

Теләсә кайсы халык иҗаты китабын яки дәреслеген ачып, шуннан мәкальләр турындагы аңлатмаларны укып карагыз, аларның хәзер бар да диярлек шул бер әзер схемада төзелгәнлеген күрерсез. Шул нигездә соңгы елларда мәкальләр турында:—алар хезмәт халыкларының бөтен тормыш, социаль-тарихи тәҗрибәләрен үрнәк рәвештә калыпка салалар,—дигән мәгълүм тезиснең алга куелганын күрәбез.

Мәкальләрне тудыруда тәҗрибә һәм практиканың роле зур булганын без

башта да күреп үткән идек. Шулай ук мәкальләрнең сәнгать әсәре булулары белән бергә, тормышта да практик роль уйнаулары билгеле мәсьәлә. Шуңа күрә дә мәкальләрнең бу мөһимлеген төсмерләп бирү ягыннан мондый аңлатманы бертөрле дә инкарь итеп булмый. Шулай ук мәкальләрнең күп кенәсе социаль-тарихи тәҗрибәләрне үрнәк калыпка салып әйткән булулары да дөрес һәм ул фикер үзе башта шул якны ачыклау өчен әйтелгәндер дә. Ләкин бездә бу тезисны да мәкальләрнең бердәнбер фәнни-гыйльми нигезе шул дип, хәтта аны мәкальнең бердәнбер төп билгеләмәсе дип күрсәтүләргә хәтле барып җитүләр булды һәм шуның белән тагын берьяклылык, схемачылык тудыруларга юл ачылды. Ягъни мәкальләрне бары тик социаль-тарихи тәҗрибә дидекме, калганын болай уйларга кала: социаль-тарихи тәҗрибә исә—сыйнфый; сыйныфлар—формация, димәк, мәкальләр сыйнфый тәҗрибә. Шулай булгач, алар тагын шул ук баягы сыйнфый формацияләр категориясе булып кала. Аның үзенә бер мөстәкыйль әдәби жанр булуы да инкарь ителә. Шул рәвешле бу тезис берничек тә мәкальләргә генә караган билгеләмә була алмый, бәлки фәннең башка өлкәләренә карата да кулланырга яраган бер сүз булып кала. Чөнки алар турында шулай ук "социаль-тарихи тәҗрибәләрне үрнәк рәвештә калыпка салып бирә",—дип әйтеп булачак. Ләкин моңа карап беркемгә дә фәнни тезисларны мәкаль икән дип аңларга туры килмәс.

Мәкальләрне аңлауга төптә комачаулый торган мондый схемачылыкларның бездә үз вакытында бик киң урын алган булуы билгеле. Моның сәбәбе тарихи һәм бик тирән. Ул бездә иске ишанлык культы һәм аның гасырлар буе халыкның миен миңгерәйтеп килгән булуы, соңгы якта исә шәхес культы һәм бигрәк тә маррчылык догмалары белән дә бәйләнгән. Халкыбызның теле, әдәбияты һәм гомумән аның гыйльми-иҗади фикеренең үсүенә төп комачау булып килгән бу догмачылык үзенә аерым тукталуны сорый. Монда тик аның мәкальләр өлкәсенә китергән зарарын гына әйтәсе килә. Мәсәлән, Маррның тел сыйнфый һәм шартлавыклы әйбер дигән бер тезисын догма итеп алу һәм шуның аркасында бездә һәр сүзнең сыйнфый астарын эзләү аеруча нык урын алды. Шуның аркасында гомумән мәкальләргә карата шикле караш тудырылды һәм хәтта аларны ликвидацияләргә омтылулар да булды. Чөнки ул "сыйнфый" сүзләр мәкальләрдә дә күп бит. Шулай булгач, билгеле, мәкальләрне дә аерым берәр сүзенә карап, сыйнфый безнеке һәм безнеке түгелгә бүлү мәсьәләсе килеп басты.

Мондый алдан ук әзер берәр схема колы булган кеше гадәттә менә ничек эш итә:

Китапны ачты, карый, анда, әйтик,—*Сабыр төбе сары алтын,*—дигән бер мәкальне күрә. Бик кыска, дүрт кенә сүзле бер җөмлә. Бик җиңел аңлашыла. Хәзер инде бу мәкаль кайсы иҗтимагый тәҗрибә җимеше? Кемнәр фикере бу? ди. Сүзләрен карый. Хәер, турыдан-туры гына бер сыйныфны белдергән сүзе юк югын, ләкин мондый көферлек эзләүче кеше үтә сизгерлеккә салына, кылны кырыкка яра: *сабыр* кем сүзе? Гарәпнекеме? Дини сүз!—Әйе, әйе. Дин ярлы халыкка сабыр итеп яшәргә кушкан. Шулай булгач, бу—капитализм чорына кайтып кала, эксплуататорлар моны ярлыга карата әйткәннәр, менә аның "симәнтикә"се, ди дә бетте. Шул рәвешле бездә бу мәкаль сыйнфый дошман сүзе итеп игълан ителә.—*Сабыр иткән—морадына җиткән,* — дигән мәкаль дә шуңа кертелә. Шуннан: "Мондый типта булган мәкальләр безнең бүгенге шартларда, әлбәттә, җирлек таба алмыйлар"*,—дип инкарь ителә. "Мондый типта..." —ягъни, шуңа охшатып башкаларын да сызарга дигәне. Ягъни, алар безнеке түгел.

Халык иҗаты буенча мондый вульгар социологизм теориясенең төптә мәкальләрнең үзенең булуына каршы юнәлгәнлеген аңлыйсы авыр түгел. Мәсәлән, шул ук Х. Галинең "Мәкальләр һәм әйтемнәр" дигән китабының сүз башында болай диелә: "Феодализм җәмгыятендә эксплуататор сыйныфлар үз интересларын үткәрү өчен фольклор материаллары арасына төрле чүп-чар кертергә тырыштылар"... "Боларның бер өлеше элекке капитализм тормышыннан калган булсалар, кайберлә-

*Карагыз: Х. Галинең "Мәкальләр һәм әйтемнәр" китабына язылган сүз башы. 1941.

рен соңгы елларгача сыйнфый чит элементлар фольклорга кертергә маташып килделәр. Мондый материалларны, әлбәттә, без үзебезгә культура мирасы итеп ала алмыйбыз, киресенчә, андый материалларга каршы көрәшү, аларны фольклор материаллары арасыннан чистарту совет җәмәгатьчелегенең бурычы булып тора". Бу куркынычлы сыйнфый мәкальләр нindiләр сон? Ул менә мисал итеп— *Кара халык, кара сарык;—Байдан акмаса да тама* һәм сабыр турындагы баягы мәкальләрне китерә. Ләкин шул китапка язылган бер тәнкыйть мәкаләдә* мона гына риза булмыйча, сызып ташланырга тиешле мәкальләр тагы да бар әле, дип, китапта калдырылганнарына да күрсәтелә. Шундыйлардан:—*Биргән бигә яраган, бирмәгән нигә яраган?—Юл газабы—гүр газабы;—Малсыз базарга бару—кәфенсез мазарга бару;—Үткән эшкә салават, калганына бәрәкәт* һ. б. шуның ишеләрне сызып ташларга тәкъдим итела һәм "тәңре", "шайтан", "фәрештә", "савап" шикелле сүзләр катнашкан мәкальләрнең китапка басылган булуы җыентык редакторының "аеруча саксызлыгы" дип, Ярми иптәшкә кисәтү ясала. Шул рәвешле, бу тәнкыйть мәкаләсенең фикере буенча, калган 700 мәкальне дә бик ныклап сызарга яки китапны бөтенләй чыгармаска тиешле булган булып чыга. Мондый гайрәт, бу хәтле тырышлыкларның нәтиҗәсе ни булып чыгасын күрү авыр түгел. Күп еллар буена мәкальләр җыю өстендә эшләгән Хәсән Галинең бу китабы нибары 700 мәкаль белән чыгуы үзе үк мондагы "сыйнфый" көрәшнең нинди күләмдә барганын күрсәтергә житсә кирәк.

Билгеле, һәрбер иҗтимагый чор, шул өземтәдә әйтелгәнчә, "үз чүп-чарын фольклорга кертергә" тырышкан булуы хак, без дә халык иҗатын алардан арындырырга тырышкан кешене мактарга гына тиеш булыр идек. Ләкин аларның кайсысы халыкныкы, кайсысы "чүп-чар" икәнен каян белергә? Бәла дә шунда, бу халыкчанлыкның бездә үзенчәлекләре өйрәнелмәгән һәм бу арындырулар да мәкальнең үзенә, үзлегенә таянып эшләнмичә, бәлки кампаниячелек һәм вульгар-социологиячелек күзлегеннән югартын торып кына эшләнгән эшләр булуында. Бу унай белән бер кампаниядә бер мәкаль безгә кирәк булган өчен генә халыкныкы дип алынып та, икенче кампаниядә нәкъ шуның үк "чүп-чар" дип сызып ташлануы яки аларның сәнгатьчә булмаганнары, чыннан да чүп-чарлары алга сөрелүе бер дә гаҗәп түгел. Шул югарыда китерелгән мисаллардан үк күрелүенчә, мәкальләргә "чистка" ясау, күбесенчә, Марр теориясе нигезендә, алардагы аерым берәр сүзгә "сыйнфый" дип карауга гына корылган механика булуы ачык. Һәм китаптан китерелгән ул өземтәдән күренүенчә, андагы сүзләр безне фольклор мирасын туплау һәм аны өйрәнүгә чакырмыйлар, бәлки аларның "бер өлешен" дошман сыйныфныкы итеп танырга, аларга каршы изге сугышка чакыралар. Шулай итеп, кешеләр бары тик шундый алдан бирелгән әзер схемалар буенча фольклорны андыйлардан "чистарту"ны изге бурыч итеп таныганнар, җәмәгатьчелекне шуна чакырып, үзләре дә җиң сызганып шул эшне алып барганнар. Эшләгән эшләре фактта исә, берннди дә "сыйныфлар"ны бетерү булмыйча, бәлки гомумән халык иҗатын һәм шулардан бик мөһим бер жанр булган мәкальләрне ликвидацияләү булып чыккан. Чөнки бу юл белән мәкальләрне өлешләп сызып ташлау аларда гомумән мәкальләрнең барысына да карата шикле караш тудырырга алып барган. Чынлап та, әгәр без мәкальләргә гомумән элекке сыйнфый җәмгыятьләрнең иске тәҗрибәләре үрнәге дип кенә карыйбыз икән, бүгенге безнең сыйныфсыз җәмгыятьтә, фән-техника чәчәк аткан, атом гыйлемнәре белән коралланган бөек социалистик ил кешесенә аларның ни әһәмиятләре бар? Нәрсәмә кирәк? Тарихка коллекцияләр җыю өченме? Анысы белән тарихчылар, музей кешеләре үзләре шөгыльләнсеннәр. Шул рәвешле, бу тезисларның, схемаларның нигезендә мәкальләрне җыю, чыгаруларның кирәге дә калмый һәм бу вульгар социологизм вәкилләре шуна ирешкәннәр дә: соңгы 30—40 ел эчендә бездә шул Хәсән Галинең кечкенә брошюрасыннан башка бер генә дә яңа мәкаль җыентыгы чыгарылмаган.

Билгеле, бу әйткәннәрдән мәкальләрнең иҗтимагый-сыйнфый җирлекләрен гомумән инкарь итү килеп чыкмый. Болар тик бездә нык тамыр җәйгән вульгар

---

* "Совет әдәбияты" журналы, 10 нчы сан, 1941.

социологизмның, догмачылыкларның әдәбиятыбызга ни дәрәҗәдә зарар китерүләрен ачу өчен языла. Югыйсә, мәкальләрнең иҗтимагый-сыйнфый мөнәсәбәт һәм каршылыкларны турыдан-туры чагылдырганнары да шактый булып, алар бу китапта үзләренә аерым тема һәм бүлекләр булып урын алалар.

Киресенчә, минемчә, мәкальләрнең үзенчәлеге һәм шул иҗтимагый функцияләре шактый катлаулы булганга һәм алар әлеге хәтле бездә тиешенчә өйрәнелмәгәнгә күрә дә бу өлкәдә шундый вульгарлаштыру, тәкълитчелек һәм башка зарарлы нәрсәләргә юл калдырылган да. Шулай ук хезмәт халыкларының тормыш, социаль-тарихи тәҗрибәләрен мәкальләрнең үзенчәлекле чагылдыруларын да (яки үрнәк рәвештә калыпка салуларын) бу китапта җитәрлек табачакбыз. Билгеле, мәкальләрнең барлык бу яклары бер безгә генә кагылышлы булмыйча, башка халыкларның шундый ук төрдәге мәкальләре белән дә мәгънә ягыннан күпмедер уртак яклары бар. Шулай ук мәкальләрнең, жанр буларак, бар халыкларда да булуын күздә тотсак, бу саналган яклар, бер безгә генә кагылмыйча, барлык халыклар өчен дә гомуми әһәмияткә ия булып торалар.

Билгеле, мәкальләр тарихи-иҗтимагый тормыштан башка туа алмый, яши алмый. Ләкин һәр халыкның үз тарихы булганга, аны үзе ясаганга, мәкальләр бу яктан караганда, нигездә, һәр халыкның үз эчке иҗтимагый сыйнфый каршылыкларын, үз тәҗрибә һәм тормыш таләпләрен чагылдыралар һәм мәкальләрне дә бары тик үз тел культурасы чаралары белән тудыралар. Бу яктан караганда, аның төрле иҗтимагый, сыйнфый баскычларны үтүе дә, андагы өлгерешләре дә, тәҗрибә һәм культура дәрәҗәләре дә үзләренә генә хас тарихи, сәяси, иҗтимагый, экономик, географик һәм башка бик күп җирле шартларга һәм күрше мөнәсәбәтләргә бәйләнгән. Халыкларның берсендә булган иҗтимагый формацияне, әлбәттә, икенчесе дә үтүе һәм нәкъ шуны кабатлавы шарт түгел. Бу хәтта бер патшалык эчендәге төрле халыкларга карата да шулай. Мәсәлән, урыс феодализмы крепостнойлык правосын үз башыннан кичергән яки чиновниклар катламы һәм сенат торгызган икән, татар җәмәгатьчелеге өчен дә шул ук нәрсәләр хас дигән сүз түгел. Яки кыргыз, казакъларга социализмга күчү өчен, әлбәттә, капитализм баскычын үтүнең дә кирәге булмаган. Шулай ук урыс промышленность капитализмы белән татар капитализмының дәрәҗәсен дә янәшә куеп булмый. Шунлыктан татар халкының үсеш дәрәҗәләрендә башка халыклар белән иҗтимагый, сыйнфый формацияләрдә гомуми закончалык ягыннан охшаш яклар булса да, бу тарихның эчтәлеге, билгеле, үзенчәлекле. Шуның белән бу мәгънәдәге мәкальләре дә, гомуми якларында уртак урыннары булуга карамастан, формалары белән генә түгел, мәгънәләре белән дә үзенчәлекле.



*Нәкый Исәнбәт. 1919 ел*

Алыйк, мәсәлән, борынгы кол асраучылык һәм коллар сыйныфына бәйләнешле булган мәкальләрне. Андыйлар да бездә аз түгел:—*Кол кайгысы бер качмак;—Кол ашаганын мактар;—Колны мактансын дисән, алыска* (еракка) *сат;—Кол котырса, коега кармак салыр,* — кебек мәкальләр аша колларның сатлык товар булулары, авыр язмышлары күренә. Кол белән би (бик, бәк) арасындагы мөнәсәбәт һәм аермалар да мәкальләрдә чагыла:—*Бигә би дисәң, өлгесе килер, колга би дисән, көлкесе килер;—Яхшы булса бидән, яман булса колдан* (күрерләр);—*Коешканы көмештер*

*—бинен аты би булыр, коешканы алтындыр—колның аты кол булыр* һ. б. Борынгы формада сугыш коллары асрау, сатулар Россия кул астына кергәч бездә беткән кебек, алпавытка коллар беркетү дә бик сирәк күренеш. Шунлыктан да коллар һәм биләр турындагы мәкальләрне бездә ханлыклар заманындагы феодаллык чорыннан яки кайберләрен аннан да борынгырак кол асраучылык, патриархаллык заманнарыннан калгандыр дип уйларга туры килә.

Галәттә, иҗтимагый мәкальләрдән кинрәк колачлысы итеп дәүләт төзелеше турындагы мәкальләрне саныйлар. Чөнки аларда халыкның көндәлек тормыш, көнкүреш кайгылары гына түгел, аның ил, ватан, дәүләт, хокук турындагы уйлары һәм мөнәсәбәтләре дә чагыла. Бездә Болгар, Казан дәүләтләре күптән җимерелгәнгә, аларга бәйләнешле күп кенә мәкальләр онытылган, юкка чыккан, әлбәттә. Шулай булса да, тарихта берничә мәртәбә дәүләт төзегән, хөкүмәт тоткан халыкта боларның кайбер эзләрен күрсәткән мәкальләрне әле дә очратып була:*—Патшалык мал белән, мал—яу белән;—Халык кайгысын хан чигәр, хан кайгысын кем чигәр?—Барма ханга, үзе килер малга, барма бигә, үзе килер өйгә* һ. б. Боларда дәүләтнең бер кеше кулында һәм каефендә булуы, ханнарның халыктан аерылган булуы, патшалык сәясәте сугышка бәйле булуы кебек хәлләр әйтелә. Хәер, патшалык турындагысы урыс патшаларының империалистик басып алучылык сәясәтләре турында әйтелгән булуы да мөмкин.*—Комы юк су булмас, бие юк ил булмас, якасы юк тун булмас, түрәсе юк йорт булмас,*—дигән мәкальдә ил—йорт, закон—хөкем тәртипләре булуны, дәүләт сәясәте тотуны яклау күренә. (Йорт—монда илнең Территориясе, түрә—закон, хөкем мәгънәсендә.) Монда башбаштак, күчмә кабилә булып яшәүдән шәһәргә, феодалларга буйсыну артык дигән димләү сизелә. Шулай ук:*—Даланың бие булганчы, каланың эте бул,*—дигән мәкальдә дә борынгы патриархаллык һәм күчмә кабилә булып яшәүнең таркалу көннәрен, феодаллык дәүләт системасын яклауны бик ачык күреп була.

Инде капитализм чорын, аның сыйнфый бүленеш һәм каршылыкларын чагылдырган мәкальләр тагын да күбрәк булуы табигый. Татар мәкальләрендә хосусый милеккә һәм байлыкка омтылуның кешедә чамасыз дәрәҗәдә комсызлык, нәфес азгынлыгы һәм саранлык уятуы күрсәтелә *(Ярлы—байга житсәм диер, бай—ходайга житсәм диер;—Татар баеса, хатын алыр;—Хәерче* баеса, *дөньяга сыймас;—Тавык симерсә, арты бөрешер* һ. б.). Байлыкның кешегә бәхет һәм тынычлык китермәве *(Бай түшәге тигәнәк, фәкыйрьнеке мамык;—Дөньяда ярлылык ачы,*—ләкин,*—Ярлылыктан яхшы нәрсә юк, ятып ашар аш булса);* байлыкның фани, вакытлы нәрсә булып, бервакытта да кеше өчен идеаль булмавы *(Байлык бер айлык;—Байлык морад түгел, ярлылык оят түгел)* һәм башка шундый кайбер фәлсәфи фикерләр дә әйтелә. Болардан күренүенчә, ярлылык үзалдына ачы һәм мохтаҗлык булса да, кешенең төп артыклыгы, төп кешелек сыйфаты байлык яки ярлылыкта түгел икәнлеге бик ачык әйтелә.

Билгеле, мәкальләр арасында ярлыларга нәфрәт белән әйтелгәннәре дә юк түгел (Ярлы *кеше яман чир, туры килсә каның эч,* кебек). Монда сыйнфый эксплуатацияне яклау күренә, мондый мәкальләр изүче сыйныфлар тарафыннан әйтелгән һәм чыгарылган булуы бик ачык.

Шулай ук мәкальләрдә ярлыларның байларга бәйле һәм мохтаҗ булып яшәүләре дә *(Байны яманларсың, байга барырсың;* һәм баягы сызып ташларга тәкъдим ителгән*—Байдан акмаса да тама,* кебекләр), байларга читтән төрттереп, астыртын нәфрәт белән әйтелгәннәре дә күп. *(Байның авызы кыек булса да, төтене туры;—Авызы кыек булса да, бай кызы ир сайлар h.* б.) Турыдан-туры эшче, ялчылар мәнфәгатен яклаган мәкальләр дә күренә. *(Эшче эшли аткан ук кук., байга иртә төшкән чык кук;—Байның эше, ялчының тамагы* һ. б.) Мондый мәкальләрнең электән үк булулары татар эшче-крестьяннарында сыйнфый аңның революциягә чаклы ук уянган булуын күрсәтәләр. (Мәсәлән, монда мисалга китерелгән мәкальләр Хужа Бәдигънең 1912 елда чыккан җыентыгында да бар, һәм аннан элегрәк тә очрыйлар.)*—Иске байның бөлгәне, яңа байның көлгәне;—Ярлы кешенең тамагы да капчыгы;—Ярлы тапканда, бай сагынганда;—Ярлы кеше акчасын яман товар бетерер h.* б. Бер-берсенә кире мәгънәдә төзелгән мәкальләрдә сыйнфый каршылык тагын да ачыграк күренә;*—Бай бай өчен тырышыр, ярлы ярлыга булышыр;—Бай булганда барын бирмәс, ярлы кеше*

*карап тормас* һ. б. Капитализм тормышында бай белән ярлының гаиләви мөнәсәбәткә керү рәвешләре туа:—*Бай белән кода булсаң, назланып мазанны алыр, ярлы белән кода булсаң, теләнеп мазанны алыр;—Бай килене булганчы, ярлының кызы булсамчы* һ. б. Шулай ук бу чорда без хосусый милекчелекнең нык алга сөрелгән булуын да күрәбез:—*Уртак малны эт жыймас;—Синеке—минеке дигән күңел тарлыгы, ары ят, бире ят—түшәк тарлыгы* кебекләрдә берсендә уртак милеккә каршы әйтелгән булса, икенчесендә хосусый милекчелек кешеләрнең табигатен ваклатуы, тар күңелле эгоистка әйләндерүе әйтелә.

Аннары БАЙ белән БИ сүзләренең әйтелешләре бик якын булганлыктан, борынгы би турында әйтелгән мәкальләрнең кайберләре дә соңрак бай исеменә әйләнеп киткән булуы мөмкин. Шуның өстенә сәүдә һәм арадашлык капитализмы Болгар-Казан жирендә борыңгыдан килгәнгә, бай турындагы мәкальләрнең барысы да соңгы йөзләрдә капитализмның нык көч алган чорларында гына килеп чыкканнар дип кырт кисеп кенә әйтеп булмый.

Шулай итеп, кайбер мәкальләрнең сыйнфый эчтәлеге шактый ачык төсмерләнгән булуына карап, аны кайсы формация һәм кайсы сыйныф мәкале булуын чамаларга юл ачыла. Ләкин "юл ачыла" гына. Әмма шуңа карап, ул мәкальне "халыкныкы" яки "түгел" дип печать сугу ай-һай кыен мәсьәлә. Чынлап та: халыкныкы булмагач һәм халык үзе инде ул формациядә тормагач, нәрсәгә аны телендә асрый?

Мәкальнең текст мәгънәсе, ижтимагый функциясе, хикмәте һәм роле аның тормышта кулланышында нык һәм күп яклы булып ачыла икәне югарыда бер әйтеп үтелде. Шуңа күрә дә мәкальне китаптан укып аңа үзең мәгънә бирү, аны нинди дә булса кулыңдагы инструкциягә карап, әзер бер схемага кертү—бер эш, әмма аның тормышта ничек кулланылуы, кем тарафыннан, нинди урында, нинди мәгънәдә әйтелүе—икенче эш. Мәсәлән, югарыда күрсәтелгәнчә, безнең китапларда сыйнфый дошман сүзе дип сызып ташланган баягы—*Сабыр төбе сары алтын* дигән мәкальне алып карыйк. Әгәр дә аны берәр бай кеше үз язмышыннан сыкранучы ярлы кешегә карата әйтсә, бу инде аңа—башыңны и дә, язмышыңа күн, дию була, бу мәгънәдә әйтүе аның сыйнфый мәнфәгатен тәгъбир итә. (Безгә хезмәт итми, кирәге юк!..) Ләкин ниндидер бер иптәшең бик кызуланып хатыны белән аерылышырга йөргәндә, син аңа ашыкмаска киңәш биреп:—*Сабыр төбе сары алтын,*—дисәң, бу чагында син бер дә сыйнфый сүз әйтмәдең, бәлки гаилә арасын төзәтешү, киңәш бирү йөзеннән әйттең. Яки шул ук мәкальне бер ярлы кеше үзенә-үзе әйтсә, бу инде аның авырлыкларны бер жиңеп чыгуга ышануы һәм шуңа хәтле ничек тә түзәргә ниятләнүе булып чыга. Өметен жуймаган кеше аның чарасына да керешергә тиеш була. Бу бик яхшы эш. Аннары, чынлап та, зур эшләр яки ижтимагый принципиаль, зур көрәшләр өчен дә озак хәзерлек һәм сабырлыклары таләп ителмимени... Күрәсең, андый мәкальләрне *сабыр* яки башка шундый сүзе өчен генә дошман сыйныф фикере дип юк итәргә ярамый. Чөнки болай итү шул ук сыйнфый сүзләр теориясе белән эш итү, маррчылыкның нәкъ үзе булып чыга. Аннары болай карау *сабыр* сүзен дөрес аңлаудан да килеп чыкмый, бәлки аны урысча *смирение* сүзенә, ягъни, пассив христианлык фәлсәфәсенә туры килә дип уйлап, кайберәүләрчә, татар сүзен урысчага механик тәржемә итеп аңлаудан да килеп чыккан эш. Хәлбуки *сабыр* сүзендә андый төшенчә юк. Ул бездә күбрәген түзү сәбатлы түзем, максатка ирешү юлында чыдамлык кебек актив мәгънәдә кулланыла. Жырда да бит: сабырлыклар белән эшләр кылсак, шаять ирешербез моратка. Шулай итеп, элек мәдрәсә шәкертләре гарәпчә язылган һәр текстны су кебек эчеп тә, шуңа шәрех—хашия (коментарий) баглау белән шөгыльләнгән кебек, монда да урысча сүзнең төбе-тамыры ни икәнен дә уйлап тормастан, шуңа бездән иллюстрация эзләүдән ясалган ялгыш килеп чыкканын күрәбез

Мәкальләргә болай сыйнфый ярлык тагып нәтиҗә ясау, кызыл кара белән сызып ташлау, кәгазьдә никадәр жинел булса да, гамәлдә нигезсез икәне шул авторларның үзләре китергән башка мисалларыннан да күренә. Әйтик,—*Кара халык—кара сарык,* мәкале капитализм чорында чыккан дигәненә каршы шунда ук кайтарып мондый сорау биреп була: ни өчен капитализм чорында? Ни өчен аның феодализм заманында яки тагын да элегрәк чыгуы мөмкин түгел? Шул

рәвешле мәкальләрне кайсы иҗтимагый формациягә теркәү үзе үк еш кына вакытта һавадан алынган булып чыга. Аннары бу мәкаль бездә "динчеләр тарафыннан хезмәт халкын кимсетү" өчен әйтелә дип аңлатыла. Дөрес, алар авызыннан әйтелгәндә, кимсетү очраклары да булгандыр. Ләкин ни өчен мәкальне "динчеләр" авызыннан гына әйттереп карарга? Аны шул ук хезмәт халкы да әйтә алмыймыни? Әйтик, сине алып бара торган олаучы агай гади генә бер нәрсәне аңламаганда, гафу үтенгәнсыман:—нишлисең бит, без шул *кара халык —кара сарык,* инде дип куя икән (һәм шуны капитализм чорында да әйткән булса), ул шуның белән үзенең надан калуына тәнкыйть күзе аша карап үкенеч белдерүен, өстен сыйныфлар кулында сарык көтүе булып кителеп йөрмәс өчен гыйлем-мәгърифәт кирәклеген төшенүен һәм, димәк ки, күпмедер дәрәҗәдә сыйнфый аңының уянуын да әйткән була түгелме соң? *Кара* сүзе монда укымаган, надан мәгънәсендә булып, гомумән бу мәкальдән наданлыкны хурлаудан башка мәгънә табуы кыен. Яки шулай ук бая сыйнфый дошман сүзе дип күрсәтелгән: *—Биргән бигә яраган, бирмәгән нигә яраган?* мәкален алыйк. Бу сүз взяткачылыкка карата көлү төсендә, ирония катыш әйтелә һәм бу фахиш гадәтнең бездә урын тотарга нигезе калмаганлыкны мәкальдәге "би" сүзе үзе үк күрсәтеп тора. Әмма ул борынгы заманнарда кешеләрнең властька ярау өчен взятка биреп яшәргә мәҗбүр булганлыкларын, масса̂ар ул вакытта ук шундый мәкаль аша бюрократиянең нигезеннән үк черек икәнен фаш итә алганнар икән, бу мәкальдә нинди контрреволюция булсын? Шул рәвешле, халык мәкальләрен ликвидацияләүгә чакырулар Марр теориясе нигезендә аерым "сыйнфый" сүзләр эзләп, шуларга бәйләнү, вульгарчылык, схематизм һәм шул ук феодализм чорының калдыгы булган догмачылык, нәкылчелек*, тәкълитчелек булып, бу чирләр белән мәкальләрдән бигрәк ул иптәшләр үзләре чирләгән булулары аңлашыла.

Дөрес, кайбер мәкальне башлап кем чыгарган һәм хәзер аны кемнәр әйтә икәнен белеп тә була. Мәсәлән,*—Иргә ышанма, Иделгә таянма;—Ирдән икмәк салмыйлар;—Ирем үлде, иргә бардым—имгәк алдым.* Мондыйларны хатыннар чыгарган һәм әле дә алар әйтә. Ләкин кайбер мәкальнең башлап кем авызыннан әйтелгәнен белеп булса да, кемнәр әйтә икәнен тәгаенләп булмый.*—Без өйләнгәч, төн кыскарды—*дип кияүләр әйткән, әмма хәзер кем генә әйтми!*—Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала?* Моны башлап ике мулланың берсе икенчесенә әйткән булуы күренеп тора. (Вульгарлаштыручылар күзлегеннән караганда, динчеләр әйткән сүз булгач, бу халык мәкале дә булмый, тот та сыз гына!) Ләкин бу мәкальне бер-берсенә салынган ике кеше, теләсә эшче, теләсә колхозчы, студент, хәтта начальник булсын, хәзер дә бөтен кеше әйтә. Билгеле, болай әйткәннән беркем дә мулла булмый һәм мулла фикере белән фикер-ләнми, киресенчә, мондый хәл тик муллалар өчен хас булган бер-беренә салынуның тискәре бер күренеш төсендә хәзерге көндә дә мисал булып кала бирә.

Яки сыйнфый булмаган, хезмәт темасына караган прогрессив берәр мәкаль алып карыйк. Әйтик:*—Хезмәт төбе—хөрмәт.* Бу бүгенге социалистик хезмәт өчен дә бик характерлы мәкаль. Ләкин аны кемнәр генә әйтми һәм әйтмәгәндер! Аны хезмәт халкы гына түгел, бай да, мулла да, патша да әйтә ала. Чөнки хезмәт барысына да кирәк. Билгеле, кайсы әйтсә дә, ул мәкальне үз урынында, үз файдасына хезмәт иттергән. Хәзер бу мәкальне кая куябыз? Эксплуататор авызында аның файдасына да әйтелүе булгач, тагын сызарга?

Вульгарлаштыручылык "теория"се буенча, билгеле, сызып барудан да җиңел эш юк. (Нинди рәхәт, нинди җиңел хезмәт бу сызу гыйлеме!) Ләкин шунысы гаҗәп: гадәттә мәкаль җыентыгында андыйларны күргәч тә сызып ташларга ашыгучы авторлар үз әсәрләрендә яки үз чыгышларында берәр унай белән үзләре үк шундый "иң сыйнфый" мәкальне дә куллана яки геройларыннан әйттерә.

Анда аның аллалысы да, муллалысы да, патшалысы да, шайтанлысы да ярый. Ни өчен? Чөнки ул анда конкрет иҗтимагый кулланышында яки сүзгә мисал булып килә һәм шуның белән аклана бирә.

Бу хәл үзе нәрсәне күрсәтә соң? Димәк, мәкальнең үзалдына мәгънәсе

Нәкылчелек—аңсыз рәвештә цитатага иярүчелек

булса да һәм ул үзенә мөстәкыйль әдәби әсәр булса да, шул ук вакыт телдәге охшату һәм кинаяле мисал буларак, бер үк мәкаль төрле иҗтимагый катлау һәм сыйныфлар тарафыннан киң кулланыла ала. Ул мисалда синең муллага яки хан кызына охшатылуың бер хәер, эткә, кошка һәм..., алла сакласын!—үзең усал каенана булсаң, кандалага охшап куюың да бар!(*Кандалага дару юк, каенанага үлем юк...)* Берни эшләр хәл юк, ил авызына иләк каплап булмый...

Шулай булгач, хикмәт нәрсәдә? Димәк, мәкальнең иҗтимагый функциясе эчтәлегеннән киңрәк. Бу ике нәрсәне механик рәвештә бергә сыйдырырга маташудан еш кына вакытта баягыча вульгарлаштырулар килеп чыга. Шулай булгач, мәкальне текстындагы аерым сүзләргә карап кына аерым сыйныф малы итеп беркетергә ярамый. Бу аның иҗтимагый (функциясен чикләү һәм кирәк чагында безгә файдалану юлын бикләү була. Әлегә хәтле мәкальләрне вульгарлаштыручылар тарафыннан җинел генә сыйнфый мөһер сугылырлык булганнары да юлбашчылар сүзендә мисал мәгънәсендә куллануларын онытмыйк. Мәкальләр сыйныфлар аша бүгенгә хәтле килеп җитә алганнар икән, димәк, аларда ул яклар чагылгалау белән бергә, гомумән халкыбызга һәм кешеләргә хас ниндидер башка сыйфатларны да алар үзләренә җыйган булырга тиешләр. Шуңа күрә дә мәкальләрне өйрәнгәндә, эшнең бер ягы белән генә чикләнмәскә, безнең эш тә аларның тагын гомумирәк башка сыйфатларын да табу, аларның шул иҗтимагый функцияләрен киңрәк ачу, тарихи һәм мисал мәгънәләрен, әдәби әсәр булу ягыннан үзенчәлекләрен аңлату булырга тиеш.


*Нәкый Исәнбәт. 1922 ел.*

Инде формация мәсьәләсенә килик. Билгеле, тарихта иҗтимагый формацияләр, кайберәүләр уйлаганча, өстән әзер килеш резолюция яки башка юл белән механик рәвештә ясалмаганнар, бәлки тарихи сыйнфый көрәшләр аша яулап алынганнар, һәр яңа формация искесен җиңеп килүе, халыкның шуны яклавы үз чорында прогрессив момент булган. Шунлыктан да борынгы кабиләчелек—патриархаллыкны җимереп феодаллык корылганда һәм даладагы күчмә халыкларны шәһәрләр үзләренә буйсындырганда чыккан мәкальләрдә, феодалларны яклап әйтелсә дә, үз заманында уңай факт булган. Мәсәлән: —*Даланың бие булганчы, каланың эте бул!* Шулай ук феодализмны фаш итеп, аны алыштырырга килгән буржуа мәкальләре дә заманында уңай урын тотканнар. Шулай ук соңыннан буржуазиянең эксплуатациясен фаш итеп, аның белән сыйнфый каршылыкка кергән хезмәт ияләренең мәкальләре инде байларны фаш итү ягыннан яңа адым булып киләләр. Шуңардан безнең өчен бик кирәкле бер нәтиҗә килеп чыга. Димәк ки, безгә хәтле сынфый җәмгыятьтә туган яки бер-бер сыйныфны яклаган мәкальләрнең монысын хан әйткән, монысын халык әйткән дип өстән карап кына билгеләргә мөмкин түгел. Бер формациянең башланган заманында феодалны яклаган мәкальне халык әйткән булса, икенче формация башында шул ук феодализмга каршы мәкальне дә халык үзе үк чыгарган булуы мөмкин. Чөнки феодаллык үзе борынгы патриархаллык системасын җимереп яңа баскычка, шәһәр һәм калалар идарәсенә күчү ягыннан башта халыкта зур өметләр тудыргач, аларны яклап әйтелгән мәкальләр килеп чыккан кебек, соңыннан шул ук ханнар, биләрнең рәхимсез эксплуатация һәм үзара бетмәс сугыш җәнҗаллары халыкка зур авырлыклар тудыргач, аларга каршы мәкальләрнең тагын шул ук халык тарафыннан чыгарылган булуы бик табигый. Димәк, һәр иҗтимагый-сыйнфый формацияләргә күчү чорында башта аны сыйныф буларак беркетүче мәкальләр туган һәм бу адымны башлаучы сыйныф кына түгел, аны халык та яклаган, аннары аларны таркатучы, инкарь итүче мәкальләр туа килгән. Без сыйныфларны тарихи үсеш һәм каршылыкларында карарга тиеш булган кебек, аларга бәйләнешле мәкальләрнең дә шул ук төрле сыйныфларның төрле чорында төрле мәгънәгә күчүләрен истә тотарга тиешбез.

Аннары бу иҗтимагый формацияләр үз эчләрендә сыйнфый булсалар да,

моңа карап тарихны гел сыйнфый кискен көрәш халендә булган итеп күрү дөрес түгел. Шулай булгач, мәкальләрнең сыйнфый характерда булганнарының һәрберсенә дә, әлбәттә инде, ул тик бу сыйныф карашына гына хезмәт итә дип төртеп күрсәтү шактый бәхәсле. Чөнки мең еллар буе сузылган ул үткән заманнарда, сыйныфлар көрәше туып көчәйгән һәм ижтимагый формацияләрнең алмашынуына сәбәп булган чорлар булган кебек, аның басылган, стабильләшкән заманнары да күп булган. Хәтта ил башына уртак бәхетсезлекләр, читтән көтелмәгән яулар, һөҗүмнәр килгәндә, гомумхалык, гомуммилләт язмышы күпмедер вакытка барлык сыйныфларны һәм җәмгыятьнең барлык катлауларын берләштереп торган заманнар да булды. (Мәсәлән, Россиядә гаять караңгы Александр I патшалыгы көннәрендә, Наполеонга каршы сугыш гомумхалык сугышына һәм ватанчылык хәрәкәтенә әйләнү елларында, сыйныфлар хезмәттәшлеге булды. Шуннан күп тә үтми тагы патшалыкка каршы демократиячелек-декабристлык кебек революцион көрәш каршылыклары да, кузгалышлар заманы да булды. Читтән килгән яуларга күп мәртәбәләр ил көче белән каршы торган Болгар-Казан дәүләтләрендә дә сыйныфлар хезмәттәшлеге "көч алган чорлар булган кебек, сыйнфый каршылык көрәше көч алган заманнар да булгандыр.) Шундый сыйныфара хезмәттәшлек һәм уртак ватан интересы көч алган көннәрдә, өстен сыйныф вәкилләре чыгарган мәкальләрнең дә гомумхалык максатын тәгъбир иткәннәре булырга мөмкин һәм ниндидер аерым патшалар-ханнарга карата гомумхалык тарафыннан уңай бәя биргән мәкальләр дә туарга мөмкин. (Урысларда кайбер олы князьләргә, Петр Беренчегә яки башкаларга карата әйтелгән кайбер мәкальләр, бездә дә:—*Урман бит би үлгән көн, ун сан нугай бөлгән көн,* дигән кебек мәкальләр очравы шуны күрсәтә.) Кыскасы, мәкальләрнең һәрберсенә карата монысы фәлән сыйныфныкы, монысы, әлбәттә, фәләннеке генә дип, борынгыдан калган бер авыз сүз өстенә печать сугып булмый. Боларның күпчелеге киң хезмәт халкы тарафыннан чыгарылган булуы бәхәссез булган кебек, кайберләре югары сыйныф вәкилләре, укымышлылар, дин вәкилләре тарафыннан чыгарылып та халыклашкан булулары бик мөмкин. Әмма инде бүгенге безнең идеяләргә туры килмәгән һәрбер мәкальне бары тик өстен сыйныфлар чыгарган, бары тик алар халыкка көчләп тагканнар дип аңлатулар мәсьәләгә бигрәк тә сай килү була. Чөнки борынгы халык безнең заман фикере белән яшәмичә, үз заманының фикере белән яшәгәнлектән, анардан бары тик безнең идеяләргә туры килгән мәкаль генә көтү бу үзе тарихи килеш түгел. (Яки бу инде киләчәк заман кешеләре дә безнең идеяләр белән генә яшәсеннәр, тарих безнең белән башлансын да безнең белән тәмам булсын, моннан соң булмасын, үсмәсен дигән шикелле балалык капризы булыр иде.) Шунлыктан мәкальләр арасында бүгенге күзлектән караганда артта калган фикерләрне саклаганнары да күп булуы табигый. Ләкин моңа карап, аларны әлбәттә биләр, байлар гына чыгарган да халык пассив рәвештә шуны кабул иткән дип уйлауның, үзендә дә халыкны бик кимсетеп карау, баринлык исе аңкый. Халык үзе әйтергә теләмәгән мәкальне аңардан көчләп әйттереп булмас, әйтсә дә аны үз иҗаты итеп, үз телендә эшкәртеп гасырлар буе саклап йөртмәс. Инде бүген безгә ошамаган берәр мәкальне халык үзе хуп күреп, үз әсәре итеп йөртә икән, монда тагын нинди дә булса башка берәр хикмәт булыр. Чөнки халык мәкальләренең, күбесенчә, икенчел, өченчел мәгънәләре дә булганга, аларның кайбер сызып ташланганнары да безнең файдага хезмәт итә алуларын баягы мисаллардан күреп үттек. Шунлыктан аларның бер билгесенә карап кына ябыштыру мәгънәләрен чикләү күп вакытта ңышлы булып чыгар. Шулай ук бу аңа бер яклы гына килү булыр.

Бу урында безгә мәкальләрнең үзләренә генә тукталмыйча, аларны тудыруда халыкның үткәндәге аң дәрәҗәсенә дә тарихи яктан килергә кирәк. Дөрес, хезмәт иясе халык байлардан золым-җәбер күрүен белгән һәм мәкальләрендә үзенең изелүен, бәхетсезлеген әйтә дә алган, ләкин аңарда хәзерге мәгънәдә сыйнфый аң да, материалистик дөнья танулар да булмаган, ул мулланың эксплуататорлыгын, суфыйларның пуркилеген* фаш иткән, ләкин аңа карап үзе алла яки дин сүзләрен авызга алмаслык революционер, атеист булмаган. Киресенчә,

*Пурки — ханжа, риячы, пуритан мәгънәсендә.

ул дингә ышанган гына түгел, һәртөрле хорафатларга, албасты-убырларга, хәтта мәче очраса, юлны куян киссә, юл унмау шикелле ахмак нәрсәләргә дә ышанган. Кыскасы, татар халкының борынгы дини ышанулары, табигатькә табынудан гыйбарәт булган шаманлык һәм соныннан мөселманлык белән бергә үрелгән кебек, анын мәкальләре дә шундый ук хорафатлар һәм дини ышанулар белән бергә аралашып барган. *(Тәнре малын шайтан кызганган;—Алла кушмаган эш булмас;—Мулланың кушканын кыл, кылганын кылма* һ. б.)

Шул рәвешле, халык мәкальләрендә сыйнфый-иҗтимагый мөнәсәбәтләр дә, әхлакый ышанулар да, башкалар да үзенчә каршылыклы һәм күп яклы булып чагыла. Бу анын тарихи хәле, фикер, культура дәрәҗәсе шулай каршылыклар берлеге булып килүеннән. Мәкальләрне темалары буенча төркемләп алып караганда, бу каршылыкларның күп яклы булып чагылуы безнең өчен бик әһәмиятле. Чөнки бу каршылыклар безгә халыкның, тарихи йөзен дөрес ачарга, аң дәрәҗәсе ничек булганын күрергә ярдәм итә. Шунлыктан бу китап шикелле гомуми һәм тулырак җыентык чыгарганда һәм мәкальләргә аңлатмалар да биреп барылганда, аларга карата югарыда әйтелгән "механик чисткалардан мөмкин хәтле сакланып эш итәргә туры килә. Шулай булмаганда, теге җыентыкларда күрелгәнчә, монда да халык мәкальләрен төшереп калдыру юлына басу, шуның белән халыкның тарихын бер яклы итеп бозып күрсәтү килеп чыгачак. Чөнки андый җыентыкларга карасаң, халык электә дә югары культуралы, хәзерге яшьләр дәрәҗәсендә аңлы булган, аларда тәкъдиргә, дингә ышанулар кая, хәтта андый сүзләрне телләренә дә алмаганнар; (чөнки андый мәкальләр сызып ташланган!) халык материалист булган, гел эксплуататорлар сыйныфын фаш итеп торган; сыйнфый аңнары белән дә бүгенге совет кешеләре дәрәҗәсендә булган булып чыгалар. (Тик шунысы гаҗәп, халык ул заманнарда ук шул хәтле материалист, атеист һәм сыйнфый аңлы да булгач, нишләп бер төркем эксплуататорлардан үзләрен издереп, талатып, алар кул астында изелеп, солдат булып сугышып, алар дәүләтен саклап, мең еллар буе кол булып дөньяда яшәгәннәр? Ни өчен шулкадәр сыйнфый аңлы халык эксплуататорларны бәреп төшереп, үзенә демократик власть төземәгән? Билгеле, мондый хәлнең тарихта булганы юк. Шуңа күрә дә мәкаль китапларында мондый хәлнең булуы хәзерге заман революциясен борынгы заманның үзендә ясарга омтылу һәм андагы кешеләрне дә фикер ягыннан хәзерге совет заманы дәрәҗәсендә үскән кешеләр итеп бозып күрсәтү була.) Үткән заманнар мирасы булган мәкальләрнең безгә, совет кешеләренә, охшаганнарын гына шулай сайлап чыгарудан тарихны бозып күрсәтү, аны идеаллаштыру яки халыкны бер дә тарихсыз итеп күрсәтү килеп чыгуы мөмкин.

Шул ук вакыт, мәкальләрнең берәр темага яки балалар яшенә карата булганнарын яки башка берәр максат белән аерым чыгарганда, билгеле инде, аларны сайлап чыгарырга туры килә. Мондый хосусый максатлар өчен төзелгәндә мәсьәлә башка, әлбәттә.

Инде мәкальләрнең гомуми һәм уртак якларыннан чыгып, аның мөстәкыйль урын тотмыйча, иллюстрация булып йөрү мәсьәләсенә килик. Мәкальләр башка әсәрләрне язганда һаман телгә алына һәм мисалга китереләләр. Бу чагында аларның кайберләре партия тарихында да, сыйныфлар тарихы китабында да, башкаларда да андагы берәр фикерне куәтләү яки юкка чыгаруда дәлил була алалар, ягъни мәкаль бу очракларда иллюстратив роль уйный. Әмма бу әле мәкаль үзе гомумән социология тарихы яки башкага иллюстрация материалы гына икән дигән сүз түгел. Мәкаль—ул авыз иҗатының бер төре булган мөстәкыйль тормышлы әдәби әсәр. Ул бер урында иллюстрация булып килергә яраса, икенче урында шул ук бер нәрсәне мактау яки инкарь, кисәтү, киңәш, күзәтү, мисал, алдан хәбәр яки хөкем һәм башка нәрсә дә булып килә алган хәлдә, үзенең сәнгать әсәре булуын югалтмый.

Күпчелек мәкальләр һәртөрле иҗтимагый-сыйнфый җәмгыять формалары аша үтеп һаман яши бирүләре ягыннан бик игътибарга лаеклы. Без аларның бу үзенчәлегенә алда тукталырбыз. Тик бу уңай белән монда безгә хәзер түбәндәге өч моментны истә тотарга кирәк. Иң элек, мәкальнең үз текст мәгънәсе булса да, ул гомумән, нинди урында һәм кем тарафыннан әйтелгән булуына карап, мәгънәсен авыштыра һәм, күбесенчә, мисал урынында китерелә. Икенчедән,

шуның аркасында бер үк мәкальнең төрле сыйныфка да хезмәт итү мөмкинлеген дә мисалларда күреп үттек. Бу исә мәкальнең икенчел, өченчел мәгънәләргә дә ия булып, кулланышта конкрет очракларга бәйләнешле булуыннан килә. Ягъни, мәкальнең иҗтимагый функциясе текст мәгънәсеннән кинрәк...

Өченче момент: мәкальләрне тудыруда тәҗрибә һәм практиканың роле зур булса да, бар эшне дә шуна гына кайтарып калдыру, аларның күләм һәм эчтәлеген дә, тормыштагы ролен дә чикләү булыр, барыннан да бигрәк, бу аларның сәнгать әсәре буларак үзенчәлекләрен танымау булыр иде. Чөнки мәкальләрнең ясалуында тәҗрибә белән сынап беленми торган һәртөрле кара ышану, хыял һәм әкиятчә шигъри образлар да (мәсәлән, киная, телбизәк һәм башка сурәтләмәләр дә) катнаша. Мәсәлән:—*Арслан айга менәмен дип аягын сындырган;—Убырның үзе туйса да, күзе туймый;—Үзем тук, кунак тук, аша, туным;—Ишәкнең башын табакка салсаң, тәгәрәп төшәр;—Былтыр үлгән ябалак, быел башын күтәргән;—Тишек ертыктан көлгән;—Эт чаба дип бет чаба;—Җимешнең асылын эт җыя;—Тавык төшенә тары керә;—Тычкан, өненә керә алмаса, койрыгына тубал тагар*—һәм башка шуның шикелле мәкальләрнең төп текст мәгънәләре каралса, турыдан-туры тормышта күреп, сынап беленә торган хәлләр турында әйтелми, шулай ук, андый хәлләрне тәҗрибә аша белергә була дип тә әйтеп булмый. Яки шундыйрак мәкальләрдән арслан, дөя кошы, фил шикелле хайван-җанварлар турында булганнарын алыйк. Мондый җанварлар безнең җирләрдә бөтенләй юк, шулап булгач, мондагы тормыш һәм социаль-тарихи тәҗрибәләр аларны китереп тә чыгара алмыйлар кебек; шулай ук алар тоташы белән тәрҗемә ителеп, экспорт белән читтән кертелгән дип тә әйтеп булмый. Мондый мәкальләр безнең телгә җәнлек-хайваннар турындагы һәртөрле әкият-мәсәлләр аша, көч, власть яки ахмаклык сурәтләмәсе буларак, халык телендә чагылуы яки символ буларак кереп киткән булулары мөмкин. Аннары социал тәҗрибә теориясе тормыш тәҗрибәсенә турыдан-туры бәйләнешле, күзәтмә характерындагы мәкальләргә (әйтик,—*Акчаны кара көн өчен сакла;—Сыерның сөте телендә* һ. б. шуның кебекләргә) туры килсә дә, кинаяле һәм икенчел мәгънәле мәкальләрне ача алмый. Кыскасы, мәкальләрнең формалашуында социаль-тарихи тәҗрибәләрнең роле зур булуын әйтү белән бергә, монда тагын аларның, авыз иҗаты һәм сәнгать әсәре буларак, үз өлкәсе, үз спецификасы барлыгын игътибарга алмыйча ярамый. Коры тәҗрибәгә генә кайтарып калдыру исә аларны халык сынауларыннан (приметы), афоризмнардан, гомумән, фәнни тәҗрибә һәм формулалардан аерып карый алмау була. Шундый абстракт яки тар, утилитар карашлар шул ук вульгар социологизм, схемачылык күренешләре булып, мәкальләрне болар да шул ук социал-сыйнфый иллюстрациягә яки тар практицизмга гына кайтарып калдыруга яисә аларны инкарь итүгә, ликвидацияләүгә алып баралар. Шунлыктан мәкальләрнең шигъри үзенчәлекләре ни икәненә, үз табигатьләрен өйрәнүгә алда кинрәк тукталырга туры киләчәк.

## Алынмачылык*

Авыз иҗатының кайбер жанрлары аерым бер халыкка гына хас булалар. Әйтик, бездәге бәетләр, урыслардагы былиналар шундыйларга керә. Мәкальләр исә башка. Теле булып та, мәкале булмаган халык дөньяда булмас. Ул һәммә халыкларда да бар һәм аңа һәр халыкта да хөрмәт бар. Жанр буларак та, сурәтләү чаралары һәм тормышта кулланышлары ягыннан да, төрле халыктагы мәкальләрнең бер-берсенә охшаш яклары бик күп. Шулай ук телләре ягыннан мәкальләр бер-берсенә охшамасалар да, мәгънәләре ягыннан уртак булганнары һәркайда диярлек очрый. Бездә дә шундый ук хәл. Кайчагында:—Безнең татар халкында менә шундый сүз бар дип бер мәкаль әйтсәң, янында булган икенче бер милләт кешесе:—Андый мәкаль бездә дә бар дип, шуны ук үз телендә әйтеп сала. Шул рәвешле, без үз мәкальләребезне башка халык мәкальләре

*Русчадагы теория заимствования дигән мәгънәдә алынды.

белән чагыштырып карасак, байтаккынасының башка телләрдә дә булуын күрербез. Бигрәк тә башкорт, чуваш, казакъ, үзбәк, әзербайжан кебек кардәш халык мәкальләре шулай. Хәтта алардагы күп кенә мәкальләрнең сүзләрендә дә уртаклык булып, бары тик әйтелешләре яки аерым сүзләр төрләнешендә генә аермалар була. Мәсәлән,—*Ут тотенсез булмый;—Азыклы ат арымас;—Аттан ала да туар, кола да туар;—Эт өрер, карван йөрер;—Түрә түрәне яклар;—Кешегә кое казыма, үзең төшәрсен;—Ат аяган ат менәр, тун аяган тун кияр;—Батыр яуда беленер;—Кылыч ярасы уңалыр, тел ярасы уңалмас;—Ир башына көн туса, итеге белән су эчәр;—Утка килгән хатынның, утыз авыз сүзе бар;—Алып анадан туар, аргамак биядән туар;—Атаннан борын капкынга төшмә;—Ана күнеле балада, бала күнеле далада;—Егет егетнең көзгесе;—Агай-энен тату булса, ат күп, апа-сенелең тату булса, аш күп;—Тәкәнең мөгезе тәңрегә житкәнне кем күргән?—Мәхәббәт жамал теләмәс;—Диңгез баштан болганыр;—Димче диңгез кичерер;—Ашаган белмәс, тураган белер;—Егет кешегә житмеш төрле һөнәр дә аз;—Сабыр иткән морадына житкән;—Бал тоткан бармагын ялар;—Әйткән сүз—аткан ук һ. б.*

Болар бездә телдән әйтелеп һәм мәкаль китапларыбызда кат-кат язып йөртелгән үз мәкальләребез. Ләкин алар кардәш төрки халыкларның, күпчелегендә шул ук сүз төзелешләрендә диярлек әйтелеп йөриләр һәм, билгеле, мондый уртак мәкальләр бик күп табылачак.

Урыс мәкальләре белән охшаш булганнарына килсәк, монда тел һәм төзелеш ягыннан уртаклык юк, әмма мәгънә ягыннан бер үк төсле булганнары шактый күп:

| | |
|---|---|
| Ни чәчсәң, шуны урырсың. | Что посеешь, то и пожнешь. |
| Ике тәкә башы бер казанга сыймый. | Две бараньи головы в один котел не лезут. |
| Төкермә коега, суын эчәрсен. | Не плюй в колодец, случится напиться. |
| Тау тауга бәрелмәсә дә, адәм адәмгә бәрелер. | Гора с горой не сойдется, а человек с человеком. |
| Жиде кат үлчә, бер кат кис. | Десятью примерь, однова отрежь. |
| Ир әүвәлендә жәфа күрми, ахырында сафа тапмас. | Кто нужды не видал, и счастья не знает. |
| Кибән астында тычкан үлми. | Скирдой мышь не задавить. |
| Бер көнлек юлга чыксаң, бер атналык азык ал. | Поезжай на неделю, а хлеба бери на две. |
| Безнең урамда да бәйрәм булыр | Будет и на нашей улице праздник. |

һәм башкалар.

Бу урында мондый сораулар туа: болар берсе икенчесеннән күчереп алынмадылармы икән? Бу охшашларның кайсысы оригинал? Кем кемнән алды икән?

Түгел, бер-берсенә күрше яшәп, катнашып йөргән халыклар арасында гына, хәтта бер-берсеннән ерак яшәгән халыклар арасында да мәкальләрнең бер-берсенә охшаулары еш очрый.

*Без:—Тимерне кызуында сук* — дибез; урыслар: — Куй железо пока горячо, —диләр, французлар: i'l faut battre l fer pendant gu'il est chand,—диләр. Шул мәкаль немецта да, венгерда да, һәммә халыкта да диярлек бар. Без:—*Кешегә баз казыма—үзең төшәрсен,*—дибез. Урысларда да шул ук мәгънәдәге мәкаль бар. Һәм шул ук мәгънәдә әйтелгән сүзне еврей Тәүратларында күреп була (псал. VI1.6). Без:—*Коега төкермә, суын эчәрсен,*—дибез, урысчасын югарыда китердек, шул ук мәкаль борынгы еврейләрнең, Талмуд китабында да бар. Урыслар:—*Начало примудрости страх божий,*—диләр (Даль, 552 бит); әмма шул ук мәкаль Мөхәммәтнең Хәдис китабында да бар. [...]

*Хатын-кызнын чәче озын, акылы кыска,*—Бу мәкаль урыста да, французда да—кайсы халыкта гына юк. Борынгы латинчада:—*Certum est longos esse crines omuibus,*

*sed breves sensus mulieribus* h. б.

Шул рәвешле, татар халык мәкальләреннән урысларда һәм башка халыкларда да уртак мәгънәдә йөргәннәренә бу китапта мәкаль аңлатмаларында күп кенә параллельләр китерелде, укучы аннан караса, күп кенә мисаллар табачак. Мина безнең мәкальләрне кытай, һинд халык мәкальләре белән чагыштырырга кулымда материаллар булмады. Ышанам ки, аларныкы арасында да безнекенә охшаганнары байтак табылачак.

Шулай булгач, "татарныкы" дип йөртелгән мәкальләр асылда безнең үзебезнекеләрме соң? Гомумән, мәкальләр аерым халыкларның үз авыз иҗатларымы, әллә һәммә халыклар арасында телдән телгә күчеп йөрмәдә гомуми хикмәт сүзләреме?

Бу хәл күп кенә галимнәрне уйга калдырган, шул хакта тикшеренүләр ясарга мәҗбүр иткән. Булган бер вакытлар,— авыз иҗаты булган әкият-мәсәлләрне, бигрәк тә мәкальләрне төптә нинди дә булса аерым халыкларның үз оригинал иҗатлары түгел, бер-берсеннән күчереп кенә алынганнар дигән фикерләргә килгәннәр.

Россиядә бу караш бигрәк тә XIX йөз ахырларында урын алган һәм фольклорда "алынмачылык теориясе" дигән мәктәпләр килеп чыгуга сәбәп булган, урыс мәкальләренең алынган чыганакларын күрсәтеп, чагыштырма җыентыклар да басылып чыккан.

Югарыда китерелгән татар мәкальләре бездә дә башкалар белән шундый ук охшашлык һәм уртаклык барлыгын күрсәтәләр. Шулай булгач, безгә дә мәкальләребезнең күчмә һәм башкалардан алынма әсәрләр икәнен расларга гына кала түгелме соң? Безнең кулда шундый чагыштырма фактлар булуга карап кына, ашыгып һәм тиз генә "әйе" дип җавап биреп булмый. Мондый теория һәм тезисларга т ә к ъ л и т итүдән элек, башта аңа тәнкыйть күзе белән карарга,—ул нинди, кайчан, ничек килеп чыккан теория? дип үз алдына сораулар куярга кирәк.

XIX йөз ахырларында Россиядә промышленность капитализмы бик нык үсү аркасында чит илләр белән сәүдә киңәйгән, монополистлар киң Россия туфрагының һәр почмагына үрләгәннәр. Шул сәүдә маллары белән берррәттән көнбатышларның күп кенә сүзләре дә, фикер-хикмәтләре дә, мода һәм модернизацияләре дә, урыс базарын күмеп киткән. Нәкъ шул вакытларда бу хәлләр фикер ияләренең кайберләрен шаштырган, алар арасында культураның гомуми нәрсә генә булуы, хәтта аерым халыкларның авыз иҗаты да күчмә һәм гомуми сюжет, гомуми мәгънәләрдә генә булуы турында теорияләр туган, ясалма гомуми тел җәмгыятьләре (эсперанто һәм башкалар) барлыкка килә башлаган. Россиядә мәкальләрнең оригиналлыгын инкяр итү, аларның алынмалы нәрсәләр генә булуы турындагы мисаллар һәм теорияләр дә шул чорларда киң мәйдан алган. Европа һәм урыс империалистлары бигрәк тә көнчыгыш илләренә колония һәм базар күзлегеннән генә караганга, бу як халыкларының үзләрен бернигә дә талантсыз, сәләтсез хайван көтүе урынында күрү аларның сәясәтләре өчен бик уңай булган, Азия халыклары экспорт товарны Европалылар кулыннан әзер килеш сатып алган кебек, фикер һәм иҗатны да һәм, димәк, мәкаль кебек акыл-хикмәт әйберләрен дә алдынгы "прогрессив идеяле" халыклардан әзер килеш күчереп алырга мәҗбүрләр дип һәм шуны бик табигый нәрсә дип караганнар. Шулай булгач, мондый алынмачылык теорияләренең урын алуы үзе колонизаторлык һәм космополитлык идеяләре алдында тетрәп төшү һәм шул тенденцияне абсолют бер күренеш итеп тану, бөтенләй шуңа йотылу белән бәйләнгән булып чыга.

Шул ук вакыт, икенче яктан, гыйлем-мәдәният, культураларның бер-берсенә йогынтысын да инкяр итеп булмый, әлбәттә. Бигрәк тә соңгы йөзләрдә машина, техника, транспорт чаралары алга киткән саен, халыкларның бер-берсенә аралашу мөнәсәбәтләре, шуның белән аларның бер-берсенә алмаш йогынты ясаулары да зур булды. Культура өлкәсендә бу аралашу тел чаралары аша булганлыктан, халыкларның иң кыска әйтелешле хикмәт сүзе булган мәкальләр дә тиз отып алынып, берсеннән икенчесенә күчүләре аз булмагандыр. Аннан тагын аларның

1 Т ә к ъ л и т иту—ияреп эшләү.

басма сүз аша таралу мөмкинлекләре дә бик киң.

Билгеле, урыс халкы, безгә караганда көнбатыш белән элек-электән бәйләнештә үскәнгә, динне дә борынгы Византиядән алган булганга, аларга Европа культурасының йогынтысы турыдан-туры булган. Әйтик, француз телен белү, Париж шәһәрен күрүләр һәрбер алдынгы урыс кешесе өчен культура билгесе итеп саналган. Шунлыктан көнбатыш мәкальләренең тапкыр һәм характерлыракларының урысларга керү юлы ачык, әмма бездә XIX йөз ахырларынача дини, фикри коймалар аша мондый мәкальләрнең үтеп кереп халыклашуы икеләрәк. Аңарчы безнең халык күбрәк гарәп, иран мәдәнияте тәэсире астында яшәп килгәнгә, алардан күчкән мәкальләрнең бездә булуы табигый. Аларның урысларга кергәннәре дә бар. Снегирев, мәсәлән, гарәп, фарсы мәкальләренең урысларга керүен татарлар аша булды дип аңлата.

Инде урыс, татар мәкальләренең үзара йогынты ясауларына килик. Билгеле, урыс, татар халыклары тарих буена бер-берсенә күрше булып та, төрле чорның төрле сәяси, иҗтимагый хәлләре эчендә, Тукай әйтмешли, "вакытлар алмашып" та бергә яшәгән булгач, алмаш йогынтысыз булмый. Россия кул астына кергәннән соң да Казан татарлары Мәскәү белән Азия арасында зур сәүдә юлларында ятканлыктан, үзара төрле сәүдә мөнәсәбәтләрендә булганнар. Бу мөнәсәбәтләр нәтиҗәсендә тел элементлары һәм мәкальләрнең бер-берсенә күчүләре дә булган, бу хәлләр соңгы заманнарда гына килеп чыкмыйча, борынгыдан ук була килгән. Мәсәлән, бездә:*—Яман ат белән терелгәннән, яхшы ат белән үлгәнең артык;— Ике тәкә башы бер казанга сыймас,*—дигән кебек мәкальләрне без XV йөздә Кырым ханы Миңлегәрәйнең олы кенәз Иоан Васильевичка язган грамотасында да очратабыз. Алар—*"Лучше умереть с добрым именем, нежели благоденствовать с худым;—Две бараньи головы в один котел не лезут,*—дигән тәрҗемәләрдә китерелүен күрәбез. Димәк, бу мәкальләр бездә генә түгел, күрше төрки халыкларда элек-электән киң таралган булган. Инде ул мәкальләрнең урыс мәкаль җыентыкларында да йөрүләре шул грамоталар тәрҗемәсе аша керүләре һәм башка юллар белән булуы мөмкин. Чөнки күршелек мөнәсәбәтләре тарихи һ. б. төрле формаларда булган.

XVIII йөздә яшәгән Украина философы Григорий Сковорода бөтен Европаны җәяүләп йөреп, үз илен гизгән кеше. Үткән йөзнең 30 елларында Снегирев аңардан түбәндәге мәкальләрне китерә:

*Курица кудахтает на одном месте, а яйце кладет на другом. — В прошлом году был пожар, а нынче все еще пахнет. — Рыба от головы начинает портиться.*

Снегирев бу мәкальләрне аңардан алынган һәм шуннан урыс мәкальләре ясалган дип уйлый. Хәлбуки, бу мәкальләр бездә дә күптән бар. Алар болай әйтеләләр: *Тавык йомырканы бер җирдә сала, икенче җирдә кыткаклый. Былтыр янган, быел исе чыккан. Балыкның башы сасыр, яманның аягы сасыр.*

Безнең халыкның үткән йөзләрдә Сковорода әсәрләрен уку яки урысчадан шуның тәрҗемәләрен алып таратып халыклаштыру ихтималы юк. Аның андый матбугаты да булмаган.

Петр Беренчедән соң, бигрәк тә үткән йөздә, урыс империячелегенең көнчыгышны колонизацияләү сәясәте аркасында, күбесенчә, урыстан башка халыкларны христиан диненә кертү максаты белән, аларның, табигатьләрен, көнкүрешләрен, телләрен өйрәнү нык мәйдан ала башлый. Тарих, этнография, география җәмгыятьләре, көнчыгышны белгечләр, тюркологлар көнчыгыш илләргә һәртөрле экспедицияләр оештырып торалар һәм аларның авыз иҗатларын җыялар, тәрҗемәләрен матбугатта игълан итәләр, шул җөмләдән мәкальләр дә бик күп җыела, аларның, оригиналрак булганнары һәм шомараклары урыс мәкаль җыентыкларына да килеп керә һәм шул юл белән Россиядәге күп кенә халыкларның мәкальләре белән беррәттән татарныкылар да урыс мәкальләре арасына кереп китә. Моның нинди күләмдә булуын аңлавы авыр түгел. Иллюстров, мәсәлән, урысларга татарлардан кергән мәкальләрнең санын 3500 дип күрсәтә. (Билгеле, монда татар дигәннән элек татар дип аталган Кырым, Кавказ халыкларының кайберләре дә керә булса кирәк.)

Инде безгә кергән урыс мәкальләре күпме дип соралса, моның чагыштырмача шактый ким булганын күрергә туры килә. Моның сәбәпләре

ачык: беренчедән, татарлар урыс мәкальләрен жыю, өйрәнү яки тәржемә итү бер якта торсын, үзләренекен дә әлегә чаклы юньләп өйрәнмәгәннәр. Икенчедән, үткән йөзнен ахырларына чаклы бездә урысча белгән кешеләр аз булган. Фольклор бастыру ул чорда үзе дә яна күренә генә башлый. Билгеле, урыс мәкальләрен тәржемә итү, халыкны алар белән таныштыруга кул житмәгән. Шунлыктан безгә урыс мәкальләренең электә язма юл белән керүе аз булып, кергәннәре дә үзара аралашу яки белеш булу шикелле очраклы юллар белән генә булган. Игенчелек тормышында урыс календарь системасы роль уйный башлагач, *"Микула житми жәй булмый, микула житми кыш булмый"* дигән кебек урыс халык тәжрибәсеннән туган мәкальләрнең килеп керүләре шушы юл белән булса кирәк.

Инде бу соңгы илле ел эчендә, бигрәк тә революциядән сон, бездә үз культураңны урыс культурасын өйрәнү аша үстерү дигән кин һәм демократик хәрәкәт башлангач, Россия гражданы булган кешегә урысча белү кирәк дигән караштан торып, урыс телен өйрәнү кин мәйдан ала. Шул унай белән безгә урыс мәкальләре дә күпләп керә башлый. Шулай ук кампанияләр унае белән игълан ителгән мәкальләр тәржемә ителеп, безгә матбугат һәм календарь аша да әледән-әле кереп торалар.

Билгеле, мондый тәржемә мәкальләрнең шома һәм шигъри булганнары халык теленә кереп халыклашып китә. Ләкин кайберләре, телләрендәге кытыршылыклары һәм бездәге мәкаль алымы белән әйтелмәүләре сәбәпле, алынма икәнлекләре бик тиз беленә.—*Балык эзләр кайда тирәнрәк, адәм эзләр кайда яхшырак.* Бу мәкаль гәрчә бездә үткән йөздә үк язмада очраса да, ул төзелеше белән үк урысча:—*Рыба ищет где глубже, человек ищет где лучше* мәкален сүзгә-сүз хатергә төшерә. Бу урысларның төп үз мәкалеме, алынмамы, анысы ничектер, әмма моны урыслар бездән алганнар дип уйларга туры килми.—*Икмәк корсак артыннан йөрми, корсак икмәк артыннан йөри,*—мәкале дә шома һәм матур эшләнмәгән, урысча:—*Хлеб за брюхом не ходит* дигәне сүзгә-сүз искә төшерә.—*Юләрне чәчеп үстермиләр, ул үзе үсә;—Безнен гомергә тиләләр житәр әле,* дигән мәкальләр дә:—*Дураков не сеют, а сами родятся;—На наш век дураков станет,* дигән урысча мәкальләрдән соңгы йөздә генә алынып, ясалып кергәннәр. Шулай ук соңгы заманда төрле кампанияләр унае белән, халыкныкына охшатып, төрле ясалма юллар белән татсыз жырлар кергән кебек, ясалмалыгы күренеп торган мәкальләр дә язмада күпләп урын ала башлый.

Билгеле, тәржемә итеп алынмыйча, халык теленчә унышлы һәм шома килеп чыккан мәкальләр дә, яки халык аны телендә йөртеп, эшкәртеп, үз шигъри малы итеп житкергәннәре дә бездә күп. Андыйларнын, хәтта без урыслардан алганмы, яки бездән аларга кергәнме, әллә үзебездән шулай туганмы икәнен дә белү кыен. Мәсәлән,—*Ерак жыйсан, якыннан алырсын. (Дальше спрячешь, ближе найдешь);—Юләр кызылга гашыйк (Дурак красного любит);—Тилегә түрә юк (Дураку закон не писан);—Тиен тәнкәне саклый (Копейка рубль бережет)* һәм башка шунын ишеләр. Мондый мәкальләрнең мәгънәләре бер-берсенә охшаган булсалар да, кайсы-кайсыннан алынган булуын билгеләү бик четерекле булганга, мәкальчеләр арасында, бигрәк тә алынмачылык теориясен яклаучылар арасында, күп кенә бәхәсләр тудырган.

Шунын белән без хәзер бу алынмачылык карашында торучыларнын ин зәгыйфь нокталарына килеп життек. Чыннан да, күп кенә халыклардагы мәкальләрнең мәгънәдәш булуларына карап кына, аларнын һәркайсы да булса һәрберсе икенчесеннән алынган дип дәгъва итәргә нинди нигез бар? Әгәр тәржемә икәнлекләрен белдерергә тел йә төзелеш ягыннан билгеләре юк икән, һәм читтән алынган булуын күрсәткән дәлил яки документлар юк икән мәгънә охшашлыгы өчен генә "алынма" дип әйтә алабызмы? Ул гына да түгел, алынган тәкъдирдә дә халык аны үзенеке итеп эшкәртеп, үз мәкальләре рәтендәге шигъри бер әсәр хәленә китергән икән, анын хәзер алынмачылыгы калмый, халыкнын ул үз тормыш һәм үз ижат малы булып киткән була.

Аннары тагын: мәгънәдәш булган өчен генә ике телдә булган мәкальләр ни өчен, әлбәттә, берсе икенчесеннән "алынма" гына булырга тиеш соң? Андый мәгънәләр һәр халыкнын үзендә туа алмыймыни? Тарихи этаплары, ижтимагый экономик формацияләре, тормыш-көн итеш шартлары ягыннан бер типтагы

баскычлар үткән халыкларда бер—берсенә охшашлы, хәтта мәгънәдәш күп кенә мәкальләр тууда табигый хәл. Ук, җәя тоткан, ат асраган яки алмагач утырткан халыкларның һәрберсендә "ук", "ат", "алма" дигән сүзләре булган кебек, укның бер аткач кире кайтмавы турында, атның иргә канат булуы турында, йә булмаса агачына күрә алмасы булу һәм алма агачыннан ерак төшми икәнлекләре турында мәкаль чыгару өчен Мәккәгә яки Тулага бару, кемнән дә булса хикмәт ишетеп кайтуның кирәге юк. Адәм үз авылында, үз киртә төбендә, үз башы белән генә дә андый хикмәткә ирешә ала. *Ни чәчсәң, шуны урырсың* мәкален алып карыйк. Урыслар шул ук мәгънәдә: *Что посеешь, то и пожнешь*, диләр. Гарәпләр: *Кәма тәхсыде йәхсыды,*—диләр. Алынмачылык теориясе белән баш ватучылар борынгы Тәүрат китабында шул мәгънәдә бер сүз тапкач, аны шуннан таралган дип уйлаганнар. Ләкин мәкальләрнең күпчелеге һәр халыкта иң элек үз тормыш-көнкүреш тәҗрибәләренә бәйләнешле булып туа икәнендә истә тотсак, нәрсәгә монда Тәүрат? Дөньяда иген чәчкән һәммә халык гасырлар буе ни чәчсә шуны үзе ура, тормышында ата-бабадан бирле шуны үз кулы белән чәчеп, үз кулы белән урып-сугып, тегерменендә тарттырып онын, икмәген ашап яши, ата-бабадан бирле бу эш шулай килгәнен һәркем белә, инде шуннан соң—*Ни чәчсәң, шуны урырсың,*— дип әйтә белү һәм үзенең шул тәҗрибәсен яхшы-яман эшләрнең дә шулай бер нәтиҗәсе була икәнлеккә мисал китерә белү өчен беркемгә дә Парижга яки Израилга барасы юк, ул аны үзе белә. Дөньяда иген иккән халыкларның барсында да мин шундый мәкаль бардыр дип уйлыйм. Инде шуннан соң да, аның башка халыкныкы белән мәгънәдәш булуына карап, читтән, хәтта Тәүраттан алынган булуын әйтеп "гыйлем" ачу өчен, йә үзең гомердә ашлык чәчмичә кеше чәчкәнне ашый торган бер кеше булырга яки үзеңнән башка халыкларны берни дә иҗат итәргә сәләтсез дип уйлаучы бер әфәнде булырга кирәк.

Шулай ук—*Терсәк бик якын да тешләп булмый,* дигән мәкальне без кемнән алдык, дөньяда кайсы акыллы халык моны башлап әйтте икән,—дип, киштәдән Талмудлар, чит телдән мәкальләр актарасы юк. Дөньяда терсәксез халык юк, аны тешләп булмый икәнен һәрбер малай да белә. Кыскасы, һәр кешенең, икенче кеше белән уртак яклары булган кебек, һәр халыкның фикерләрендә һәм дөньяга карашларында, тәҗрибә һәм әхлагында да икенче халыклар белән уртак нәрсәләр күп була. Шунлыктан мәкальләрдә дә уртак мәгънә булуга карап кына һәркайсы да читтән алынган дигән нәтиҗә чыгару дөрес түгел. Аннары тагы мәгънә ягыннан уртак мәкальләр дә төрле халыкта төрле формада әйтелүчән була. Мәгънәсе белән формасының тапкыр килеше сирәк очрый торган хәл. Димәк, алынма булганда да, мәкальчә итеп төзелә һәм әйтелә белергә яки тагын матбугат һәм җыентыклар аша популярлаштырылырга да тиеш була. Моның шулай икәнен белү өчен нинди дә булса бер мәкальне алып, турыдан-туры тәрҗемә итеп карау җитә. Башка телгә күчерелгәч, ул еш вакытта үзенең тәмен-тозын, иплелеген, ритмын, мәкальлеген, кайчагында мәгънәсен дә югалта икәне билгеле. Чөнки халык үз мәкальләрен башка халыкларда очрамый торган үз гореф-гадәтләренә һәм мөнәсәбәтләренә, үз зәүкына, үз тел мөмкинлекләренә, үз аңы һәм рухына каратып төзи.

Бу уңай белән безгә көнчыгыштан кергән китаби мәкальләр турында да әйтеп үтәргә кирәк. Безнең Болгар-Казан йортында гарәп хәрефендә китаплар уку, мәдрәсәләр тоту мең ел буе яшәп килгән. Шул озын дәвер эчендә муллалар, хәлфәләр халыкка әллә нихәтле "вәгаз сөйләгәннәр", ягъни, үгет-нәсихәт сөйләп, төрле аят-хәдис укыганнар, тәрҗемә итеп тә күп кенә мәкаль һәм хикмәтле сүзләр китергәннәр. Бу үгетчеләр арасында телгә бик осталары, шагыйрьләре дә булган. Шулай булгач, тәрҗемә мәкальләрне шактый шома итеп әйтә белүчеләр дә очраган.—*Карамагыз үземә, карагызчы сүземә—Мәхәббәт җамал теләмәс; —Хаклык ачы булыр (Әлхаккы мөррен)* кебек кайбер мәкальләрнең безгә шул юл белән кергәнлеге күренә. Мең ел буена эшләр шулай барса да, сан ягыннан алып карасаң, безгә китап аша кергән андый мәкальләрнең күләме бер йөз чамасыннан күп артмавы күренә. Инде кардәш халыклар белән мәгънә һәм төзелештә уртак булганнарына килсәк, монда эш бераз башкачарак. Карталардан күренгәнчә, борынгы Болгар—Казан—Кыпчак территориясе бик киң булып, төрки

кавем-кабиләләрнең конгломераты (катнашмасы) булган. Боларда гадәт-йола уртаклыгы зур булган кебек, мәкальләрнең тел структуралары да якын һәм бер-берсеннән әзер килеш алырга мөмкин булганга, мәкальләрнең бер-берсенә күчүләре җинелрәк, күбрәк була. Шул рәвешчә, территориаль яктан да, тел, гореф-гадәт, тормыш һәм кара ышанулар ягыннан да, шулай ук мәкальнең төзелеш алымнары буенча да уртаклыгы зур булган. Андый мәкальләрнең мирас юлы белән безгә килгәннәренең күбесе хәзер асылда, безнекеме, әллә анысы монысыннан алынганмы икәнен дә билгеләве кыен мәсьәлә. Әмма инде казакъ яки башкортның үз күчмә тормышы һәм йолаларына караган, үз тел әйләнешләре һәм үзләренә генә хас кайбер сүзләре катышкан мәкальләрне икеләнмичә үк алардан алынган дип әйтеп була. Мәсәлән, Бәдигый җыентыгында: — *Алатауның башы ерак, төбе якын, казакъның теле йомшак, эче ялкын,* дигән мәкаль китерелә. Монда алынган Алатау кайда да, Татарстан кайда? Шуның өстенә монда казакъ дигән сүзнең дә булуы өстенә мәкальнең төзелеше 12 иҗекле казакъ үләне алымында әйтелгән. Шулар өстенә ул мәкаль казакъның үзендә дә әйтелә торган булса, безгә аның алардан алынган булуын уйларга кала. Инде шундый казакъ, кыргыздан яки үзбәктән алынмалы мәкальләр Себердә Бараба, Тубыл, Ум-тум татарлары арасында тагын да күбрәк очравы табигый. Чөнки андагы казакълар белән татарлар бер-берсенә күрше торып, бер-берсенә катнашып, йөрешеп торганнар һәм торалар.

Инде бездә андый алынма мәкальләр күпме дигәндә, мин бу җыентыкта кардәш халыклардан алынган яки уртак дип кыеп әйтерлек мәкальләр биш-алты йөз чамасыннан артмас дип уйлыйм. Урысчадан алынма мәкальләр 300 тирәсендә. Җыеп кына әйткәндә, матбугат ашамы, яки башкачамы, алынма мәкальләрнең барлыгы, чамача, бу җыентыкта бер меңнән күп артык булмас.

Кыскасы, безнең мәкальләрнең урыс яки күрше кардәш-ыру халыкларныкы белән мәгънәдәш булганнары, әлбәттә, барысы да аларга бездән кергән яки без алардан алган дип өзеп әйтеп булмый. Андый мәкальләрнең күпчелеге һәр халыкның үзендә туарга мөмкин булган кебек, бездә дә ул шулай. Шул ук вакытта бездә алынма мәкальләр дә бар. Алары исә халыклар арасында культура һәм хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре таләп иткән дәрәҗәдә, билгеле бер күләмдә, кайбер иҗади эшкәртүләр, үзгәртүләр белән алынганнар. Әмма мәкальләр гомумән оригинал түгел, күчмә, алынмачыл нәрсәләр генә дигән сүзләр халыкның үзлеген һәм иҗатчылыгын инкяр итүче яки үзләрен сайландык раса дип, башкаларны исә үзләренә кол булырга гына лаеклы, сәләтсез һәм кыйммәте ким халыклар дип караучы империалист-колонизаторлар яки алар тарафыннан йотылырга күнгән кешеләр сүзе генә булып кала.

Моның шулай икәнлеген татар мәкальләренең ничек барлыкка килү һәм аларның үзенчәлекләрен өйрәнү унаенда тагын да яхшырак күрербез.

## Мәкальләрне тәртипкә салу

*(Классификация)*

Мәкальләрне җыю бер эш, әмма аларны нинди тәртиптә бирергә?

Өстән караганда җинел генә кебек күренгән бу эш гамәлдә иң авыр һәм бик күпләрнең башын әйләндергән мәсьәлә. Бу хакта бәхәс туктаганы юк һәм иң яхшысы менә шушы система гына дип әйтерлек гомуми бер фикергә әле дә киленгәне юк.

Эшнең бу рәвешле торуы җыелган мәкальләрнең дә матбугатка чыкмый ятуына төп сәбәпләрнең берсе булып тора дияргә мөмкин.

Билгеле, монарчы кулланылган яки тәкъдим ителгән күп кенә тәртипләр, —классификацияләр барлыгы мәгълүм. Мәкальләрне алифба хәрефләре тәртибендә төзү бар, әхлакый нормалар нигезендә тәртипкә салу, тематик нигездә төзү, әйберләргә карап бүлү (предмет тәртибе), социаль дифференцияләр буенча бүленеш, монографик тәртип һәм башка төрле тәртипләр бар. Кыска гына әйткәндә, мәкальләр турында төрле карашлар никадәр күп булса, тәртипкә китерү

турында да шулхәтле төрлелекләр яши.

Болар арасында социаль-сыйныфый дифференциацияләр буенча мәкальләрне бүлү безнең өчен беренче карауга бик муафыйк һәм әзер метод булып күренә кебек, ләкин эшкә килгәндә моның мөмкин түгеллеге үткән битләрдә ачык күренде. Ул методның ни өчен мөмкин түгеллеге турында җыеп кына бу урында өч сәбәбен әйтеп китәм:

Беренче сәбәп: иң элек, башта күреп үткәнебезчә, турыдан-туры кайсы да булса бер сыйнфый чорныкы дип атап булган мәкальләрнең бик үк күп булмыйча, сыйнфый социаль билгесе булмаганнарының күпчелек булуы (әйтик,*—Аш ашка урын бирә;—Кызлар күнеле кызган казан;—Эт күзе төтен белмәс;—Тиле түрен бирмәс;—Тел сөяксез, кая бөксәң дә бөгелә;—Азыклы ат арымас;—Бал тәмле дип бармак чәйнәп булмый,* тибындагылар).

Икенчедән, мәкальнең кайбер иҗтимагый билгеләре булганда да аны тарихи билгеле бер чорга гына кайтаруның авырлыгы. Мәсәлән,*—Тимерне кызуында сук,* —дигәндә, эшченең тимер сугуы бар һәм ул мәкаль безнең "Интернационал" гимнда да бар, аны шулай булгач, 1917 елгы пролетариат революциясе чоры рәтенә кертергә тиеш кебек күренә;). Әмма тикшереп китсәң, бу мәкаль соңгы чорларда гына чыкмаган, ул адәм баласы дөньяда тимер табын эшли башлаганда ук чыккан булырга охшый, чөнки аның төрле халыкларда һәм бик борынгы кулъязмаларда очравы билгеле. Шул рәвешле, гамәлдә без шул өч кенә сүздән торган мәкальнең дә тарихи кайсы чорга керү ягыннан, аның кайчан чыгып, кайсы чорның сыйнфый дифференциациясен һәм мөнәсәбәтен күрсәтә икәнен дә тәгаен генә әйтә алмыйбыз.

Өченчедән, турыдан-туры бу фәлән чор, фәлән сыйнфый идеологияне чагылдыра дип әйтеп булган мәкальләр дә кулланышта үз чор һәм үз социаль әйләнәсендә генә торып калмыйлар, бәлки төрле заманнар, төрле сыйнфый баскычлар аша күчеп яши бирәләр һәм төрле сыйныфларга, хәтта капма-каршы сыйныфка да хезмәт итәләр... Димәк ки, мәкальләрнең икенчел мәгънәләрендә, мисал сүз буларак, төрле социаль-сыйнфый катлауларга хезмәт итү сәләте бар. Бер үк мәкаль урынына карап, төрле сыйныф вәкилләре телендә төрле роль уйныйлар, шуның белән бер социаль катлауга гына карап калмыйча, төрлесенә хезмәт итәләр. Шулай булгач, мәкальләрне тәртипкә салганда, аларның күпчелеген теге яки бу чорга кайтару мөмкин түгел һәм гомумән аларны тарихкамы, чоргамы иллюстрация итеп тезеп алмыйбыз. Моңар чакыру аларның үзенчәлеген танымауга, функцияләрен чикләп күрсәтүгә, аларны көчләүгә һәм социологизм белән шөгыльләнүгә чакыру була. (Бу хакта икенче бүлектән кара.) Димәк, барлык мәкальләр өчен дә уртак бер сыйнфый тәртип була алмый.

Хуш, инде шулай мәкальләрнең икенчел мәгънәләре булып, аларның яшәүчәнлеген, динамикасын һәм актуальлеген шулар хәл итешә торган булгач, гомумән, мәкальләрне икенчел мәгънәләре буенча гына тәртипкә салу кирәк булмыймы?

Бу да бик мөһим мәсьәлә һәм аның буенча эш итүчеләр дә, аны яклаучылар да күп булды. Әйтик,*—Этнең күнеле бер сөяк,*—дигән мәкальне алып карасак, ул турыдан-туры эт турында булып, чынлап та аның табигатен күзәтүдән алып әйтелгән. Бу аның беренчел мәгънәсе. Һәм бу мәгънәсе белән ул әле мисаллы мәкаль булып та җитми, бәлки ул бер сынау, күзәтү кебегрәк. Әмма аның тулы мәкальлеге икенчел мәгънәсеннән килә: ягъни кеше кулындагы малга ымсынып яшәгән комсыз һәм бәйләнчек кешедән котылу өчен, аңа үзеннән бер ташландык өлеш чыгар да авызын томала дигәнгә мисал була алуы. Беренчел мәгънәсе белән ул терлек, хайваннар бүлегенә, эт турындагы мәкальләр рәтенә керсә, икенчел мәгънәсе белән әхлакыйгамы, бәладән йолынугамы, гражданлык мөнәсәбәтләренәме яки башкагамы каядыр бер идея категорияләренә керергә тиеш була. Бер мәкальне ике-өч урынга кертеп язу нигезле булмый.

Билгеле, мәкальләр югарыда алынганча эт турындамы, ат яки башка турындамы булсын, аларның беренчел мәгънәләре икенчел мәгънәгә күчерелүе асылда кешегә мисал итү өчен. Димәк, мәкальләрдә күздә тотылган нәрсә кеше үзе була. Монысы бик яхшы. Хуш, инде шулай булгач, аларны кешеләр төренә бүлеп кенә тезәргә кирәк булмыймы? Бәлки аларны әхлакый кагыйдәләр, нормалар

итеп кенә төзәргә кирәктер? Мәсәлән, әрсез кеше, начар кеше, ашка арт куючы кеше, хәтәр кеше һ. б.

Һәм шулай бүлүчеләр дә булды. Урысларда бу тәртипнен башында В. Даль тора. Бездә дә баштарак Хәсән Гали һәм соныннан Л. Җәләйләр[1] үз җыентыкларын Дальчә эшләделәр. Совет фольклористикасында бу методны субъектив психик метод дип тә йөртәләр. Әгәр дә барлык мәкальләрнең нинди дә булса анык бер генә әхлакый сурәтләмә һәм нормага кергәнен ачыклап булса һәм шул нормага сыйдырып калыплап булса, бу метод, билгеле, үзенә күрә әһәмиятле бер урын тотачак иде.

Ләкин моны эшкә ашыру мөмкинме? В. Даль үзенен зур җыентыгында мона ирешә алмавы турында яза. Дөрестән дә анын һәр бүлектәге кайбер мәкальләренә карата,—ни өчен анда кергән, ник монда кермәгән?— дип, каршы төшәргә мөмкин. Мәсәлән, ул:—"Работа— праздность" дигән бүлеккә шундый мәкальләр һәм әйтемнәр кертә:—*Прет как сивый мерин;—Кобылка маленькая, а седлу место есть;—От кикиморы не дождемся рубахи;—С отказною бог по дворам не ходит* һ. б. Билгеле, мәкальләрнең икенчел мәгънәләрен тегеләй дә, болай да анларга мөмкин булган кебек, аларны тартып сузып, бу бүлеккә дә, тегендә дә кертеп була. Мәсәлән, трамвайда берәү берәүгә төртелә икән, ана карата:—*Прет как сивый мерин* диюләре мөмкин. Шул сүз үзенне тота белүгә дә, ашыгу, кабалануга да, тупаслыкка да, эгоистлыкка да, тагын башкаларга да мисал була ала. Шул рәвешле, мондый әйтем һәм мәкальләрнең Даль биргән "Эш яки ял" бүлегенә ул хәтле ни мөнәсәбәте бар? Аларнын урыннарын китаптан ничек эзләп табарга? Бу мәкальгә мин югарыдагы мәгънәләрнең берсен биреп, үзем уйлаган бүлекләрдән карасам да ул мәкальләрне таба алмам, ә Дальнең ана үзе нинди мәгънә биреп кая теркәгәнен каян белергә? Инде бик тырышып эзләгәч, ул мәкальне китаптан эзләп тапсан да, шул бүлеккә кертелүе белән килешү-килешмәү һәркемнең үз ихтыярында кала. Чөнки мәкальнең икенчел мәгънә һәм әйтелү урыннары төрлечә булганга, бу нәрсә бәхәсле. Шунлыктан анын бу системасы халыкнын рухи йөзен күрсәтү ягыннан әһәмиятле һәм үзенчәлекле булса да, монын өчен мәкальләрне тартып-сузып көчләү, төрле мәгънәдә һәм төрле урында кулланырга мөмкин булганнарын да бер генә әхлакый категориягә, әзер схемага буйсындыру кебек унайсыз хәлләр килеп чыга. Ул шуна охшаган кимчелекләре өчен төрле тәнкыйтьләргә очрады. Даль үзе дә шундый сәбәпләр аркасында бер үк мәкальләрне төрле бүлекләргә кертеп, кабатлаулар ясарга мәҗбүр булуын һәм бу мәшәкатьле эшкә күп еллар гомер бирсә дә, шуннан да артыкны эшли алмаганлыгын язды. Бу урында Дальгә аерымрак тукталуым анын системасы безнен татар мәкальчеләрен (һәм шул җөмләдән вакытында мине дә) үзенә җәлеп итүе өчен. Бездә шул юл белән эш күрүче Хәсән Гали күп еллар буена мәкальләрне анынча бүлекләргә бүлеп, тәртипкә салып караган. Ләкин канәгатьләнерлек бер нәтиҗәгә килә алмаган өченмедер, тиешле югарылыктагы китап эшләп чыгара алмаган. Әмма анын соныннан дөньяга чыгарган кечкенә китабында "Социаль тормыш һәм хезмәт", "Табигать", "Тел һәм сүз" дигән өч бүлек кенә ачуыннан, баштагы рухи-әхлакый концепциядән китеп, мәкальләрнең нигезендә материалистик критерий табарга омтылуын күрәбез. Ләкин ул һаман да мәкальләрне икенчел мәгънәләре буенча төзү принцибыннан котыла алмаган, шунлыктан төрле бәхәсләргә юл калдырган. Мәсәлән, ул: *"Эгнен авызына төшкән сөяк май булып эрер"*,—дигән мәкальне социаль көнкүреш һәм хезмәт бүлегенә кертә. Әмма *"Песинен бүе җитмәсә, ит сәрсегән дип әйтә"* мәкален табигать бүлегенә кертә. Нигез кайда? Әгәр беренчел мәгънәдәгеләре буенча алына икән,—эт тә, песи дә, хайван буларак, табигать бүлегенә керергә тиешләр; инде алар икенчел мәгънәләре буенча социаль көнкүреш яки хезмәтнең нинди дә булса бер ягын ачалар дип карала икән, ул чагында икесе дә шул бүлеккә кертелергә тиеш була. Нәкъ шундый ук хәлне Л. Җәләйләр китабында да күрәбез. Алар китапнын кереш өлешендә Даль буенча баруларын язалар һәм икенчел мәгънәләре

[1] "Татар халык фразеологиясе, мәкальләр һәм әйтемнәр", Л. Җәләй, Н. Борһанова, Л. Мәхмүтова, 1957. Кыскалык өчен монда Җәләйләр дип кенә алынды.

буенча, үзләре алдан төзегән әхлакый-рухи схемадагы бүлекләргә кертәләр һәм шунлыктан Дальгә караган бу сүзләр аларга да кагыла.

Шуның өстенә, мондый тәртип практик яктан да җайлы түгел. Без үзебезгә кирәкле мәкальнең урынын эзләүдә мөшкеллеккә очрыйбыз. Мин, мәсәлән, Дальдән кайбер мәкальне табу өчен, бөтен китабын актарып эзләргә мәҗбүр булгаладым.

Шул рәвешчә, субъектив-психик метод дип йөртелгән Даль тәртибе, үз заманында кимчелекле булган кебек, безнең заманда да фәнни яктан да, практик яктан да шул килешендә кулланырга яраклы түгел. Инде бездә турыдан-туры әхлакый нормаларны күрсәткән мәкальләргә килсәк, билгеле, бездә алар байтак кына. (*—Сабыр иткән—морадына җиткән;—Усаллыкка тәһарәт кирәкми;—Усал булсаң, асарлар, юаш булсаң басарлар* һ. б.) Билгеле инде, кешенең рухи сыйфатларын күрсәтеп торулары ягыннан мондый мәкальләр үз рәтләрендә, үзләренә бер төркем астына тупланырга хаклылар. Ләкин барлык мәкальләрне дә көчләп шулар категориясенә тартып-сузып китерү мөмкин түгел. Шунлыктан бу методны да төп нигез итеп алып булмый.

Инде мәкальне тәртипкә салуда элегрәк бик киң урын алган әлифба тәртибенә килик. Бу инде иң җиңел һәм башлангыч форма дияргә ярый. Мәкальнең баш һәм икенче хәрефләре нинди булса, шул хәрефләр рәтенә терки бирәсең. Бездә дә Каюм Насыйридан алып Хуҗа Бәдигъка кадәр (1912 ел басмасы) шул тәртиптә төзи биргәннәр. Билгеле, монда инде мәкальләрнең эчтәлеге нинди булуга игътибар ителми, шунлыктан беренчел мәгънәсе дә, икенчел мәгънәсе дә, материаль ягы да, социаль ягы да, темасы да, берсе дә каралмый. Бу инде мәкальләрне саф тышкы формасы ягыннан, хәрефләр буенча гына теркәү булып чыга. Шунлыктан анда *ат* (хайван) янына *ат* (исем), *эт* янына *эт* сыя. Шундый формальлек булу ягыннан Даль үзенең китабына язган сүз башында хәреф тәртибенә каршы төшә. Анынча, мондый төзелеш хәрефтән башка тотыныр нәрсәсе булмаганлыктан, иң гаҗиз, ясалма юлга басу. Чөнки монда мәкальләр һичбер мәгънә һәм бәйләнешсез, бары тик очраклы рәвештә, тышкы ягына карап кына җепкә тезелә. Анынча, мондый китапны укырга ярамый: һәр юл башыннан сүзнең җебе ычкынып, икенче темага күчеп торганга һәм бәйләнешсез булганга, беренче биттә үк безнең, акылыбыз бүлгәләнеп талчыга, кирәгенне эзләп таба да алмыйсың, көнкүрешнең теге яки бу ягы турында халык ни әйтә—анысын да күреп булмый. Мәкальләр буенча халыкның көнкүреш мөнәсәбәтләре турында, рухи һәм әхлакый үзенчәлеге турында гомуми нәтиҗә, нинди дә булса сөземтә һәм сыгымта ясап булмый. Бер үк эшкә караган, мәгънәсе белән бер төрдән аерылгысыз булган мәкальләр бер-берсеннән ераккa куелганнар, әмма ләкин аерым төрдән булганнары янәшә торалар; бер төрдән булган мәкальләрне сайлап җыярга кирәк булса, укучының үзенә кала; ләкин моның өчен бөтен китапны укып чыгарга, анда үзеңә билгеләмәләр ясап, йөзләрчә, бәлки ме*ңнәрчә юлны күчереп алырга туры* килә... Даль фикеренчә, бер сүз белән әйткәндә, бу әлифба тәртибе җыентыклары бары тик искә төшкән берәр мәкальнең анда бармы, әллә төшеп калганмы икәнлеген эзләп карау өчен генә, яки юану өчен генә булмаса, башкага хезмәт итми. Һәм ул үз җыентыгында әлифба тәртибен бертөрле дә файдаланмавын китабының зур бер уңышы итеп санавын әйтә.

Дальнең һәм башка кайбер фольклорчыларның әлифба тәртибенә каршы аяусыз һөҗүмнәре безнең тәнкыйть дөньясына нык йогынты ясады. Хуҗа Бәдигъның беренче хезмәте булган 1912 елгы җыентыгы шундый хәреф тәртибендә булганлыгы өчен нык гаепләнде. Шуннан соң Х. Бәдигъ тә, Хәсән Гали дә үз мәкаль җыентыкларын яңадан бүлеп төзегәндә, әлифба тәртибеннән бөтенләй баш тарттылар.

Әлифба тәртибенең үзенә күрә уңайлыклары бар, әлбәттә. Мәсәлән, сүзлекләр төзүдә әлифба тәртибе беренче шарт һәм ансыз мөмкин дә түгел. Шулай ук мәкаль кебек берничә генә сүздән торган һәм саны бик күп булган вак фольклорны белешмә өчен китаптан эзләп табуда әлифба тәртибенең җиңеллек тудыруы шөбһәсез. Аннары татар җөмләләрендә ия күбрәк сүз башында килергә яратканга, мәкальләрне баш хәрефләр буенча төзегәндә дә, бер иягә һәм димәк ки бер нәрсәгә караганнарының барысы да булмаса да, шактый гына өлеше бер

тирәгә җыела ала. Әйтик, ат сүзе белән башланганнар:—Ат тоз *диеп картаер;—Ат кешнәшеп таныша;—Ат туйган жиренә;—Ат аунаган жирдә төк калыр һ. б.* Адәм, кеше, эш, эт, кош һәм башка сүзләр белән башланганнары да шулай. Димәк, бу тәртип практик-белешмәлек ягыннан җинеллек тудырган кебек, безнең мәкальләр өчен мәгънә, тема ягыннан да бөтенләй үк буш түгел. Шунлыктан бу мәсьәләдә бездә Даль яки Шахновичларга ияреп, әлифба тәртибен шулхәтле тырышып инкяр итү үзе гыйлемне практикадан аерып карау, читтән прокатка алынган әзер теория һәм схемачылыклар колы булудан башка нәрсә түгел. Шунлыктан булса кирәк, башка төрле системага салынган мәкаль китапларының да бик үк уңышлы булмаулары кайбер фольклорчыларда янадан әлифба тәртибен яклауга һәм практикада иң кулае дип, шул тәртиптә бирүгә омтылыш тудырды. (Мәсәлән, "Башкорт халык авыз ижаты" дигән җыентыкта мәкальләр хәреф тәртибендә бирелә. 1955 ел.) Даль үзе дә мәкальләрен шулай үзенчә бүлекләргә бүлгән хәлдә, алар эчендә хәреф тәртибен дә күзәтә алган булса, аерым мәкальләрне эзләп табуга зур ярдәм иткән булыр иде. Чөнки ул әлифба тәртибендә төзелгән мәкаль җыентыкларын: "Алардан бер темага мәкаль эзләү өчен бөтен китапларын актарырга кирәк" —дип гаепләсә, нәкъ шуның киресенчә, аерым бер мәкальнең үзе кайсы бүлеккә кергәнен белү өчен Дальнең дә бөтен җыентыгын укып актарып эзләргә кирәк.



*Нәкый Исәнбәт. 1940 ел.*

Монографик дигән тәртип тә бар. Монысы инде мәкальләрне аерым районнар буенча һәм аерым куллардагы дәфтәрләр буенча төзеп игълан итү. Тар гыйльми максат өчен, болар да әһәмиятле, ләкин сезнең кулыгыздагы бу җыентыкның максаты ул булмаганлыктан, бу китапка монографик тәртип нигез була алмый.

Болардан тыш, мәкальләрне әйберләр буенча (предметный метод) һәм тематик тәртип дигән төзүләр бар. Әйберләр буенча булганда, бер нәрсәгә караган мәкальләрне (әйтик, сүз турында, дөнья турында, дөя, кәҗә турында һ. б.) булганнарын үзләрен бер җиргә туплау. Димәк, монда мәкальләрнең гомумән үз мәгънәләре алда тотыла. Бу яктан караганда, бу тәртип күп яктан яхшы. Чөнки монда бернәрсәгә караган мәкальләр бергә җыелуы белән халыкның да шул нәрсәгә карашы, мөнәсәбәте күп яклы чагыла, шулай ук бернәрсәгә караган мәкальләрне табу — сайлап алу да шактый җиңелләшә. Чөнки бүлек башлары һәм китапның эчтәлек тәртипләре буенча мәкальләрне тиз табып була. Ләкин бу метод белән эшләүчеләрнең җыентыклары да нык кына тәнкыйтькә очрадылар. Монда төп кимчелек мәкальләрнең вакыт һәм урын-арадан (мөсафәдән) тыш алынган килеш, тоташы белән агып баруларында. Билгеле, болай төзегәндә, тарихилык, социаль төсмерләнеш бер дә күзәтелми диючеләр булды, ләкин мин бу фикергә тулысынча кушыла алмыйм. Чөнки әйберләр рәтендә тарихи-иҗтимагый категорияләр дә үзләренә урын алмый хәлләре юк. Ләкин кайбер мәкальләрнең бу нәрсәгә дә, теге нәрсәгә дә караган булуларыннан, аларны теге бүлеккә дә, бу бүлеккә дә кертергә кирәк булганлыктан, кабатланулар килеп чыга. Шунлыктан бу төзелешне кайберәүләр схемачылык һәм субъективлык дип тәнкыйтьләделәр һәм вульгар-социологлар тарафыннан хәтта аны бу марксистик бүленеш түгел, буржуаз фольклорчылык, алып ташланырга тиешле метод дип чыгучылар булды.

Бездә Хуҗа Бәдигънең 1926 елда бастырган мәкальләр җыентыгы шушы принципта торып, ягъни әйберләр тәртибе буенча төзелгән иде.

Хәзерге кайбер фольклорчылар тарафыннан бик нык алга сөрелгән тематик тәртип бар. Монда нигездә әйбер түгел, тема ята; шуның белән бергә, әйбергә караган мәкальләрне бергә теркәмичә, темага караганнарын теркиләр. (Мәсәлән, урыс мәкальчеләреннән Шахнович бу метод белән "Поплар һәм дин турында"

дигән җыентык бастырган.) Бу методны бик мактап, әйберләр тәртибенә һәм башкаларга каршы яңа ысул диючеләр дә булды.

Бу тәртип күп кенә яклары белән әһәмиятле булса да, аны да гыйльми нигезгә салынган яңа һәм берданбер дөрес метод дип булмый. Аннан ул яңа да түгел, немецларда күптән бар. Икенче яктан, темаларга бүлүдә ул шул ук үзе гаепләгән субъектив-психик методтан, схемачылыклардан берничек тә арына алмый, әйберләр буенча тәртипкә дә килеп кушыла. Ни өчен дисәң, мәкальләрне темалар буенча туплаганда да аларнын һәр төркеме бер билгеле вакыт һәм урынга гына каравы, тарихилыгы һич тә килеп чыкмый. Чөнки һәр мәкальнең үз тарихы үзенә, һәркайсы үзенә бер мөстәкыйль әсәр. Аннары, темалар буенча туплау да югарыда әйтелгән әйберләр тәртибенә гел каршы нәрсә генә булып чыкмый, чөнки мәкальдә алынган әйбер белән аның темасы еш кына бергә туры килә. Әйтик, немецларга ияреп, Шахнович "Поп һәм дин турында"гы мәкальләрне бергә җыйнап моны тематик метод һәм мәкаль фәнендә яңалык дип атый икән, бездә Хуҗа Бәдигъ ана хәтле 1926 елда ук үзенең мәкальләр җыентыгында мондый мәкальләрне "Рухани затлар һәм дин" дигән бүлектә биргән, ләкин Х. Бәдигъненң методы әйбер тәртибе дип аталса да, монда тематик метод белән икесе арасында каршылык күреп булмый. Шунлыктан да бу соңгыларның "әйбер методы"н бик каралап күрсәтергә тырышуларын бик үк урынлы дип булмый. Гамәлдә чуалчык кына тудырганга, мондый "саф темачылык" методы корулар да асылда социологизм схемачылык һәм схоластикадан башка нәрсәгә илткәне күренми.

Шул рәвешчә, урысларда һәм бездә таралган һәртөрле мәкаль җыентыкларына һәм аларны төзү ысулларына күз салып чыкканнан соң, аларның төптә ике төркемгә генә кайтып калганын күрербез: беренчесе—баш хәрефләр төзелеше буенча, ягъни әлифба тәртибе дип йөртелгән формаль метод; икенчеләре—мәкальләрне мәгънәләре буенча тәртипкә салу. Бу соңгысының күп төрле һәм ызгышлы булуы исә, күбесенчә, мәкальнең мәгънәләрен һәм функциясен кайсы ноктадан карап аңлауга кайтып кала. Моны аңлау исә, иң элек, мәкальчеләрнең дөньяга карашлары һәм бу хактагы белемнәре белән бәйле булганлыктан, мәкальләрне төркемләүләре дә төрлечә килеп чыга. Урыс мәкальчеләреннән Снегирев, мәсәлән, мәкальләргә ата-бабадан безгә калган, мәңгегә үзгәрмәс васыятьләр, хакыйкатьләр итеп караган; шунлыктан ул аларны китабына мин һәм мин түгел (субъект, объект) һәм к а г ы й д ә ч е л е к шикелле идеалистик өч төшенчә ноктасыннан карабрак төзегән. Дальнең дә үз китабының башын "Алла—иман" дип ачып җибәрүеннән үк мәкальләргә рухи, әхлакый нормалар ягыннан каравы, Иллюстровның исә, юрист буларак, аларга хокук һәм кануннар ноктасыннан карап туплавы күренә. Җыентыкларындагы субъективлык, схемачылыклар исә, мәкальләрне шул ук алдан үзләре ясап куйган әзер фикерләренә туры китереп сайлау яки үз идеяләренә мәкальләрдән иллюстрация төзүдән килеп чыккан хәл. Инде соңгы елларда урысларда темалар буенча бүлеп төзелгән мәкаль җыентыкларына каралса, кем ничек тели шулай бүлеп, мәкальләрне дә һәркем үзе белгәнчә темаларга керткән булуы күренә. Инде соңгы заманнардагы схемачылыкларга килсәк, алар, иң элек, мәкальләрнең үзләрен мөстәкыйль тарихи һәм эстетик үзенчәлекле жанр булуларын танымыйча, бәлки аларны сыйнфый, иҗтимагый формацияләргә иллюстрация өчен генә материал итеп карау, тел белемендә шәхес культчылыгы, социологизм штампларының урын алуы аркасында килеп чыккан булсалар кирәк. Билгеле, соңгы вакытларда бу өлкәдә күренгән фикри, иҗади кузгалу, җанланулар мәкаль белемен дә дөрес юнәлештә үстерергә ярдәм итәчәк.

# Икенче башлам

## Татар халык мәкальләренең хосусый яклары, үзенчәлекләре

### Безнең мәкальләр ничек барлыкка килгән?

Татар халкында мәкальләр ничек килеп чыгу турында әлегә хәтле бездә бер сүз дә әйтелмәгән дисәк тә ярый. Шунлыктан, башлангыч рәвештә бу турыда кайбер фикерләремне әйтеп үтмәкче булам.

Мәкальләрне халык иҗаты, дибез. Шул сүзнен үзеннән үк күренүенчә, бу иҗатның күмәкчел булуы аңлашыла. Ләкин халык иҗаты дигәч тә, мәкальләрнең бервакытта да шәхси авторлары булмаган, һәрберсен халык бергәләп утырып, киңәшеп чыгарган, аны җыелышларда кабул иткән дә шуннан бирле югалтмыйча үз авызында саклап йөртә дигәндәй, беркатлы гына аңлаучы кешеләр, уйлыйм ки, хәзер инде табылмастыр да. Шулай да, мәкальләрнең килеп чыгуына карата булган фикерләр күп яктан аңлатылуга мохтаҗ.

Билгеле инде, халык иҗаты әсәренең авторы мәгълүм булмаса да, башта ул кем булса да берәү тарафыннан иҗат ителә. Мәкальләр дә шулай. Кемдер башлап аны әйтеп җибәрә, кемдер тагын аны эләктереп ала, башкаларга тапшыра. Ник эләктереп алган, ник ул шуннан мәкаль булып киткән, ник гади бер сүз генә булып калмаган, тикшереп, уйлап карасаң, менә җавап табасы шактый читен. Мәкальләр тарихи күренеш булып, күпчелеге дә ерак үткән заманнарда туганлыктан, аларның борынгы замандагы туу шартларын белү генә төп мәсьәләне хәл итәчәк. Бу инде, безнең татар мәкальләренә карата әйтсәк, моңарчы беркем дә кермәгән чытырманга керү белән бер. Монда исә без мәкальләрнең килеп чыгуында хәзергегә бер дә охшамаган шартлар һәм ят хәлләргә килеп очравыбызны да ихтимал тотарга тиешбез. Балта кермәгән бу борынгы мәкаль урманы алдына туктагач һәм, тәвәккәлләп, аз-маз урман арасына кереп чыккалап та йөри башлагач, аның каян булганы хакында минем башта кайбер уйлар туды. Бәлки болар бик кыюсыз беренче адымнардыр, бәлки монда хакыйкатьтән бигрәк хыялдыр, шулай да мин борынгы мәкальләребезнең килеп чыгуы турында башымда туган бу уйларымны сезнең белән бүлешәсем килде. Калганын иптәшләр төзәтергә яки тутырышырга ярдәм итәрләр.

Мәкальләр чыга башлаган иң борынгы җәмгыятьне алып карыйк. Анда да мәкальнең шәхси авторы булганмы, әллә җәмгыять күмәк рәвештә үзе чыгарганмы? Ул заманнарда җәмгыятьнең яки ыру-кабиләнең һәр әгъзасы үз күмәге өчен яшәгән булуын беләбез. Ул бу заман кешесе кебек милек хуҗасы да түгел. Шәхес буларак та формалашып җитмәгән. Шунлыктан аңа күмәк өчен уртак фикер әйтү характерлы булган. Табигать яки җәмгыятьтәге бер күренеш турында ул ни әйтсә дә кабилә күзлегеннән карап бәяләвен әйткән һәм кабиләнең тел очында торган бер мәгънәне әйтеп җибәргән була. Кыскасы, иң борынгы мәкальнең дә авторы булган, ул заман мәкале дә чыгышы белән шәхси иҗат булган, ләкин аның гомуми фикер һәм уртак иҗат булып китүенең юлы тагы да киңрәк, җиңелрәк булгандыр диясе килә.

Ләкин борынгы ыручылык җәмгыятенең ыру башлыгы булганын онытырга ярамый. Анда хөкем, тәртип эшләре дә, димәк ки, кабиләнең тәҗрибәсе, иҗади фикере булган мәкальләре дә, башта аның аша, аның сүзе яки мәгъкуль күрүе аша тәгъбир ителгән булса кирәк. Кыскасы, сәнгать һәм идеологияне бер кулга җыйган бер җитәкче кеше булган һәм табигатьтән тыш сихри куәтләрне буйсындыруда (чөнки ул заманда табигатькә табынганнар), димәк ки, борынгы мәҗүси дини идарә дә башта аның кулында булган. Кабилә башлыгына гадәттән тыш сихри куәткә ия кеше дип караганнар. Мондый заманнарда мәкаль, хикмәт сүзләре, кабиләнең аерым әгъзалары тарафыннан тудырылганнары да, башның

әйтүе аша гына хөкем, кагыйдә, дәлил булып кулллануы билгеле. Ул гына да түгел, ул үзе дә мәкаль, хикмәт тудырышуда төп урын тоткан кебек, мирас юлы белән элеккеләрне дә ул күбрәк саклаган булырга тиеш.

Ләкин бу иң борынгы заманда, ыру-кабилә тормышы бик артта, культура, техника бик түбән булган өчен генә барлык житәкчелек, белем-тәҗрибә, идеология һәм димәк ки,хикмәт сүзе булган мәкальләр дә шулай бер кеше авызына җыела алуы мөмкин булган. Соңыннан тормыш һәм белем-техника алга киткән саен, бу өлкәләр дә кинәеп үсеп, аерым кешеләр кулына тапшырыла баралар. Кабилә башлыгы белән беррәттән бездә дини идеология, культ башлыгы, күрәзәче, багучы (шаман), башкаларда жрец, каһин, оракул кебекләр килеп чыккан. Борынгы багучы ул табигатьне буйсындыручы ырым-сихер куәтенә ия дип каралган, ул моны көй, җыр, биюләр аша башкарган; иң борынгы шаманга музыкант та, шагыйрь дә, биюче дә булырга туры килгән; тел һәм сүзнең көче, аның шигъри тәэсире, хикмәте ачылган. Шаманның күрәзәлеге хикмәт һәм мәкаль тудыруга хезмәт иткән.

Башка халыкларда, әйтик, борынгы мысырлылар, греклар, ромалыларда дин башлыклары авызыннан, каһин-жрецлар, оракуллар тарафыннан әйтелгән хөкем карарларының яки дәрәҗә күтәрү өчен, үзләренә күктән ачылган серләр дип игълан иткән хикмәтле сүзләренең кайберләре халык авызына төшеп, мәкальләр булып киткәне билгеле. Шулай ук элекке культуралы халыклардагы хәкимнәрнең тирән мәгънәле сүзләренең кайберләре халык теленә төшеп, еллар үтә шомарып, мәкаль булып киткәнен шул ук грек философлары әсәрләреннән күреп була. Моннан ике мең ярым еллар элек Грециядә хәкимнәр, философлар җәмгыятьтә бик данлы урын тотып, аларның хикмәтле сүзләрен телгә алу анда шул хәтле нык таралган бер хәл булса кирәк ки, шул заманның бөек философы Аристотель хәтта гомумән үз заманында телдә йөргән барлык иске мәкальләрнең килеп чыгуын хәзер исемнәре онытылган иң борынгы философларның әсәрләреннән безгә мирас булып телләрдә сакланып калган кисәкләр дип саный. Билгеле, бездә дә борынгы ыручылык тормышында, исламга чаклы ук, мәҗүси дин башлыклары—имчеләр, багучылар, күрәзәче шаманнар тарафыннан тудырылган мәкальләр булган. Элекке ияләргә—табигатькә табынуның эзләре төрле мифләргә, йолдызларга, утка, суга, тимер һәм башкаларга хөрмәт аңлаткан мәкаль һәм кара ышануларда күренә:*—Ала таң, бола таң, тимер казык олатаң* (тимер казык йолдыз олы ата, ягъни ыруның төп атасы булу, тотем);*—Утның күңеле көр булсын;—Тәңрегә әйткән, кирәмәткә биргән;—Убырның үзе туйса да күзе туймас;—Пычак белән уйнама, озаер һ. б.*

Шулай ук күрәзә-шаманнарның мәкальләр тудырышудагы борынгы эзләрен хәтта бүгенге татар мәкальләренең төзелеш-структураларыннан да күреп була: аларның күбесе киләчәк заман хәбәр фигыльләре белән эшнең ничек буласын алдан хәбәр бирү—күрәзәлек алымнарында төзелгән:*—Ат аунаган җирдә төк калыр;—Аттан ала да туар, кола да туар;—Кеше каны җирдә ятмас;—Сакалы озын кешенең, акылы кыска булыр; —Батыр яуда беленер, телчән дауда беленер; —Батыр ярасыз булмас;—Юрга менгән юлдашыннан аерылыр, күп яшәгән кордашыннан аерылыр;—Ир сәфәрдә беленер, ат чанада беленер;—Уңган хатын ул китерер, изге хатын кыз китерер;—Ашыккан кыз иргә барса да мантымас;—Оясында ни күргән, очканында шуны күрер;—Эчәге биргән куп алыр, һич бирмәгән ни алыр?—Көлке көлә килер, арттан куа килер;—Ашык уйнаган азар, туп уйнаган тузар;—Сүз куган бәлагә, юл куйган казнага юлыгыр;—Ашыккан житмәс, боерган житәр;—Башы зур бай булыр, аягы зур кол булыр;—Бүре баласын бүреккә салсаң да иш булмас;—Олан яшьтән, тары колактан беленер һ. б.*

Шул мәкальләрнең тел төбенә яхшылап каралса, аларда нәрсәнеңдер булыр яки булмаслыгын, булачагы нәрсәдән беленүен, кешенең сакалы, башы, аягы нинди булуы нәрсәгә галәмәт икәнен, нәрсәне ничек иткәндә нәрсә булып чыгачагын һәм башка шундыйларны алдан хәбәр итү төсендә корылган булуын күрерсез. Бу инде Тубыл —Төмән яки Ишемтамак татарларының әле соңгы заманнарга чаклы сөяк яндырып карап, алдан күрәзәлек иткәннәре кебек, борынгы багучылык-күрәзәлек йоласынча һәм алымнары белән сөйләү була. Билгеле, мондый мәкальләрнең шарт һәм реаль сәбәпләре юк дип һәм аларны турыдан-

туры борынгы күрәзәлек мәкальләре дип кенә дә әйтеп булмый, игътибар итегез, монда тик аларның тел йоласына кергән алымнары турында сүз бара. Эш монда шундый мәкальләрнең әйтелеш тоннары, киләчәк заман фигыльләрен файдалану йолалары үзләреннән элек булып та хәзер онытылган борынгы күрәзәлек мәкальләре алымын файдаланып төзелгән булуында. Шулай төзелгән булулары мәкальләрнең тонына да килешеп тора, ул безне төрле хаталарга төшүдән алдан кисәтү кебек булып яңгырый.

Тормыш катлаулана. Борынгы ыручылык һәм күчмә патриархальлектән чыгып, Болгар бабайлар да акрынлап утрак тормышка күчә, феодаллык тәртипләре җирләшә, кабиләләр берләшү, ханлыклар төзелүгә юл ачыла. Мондый катлаулы яна җәмгыятьтә идеология өлкәсе дә багучы яки сихерче күрәзәләр кулында гына кала алмый, чөнки багучы-шаман ул шигырьнең сихри көчен үзенең ырымнарына, чир качыру, убыр-бичура куу кебекләргә генә файдалана, әмма аның иҗтимагый-әдәби ролен үзендә тота алмый, чөнки ул төп профессиясе буенча бары тик культ кешесе, мәҗүс. Шунлыктан бездә борынгы ыручылык һәм күчмә патриархальлек заманнарында ук шигырь-хикмәт өлкәсе шаманнар кулыннан китеп, үзенә аерым тармак булып үсә башлый, безнең тарихыбызда бу эшнең төп профессиональләре булып җыручы чичәннәр килеп чыга.

Бездә мәкальләрнең килеп чыгу һәм культуралашуына һәм кайбер борынгы мәкальләрнең әлегә хәтле саклануына иң нык хезмәт итүчеләр, минем карашча, шушы чичәннәр булганга, алар турында әлегә беркайда да әйтелмәгәнгә, биредә мона аерым тукталып үтәргә тиеш табам.

Чичән дип аталган кеше хәзер бездә үзе түгел, хәтта сүзнең үзе дә кулланудан төшеп, авыз иҗатында гына калып бара. Х. Бәдигъ "Мәкальләр җыентыгы"ның 1912 елгы басмасында чичән сүзенә пөхтә, көяз, фырт дип аңлатма бирә, тик 1926 елгы басмасында гына сүз остасы дип дөресли. Китабының һәр ике басмасында чечән, дип язылган. Бу сүзнең халыкта сүз остасы мәгънәсендә йөрүе билгеле. Ул *бик телгә чичән кеше,* диләр. Кайбер сөйләшләрдә чәчән формасын да кулланалар. Казакъларда шешен, башкортларда сәсән йөри. Соңгыларда шул исемдә әдәби, рәсемле бер журнал да чыгарылды, һәм тоткарсыз рәвештә җыр чыгарып әйтә алучы берничә халык шагыйренә сәсән исеме бирелде. Монысы безнең өчен тагын да әһәмиятле. Чөнки монысында чичән сүзенең матур сөйли белүче генә түгел, илһами рәвештә, кәгазьгә язмастан, тоткарсыз шигырь әйтүче шагыйрь-импровизатор мәгънәсен дә үз эченә алуын күрсәтә, һәм ул тарихлар буенча шулай да. Чичән сүзе элек сүз остасы дигәнне дә, җыручы-импровизатор дигән мәгънәне дә аңлаткан. Димәк, ул һәр ике профессияне үзендә бергә җыйган кеше, борынгы халык шагыйре дигән сүз.

Бездә дә чичән дигән исемдә зур хөрмәтле халык кешеләре булуы татар мәкальләренең үзләреннән үк күренеп тора: *Батыр яуда беленер, чичән дауда беленер.* Димәк, батырлар ил чигеннән килгән яуны бетерүдә беленсәләр, чичәннәрнең телгә осталыгы да ил эчендәге дауларны (конфликтларны) бетергәндә беленә. *Чичәннең теле уртак, чибәрнең кулы уртак.* Моннан чичәннең сүзе мәгънә һәм хикмәткә, димәк ки, уртак әһәмияткә ия булуы, шуның белән халыкка уртак булуы әйтелә. Аның бу осталыгы эштә һөнәрле кешенең кулына чагыштырыла.

Шулай ук борынгы халык дастаннарына караганда, чичәннәрнең сынчы (сынаучы—алдан хәбәр итүче) булулары да бик ачык күренә. Мәсәлән, кабилә һәм феодаллык тормышында кайбер кешенең кемлеген сынап белергә хаҗәт төшә. Моны белү ул заманда бик җиңел булмаган. Бигрәк тә дәүләт тирәсендәге кешеләрнең хокук дәрәҗәләре аның асылы-нәселе кем булуга бәйләнгәнлектән, бу белгечлек аеруча әһәмият казана. Шундый сәләт һәм осталык сорый торган бу эш с ы н ч ы л ы к дип аталган. (Бу сүзне хәзерге сынлы сәнгать белән бутарга ярамый.) Сынчылар кешенең йөзенә, кыланышына бераз гына карап торгач та, читләтеп бер-ике сорау белән аның нәселен, чыгышын, үзенең кемлеген, киләчәк язмышын әйтеп бирергә тиеш булганнар. Пәйгамбәрлек итү шикелле, мондый серле-хикмәтле эшнең дә чичәннәр тарафыннан башкарылуы безнең өчен бик әһәмиятле. Мәсәлән, дастаннарда күренүенчә, олы хан үзенә җибәрелгән бер илченең кем икәнен ачу өчен кайдадыр халык арасында яшәгән шундый бер

өлкән жырчы чичәнне чакырта. Бу чичәннең яше ике йөзләргә житкән карт булуы (ягъни, тормышта күпне күргән, кешеләрне күп сынаган, бай тәжрибәгә ия булган образ булуы), кат-кат чакыртып та бик ялындырып, алтын арбада мамык түшәкләр өстендә генә килүе, гаять дәрәжәдә мәһабәтлеге, ул мәҗлес түрендә беренче урынга утырып, олы хан үзе аның каршында аякчы* булып, кулыннан бал бирүләре бик әсәрле рәвештә сурәтләнгән. Ул үзен олы хан алдында бөтенләй иркен, бәйсез тота. Аның үтенечен теләр-теләмәс кенә кабул иткәч, шунда утырган илчене, үзенә сиздермичә, сыный башлый, югарыда әйтелгәнчә, ана жинел генә бер йомыш үтәргә куша, читләтеп кенә берәр сорау бирә. Йөзенә, кыланышына текәлеп караганнан соң, думбрасын кулына алып, бу әйтелгән илченең үткәнен һәм киләчәген әйтеп, кемлеген ача башлый. Шунысы кызык: ярым көйләп уку, ярым жыр шикелле тезелгән бу сүзләр мәкаль һәм шигъри образларга бай тезмәләрдән тора.

Без мәкальләрнең килеп чыгулары, бер яктан, борынгы сынау, тәжрибә һәм хәтта күрәзәлекләр белән бәйле булганын күргән идек. Монда аның, нәкъ шул хасияте жыручы чичән тарафыннан сынауга тотылганын күрәбез: ягъни мәкаль үзе сынаудан туса, аны мәгълүм тәртипләрдә тезә белү һәм шул алымда үзеннән дә илһами сүзләр куша белү аша сынчылык итеп була дип уйлаган борынгылар, кемнең кемлеген дә мәкальчелек белән сынап, ачып була дип эш иткәннәр. Шуның аркасында без ул борынгы заманнарда мәкаль һәм аны барлыкка китерү сәләте гаять зур хөрмәтле урын тотканын, мәкаль ул яшерен, серле, хикмәтле көчләргә ия, аның алымы белән эш итә белүче кеше хәтта пәйгамбәр дәрәжәсендә эшләр эшли ала дип каралганын күрәбез. Бу яклары белән ул чичән борынгы грекларның шул ук оракулына, мысырлыларның жрецына, гарәпнең шәехенә, каһиненә, бездәге багучы, баксы, бәхши, күрәзә, шаман һәм сынчыларга якын тора. Бу исә борынгы кабилә тормышы катлауланып, аксакаллар һәм шаманнар инде халыкның тел, тәжрибә һәм хикмәт байлыгын, авыз иҗатын үзләренә туплап бетерә алмагач, идея һәм сәнгать өлкәсен шул эшнең аерым осталары булган шагыйрь-чичәннәргә тапшыра башлауларыннан килеп чыкмагае. Билгеле, мондый жыручыларга һәм хәким-чичәннәргә борынгылар тәжрибә һәм хикмәтнең сихри көченә ия дип караганнар, шунлыктан аларның исемнәре алдында олы ханнар да куркып торган һәм чичәннәрнең күнелләрен аулап, алар аша властьларын жәяргә, халык арасында үз дәрәҗәләрен күтәрергә тырышканнар. Ләкин тарихларда һәм югарыда китерелгән мисалларда күрелүенчә, халык шагыйре һәм хәкиме булган чичәннәр үз иҗат профессияләренә бик зур бәя биргәннәр, тәхет алдында үзләрен вак тотмаган кебек, халык кузгалышлары вакытында аларның хәрәкәт башына менгән чаклары да еш булган. Бу чагында аларның тел-иҗат куәте реаль чынлык көченә әйләнгәнгә, ханнар өчен бу бик куркыныч тудырган. Мәсәлән, шундыйлардан Җамукай чичәннең найманнар күтәрелеше башында торуы һәм үзенең тел кылычын Чыңгыз кылычына каршы куеп, утыз еллар буе аңар баш бирмичә күтәрелеш алып баруы тарихларда бик билгеле. Менә шулардан без борынгы шагыйрь-чичәннәрнең иҗтимагый тоткан урыннары бик зур икәнен, аларның шигырь-хикмәт сүзләренә халыкта бик зур ихтирам сакланганлыкны аңлыйбыз.

Кытай тарихларыннан күренгәнчә, сасаныг дип (чичән, чәчән, сәсән) аталган кешеләр төрки кавем-кабиләләрнең вәкилләре арасында борын-борыннан очрый һәм халыкның иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләрендә дә аларның билгеле эз калдырулары күренә. Шулай итеп, бу сүз — үз авызыннан шигырь-хикмәт чәчә белүче чәчәнме, әллә мәсьәлә чишә белүче хәким мәгънәсендә чачәнме, ул хәтлесен белеп булмый. Ләкин бу сүзнең Кытайдан алып безнең бу җирләргә хәтле таралып яшәгән һәммә төрки халыкларда очравы, борынгы кавымкабиләчелек һәм патриархальлек заманнарында мондый жанр иҗатның һәммәсендә дә нык таралган булуын күрсәтә.

Чичән, жыручы буларак, ничек иҗат итә соң? Безгә монда аның шунысын белү әһәмиятле. Дөрес, ул безнең борынгы шагыйрь, ләкин ул бу замандагы

*Аякчы — жамаяк, касә сонучы.

шагыйрьгә бик аз охшаган. Иң элек ул шигырьне язып чыгармый, сөйләп тә чыгармый, аның кулында думбра, ул шунын кылларында күтәренке, ярым көйле авазлар белән безгә тоткарсыз тезмә чыгарып сөйли. Ул илһами әйтә белүче импровизатор дидек. Бу һөнәргә ул ничек ирешә соң? Иң элек ул язусыз, хәтердән генә эш иткәнгә, аның хәтерендә фольклор һәм сүз алымнарының запасы бик зур. Ул борынгы халык җыр дастаннарының күбесен күңелдән әйтә, аларның шигъри алымнарын, сюжет һәм мотивларының һәр очракта ничек сайланышын, төзелеш, композициядәге йолаларын алдан ук белә. Гомумән, сөйләү теленең остасы буларак, борынгы телне сурәтле ясый торган бөтен чараларны, канатлы сүз, әйтемнәрне, фразеологияләрне, бигрәк тә мәкальләрне күп белә. Аның шигырь-дастаннарны тоткарсыз сөйли алу һәм тирән хикмәтле итеп чыгара белүенең тагын төп сере дә шул запаска ия булуында. Мәкальләр, ритмга һәм рифмага бай булулары сәбәпле, дастан шигъри формаларында төп тукымалар яки әзер кәрәзләр булып хезмәт итәләр, шулар буенча чичән балавызны теләгән якка, теләгәнчә суза. Шунын белән безнең ул борынгы шагыйрь-чичәнебез, аркасына думбрасын аскан хәлдә, авыл-шәһәрләр аша бик иркен гизә; кайда тагын шундый бер шагыйрь барын ишетсә, анда барып мәҗлестә аның белән ярышка керә, кара-каршы хикмәт, шигырь әйтешеп җинешә. Мәкальләрнең кагыйдәчел, дәлилле һәм мисаллы булулары чичәнгә хөкем тәртипләренә катышырга да мөмкинлек бирә. Шунын өчен дә чичән ул туй-мәҗлесләр түрендә генә түгел, ил эчендә барган дау-ызгышларны хәл итешүгә дә чакырып китерелә. Менә ни өчен ул дауда беленә!

Шул рәвешле, чичән—халык шагыйре һәм хәким кеше. Шагыйрь буларак, ул җыр, эпос-дастан тудырса, хәким буларак, ул тирән мәгънәле шигырь, хикмәтле сүз әйтә. Моның өчен ул борынгы мәкальләр алымыннан бик нык файдалана. Ул искиткеч күп мәкаль белә. Жанрның төзелеш һәм ритм йолалыгын (традицияләрен) бик нык үзләштергәнлектән, бу алым белән тоткарсыз иҗат (импровизация) теземнәре әйтү ана җиңел дә, табигый дә. Шунын белән ул бер ише мәкальләрне төзек бер композициядә тезеп, дастан сюжетын куәтле дәлил һәм конфликт мотивларына әверелдерә. Билгеле, ул мәкальләрне, тышкы охшашлыкларына карап, механик рәвештә генә төземи, бәлки, шагыйрь һәм хәким буларак, үзе дә шул типта мәкальләр ясый, алар белән теземне цементлап, бөтен бер фикер һәм хис әсәренә әйләндерә. Шуның белән мәкальләрдән үзенә яна бер төр фольклор жанры килеп чыга. Дастаннардан күренүенчә, моны сарын (сарнап яки мәкальләрне бер-берсенә сарып, күтәренке бер тавыш белән әйтү) яки тулгау диләр. (Яки т у г ы л а у, әйтик, каймакны тугылап язып май төшереп булган кебек, бер ише мәкальләрдән тугылап олы бер фикер чыгару була.) Башкортлар моны кобаер әйтү диләр.

Шулай булгач, бу инде мәкальләрнең очраклы теземе генә түгел, бәлки аларны билгеле бер юнәлештә сару юлы белән хикмәт сөземтәсе чыгару нәтиҗәсендә, тагын да тирәнрәк мәгънәле, яна сыйфатлы, көчле бер яна жанр тудыру дигән сүз. Бу урында бәлки: хәзер бу жанр ник бер дә күренми соң? Ул кая киткән? — дип сорарлар. Моның җавабы шул: күрәсең, һәр нәрсә дә гел үсеп, алга китеп кенә тормый: була да, үсә дә, бетә дә. Әдәбиятта да, шулай ук авыз иҗатында да, бер заманнарда бик югары сәнгать жанрлары туып та икенче дәверләрдә югалырга, үләргә мөмкин. (Әйтик, халыкларда борынгы героик дастаннар жанры бетү яки бездә хәзер бәетләрнең таркалу, бетүгә йөз тотулары.) Шунын кебек мәкальләрнең дә, иҗтимагый фактор буларак, хәзерге шикелле генә роль уйнамаган, бәлки иң зур шигъри хикмәт, канун урынында хөрмәтле тотылган чакларе булган. Чөнки анда газит-журнал, театр, язма әдәбият булмаган кебек, шулай ук суд, хөкем эшендә дә язылган законнар йөрмәгән. Шәригать хөкемнәре булса да, анысы күбрәк дин ягын караган. Мәкальләр халык тормышының тарихи төп нигез кагыйдәсе, хөкеме, үлчәве, хокукы һәм фәлсәфәсе, җәмгыять фикере булып яши биргәннәр, шунлыктан, мәкаль байлыгына һәм аның алымнарына ия булган шагыйрь-чичәннәрнең бу ысул белән тирән хикмәтле жанр-сарын тудыруга ирешүләре дә шул борынгы дәвердә булган. Инде болгар-татарларның сәхрави күчмә тормыштан күптән китеп, башка формацияләргә керүе мәкальләрнең тормыштагы роле үзгәрүгә, шагыйрьләрнең роле дә алышынуга

сәбәп булган. Шагыйрьлек бездә язма, дини, китаби культура белән бәйләнеп киткәнгә, тормыш үзе дә күбрәк дин-шәригать, патша законы шикелле китаби кагыйдәләргә һәм башка шундый нәрсәләргә бәйле булып калганга, шагыйрьләрнең, мәкаль иҗат итүдәге рольләре дә чикләнә барган. Әмма ләкин безнең халык телендә әлегәчә тезмә характерда кайбер озын мәкальләр яки аларның кайбер юллары сакланып калган икән, алар өчен дастан һәм сарын әйтүче борынгы шагыйрь-чичәннәргә бурычлы.

Торымтайдан елгыр кош булмас,
Тургай да тибеп, каз алмас,
Аткыйочтан* "йөгерек ук булмас,
Атса—күбә бозалмас.
Һөнәрсез сине куралмас,
Илдән илгә җилеп үтсән дә,
Бу дөньялар сина да калмас...**

Томанлы көн төлке узар,
Буранлы кан бүре узар;
Җаена чапса ат узар;
Кузалак арба юл бозар,
Яман бикә туй бозар;
Биш бизәнгән көн дә узар...

Күренә ки, бу тезмәдәге мәкальләрне аерым-аерым алганда, һәрберсе үзенә бер гомумиләшкән фикер, ләкин монда алар бер үзәк фикергә җыелып, тагын да гомумирәк фикер һәм нәтиҗә ясалган. Дастаннарда исә аерым образларның телендә алар сюжет конфликтына кереп, гаять көчле, әсәрле мотивларга әйләнәләр.

Заман ахыр булганда,
Ата телен ул алмас,
Ана телен кыз алмас;
Байның телен ярлы алмас,
Ханның телен кара алмас;
Әйтә биреп кайтаем,
Үле телен тере алмас;
Кардәштән чыккан яхшыны
Үз агаең куралмас,
Заман ахыры билгесе —
Бергә туган туганың
Тату да булып торалмас.

Бу соңгысында инде без көнкүрештә борынгы патриархаль тормышның таркалуын, феодаллыкның җимерелүен, бу хәлләрдән:—Халык бозылды, заман ахыр житте,—дигән бер фикергә килүне күрәбез. Бу сарынның феодалчылыкның таркалыш көннәрендә әйтелгән булуы ачык. Ләкин шул теземнәр аерым мәкальләрдән торалар, аларның кайбер юллары әле дә булса телләрдә аерым мәкальләр булып йөрүе бер караудан ук күренеп тора. *(Ата телен ул алмый, ана телен кыз алмый һ. б.)*

Агачның башын киссәң, төбе калыр,
Икенең бере үлсә, бере калыр,
Ялгызның үзе үлсә, кеме калыр?
Менгән аты, кигән киеме яуга калыр.

Аерым мәкальләр яки аларның шундый берничә юллыклары урта йөзләрдән калган дастан-кучерекләрдә яки тулгау, сарыннар тезмәсендә очравы безгә аларның борынгы чичәннәр телендә нык кулланылуын һәм күбесенең турыдан-туры алар тарафыннан барлыкка китерелүен һәм шул теземнәр аларның саклануына

---

* Аткыйоч—укның бер төре.
** Алып би солтан дастаныннан.

да шактый ярдәм итүен күрсәтә. Бу хәл элек безнең Болгар—Казан халык иҗатында шулай булып килгән кебек, Радловның үткән йөзнең 70 елларында, Тубыл, Бараба татарларыннан күп кенә шундый әсәрләр табып алуында да күренә. Илле еллар гына элек Әстерхан нугайларыннан язып алынган материалларда да шундый алымда мәкальләр тезмәсе очрый.

Соңга табарак шагыйрьлек һәм тел осталыгы сәләте тагын икегә аерылып, чичән сүзенең мәгънәсе сөйләү теленең осталыгына кайтып калган; ул мәҗлесләр тотучы, даулар хәл итүче, сүзгә тапкыр, үткен телле оратор мәгънәләрен эченә җыйган. Шулай булса да, думбра кыллары астында, аларның ярым сөйләү, ярым көйләү юлы белән сарнап, тоткарсыз шигырь-хикмәт тудыра алу йоласы күчмә кабилә халык шагыйрьләрендә әле дә калган. Казакъ, кыргыз халык шагыйрьләре, әйтик, Җамбул, Туктаголлар бүгенге көндә дә шул юл белән иҗат итеп килделәр. Алар инде чичән дип тә, шагыйрь дип тә түгел, акын дип аталалар. Акын, Радлов аңлатуынча, шул ук хәким дигән сүздән алынган. Бу дөрес булса, димәк ки, бу сүздә шигырь белән хикмәт аерылмаган, шагыйрь дә, хикмәт иясе дә була, ягъни ул да чичән дигән сүз. Шул рәвешле ч и ч ә ндә без шигырь белән хикмәтне бергә килеш, синкретизм хәлендә табабыз. Бездә дә бу йола шушы йөз башларына хәтле бетеп житмәгән. Мәсәлән, Казан артының Мәңгәр татары Сабирҗан акын һәм Лаеш ягындагы Байчыга авылының Байчыгави акыннар, шулай ук шагыйрь Акмуллалар шушы XIX йөз ахырларында гына Казакъ арасына китеп, аларның акыннары белән тоткарсыз ярышта тудырган әсәрләре бу думбра кылы астында җырлап-сөйләп шигырь-хикмәт әйтү йоласының бездәге язма шигырь көнендә дә үзенә сукмак салып килүен күрсәтәләр. Акмулла: "Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән"—дигәндә, шигырь белән хикмәтне аерымсыз каравын әйткән булса, үзе дә шагыйрьлек һәм хәкимлекне бергә җыйган борынгы чичән сыйфатында алга басып, шигырьне язып та, тоткарсыз сөйләп тә чыгара белү сәләтен күрсәткән кеше. Шул ук Акмулла алымнары белән әсәрләр тудырган Мәҗит Гафуриның баштарак язган "Себер тимер юлы" яки бигрәк тә "Яшь гомерем" дигән әсәрләре алып каралса, аның да казакъ акыннарының шигырь-хикмәт йоласына ия булганын күрәбез. Гафури соңрак, белмим, Тукай тәэсире астына төшеп, ни өчендер, бу юлдан баш тарткан, әмма Тукай аның нәкъ шул акыннар алымы белән язган "Яшь гомерем"енә зур бәя бирә. Гафуриның ул әсәрләре Акмулланыкы кебек үк мәкаль һәм афоризмнарга бай булулары, ничек итеп шигырь тезмәсендә хикмәтне файдаланып, активлаштыруның, шагыйрьлек белән хәкимлекне бергә җыюга омтылуның үрнәге булып тора. Тик монда безнең бу соңгы хәким-шагыйрьләрнең борынгы чичәннәрчә турыдан-туры ирекле мәкаль тезмәчелеге һәм дастанчылык алымнарыннан аерыла төшеп, 11—12 иҗекле казакъ өләңчелеге тезмәсен файдалануларын әйтергә кирәк.

Кыскасы, безнең мәкальләребезне тудырышуга борынгы шагыйрь һәм хәкимнәребез булган чичәннәрнең роле бу язылган юллардан яхшы аңлашылса кирәк. Чыннан да, мәкальләрне халык хикмәте дибез икән, шигырьне дә хикмәт әсәре дип танучы һәм шул юлда иҗат итүче борынгы шагыйрьнең мәкальләр тудырмыйча хәле юк. Шул ук караштa торып һәм шуңа якын йолалар белән эш итүче Акмулла, Гафурилар да үзләренең шигырьләрендә хикмәт тудырулары һәм ул хикмәтләрнең дә мәкаль булып халыклашулары шуның белән бәйле. Шул рәвешле, борынгы җыручы чичәннәр мәкаль-хикмәт тудыруда профессиональ кешеләр булганга, аларның иҗат алымнарына бу урында аерым һәм киң рәвештә тукталынды.

Билгеле инде, мәкаль иҗат итү бер чичәннәргә генә кайтып калмаган, тормышта аның башка юллары да күп. Мәсәлән, бездә тарихта билгеле кайбер аерым кешеләр тарафыннан берәр вакыйгага карата яки шундый кешеләрнең үзләренә карата әйтелеп, мәкаль булып киткән сүзләр дә, табигый, аз булмагандыр. Ләкин безнең тарихыбыз язылып киленмәгән кебек, дәүләт булу ягыннан да революциягә хәтле үзбилгеләнешлеген югалткан халык булганга, андый мәкальләр телебездә бик аз калган, яки мәкале калса да, әйтүчесе текстта күрсәтелмәгәнлектән, белүе кыен. Бу хакта алдарак, мәкальләрнең борынгылыгын сөйләгән җирдә туктарбыз.

Безнең мәкальләрнең тагын бер төренең барлыкка килүенә сәбәп, халык

теленде мисал өчен сөйләнеп йөргән һәртөрле кечкенә хикәяләр—мәсәл һәм мәзәкчәләр—булуын әйтергә кирәк. Бу мәсәлләрнең читтән алынганнары (әйтик, —*Төлке дә йөземгә буе житмәгәч, пешмәгән дигән,*—борынгы грек эзоп мәсәле) бик сирәк булып, күпчелеге үзебезнең көнкүреш һәм кешеләр хәленнән яки кош-корт, җәнлекләр тормышыннан алынган була. Мәҗлес тотарга яраткан кешеләр шундый кыска, ләкин сюжетлы, тапкыр мисаллы мәсәл, мәзәкләргә бик оста булалар, сүзләрен шундый әсәрләр белән бизәп, сүзгә тәм, мәҗлескә ямь бирә беләләр. Бу мәсәл һәм мәзәкчеләрнең ахырында кыска һәм тапкыр итеп әйтелгән кызыклы бер фразасы яки төше була. Шул төштә искә алып куярга кирәкле берәр мәгънә ята. Менә шундый фразалар, тәгъбирләр яки шул мәсәлләрнең бөтен сюжетын искә төшерә торган берәр генә җөмләләр соңыннан мәкаль дә булып китәләр. Мәсәлән: *Җиде бәҗаны бер бүре ашаган.* Шулай ук халык арасында мәшһүр диваналарның мәзәкчәләреннән* таралган кызыклы һәм гыйбрәтле тапкыр сүзләр, Хуҗа Насретдин, Мәнди, Гыйбеди, Мокыт турындагы мәзәкчәләр яки Рәхми тылмач, Габбас мулла кебек тапкыр телле кешеләрдән калган кайбер сүзләр дә халыкта мәзәкчәле мәкаль төсен алып киткәннәр. Ләкин күп кенә мондый хикәя, мәсәлләр, яки мәзәкчәләргә бәйләнешле күп кенә мәкальләр, заманнар үтү белән, хикәя-мәсәлләрдән бүленеп, бәйсез яши башлаганнар. Ул хикәя-мәсәлләр онытылган, мәкальләре исә алардан бүленеп, аерым яшәүләрендә дәвам иткәннәр. Мәсәлән:—*Аша, ашаганнан үлмәссең, Габдулла биясе түгелсең,*—диләр. Ул нинди Габдулла биясе? Моның артында нииндидер мәсәл яки мәзәкчә ятканы күренеп тора. Ләкин аны белеп әйтүче юк.—*Файдасын файда, кара сыер кайда?*—һәм башка кайбер мәкальләр белән дә эш шулай тора. Кыскасы, мәкальләрнең бер төрләренең барлыкка килүләре хикәя, мәсәл һәм мәзәкчәләр белән бәйләнешле. Билгеле, тормыш-көнкүрештән алынган мондый характерлы вак хикәя яки мәсәл-мәзәкчәләр барлыкка килү бүген дә тукталмаган кебек, бу юл белән кайбер тапкыр сүзләрнең мәкаль булып китүе бүгенге көндә дә дәвам итә, шулай ук телгә—җавапка тапкыр кешеләр дә булудан тукталганы юк. Кыскасы, бу юл белән дә мәкальләр ясалу һаман да бара һәм барачак. Мәсәлән, тормышта шундый уенчак, шук табигатьле, сүзгә җор кешеләр очрый, авызыннан әллә нихәтле мәзәк, тапкыр мисаллы сүзләр явып кына тора. Әгәр язып ала барсаң, шуларның байтагы тормыштан алынган мәкаль урынында йөрерлек сүзләр була. Халык ял сәгатьләрендә шундый кешеләрне тыңларга, сөйләндерергә ярата. Мондый мәзәкчеләр, тапкыр кешеләр авызыннан чыккан сүзләр, күбесенчә, җиңел мәгънәле такмаза булса да, кайбер сүзләре бик тиз таралып, мәкаль урынында кулланып китүен күрү дә авыр түгел, һәм шул ук вакыт бик салмак, әллә нидә бер сүз әйтеп куя торган авыр табигатьле кеше дә бик сирәк, бер генә сүз әйтеп куйса да, әйткәне бөтен илгә таралырлык бер әһәмиятле сүз-мәкаль булып чыга. Билгеле, мондый аз сүзле, акыл җыеп утырган кеше кирәк чагында гына сүз әйтеп куйганга, хикмәт әйтүе гаҗәп түгел. Ләкин шуңа карап мәкальне гел акыллы, хикмәтле кешеләр генә чыгара икән дип уйларга ярамый. Халык бертөрле юләрсымак кешеләрнең хәлләренә дә бик игътибар итүчән һәм шуның сәерлегендә бер хикмәт юкмы икән дип, сүзләренә үзенчә мәгънә бирүчән. Шуның белән хәтта диваналар, бертөрле сәер кешеләрнең мәзәк сүзләренең кайберләре мәкаль булып киткәне дә бар. Шунысы билгеле: шул сүзне әйттергән хәл үзе дә кызыклы булса һәм сүзнең хикмәте шул вакыйгасыннан башка аңлашылмаса, аны шул вакыйгасы—авторы белән бергә кушып сөйләнелә, әмма анысының әһәмияте булмаса, фәлән авылның, фәлән кешесе әйткән дип икенче бер авылда да иясен кушып сөйләүнең кирәге дә калмый.

Элекке заманда Казан арты Күәм авылында Зариф дигән бер кеше булган. Бала-чагасы күп, үзе фәкыйрь, ничек тә бер сыер сатып алырга хыялланып акча җыйган. Ләкин Зариф агай бик кызу, дуамал кеше икән. Яннарындагы Әтнә базарына барып, аны-моны карамыйча, сыер урынына үгез алып кайткан. Капка төбенә җыелышып торган күршеләре:—Карале, Зариф туган, сыер түгел, үгез бит

* Мәзәк—гомумән көлке, кызык (шутка); әмма кечкенә көлке хикәячек, анекдот мәгънәсендә әйтелгәндә мәзәкчә дип алынды.

бу, дигәч, Зариф кызып:—Үгез булмагае чорт булсын, балаларга сөт булсын! — дип, капкасын каерып ташлаган да, үгезен кертеп, ябып та куйган.

Тирән уйлап әйтелгән сүз түгел, мәкаль чыгарам дип тә әйтелмәгән, тәҗрибәдән түгел, бәлки жаны кайнаганга әйтеп жибәргәндер, ләкин бу сүз шундук авторы, вакыйгасы-ние белән телгә кергән һәм мәкаль булып киткән. Болай карауга акылга да туры килми, әмма халык бу сүзгә үзе мәгънә бирә һәм аның хикмәтен таба белә. Ул нинди дә булса бер максатка житәргә аптыраганнан адәм бер дә туры килми торган чараны да эшләп ташлый дигән хикмәтле мәгънәгә гүзәл мисал була ала.

Шулай итеп, конкрет тормыш очракларыннан шул вакыйганың вакытын, урынын, үзен һәм катнашучыларын төсмерләп сөйләгән хикәягә төренеп, тапкыр әйтелгән бер юрам сүз (тәгъбир) килеп чыга. Мондый кечкенә сюжетлы хикәя, мәсәл йә булмаса мәзәкчеләрнең төше гадәттә ахырында була һәм шул сүз тапкыр бер хикмәтле мәгънәгә ия булса, мәкаль рәвешендә генә дә куллана башлый. Бу мәкаль вакыйгасыннан башка да аңлашылса һәм әйтелә алса, анысын кушып сөйләүнең бик үк кирәге дә булмый. Шул рәвешле мәкаль туа, аны тудырган конкрет очрак онытыла, ләкин мәкаль үз алдына гомуми (типик) мәгънәгә дә ия булуы белән үзе хәзер тормышта бик күп төрле конкрет очракларга мисал урынында йөртелә башлый.

Билгеле инде, монда китерелгән мисаллардан мәкальләрне бары тик борынгы кабилә башлыклары, көрәзәләр, хәким һәм шагыйрь чичәннәр, тапкыр телле яки юләрсымак кешеләр тудырган, аннары бары мәзәкчә-мәсәлләр аша гына туган икән дип аңларга ярамый. Мәкальләрнең моннан башка да туу юллары күп һәм бүген дә туудан туктаганы юк. Дөньяда беркемнең дә авызы тегелмәгән. Шуңа күрә дә хәзерге телебездә йөргән мәкальләрнең күпчелеге дә гади хезмәт халкы телендә барлыкка килгән дип уйларга кирәк. Инде ул соңгы заманнарда ничек турыдан-туры тормышның үзеннән барлыкка килүенә кайбер мисаллар бирик.

Һәркайсыбыз үзебез дә беләбез, кеше тормышта һәрвакыт төрле каршылыклар эчендә яши, һәм яшәү өчен дә шул каршылыкларны жиңәргә мәжбүр. Ул шулай үз бәхете өчен яки кеше бәхете, халык бәхете өчен зур теләкләргә ирешү юлында өзлексез көрәш алып бара. Үзенең көчен дә, каршы якныкын да кат-кат сыный, көрәш гел тигез генә бармый, бер кайтып аңа тынгылык бирсә, бер ташып аны яңадан элеп ала, үсә, күтәрелә, шул хәтлегә житә, монда йә үлем, йә тереклек!.. Кеше шул чагында йә үзенең бәхетенә ирешеп, аны йөрәгенә кысасасы, кочасы, йә үзенә дошман як көчне, дөнья каршылыкларын жиңәсе, ватасы, жимерәсе килә. Кешедәге бу хиснең ташкыны Сәгыйть Рәмиевтә болай әйтелгән:

Аһ, әгәр бу күңелем үткен
Сөнге йә ук булсае!
Яисә ул бер уй булән су!
Яндырыр ут булсае!

Әмма соң бу дөньясын бер
Эт итеп атар идем,
Тау-суын да яндырыр һәм
Күкләрен ватар идем!

Шул рәвешле бу көрәштә кешенең теше-тырнагы, уе-йөрәге генә түгел, тавышы-теле дә турыдан-туры катнаша, кешенең шул чагында кайнаган бу хисләре үзенә мәгънә табасы, ачыласы, әйтеләсе, кешеләр күңелендә дә моңа жавап яки уртаклык табасы килә һәм шул хис, шул уе аваз булып, мәгънә булып аның телендә ташып чыга. Берләре шулай, Рәмиев әйткәнчә, "су яндырырлык ут" булып, хис ташкыны булып әйтеп ташланса, берләре исә, күп сыналган бер фикер нәтиҗәсе, шунын бер тәгъбире булып чыга. Чөнки кеше бу аяусыз көрәштә ачы тәҗрибәгә, "арткы акыл"га ирешә, ул аларны, табигый, башкалар белән уртаклаша. Менә шул эчтә ташыган мәгънә яки хиснең яки ачы тәҗрибәләрнең иң көчле тәгъбирләре булып чыкканнары авыз иҗаты аша, жыр, мәкаль һәм

башкаларда чагылып килгән. Шулар арасында иң кыска, иң тәҗрибәчән, шул ук вакыт бөтен бер фикергә ия булганнары да мәкальләрдер.

Ләкин бу әле эшнең бер ягы гына. Бу әйткәннәрдән мәкальләр бары кешедә ташыган хиснең омтылышы, күңел авазы (лирика) гына икән, һәм бары шул юл белән генә туа икән дигән берьяклы фикер калмасын. Юк, алай түгел, мондый очракта мәкаль ул хиснең *гомуми мәгънәсе*, аның *бәя табуы* булып туа. Әйтик, ачу бер хис, ләкин *Ачу йоту—тау йоту*,—дигән мәкаль ачу белдерү түгел, бәлки шул хисне йотуның авырлыгы турында гомуми бәя әйтүдер. Бу мәкальне башлап әйтүче бик зур ачу хисе кичергән һәм шул чагында үзен тыеп калуның бик зур авырлыгын тойган булса, анысы аның үзенең шәхси, хосусый, очраклы ягы, әмма шул хискә биргән бәясе бар кеше өчен дә уртак, чөнки ачу йоту һәркем өчен дә *авыр* шул авырлыкның "тау йоту" дип бер сүз белән көчле шигъри сурәтләмә белән әйтелгән мәгънәсе һәммәбез өчен дә гомумидер. Менә аның башкалар өчен дә уртак бер фикер яки мисал буларак телдән телгә күчеп, күмәкнең малы, ягъни мәкаль булып китүенең сере дә шунда.

Димәк, мәкальләрнең берләре кешенең тормышта дучар булган бер хәлдә, аның җан кыставы, аның тел очында әйтеләсе килгән мәгънәнең чарасыз рәвештә үзенә әйтелеш табуы төсендә туа. Ләкин бу әле аның әһәмиятле мәгънәне һәрвакытта да шул минутында үзе чыгарып әйтә дигән сүз түгел. Киресенчә, кешене бер хис биләп алганда, әйтик, ачуы-зәһәре купканда яки курыкканда, аның акылы шул хәтле киеренке була ки, ул үз хисенә бәя бирерлек хәлдә булмый, күп вакытта ул аны әйтергә сүз дә таба алмый. Шунлыктан, башыңа төшкән бер эшкә бер тәгъбир табу, бер хөкем чыгару өчен, аны нәкъ шул вакыт үзең әйтеп бирү шарт түгел. Күп вакыт киресенчә дә була: сине эчтән тыгызлаган, тел очына килгән нәрсәне телең белән юрап әйтергә сүз таба алмый торганда, шуны сиңа янындагы берәр тыңлаучы әйтеп җибәрә, шундый шәп әйтә ки, сиңа бары: "Әйе, шулай шул",— дип, кул куярга гына кала. Чөнки тормышта берәү башына килгән кайбер хәлләр икенчеләргә дә килеп торган кебек, шул чагында кичергән хисләрендә дә уртаклык бар. Шунлыктан, берәү сүз таба алмый торганда, янындагы кеше менә объективрак килә ала һәм бу хиснең уртак мәгънәсен табышып та бирә. Шулай булгач, мәкаль булып китәрлек ул мәгънәне башына эш төшкән һәр кеше үзе чыгарып әйтү шарт түгел, һәм ул тормышта күбесенчә шулай да: башыңа бер эш төшсә, аптырасаң, бар, дөнья күргән берәр акыллы кешегә киңәш ит, ул синең хәлеңә керер, уртак мәгънәсен табышыр, шул вакыт ул менә мисаллар-мәкальләр китерер, яки үзе үк сизмәстән шул уртак мәгънәне табышканда, үзеннән мәкаль әйтеп ташлар.

Яки болай да була. Син кем беләндер бәйләнештең, дауга кердең яки сүзгә килдең. Кайттың, эш үткәч, хәзер син аны тынычлабрак кайтадан уйлап карыйсың.—Ах,—дисең,—ул миңа алай әйткәндә, мин болай әйтәсе калган икән, мин сүземне менә ничек-ничек дәлилләргә тиеш булганмын; ах, ник шулай дип кенә әйтмәдем; менә бит, шулай бер генә сүз белән әйтергә булган! —дип, сиңа хәзер арткы акылың исенә төште, бу акыл хәзер "дошман"ны бер бәрүдә кисәрлек яңа һәм үткен бер фраза булып туды, ул синең телеңдә кат-кат әйтелә торгач, матур да, шома да булып китте, мәгънәсе дә аның саен конкретлаша барды. Бик мөмкин ки, син хәзер бу эшең белән, үзең дә сизмәстән, нинди дә булса бер яңа мәкаль иҗат итеп ятасың. Бу яңа сүзең үзеннең үткән эшең—һәм аңа булган хисеңә, мөнәсәбәтеңә кайтадан анализ ясап, аңа үзең үк яңа мәгънә һәм бәя бирүең аркасында күңелеңә килде яки синең үз миеңдә туды. Халыкча әйткәндә, "арткы акыл" дип йөртелгән синең бу яңа сүзең, күп вакытта, мәкаль урынында ук кулланырлык әһәмиятле бер сүз була.

Шулай итеп, мәкальне яки мәкаль булып китәрлек мәгънәле сүзне тормышта без һәркайсыбыз үзебез дә сизмәстән чыгарып әйткәли торабыз. Тик үз башыбыздан гына әйткән булгач, аларның мәкаль дәрәҗәсендә булуына әһәмият тә бирмибез, йә ул башкаларга ишетелмичә, йә онытылмыйча кала. Эш үткәч, без үзебез дә аны онытткан булабыз. Шулай итеп, тормышта мәкальләр һәр көн, һәркайда иҗат ителгәләп тора. Акылы, йөрәге бар һәркем хис һәм хикмәт иясе, һәркем иҗат иясе. Тик без тормыш ыгы-зыгысы белән мондый иҗади мәгънәле сүзләребезгә әһәмият бирә алмаганлыктан, алар йомыш үтәүче очраклы бер сүз генә булып

калалар, бик сирәкләре генә колакка-телгә төшеп, шомарып мәкаль булып китә. Димәк, мәкальләрнең туу юллары күп. Ләкин, ничек кенә барлыкка килмәсеннәр, һәр мәкальнең дә шәхси авторы булуы монда язылганнардан яхшы аңлашылгандыр дип беләм. Алай булгач, аларның халык иҗаты булуы нәрсәдә соң? Авторлары булып та бары тик без аларны белмәгән өчен генәме?

Юк, аның өчен генә түгел. Мәкаль тормышта очраклы бер хис юралышы (тәгъбире) кебек булып туса да, халык өчен уртак әһәмияткә ия булуы анарда гомумиләштерелгән бер фикер ятканын күрсәтә, дигән идек. Башлап әйткән кеше, ихтимал, үз сүзенә ул уртак мәгънәне бирмәгән дә булыр, ләкин анар башкалар бирәләр. Шулай итеп, мәкальдә бер конкрет очраклы әйбер турында гына сүз барса да, мәгънәсендә абстрактлаштырылган бер гомуми фикер ята. Бу нәрсә мәкальдәге очраклы образны типик (гомуми) ясый, шунлыктан мәкальдәге очраклык кирәк һәм зарури булып чыга.

Шушы мисаллардан күренүенчә, безнең бу заманда мәкаль ничек барлыкка килә дигәнгә, ул, күбесенчә, тормыштагы конкрет хәлләр, төрле кичереш һәм чаралардан гомуми нәтиҗә, һәммәбез өчен гыйбрәтле бер өлге сүз, уртак әһәмияте булган бер арткы акыл, бер тәҗрибә яки иҗади хыял кыставы астында килеп чыккан бер мисал булып туа дип әйтсәк, ялгыш булмас. Шунлыктан ул кирәк урында бер дәлил, гомуми бер кагыйдә, уртак бер хөкем, өлге яки мисал булып йөри бирә. Инде хәзер аны башлап дөньяга кем чыгарганы, кем әйткәне дә онытыла. Эш анысында йөрми, эш бу әйтелгән мәгънәнең хаҗәте төшкән саен кирәк һәм уртак булуында. Хәер, аны инде кем әйткән дип бик төпченгәнне дә яратмыйлар,— *Сүз иясе белән йөрми*, дип кенә җавап бирәләр. Шулай итеп, авторы югалган, берничә сүздән генә торган бу кечкенә әсәр һәркемгә, һәркайда кирәк булып, күмәкнең малы булып йөри башлый. Әйтелеше белән дә ул телдән телгә йөреп һаман ипләнә, шомара, мәгънәсе дә конкретлаша бара. Менә аның күмәк иҗат, халык иҗаты булуы нәрсәдә!

Билгеле, бу әйтелгәннәрдән мәкальләр тормышта тагы тик тә шул юл белән генә туа икән дип уйларга ярамый, бу тик гомумирәк бер мисал гына. Югыйсә кешенең шәхси, иҗтимагый тормыш хәлләре, табигатькә мөнәсәбәтләре, иҗади хезмәте нихәтле катлаулы булса, мәкальләрнең килеп чыгулары да һәр мәртәбәсендә аны башлап әйткән кешенең шундый ук катлаулы хәлләренә, сәләт һәм тапкырлыкларына бәйләнгән.

Безнең мәкальләрнең барлыкка килүендә кайбер башка сәбәпләр турында сүз уңаенда алда да әйтeләчәк булганга, монда барысына да аерым тукталып тормыйбыз. Җыеп кына әйткәндә, безнең мәкальләрнең үткәндәге һәм хәзерге чыганаклары шулар: а) иң борынгы җәмгыятьтә аерым кешеләр һәм бигрәк тә ыру башлыкларының тәҗрибә һәм ышанулары, абруй казанган сүзләре нәтиҗәсендә туган мәкальләр; б) борынгы культ кешеләре, күрәзә, багучылар (шаманнар) тудырган мәкальләр (бу борынгы ике төрдән калган мәкальләр хәзер аз); в) борынгы халык шагыйре һәм хакиме булган чичәннәрнең дастанчылык һәм сарын алымнарыннан яки дауларны хәл итүче хөкем сүзләреннән туган мәкальләр (болардан калган тезмәләр яки өзекләр шактый күп табыла); г) тарихи аерым шәхесләр авызыннан яки аларга һәм вакыйгаларга карата әйтелгән мәкальләр (мондыйлар аз); д) язма әдәбият аша аерым шагыйрьләр йә башкаларның тапкыр һәм үткен әйтелгән афоризм булырлык сүзләреннән халыклашып киткән мәкальләр; е) вәгазь-нәсихәт яки дини китаплар аша алынмачылык юлы белән килеп кергән мәкальләр; ж) күрше халыклар белән культура һәм хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре аша, аларныкыннан тәрҗемә яки янарту юлы белән ясалган мәкальләр; з) тормышта булган яки берәр хыялый вакыйгадан алып халык телендә мисал өчен сөйләнеп йөргән һәртөрле кечкенә хикәя, мәсәл һәм мәзәкчәләрнең җимеш төше яки сөземтәсе урынында әйтелгән һәм мәкаль булып киткән сүзләр; и) шаян телле шук кешеләр тарафыннан җинелчә, ләкин тапкыр һәм оста әйтелгән кайбер җор сүзләрдән хасил булган мәкальләр; к) тормышта булып торган сәер вакыйгалар һәм сәер сүзләр тудырган кешеләрдән килеп чыккан мәкальләр; л) гомумән башка төр фольклор жанрларыннан алынган, кайбер аерым юралыш сүзләрдән килеп чыккан мәкальләр; м) һәм, иң зур күпчелеге дә, тормыш һәм табигать белән көрәштә һәркем башында туып торган хәлләр

тыгызлавы астында аерым кешеләр тарафыннан элек тә һәм хәзер дә туып, барлыкка килеп торган мәкальләр.

Кыскасы, халык мәкальләренең барлыкка килү юллары күп һәм төрле булып, аларны монда күрсәтелгәннәр белән генә дә чикләп булмас. Шулай булса да, әйтергә кирәк, аларның иң зур күпчелеге дә күп гасырлар буе хезмәт иясе халкының турыдан-туры табигать һәм тормыш каршылыклары белән көрәшләрендәге тәҗрибә һәм сынауларының мәгънәсе, сыгымтасы булып, халкыбызның һәртөрле ышанулары, рухи байлыгы, тел һәм иҗат байлыгы булып, шул мәгънә һәм хиснең гомуми юралышы—тәгъбирләре булып барлыкка килгәннәр... Күпчелек мәкальләрнең тема һәм мәгънәләре шулай ук тормыштагы кулланышлары шуны күрсәтә һәм моның шулай икәнен күрү өчен, шушы китапның бүлек башларына бер күз салып чыгу да җитә. Турыдан-туры эш һәм хезмәт темасына багышланган мәкальләрнең саны мең ярымлап булуы, табигать һәм аны эшкәртү темасында бик күп мәкальләрнең дә күпчелеге шуны чагылдыруы һәм ахырда бирелгән сынаулар бүлеге үзе генә дә күп нәрсә аңлатса кирәк.

*Дәвамы бар.*

---

## Киләсе саннарда укыгыз:

***Чәчмә әсәрләр***

**Барлас Камалов.** Дөмбер Даниял. *Повесть.*
**Әнәс Галиев.** Чигенгәндә. *Повесть.*
**Мансур Вәли**. Мәхәббәт маҗаралары. *Новеллалар бәйләме.*
**Фәнис Яруллин.** Бер күрешү үзе бер гомер. *Пьеса.*

***Шигърият***

**Шәүкәт Галиев, Роберт Әхмәтҗанов, Равил Фәйзуллин, Нур Әхмәдиев** шигырьләре.

***Фән***

**Нәкый Исәнбәт** *(тууына 100 ел тулу уңаеннан).* Мәкальләребез турында. Автор исән чагында төзәтеп һәм баетып калдырылган вариант.
**Зәрия Хәбипова.** Идегәй үткән юл. *Эстетик-фәлсәфи тикшерену.*

***Публицистика***

**Әгъзам Фәйзрахманов**. Гасыр бусагасын атлаганда.
**Вахит Юныс.** Кызыл кхмер.

***Әдәби тәнкыйть***

Туксанынчы еллар әдәбияты. *(Анкета сорауларына җаваплар).*
**Факил Сафин**. Кадыйр Сибгатуллин иҗаты.

*Милләттәшләребез чит илләрдә*

# ТАТАРГА ТУГРЫ ТӨРКӘР

***Төркәр Соуккан—төньяк кешесе. Финляндиядә туган, Швециядә гомер итә. Телләре, диннәре ягыннан безгә ят халыклар арасында яшәсә дә, ул күңеле белән, рухы белән чын татар. Менә дигән итеп татарча сөйләшә, татарча укый, яза, җырлый һәм татарны дөньяга танытыр өчен төрле гамәлләр кыла. Мин аның белән беренче мәртәбә ул «Ватан» җәмгыяте чакыруы буенча Казанга килгәч, 1993 елда танышкан идем.***

***Төркәр Хельсинки шәһәрендә дөньяга килгән. Әтисе Твюек Усманали бирегә Төркиядән килеп Хельсинки янындагы Ярвинпәә дигән шәһәрдә мөгаллим һәм мулла хезмәтләрен башкаручы, энисе Әминә исә нәселе ягыннан Түбән Новгород губернасының Сергач өязе Актүк авылыннан чыккан татар кызы була.***



*Төркәр Соуккан һәм Илбарис Надиров. 1999 ел.*

*Төркәрнең балачагы Ярвинпәәдә уза. Шундагы татар даирәсендә теле ачыла, тәүге миллилек сабакларын шунда ала, әтисе белән шундагы мәчеткә йөри. Гаиләләре Стокгольмга күчкәч, Төркәр шунда урта мәктәпне тәмамлый, хәрби хезмәттә булып ала, университетта хокук һәм гуманистика факультетына кереп, берүк вакытта гарәп теле өйрәнә башлый. Нияте күп телләр өйрәнеп тюркология фәненә килү була, әмма хокук фәннәре үзенә ныграк тарта. Шул вакыт аны—лейтенант Төркәр Соукканны Берләшкән Милләтләр оешмасының швед батальоны белән төрек теленнән тәрҗеман итеп Кипрга җибәрәләр.*

*Стокгольмга кайткач, ул Мауд исемле швед кызына өйләнә. Алар бәхетле яшиләр, өч бала үстерәләр. Тик Мауд моннан биш ел элек каты авырудан вафат була.*

*Төркәр Соукканның төп белгечлеге-хокук дөньясы. Шуңа күрә аны «Инсан хокуклары, демократия, милли күпчелек вә азчылык мөнәсәбәтләре» дигән замани проблема буенча эш алып барыр өчен төрле илләргә җибәрәләр. Соңгы елларда ул берничә тапкыр Страсбургта, Гаагада, Тиранада, Ригада була, форум-җыелышларда инглиз телендә чыгышлар ясый, лекцияләр укый. Аның инсан хокукларына багышланган берничә мәкаләсе матбугатта дөнья күрә.*

*Берүк вакытта ул этнография фәнен өйрәнүне дә дәвам итеп, бу өлкәдә белгеч буларак аерым бер диплом алуга ирешә. Сиксәненче еллар уртасында Төркәр Соукканның Швеция һәм Финляндиядә яшәүче төрки-татарлар турындагы ике мәкаләсе басылып чыга. Алар дөнья халыкларының антропологиясе һәм этнографиясенә караган ике журналда—Швециядә һәм Даниядә чыгалар. Заманында мин Төркәрнең бер хезмәтен үземнең Финляндия татарлары турындагы мәкаләмдә файдаланган да идем.*

*Татарны Швециядә таныту гамәле белән Төркәр Соуккан әүвәл-әүвәлдән шөгыльләнеп килә. 1995-1996 елларда Татарстанга Швеция радиосыннан композитор Фолке Рабе һәм музыка белгече Матс Эйнорссон килгәннәр иде. Алар Казанда, Чаллыда, Зәйдә һәм Тукай районы авылларында булып, татар халык музыкасы, җыр сәнгате һәм уен кораллары турында бай гына мәгълүмат туплапдылар. Яннарында тәрҗеман һәм киңәшче сыйфатында Төркәр Соуккан йөрде. Җыелган хәзинә нигезендә алар бик тә кызыклы музыкаль программа төзеп, моннан өч ел элек Швеция радиосы буенча алты сәгатькә сузылган алты тапшыру оештыралар.*

*Соңгы елларда без Төркәр Соуккан белән хатлар алышып торабыз. Үз хатларында Төркәр гомер юлы турында хисләнеп, дулкынланып яза. Кайбер өзекләр китереп үтим:*

*«... 1993 елда Казанга беренче килүемнең тәэсирләре бүген дә күңел түремдә. Бабаларыбыз иленә килеп, андагы кешеләр белән үз телемдә—газиз анам телендә сөйләшергә насыйп булды. Җирсү хәсрәте миндә бүген дә бар, ул читтә яшәүче татар күңелендә һич тә бетми торган бер хәсрәттер.»*

*«...Татар җырына мәхәббәт миңа бишектә ук сеңгән. Ярвинпәәдә үткән бала чагымда ук исемдә калган «Агыйделдән көймә килә», «Илкәем», «Моңлы сазым», «Туган тел», «Күбәләгем» кебек җырларны үзем дә җырлап үстем. Миңа иң зур тәэсир ясаган җырчы Рәшит Ваһапов булды. Әнием ягыннан ул миңа кардәш тә. Сергач мишәре бит. Җирсү хәсрәте көчәйгәндә мин аның «Нурия», «Фирдәвескәй» җырларын көйләп юана идем.»...*

*«...Финляндиядә минем туганнарым бүген дә яшиләр. Шуңа күрә мин анда еш булырга тырышам. Татарча сөйләшү, милли ризыклар ашау, кан-кардәшләр белән күрешү миңа һәрвакыт яшәү дәрте өсти. Казаннан Финляндиягә килгән татар концертларына, Камал театры сәхнәләренә дә барып йөрим. Финляндия татарлары бүген дә гөр килеп, мөстәкыйль җәмгыять-мәхәллә булып көн күрәләр. Үкенечкә күрә Швециядәге татар җәмгыяте озын гомерле була алмады.»...*


*«...Яңа гаиләм барлыгын беләсез инде. Аның корылу тарихы болай булды: Швеция радиосы вәкилләре белән 1995 елда Чаллыдагы «Болгар» ансамбленең җырларын язып алган идек. Шунда мин җырчы кыз Гөлүзә Зиатдинова белән таныштым. Аннары без хатлар алышып тордык. 1996 елда мин аны әти-әнисеннән сорарга дип кабат Чаллыга киттем. Шул вакыт безгә никах укылды. Гөлүзә белән без үзебезне бәхетле кешеләр дип саныйбыз. Ул инде шведлар җиренә ияләшеп килә, швед телендә сөйләшә дә белә»...*

*Шулай итеп, Төркәр Соуккан—Швециядә хокук фәннәре укытып танылган педагог һәм фәнни хезмәтләре булган галим генә түгел, ул газиз халкы татарга файдалы хезмәт күрсәтергә омтылып яшәүче үзебезнең кеше—Татарстан кияве дә.*

*Төркәр Соуккан хәзер Татарстанга ел саен җәйләрен Гөлүзә белән бергәләп кайтып йөри. Кайда барсалар да туган-тумачалары, дуслары аларны кочак җәеп каршы алалар, чөнки Төркәр дә, Гөлүзә дә ачык күңелле, туган җанлы мөлаем кешеләр, өстәвенә икесе дә мәҗлес күрке булырдай җырчылар. Бу урында быел җәен Казанда очрашканда алар хәбәр иткән бер кызыклы яңалыкны язмый калалмыйм. Бу елның май аенда Стокгольмдагы Швед Шәрекъ җәмгыяте төрек музыкасы кичәсе оештыра. Анда башка төрки халыклар турында да сүз була. Татар музыкасы һәм җырлары турында сөйләр өчен кичәгә Төркәрне чакыралар. Аның бер сәгатькә сузылган чыгышында ул үзе дә, Гөлүзә дә татарча җырлап, көйләр уйнап күрсәтәләр, аудиокассеталар ярдәмендә Рәшит Ваһапов, Хәйдәр Бигичев, Гөлзадә, Фән Вәлиәхмәтов, Айдар Галимов һ. б. артистлар башкаруында җырлар, мөнәҗәтләр, бию көйләре яңгырый. Тамашачылар бу «фәнни концертны» яратып, хозурланып тыңлыйлар, ә Гөлүзәнең моңлы вә шаян җырларын алкышлар белән күмәләр. Татар күңелендә милли җырлар еракта да шулай тибрәнә, шулай дәртләнә....*

*Төркәр Соукканның «Казан утлары»на дип махсус язып миңа җибәргән бу мәкаләсе татар диаспорасы тарихын өйрәнүчеләр өчен мәгълүматка бай һәм фәнни яктан җитди бер чыганак булыр дип ышанасы килә.*

**Илбарис НАДИРОВ**



**Төркәр Соуккан,**
Швеция полиция академиясе доценты.

# ШВЕЦИЯДӘН ТАТАР ТАВЫШЛАРЫ

Интернеттан дөньядагы татарларның саны турында мәгълүмат сораганда Швециядә 80 татар бар диелә. Ул татарлар кемнәр, аларның гомерләре вә бергәлек омтылышлары нинди рәвештә тәрәккый иткән? Бернична ел элек мин аларны очратып, кыскача әңгәмәләр уздырдым. Бу сөйләшүләрнең максаты швед татарларының тарихын, икътисад вә кәсепләрен, кулланган телләрен, этник-милли аңнарын, Швециядәге бергәлек эшчәнлекләрен һ. б. ачыклап белү иде. Әйдәгез, шул шәхесләрне тыңлыйк әле!

*А. (1926 елгы хатын): Үзем Көнбатыш Финляндиядәге Кеми шәһәрендә тудым. Әнкәем Рәсәйдән, Нижний Новгород губерниясе, Сергач районының Өчкул авылыннан иде. Әтием дә Сергач якларыннан. Рәсәйдәге революциядән соң, Финляндия һәм Рәсәй арасындагы чикләр ябылгач, әти сәүдәгәр булып Финнар иленә килгән. Братлары белән башта Оулу шәһәренә урнашкан һәм анда кибетләре дә булган. Шул кибеттә алар материя вә трикотаж әйберләре сатканнар. Утызынчы елларның азагында татарлар үзләре Вааса шәһәрендә балалар һәм яшьләр өчен җәйге курслар оештырдылар. Мин дә ике-өч җәй ул курсларда белем алдым. Укытучы бер хатын-кыз булып, гел дин дәресләре бирде. Өйдә без мишәрчә сөйләшә идек, урамда финча. Өйдә һәм бүтән урыннарда татарлар арасында финча сөйләшкәндә әти-әниләр һәм бүтән олылар: «Чит телдә сөйләшмәгез, мөселманча сөйләшегез»,—дип кисәтеп ала иделәр. Кеми шәһәрендә 1926 белән 1940 ел арасында татар гаиләләре бик нык аралашып яшәделәр. Аннары мин Хельсинкига—ике туганым янына күчтем һәм анда Гыйбадулла Мортазин һәм Ариф Рами исемле укытучыларда милли дәресләр алдым. Безгә динне вә татар һәм төрек телләрен өйрәттеләр. Финнар арасында үзебезне еш кына төрекләр дип таныта идек, чөнки «татар» дигәндә, бигрәк тә бала чакта, безне мыскыллап «таттары»* дип атап борчыдылар. 1947 нче елда мин татар ирем белән Швециягә күчтем. Бу елда без тире, мех һәм туннар эшендә идек һәм берничә ел кибет тә тоттык. Балаларыбызның өйдә швед телендә сөйләшүләренә каршы килмәдем.*

*Швед илендә үземне төрек дип йөртәм, ләкин төрекләргә шимал төрке (төньяк төреге) дип әйтәм. Катыш өйләнүләр минемчә яхшы түгел. Тел һәм дин юк булыр дип куркам. Тойгыларым татарлыкның дәвам итүен хуплый. Оныкларымның татарча өйрәнүләрен һәм татарлык белән кызыксынуларын теләр идем. Кызыма боларны әйттем, ләкин ул бу эшкә игътибар итми.*

*В. (1923 елгы ир-ат): Эстониядәге Нарва шәһәрендә тудым. Әтием Сергач районындагы Куйсу авылыннан. Әнием дә Сергачтан иде. Мин аларның бердәнбер балалары. Без 1920 нче елларда Питер аша Нарвага килгәнбез. Әти нигездә коммунистлардан качкан, чөнки аңа «кулак угълы» тамгасы сугылган булган.*

*Минем башлангыч мәктәбем алман халык мәктәбе иде. Дүрт ел анда укыдым, аннары эстон мәктәпләренә йөрдем. Барлыгы уникe ел белем алдым. Нарвада һәм Таллинңда татар балалары өчен өч айлык җәйге курслар оештырган иделәр. Анда дин, тарих, татар һәм гарәп әлифбасы укытыла иде. Бу курслар 1936 белән 1938 арасында булган иде һәм укытучы булып Галимҗан Идрис вә Ариф Рами эшләделәр. 1938 елда Нарвада чама белән 100, Таллинңда да шулай ук 100 ләп татар бар иде. Ул вакытларда чын мәчет юк иде әле. Таллинңда намазларны бер-берләренең фатирларында укый*

---

*Язмада автор стилистикасы сакланды.

*Фин һәм эстон телләрендә «таттаре» сүзе «чегән» дигән шикеллерәк мәгънәне аңлата.

иделәр. Ә бервакыт Нарва татарлары үзләренә йорт сатып алдылар. Астагы катта балаларга уку залы (мәктәп) һәм югары катта гыйбадәтханә (мәчет) ачтылар. Шулай итеп, Нарвадагы иҗтимагый һәм дини тормыш шактый алга китте. Мөселман (татар) зираты да бар иде. 1940 елда Эстонияне Кызыл Урда басып алгач мин алманнар урдасында чик сакчысы вә соңрак бер ел Белоруссиядә тәрҗемәче вазифаларын үтәдем. Алманнарның сугыштагы хәлләре начарая башлагач, 1943 тә Финляндиягә качтым. 1944 тә Финляндиядә бер мишәр кызына өйләндем. Соңрак, 1947 дә гаиләм белән Швециягә юнәлдек. Ул чакта белгәнем буенча бөтен швед илендә чама белән 12 татар кешесе бар иде. Бер ел үткәчтен Финляндиядән тагын ике гаилә килде. Алар кызыл армиядә хезмәт кылып финнарга әсир калган шәхесләр иде. Сталинга кайтарылмас өчен Швециягә качканнар. Еллар буе без мондагы татарлар һәм шушы диндәге төрки кешеләр нык аралашып тордык. Бала чагымда өйдә татарча сөйләшә идек. Эстонча сөйләгән чакта: «Мөселманча сөйләгез!» дип кисәтә иделәр. Кайбер очракта олылар маңгайга да берне манчый иделәр. Урамда инде эстонча сөйләшәбез. Үз арабызда милләтебезне мишәр дип тә атый идек, ләкин күп очракта «татар» этнонимын кулландык. Эстониядә «төрек татары» дип тә әйтә идек, чөнки шул этнонимны эстон газеталары кулланды. Соңгы рәсми эстон документларында безне төрек дип язган иделәр. Әмма дә ләкин мин үземнең төрек түгеллегемне аңлыйм—төрекләр белән татарлар арасындагы төрле аермаларны бик яхшы беләм.

С. (1913 елгы хатын): Мин үзем Эстониядә, Нарвада тудым. Әтием Кавказда туган татар вә әнием Питерда туган мишәр иде. Алар Сергачтагы Суксу авылында өйләнгәннәр. Без 1915 тә Раквересә күчкәнбез. Ул Таллинн белән Нарва арасындагы бер урын. Анда ул чакта өч татар гаиләсе булган һәм алар Сергач якларындагы Суксу, Куйсу, Янгапар кебек мишәр авылларыннан булганнар. Мин алты еллык урыс-эстон мәктәбен бетердем. 1920 дә Нарвага күчкәндә анда чама белән 15 татар гаиләсе бар иде. Үзем уналты-унҗиде яшьтә булганда өч ел буе җәен Берлиннан Галимҗан Идрис исемле мөселман кешесе Нарвага килеп андагы татар балаларын укытты. Татарлар җәен арендага алган рус мәктәбендә Галимҗан әфәнде ислам дине вә татар теле дәресләрен бирде. Анда җыр һәм театр-спектакльләр дә куелды. Әти сәүдәгәр—Нарвадагы базарда, аның кул астында 14 мишәр сатучы булып эшли иде. Әтинең ул базарда җиде сату чатыры бар иде. Анда материя, көзге, башмак баулары, чәч ташлары һ. б. сатылды. Башта татарлар дини бәйрәмнәрне бер-берләренең өйләрендә уздырдылар. Мулла ул өйләргә үзе килә иде. 1920 елларның уртасында Нарва мишәрләре сатып алып, бер бинада мәчет кордылар. Мин Эстониядә яшәгән чорда анда чама белән 300 кеше йөрде. Күпчелеге Нарвада яшәүчеләр.




Швеция татарларының төрки—ислам оешмасы мөһере. 1940 ел.

Ирем 1911 елда Таллиннда туган. Аның әти-әнисе дә Сергачныкы иделәр—Куйсу авылында өйләнгәннәр. Иремнең Таллиннда үз кибете бар иде. 1942 дә (Кызыл Урда 1940 елларның май аенда Эстонияне басып алгач) эстон коммунистлары килеп иремне һәм кайнатамны кибетләреннән куып, андагы мал-мөлкәтне юк иттеләр.

Тормыш шактый катлаулана бару сәбәпле, без 1943 тә балыкчылар ярдәме белән көймәләрдә Финляндиягә качтык. Көймәдә барлыгы алты татар идек. Бүтән качкыннар—эстоннар. Финляндиядә туган һәм танышларыбыз булганга без лагерьларга эләкмәдек. Безгә татарлар янына барып урнашырга рөхсәт бирелде. 1944 тә Финляндиядәге вәзгыятебез катлауланды. Янә биредән качарга карар кылдык. Бер балыкчы белән килештек һәм, акчабыз булмаганга ул бездән материя һ. б. әйбер алып, швед ягына илтергә риза булды. Ике чемоданыбыз бар иде—берсе балыкчыга калды. Шул рәвештә без 1944 тә шведлар иленә килдек. Өч ай качкыннар лагеренда яшәдек. Аннан соң ирем биредә тун тегүче булып эшләде. Үземә фабрикта да, хастаханәдә дә эшләргә туры килде.

Д. (1920 елгы хатын): Финляндиядә Латыш шәһәрендә тудым. Әти-әниләрем Сергач мишәрләре. Биш-алты яшемнән башлап Теряуки (Рәсәйдәге бүгенге Зеленогорск)

*каласында үстем. Әти беренче дөнья сугышына хәтле үк Финляндиягә килгән. Авылда дәү әтинең өе булган һәм анда авыл хуҗалыгы вә мал асрау белән маташкан булганнар. Әти Рәсәйдә чакта сәүдәгәр гыйлемен өйрәнә башлаган, ләкин йөрегән вә дәлилләнмәгән бер сүз буенча, Рус армиясенә эләкмәс өчен Фин иленә качкан. Анда сәүдә белән шөгыльләнгән. Финляндиягә күчкәч, вә бигрәк тә сугыштан соң, андагы татарларның тормышлары яхшыра башлады. Ике татар кибет ачты. Абыем кием кибете һәм бер яшьтәшем материя кибете тотты. 1948 дә гаиләм белән Швециягә күчтек, чөнки Сталин Финляндияне бик каты шартлар белән бәйләгән иде һәм Совет системасының Финляндиягә дә урнашуыннан, димәк, кызыллардан курка идек. Без шведлар иленә килгәндә монда 7-8 татар гаиләсе һәм Союздан чыккан тагын берничә мөселман гаиләсе бар иде. Зур өлешебез Стокгольмның үзәгендә торганга еш аралаша идек. Швециядә үземне ара-тирә Финляндия төреге дип таныйтам. Еш кына болай дигәнем бар: «Мин Финляндиядән. Анда төрекләр бар һәм алар чыгышлары белән Рәсәйдән. Аларның милләтләре татар». Швециягә килгәнче өйдә татарча гына сөйләшә идек. Балаларым финча да өйрәнделәр һәм фин дуслары белән финча сөйләшә иделәр. Швециядә нигәдер балаларым белән һаман шведча сөйләшәм. Билгеле, алар татарча да яхшы аңлыйлар.*

*Е. (1915 елгы ир-ат): Мин Татарстанда, Казаннан ерак булмаган Биектау районында тудым. Авылымда татар мәктәбенә йөрдем. Анда бөтен дәресләр татарча һәм атнага ике сәгать дәресләр русча бирелә иде. Аннары бер ел Казанда укыдым. Өйдә татарча сөйләшә идек, ләкин русча сөйләшү дә тыелмаган иде, чөнки тирәбездә гел татарлар булганга татарчабызның онытылу куркынычы юк иде. Миңа егерме алты яшь булганда, алманнар Смоленскка житкән чакта Белоруссия фронтына юлландым. Фронтта ике ай сугышкач әсир булып калдым һәм Борисоводагы бер алман әсирләр лагерена эләктем. Андагы вәзгыять ачлык хөкем иткәнгә бик начар иде. Әсирлектә мине лагерьдан лагерьга илттеләр. Берара юк булмас өчен ат карарга туры килде. Кухняда да эшләдем һәм анда миңа, ичмасам, ипи эләгә иде. Аны һәм миңа бирелгән тәмәкеләрне саклап йөрдем. Боларга мин яңа кием белән итек алыштырдым һәм шул рәвештә үземне офицер дәрәҗәле хәрби сыйфатында күрсәтергә мөмкин булды. Шул сәбәпле мине офицерлар лагерена күчерделәр һәм соңрак тагын Минсктагы бер лагерьга эләктем. Аннары кабат берничә тапкыр төрле лагерьларга күчерелдем. 1945 тә алманнар җиңелгәч, Кызыл Урда белән элемтә алып аларның солдаты булганымны игълан иттем, армия белән берләшергә теләгәнемне әйттем. Шул чагында бер рус офицеры мине кисәтте: «Син бик ялгыш адым ясыйсың, сиңа инде бүтән союзга кайтырга ярамый,»—диде. Ул рус кешесенә бик рәхмәтлемен. Ул мине Себергә җибәрелүдән, шәфкатьсез сөргеннән, хәтта атып үтерелүдән коткарды. Мин исемемне алыштырдым һәм поляк сыйфатына кердем. Миңа Варшава татарлары булыштылар. 1946 белән 1952 еллар арасында Польша пароходларында эшләдем. Эшем аркылы Швециягә барып чыгарга туры килде. Шушы илдәге татарлар белән элемтә алдым. Бераз вакыт үткәчтен бер төрек кызына өйләндем һәм аңардан ике угълым булды.*

Югарыда биш Швеция татарының тәкъдирләренең кайбер өлешен күреп үттек. Әлбәттә, шушы әңгәмәләргә таянып Швеция татарларының тормышын бераз күзалларга була. Шулай да статистикага күз салыйк әле. 1980 елларның урталарында гайре рәсми бер санау буенча Швециядә чама белән 50 төгәл татар (атасы да анасы да татар булган шәхесләр) бар иде. Ярты татарларны (катнаш өйләнүләр аркылы йә дә анасы гына татар булган кешеләр) өстәгәндә сан чама белән 80 гә житә. Димәк, татарлар бу илдә бик аз. Башта әйтелгәнчә, интернет системасындагы сан шулдыр. Татарларның саны күбрәк тә булгандыр бәлки—анысы бик мөмкин, чөнки санаучының белмәгән кешеләре дә булгандыр, әмма дә ләкин сүз гел борынгы татарлар категориясеннән генә барганда 80 шәхес чынбарлыкка бик якын булырга тиеш. Бу кешеләрнең бүген әлбәттә бер өлеше арадан китте инде. Мисал булып әңгәмәләр биргән ике кешене күрсәтеп була. Алар вафат булды. Баягы категориядән тыш тагын ике төркемнән күрсәтергә мөмкин. Алар бик борынгы татарлар һәм яңа татарлар.

Борынгы татарлар арасына нәкъ менә әңгәмәләр биргән кешеләр һәм алар кебек икенче дөнья сугышында һәм тиз ара сугыштан соң Финляндиядән, Эстониядән, моннан тыш бүтән илдән Швециягә килгән кешеләр керә.

Яңа татарлар төркеменә соңгы елларда Советлар Союзыннан һәм соңрак

Рәсәйдән килгән кешеләр керә. Алар күбесенчә, йә шведка, йә дә Швециядә яши торган мөселманнарга кияүгә чыккан хатын-кызлар. Әлеге көндә иллә мәгълүм булган яңа татар 7-8 тирәләп кеше. Берничәсе Сергач якларыннан булган мишәрләр. Берикесенең тамырлары Татарстаннан вә чыгышы белән әнисе татар, әтисе башкорт булган бер шәхес тә мәгълүм. Швециянең 9 миллион халкы арасында бу төркемгә кергән, ләкин әле дә беленмәгән кешеләрнең булуы да ихтимал.

Борынгы татарлар күбесе Эстониядән һәм Финляндиядән килгәннәр. Якынча һәммәсе үзләренең әти-әниләренең һәм баба-әбиләренең чыгышлары белән Рәсәйдәге борынгы Нижний Новгород губернасы, Сергач районындагы авыллардан.



*Стокгольмда концертлар бинасы. 50 нче елларда татарларның гает намазлары һәм чәй кичәләре шушында уза.*

Иң элек татарларның күпчелеге Стокгольмда һәм башкала тирәсендә тора иделәр. Шул сәбәпле бик нык аралашып яшәделәр. Бер-беренә кунакка йөреп һәм бигрәк тә дини бәйрәмнәрдә берләшеп күрешә иделәр. Татарларны берләштерүче оешма һәм чын мәчет булмаганга, шәһәрдәге төрле биналарда арендага заллар алып гает намазларын шунда укый иделәр. 1948 дән башлап 15 ел Осман Соуккан исемле кеше мулла вазифасын алып барды. 1940 елларның азагында татарлар бик нык берләшеп дәртләнде вә 1949 да иске илләре Финляндия һәм Эстониядәге эшчәнлектән үрнәк алып бер оешма корырга ният кылдылар. Бер-берләрен яхшы таный иделәр, халыкның дини һәм иҗтимагый хаҗәте арта бара иде һәм арада оешма эшләре белән таныш һәм тәҗрибәле кешеләр дә бар иде. Корылган оешманың рәсми исемен "Дини-мәдәни төрек-ислам оешмасы» дип куйдылар. Шушы исемне оешманың тамгасында һәм рәсми кәгазьләрендә дә табып була. Төрек сүзен кертүнең сәбәбе—арада бер-ике төрек булуы (мисалга мулла үзе). Иң эшчәннәре арасында бер казакъ, бер лезгин һәм бер төрек булган булса да, ун оештыручының арасында җиде татар бар иде. Шушы оешма төрле вазифаларны өстенә алды, мәсәлән, гает намазлары һәм чәй кичәләре тәртипләү, ул очраклар өчен бүлмәләр, заллар табып алу, чакырулар язып җибәрү һ. б. Чәй кичәләре, кызганычка каршы, бик озын аралар белән тәртипләнде. Баштагы елларда ул кичәләргә берничә кешедән тыш гел татарлар килә иде. Соңыннан төрле милләт вәкилләре дә чакырыла башлады. 1940 елларның азагыннан хәзерге көннәргә кадәр бер биш еллап кала, димәк 45 ел эчендә чама белән алты чәй кичәсе искә төшә. Йөзләп кеше чакырылса, шуның утызлабы Финляндия кунаклары иде. Татарларның күп булмавының бер сәбәбе—байтак татарның яннарында чит милләттән булган хәләл җефетләренең вә бүтән кунакларның килүләре.

Оешма баштан ук Стокгольмда бер зур каберстанда мөселман зираты өчен

урын да алып куйган иде. Рәис вазифасы үзәк түгәрәктәге ир-атлар арасында әйләнеп йөрде. Табигый сәбәпләрдән рәислек күп вакыт татар кулында булса да, бүтән милләт кешесенә дә бирелә иде. Бер чор дәвамында Осман Соуккан мулла вазифасы белән берлектә рәис вазифасын да өстенә алган иде. Берара лезгин да рәис булып торды. Җитәкчеләр һәм ин эшчәннәре арасында бик мөһим роль уйнаган кеше эстон татары Али Закиров абый иде. Швециядәге бөтен гомере буе татарларның дини һәм иҗтимагый кирәкләре өчен көрәште ул. Рәислекне дә ничә чор буе алып барды. Оешма, әлбәттә, бер-ике кешедән генә тора алмый. Арада исемнәре санап әйтелмәгән, тырышып эшләгән бүтән татар кешеләре дә бар иде. 1950 елларда Швециядә мөселман илләреннән килгән кешеләр күбәя башлады. Болар—гарәпләр һәм төрекләр. Оешмага әгъзалыкка аларны да ала башладылар һәм оешманың исеме дә «Ислам җәмгыяте» булып алмашынды. Шуның белән оешманың татар сыйфаты да әкрен генә юк була башлады. 1960 елларда, төрекләр зур күләмдә илгә килә башлагач, оешма милли татар сыйфатыннан чыгып халыкара оешмага әйләнеп китте. Татарлар бүтәннәргә караганда аз булганга башка милләт вәкилләре дә оешманы җитәкли башлады.

Үзара гаилә аралашуыннан тыш бүгенге татарлар мәет җирләгәндә һәм ара-тирә мәүлет кебек дини бәйрәмнәрдә очраша. Финляндия татарлары белән элемтәләр нык, ләкин әлбәттә гайре рәсми рәвештә берәүләр һәм гаиләләр арасында гына. Берберләренә шалтыраталар һәм туган вә дусларны карар өчен ара-тирә Финляндиягә юлга да чыгалар. Аннан да кешеләр шул ук рәвештә килгәли. Эстония яна гына суверен ил булгач андагы туган-тумачалар белән дә аралашу җинеләеп китте. Мәсәлән, Стокгольмнан су юлы йә дә очкыч белән Таллиннга сәяхәт итү Хельсинки юлы сыман бөтенләй проблемасыз.

Швециядә Эстония һәм Финляндиядәге шикелле балаларга милли курслар тәртипләнмәде. Бер ара Осман Соуккан берничә татар баласын үз өендә укыткан иде. Соңрак швед татарларының берничәсе балаларын Финляндиядә ел саен тәртипләнгән җәйге курсларга җибәреп тордылар.

Беренче буынның бер өлеше большевиклар режимыннан качып киткән кешеләр булганга күрә, баштарак алар катлаулырак шартларда яшәделәр. Өч-дүрт кеше мех һәм тун эшләрендә урын табып шөгыльләнде. Аларның икесе бер вакытлар үткәч Стокгольмда кибетләр дә ача алдылар. Бүтәннәре (качкыннар гына түгел) шведлар сыман төрле эшләргә керделәр.

Икенче буын арасында берничәсе генә тире һәм тун эшләре белән маташты. Бу буын вәкилләренең байтак өлеше югары уку йортларында һәм университетларда укып чыктылар. Укулары һәм кәсепләре буенча баш мөһәндис (инженер), журналист, юрист, педагог, балалар бакчасы укытучысы һ. б. булганнары да бар. Болар гомумән дәүләт хезмәткәрләре булып эшлиләр. Үз эшен фирма итеп оештырып алып баручылар да бар, ләкин алар сирәгрәк.

Беренче буындагы өлкәнрәкләр арасында ук чит милләт кешесенә өйләнгәннәре бар. Кайберләренең хәләл җефетләре төрекләр. Икенче һәм өченче буын исә рәсми рәвештә өйләнеп теркәлмичә генә яшиләр, аларның балалары да бар. Ул гадәт швед илендә модага әйләнде, шведлар арасында ул инде әллә кайчаннан бирле барадыр. Соңгы кырык ел эчендә Швеция татарлары тарафыннан корылган ун-унбер гаиләне дә шундыйлар исәбенә кертеп була. Мондый гаиләләр кору татарлар арасында да таралды. Шушы ике төрле гаилә сыйфатларын күз алдына алсак, чиста татар гаиләләренә бер-ике мисал гына табыла. Байтагы швед һәм финнар белән тора. Бер өлеше мөселманнар белән, мәсәлән, төрекләр белән яши.

Югарыда әйтелгәннәрдән Швециядәге татарларның киләчәге бик үк якты булмавы аңлашыла булса кирәк. Табигый артым булмаганга күрә алар бетүгә йөз тота. Кызганычка каршы, алар Финляндия татарларына караганда ассимиляциягә тизрәк бирешәләр. Һәм аның шулай дәвам итәчәге ачык күренә.

*

## *Мостай Кәримгә 80 яшь*

# ПРОМЕТЕЙ УТЫҢ СҮНМӘСЕН!

*Вак мәшәкать, ыгы-зыгы тәмам,*
*Бар эшемнең чыктым очына.*
*Шуңа күрә бүген таңнан алып*
*Күкрәгемнән кошлар очырам.*

Мостай Кәрим.

Мостай Кәрим дигән исемне хәреф танып, укый-яза башлаган еллардан бирле беләм шикелле. Дөрес, әле ул вакытта миңа Мостай Кәрим, Фатих Кәрим дә, Хөсни Кәрим, Ярлы Кәрим дә, Марат Кәрим дә әлләни аерылмый, миңа исемнәр берни аңлатмый әле. Китаплары гына кызык булсын! Шул сабый малай дәвереннән, ярты гасыр дәвамында ничә дистә мең китап укылмаган да, ничә мең автор исеменә юлыгылмаган! Күпләре онытылган, кайберләре белән үз вакытында тәэсирләнеп, тәмам сихерләнеп, еллар үтү белән хәтер томаннары артында югалган, әмма аерым берәүләре торган саен күңелдә ныграк тамырланган. Мостай Кәрим әнә шул соңгыларының берсе булып чыкты. Ялгышмаганмын—чорыбызның бөек әдипләренең берсе икән ул!



60 елларда, әдәбиятта мәңгелек шигырьләр язып калдырырбыз дип ихлас ышанган без—яшь максималистларга—Мостай Кәрим исеме үзенә магнит сыман тартып торган шөһрәтле исем иде. Кара, үзебезчә, без аңлый торган телдә яза торган шагыйрь бөтенсоюз, бөтендөнья мәйданында бил алыша! Әнә—Балтыйк якларыннан Ленин премиясе алган Э. Межелайтис килеп чыкты. Кавказдан—Р. Гамзатов, К. Кулиев... Ерак Кыргызстанда туып-үскән Ч. Айтматовның исеме телләрдән төшми. Казакълардан—яшь, темпераментлы О. Сөләйманов калкып килә... Идел буеннан, без татарлардан, нишләп андый гайрәтле әдипләр күренми? Уйландыра иде, бик уйландыра иде бу хәл. Дөрес, татар әдәбиятында да теге яки бу ягы белән әлеге азаматларга тиң, хәтта иҗатларының кайбер сыйфатлары белән өстенрәк әдипләр дә бар барын... Әмма дөнья күләм иҗтимагый яңгырашлар алалмыйлар. Нидер җитми. Теге әдип белән бу әдипне бергә кушсаң, фәлән бөек килеп чыгар иде дә бит дигән уйлар да килгәли иде. Хәер, империя олимпларында утыручылар да татарны артык үстерергә ашкынып тормадылар шул. Бәхетебездән, рухи түбәбезне күтәреп әле дә ярый легендар Муса Җәлил кайта алды. Үлеме белән үлемсезлек яулап абруебызны күтәрде... Әмма шул чорда исәннәр арасында бүтән халыклар өчен республика, милләт символы булырлык әдипләр күтәрелеп үк җитә алмады... Шулай да, күрше тугандаш Башкортстан вәкиле булса да, Мостай Кәрим дигән олы исемнең яктысы безгә дә төште, үзебезне хаклы санап, аның белән без дә горурландык.

Башта әсәрләре күңелгә иңеп калган булса, соңрак—60 еллардан башлап—аның үзе белән дә шактый еш аралашып яшәргә насыйп булды. Кайбер язучы яки шагыйрьнең фәкать әсәрләрен генә белеп яшәү дә бик җиткән. Үзен, кеше буларак

кубрәк белгәч, кайчак әсәрләреннән алган татлы тоем тоныкланыбрак та кала. Талантлы кешенең холык-фигыле гел генә дә бал-шикәр түгел шул. Ә Мостай ага белән очрашып сөйләшүләр үзе бер гомер. Акыл иясе, олпат, алдан күрүчән зирәк, яшьли аксакал була алган талант... Озын гомер кичергән һәр кеше диярлек миллионлаган кешеләр белән очраша бу дөньяда. Һәркемнең күнелендә сокланулы тойгы калдырып яши алу—үзе бер талант. Исемнең бөек булып формалашуында зур фактор.

Мостай Кәрим Казанга еш килде, Татарстан җәмәгатьчелеге белән һәрчак дустанә мөнәсәбәттә булды. Зур тантаналар, Тукай, Җәлил кебек шәхесләргә багышланган юбилейларда еш катнашты, онытылмас чыгышлар ясады, мәкалә-хезмәтләр язды, бәйрәмнәребезне уртаклашты, табын күрке булды. Үзенең дә байтак китаплары Казанда басылып чыкты. Татар әдәбиятының бөек әдәбият икәнен яшьли үк танып, аның корифейлары белән горурланып яшәде һәм хәзер дә шул тойгылар белән яши дип беләм. Хәсән Туфанга багышланган берничә шигъри юлын гына искә төшерик.

Шагыйрьгә нигә чин кирәк,
Нәрсәгә Ана титул!
Патшалар ятлап алырлык
Шигырьләр яза бит ул!

Исемнәр димәктән, Мостай Кәрим совет чорындагы илкүләм дәрәҗәле бөтен исемнәрне яулап алган әдип. Ул инде 44 яшендә үк Башкортстанның халык шагыйре иде. Ул—СССР Дәүләт премиясе лауреаты, Станиславский исемендәге Дәүләт премиясе һәм Башкортстанның Салават Юлаев исемендәге премиясе РСФСР лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое, Ленин премиясе лауреаты... Хаклы алынган дәрәҗәле исемнәрме? Һичшиксез! Бүген кайбер яссу маңгайлылар уйлаганча, сәяси уеннар корып, номенклатура кануннарына ярашып кына андый үрләргә менеп булмый. Акча диганнәре бүгенгедәй тормыш доминанты түгел иде әле ул чакта. Кешене кешедән, талантны талантсыздан, шәхесне инфузориядән бик яхшы аералар иде.



*Сулдан уңга: А. Гыйләҗев, Ш. Мәхмүтов, Х. Туфан, А. Айвазов (Азербайҗан), М. Кәрим, Г. Ахунов, Х. Госман, М. Гайнуллин (Уфа). Казан дәүләт университетында очрашу. 1970 ел, 15 январь.*

Мостай Кәрим иҗаты—киләчәктә күп буыннар өйрәнерлек гаҗәп бай һәм күпкырлы иҗат. «Европа-Азия» шигырьләр циклы, «Кара сулар» поэмасы, күп санлы фәлсәфи-лирик шигырьләр аны чорыбызның олуг шагыйре дәрәҗәсенә күтәрсә, «Озын-озак балачак», «Ярлыкау», «Авылым адвокатлары» исемле чәчмә әсәрләре аны проза остасы итеп танытты. Ә «Ай тотылган төндә», «Айгөл иле», «Ташлама утны, Прометей!» кебек пьесалар авторын тамашачылар атаклы драматург итеп бәяләде. М. Кәримнең йөзләгән тәнкыйть, әдәби-публицистик язмаларын укыган кешеләр аны халкының хәким ельязмачысы итеп кабул итте. Төрле жанрларда үз биеклеген саклап, югары кимәлдә иҗат итүчеләр сирәк дөньяда.

Ни гаҗәп, олуг шәхесләр тирәсендә кирәкмәгән, ясалма низагъ тудыручылар, мәгънәсез сүз куертучылар да табыла. Кайчак әйткәлиләр: янәсе ул, теләгәндә, татар шагыйре булып китә ала иде! Мостай Кәрим—татармы, башкортмы, россиянмы? Бәлки, бөтенесеедер! Шунысы ачык: Мостай Кәрим—башкорт шагыйре, башкорт әдәбиятын үстергән, анын яңа бер этабын тудырган, яңа бер сәхифәсен ачкан әдип. Кардәш, тугандаш халыкның бөек әдибе булу без татарларга куаныч, шатлык түгелмени? Әлбәттә, куаныч, әлбәттә, шатлык. Шуңа күрә, Мостай ага ул безнеке дә! Гомумкешелекнеке дә. Ә менә соңгысына үзеңнән өлеш кертә алу—анысы инде ходайның сирәк затлары вазифасы, бөекләр миссиясе.

...Моннан нәкъ утыз ел элек бөтен Башкортстан, ул вакытта ук республика горурлыгына әйләнгән Мостай Кәримнең 50 еллык юбилеен зур тантана, зур бәйрәм итеп үткәргән иде. СССР дигән илнең иң зур язучылары җыелган иде бу юбилейга. Татарстан делегациясе составында Х. Туфан, Г. Ахуновлар белән берлектә миңа да катнашырга туры килде анда. Ул көннәрдә Уфа күпмиллэтле совет әдәбиятының Мәккәсе иде шикелле. Кемнәр генә юк иде анда! Р. Гамзатов, Ч. Айтматов, Д. Кугелтинов, К. Кулиев, Х. Туфан, М. Дудин, Я. Ухсай... Фәкать зур шәхес кенә үз янына үзенә тиң йолдызларны җыя ала. Белмим, астрономнар бирәр яңа ачылган йолдызга Мостай Кәрим исемен кушарлармы, юкмы, әмма шунысы анык: күп миллионлаган укучыларның күңелендә ул иңдергән нур елдан ел яктырак яна.

Мостай агага бу айда сиксән яшь тула икән. Дөресен генә әйткәндә, бу юбилей мине бераз сискәндереп җибәрде, көтелмәгән хәл кебек тоелды. Без аны өлкән яшьтә итеп күрергә гадәтләнмәгән шул. Ул, безнең өчен һәрвакыт сәламәт рухлы таза ир-егет. Шулай да... 1942 елны сугышта йөрәгенә пуля ярчыгы килеп кадалгач, ул сиксән яшьләргә җитәрмен дип уйлады микән? Ходайга рәхмәт. Бу юлларны язганда Сара апа Садыйкованың Мостай ага сүзләренә язылган «Өченче көн тоташ кар ява» җыры яңгырап куйгандай булды.

1970 елда язган бер шигырем искә төште. Ул атап Мостай агага махсус багышланмаса да, бу очракта хәзерге уйларыма тәңгәл килә.

Яу-дауларны күргәннәр күп.
Көрәш-шауда җингәннәр күп.
Вакыт-яу—ин-иң яманы!
Җиңүчеләр сирәк аны!

Вакыт белән хезмәте тау
ирләр генә алыша ала.
Заман, иелеп, җиңүченең
шанлы исемен алып кала.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**
*Татарстанның халык шагыйре.*
*19 сентябрь 1999 ел.*

❀

*Сәнгать*

# КОДРӘТ ИЯСЕ

## РӘССАМ ИЛДАР ЗАРИПОВКА 60 ЯШЬ

Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Россия Федерациясенең халык рәссамы Илдар Зарипов Казан каласының Ягодный дип йөртелгән бистәсендә үз өйләрендә көн күрүче Касыйм абзый белән Мәймүнә апа гаиләсендә 1939 елның 15 ноябрендә дөньяга килә. Буяу карандашын иң әүвәл 4-5 яшендә күрә: Мәхмүт абыйсы бер тартма «Спартак» дигән буяу карандашы алып кайта да шундук самолетлар, танклар ясарга, аларны төрле төсләргә буярга тотына—сугыш заманы бит, сугыш!.. Илдар абыйсының шулай оста рәсем ясаганын, кара танклар өстенә зәңгәр самолеттан кызыл бомбалар коелганын биһуш булып күзәтә, карандашларны берәм-берәм кулына ала, иснәп карый. (Сәнгатькәр әле дә шул исне хәтерләвен тәкрарлый.) Анысы шулайдырмы, юктырмы,—һәрхәлдә, абыйсы алып кайткан «тәмле исле» карандашлар Илдарда рәсем ясау дәртен кузгата шул...

Бу һөнәргә ныклап торып ябышкач, 5 сыйныфта укып йөргәндә, Соцгородтагы Пионерлар сараенда сәнгать түгәрәге эшләгәнен ишетә. Ике уйлап тормый малай—шунда йөри башлый. Петр Дмитриевич Кудрявцев—аның беренче һөнәри укытучысы. Шул төбәктә яшәп тә атна буена берни ясамыйча, буш кул белән килгән малайларга үпкәләп, түгәрәк житәкчесе Илдарга елмая:

—Килеп життеңме, академик? Йә, күрсәт әле эшләренне!..—ди.

Илдарның папкасы беркайчан да буш булмый. Ул үзенең яңа эшләрен олуг бер тантана белән идәнгә җәеп сала, остазыннан хуплау сүзләре ишеткәч, тагын да ныграк дәртләнеп эшли.

Гомумән, киндернең тәэссорат көче нидә соң? Рәссамның да, синең кебек үк, табигатькә гашыйк булуында, мөкиббән китүендә; гади генә бер күренешне дә, хыялы белән баетып, сиңа илаһи бер дөнья итеп тасвирлап бирү осталыгында; сине үзенең таланты-кодрәте белән сихерләвендә.

Гаҗәеп хәл инде: математика галиме саннарны, формулаларны исендә тоткан шикелле, рәссам да әллә күпме сюжетны, күренешне хәтерендә саклый. Дөресрәге, ул теләсә кайчан үзенә кирәкле хәлне, күренешне җиңел генә күз алдына китерә һәм шуны тасвирлап бирә алыр иде сыман. Әмма Илдар аны тулаем әзер килеш, үзе уйлап чыгарган яки хәтер сандыгыннан актарып алган һәм күз алдына аермачык китергән хәлендә язып куюдан ерак тора. Эшли башлау белән, элек уйланган сюжетына үзгәрешләр кертә, язу ысулын да хәйран нык үзгәртә. Яңа теманы язарга керешкән чагында туры килеп, сораштыра калсаң, гаптәшемне рәнҗетмәгәем дип шөбһәләнгән сыман, каты бәрелмәскә тырышып кына:

—Үзем дә белмим бит әле нәрсә килеп чыгарын,—ди һәм,—син керешәсең бер теманы язарга, бер күренешне сурәтләп бирергә—килеп чыга бөтенләй икенче нәрсә,—дип төшендереп бирергә ашыга. Кыл-каләменең сабы белән көмеш йөгергән башын кашыгандай иттерә дә рәхәтләнеп көлеп җибәрә.—Кайчагында берни килеп чыкмый! Андый хәлләр дә булгалый шул...

Автор яңа картинасының ни рәвешле очланасын алдан ук әйтә алмый, үз-үзенә мөкиббән китү, масаю аның табигатенә һич тә хас нәрсә түгел. Нинди сәләтле һәм әзерлекле була торып та ул еш кына «бураэнага төшә алмыйча»—төсләрнең нәкъ бу урында кирәклеләрен таба алмыйча иза чигә. Ә инде төсләрне сиземли Зарипов, искиткеч шәп сиземли.

Гел мажорный гына булмый аның сәнгать түгәрәгенә йөрүләре. Гыйнвар суыгы. Соцгородтан кичләтеп кайтырга чыккач, трамвай ватыла. Җилгә каршы 3-4 чакрым җәяү кайтасы. Барыннан да элек ул борыны өшегәнне абайлый. Тотып карамакчы була—бармаклары да өшегән! Йөрәге «жуу» итә:

—Кисәләр икән бармакларны! Була алмыйм икән рәссам!..

Шунда да югалып калмый, уңга борылып, түбәнгә йөгерә малай—котылу юлын эзли. Бәләкәйрәк йортларның кайсында ут яна, кайсында юк. Уты булса да, малай-шалайга беркем төнлә ишек ачмаячак, усал этләрен ырылдатудан файда чыкмаячак. Әнә теге бaрактан да кулае булмас. Озын гына коридорда житү кызларны күргәч, Илдар:

—Апа! Кулларым өшеде! Бармакларым кыймылдамый!—дип ачыргаланып кычкырып җибәрә.

Кай арада бүлмәләрдән кызлар атылышып чыгалар, аны якындагы бер бүлмәгә алып керәләр. Авылдан төзелешкә килгән унган кызларның кайсы бүреген, телогрейкасын, ботинкасын салдыра, кайсы ул арада каз мае алып килә, өшегән борынын, кул-аяк бармакларын уарга тотына. Малайның бар кайгысы—кул: шунсыз рәсем ясый алмыйсың.

—Апа дим, кулны кисмиләрме соң минем? Бармакларым кыймылдамый бит инде! Үлде бармаклар, бетте бу яраткан һөнәр! Әни әйткән иде, йөрмә дип, көн бик зәһәр дип. Сүзен тыңламадым шул...

—Юк, энем, без хәзер синең бу матур бармакларыңны сихәтлибез, гармун уйнарлык булыр.


—Син аңа, кызлар кочарлык булыр, диген, ахирәт.

Малайның үз кайгысы кайгы:

—Гармунның да кирәкми, кызларың да! Миңа карандаш тотарга кирәк, кыл-каләм тотарга! Художник булам мин! Бармакларым кый-мыл-да-мый-ла...

—Елама гына, энем, каз мае өшегәнне кайтармый калмас, иншалла. Менә чәнти бармагына жан керде шикелле...

Әнә шул үзәкләренә үткән зәмһәрир суыктан соң рәссам кышкы суыкны тасвирлаган һәр әсәренә жан жылысын өстәргә дә жаен таба—йә өйдәге жылыны, йә эссе мунчаны күрсәтә.



*Ир канаты— ат булыр. 1976 ел.*

Ине-буе бер чамадарак картина, әллә ни зур түгел, метр ярым чамасы гына. Игътибар үзәгендә тәрәзә. Тәрәзәнең тирә-ягын астан да, өстән дә, шулай ук уңнан да, сулдан да кар баскан да бәс сарган. Бүрәнә араларына, тәрәзә рамына мул булып яткан кар табигатьтә суык кыш хөкем сөргәнен сиздереп тора. Шунда үсеп утырган ак каен ботаклары тәрәзәне каплый яза һәм үзенә күрә бер гармония китереп чыгара. Һәй, бүрәнәләрдә дә, каенда да түгел, тышкы суыкларга контраст сыйфатында тасвирланган эчке бер халәттә икән ләбаса хикмәт!

Синең соклануыңны, таң калып каравыңны мәгъкуль күреп, автор үзе елмая, кулын болгый-болгый, хыяллары белән уртаклаша:

—Бу—авылның чите бит. Шүрәлеләр килә төнлә белән. Монда нинди чибәркәй мунча кирә икән, дип, куакларны аралап, агачның ботакларын аергалап, мунчага якын ук килә дә тәрәзәнең түңын өреп үзенә бер күз ясый. Кызык бит, әй!—дип, әкиятчедәй онытылып сөйли дә сөйли.

Авторның шулай рухланып сөйләве, әлбәттә, сиңа да тәэсир итә. Үзең дә сизмәстән, син дә сихерләнәсең, әкият дөньясына кереп китәсең. Төш күргәндәй, теленә салынып:

—Кайсы яктан соң сез, шүрәлеләр? Арча ягыннанмы, Дөбъязлармы?—дип сораган буласың.

Автор югалып калмый, көлә генә:

—Юк, без Киек ягыннан, диләр сиңа шүрәлеләр.—Синең аптырашта калуыңны шәйләп, тизрәк төшендерү чарасына керешә:—Иләт елгасының теге ягы, Татарстанның чиге инде ул авыл. Анысы аның әти авылы, Мари ягы. Аннан китә инде тайга урманнары... Аю-бүре әле дә бар анда. Теге, мәче төсле кыргый җанвар да бар, ничек диләр әле, рысьмы?

—Безнең авылда селәүсен диләр бугай.

—Әнә шулар да бар. Куе урман. Тайга...—Нәкышь остасы бераз уйга калып, әзер көе яткан кыл-каләмен кулына ала да ап-ак мунча бүрәнәсенә кыйгачлап кара сызык сызып куя. Аннары, кыл-каләмле уң кулын дирижер сыман югары күтәргән килеш, читкәрәк чабып китә дә, әле генә сызган сызыгына, ничек төште икән бу, дип озаклап карап тора, төпченә.—Анда саллы итеп салалар өйне, калын бүрәнәдән. Менә бола-а-ай анда бүрәнәләр, тигез, калын үзләре. Тайга бит. Урман...

Автор үзе шулай кулларын дирижердай болгаганда, гүя, тирә-якка моң чәчелә—кышкы суык чынлап ала да, бөтерелеп, читкә авыша; аның урынына җанга ятышлы бөтенләй икенче көй агыла башлый. Монысы мунчаның ныгытып ягылганын, суының кайнар, парының эссе икәнлеген сөйли. Бигрәк тә инде себерке белән чабынып утыручы асыл затның матурлыгын-сылулыгын мактый, аның чибәрлегенә мәдхия җырлый. Автор гаҗәеп куе итеп җылы төсләрне юкка гына салмаган шул: сары, көрән, кызгылт төсләр берсе белән берсе аралашып хәрәкәт,—юк, алай гына түгел,—күркәм хисләр, якты өметләр китереп чыгара. Моңа карап һич тә син битараф кала алмыйсың. Матурлыкта икән дөреслек, дөреслектә икән матурлык, дип уйлап куясың.

Хыялга бирелүеңне автор шундук шәйләп ала. Янына килеп баса да, хәйран дәртләнеп:

—Җылы гына нәрсә килеп чыга бит. Кызык бит! Бер чәчәк шикелле утыра бу чибәркәй. Нинди нәфис үзенең тәннәре...—дип куя.

Син дә аның сүзен җүпләп:

—Тән симфониясе инде, һич тә бүтән нәрсә түгел,—дисең.

Авторның:

—Чибәр дә инде бездә, безнең авылда, безнең якта хатын-кызлар! Бүтән бер җирдә юк андый матурлар да нәфисләр,—дигән сүзләре аның дөнья күргән егет икәнлеген, гүзәллеккә соклана белгәнен, кеше танышының исбатлый. Әмма үзенең һич кенә дә әкият дөньясыннан аерылырга исәбе юк икән әле:—Шүрәлеләр чынлап та карыйлардыр инде төнлә белән тәрәзәдән. Урманда салкын, ә монда мунчадан эссе бәреп тора. Әчтә җылы шундый!.. Өстәвенә бер асыл зат хушланып утыра, сихәтләнеп. Кызыга шүрәлеләр. Кызыкмый хәле юк, шул тикле нәфис тәнне күргәч. Үзең дә кызыгырсың, әй!—дип, яңгыратып көлеп җибәрә.

Ул арада очып кына картинасы янына бара да янә бер сизелер-сизелмәслек кенә сызык сызып куя. Аннары сиңа сер итеп кенә әйткәндәй:

—Бик свежи әле бу. Мичтән генә чыккан ипи шикелле. Берәүнең дә күргәне юк әле. Син беренче күрәсең,—дип куя.

Олуг талант иясе табигатьнең үзендә әллә кайларга чәчелгән дә сибелгән гүзәллекне рәссам күзе белән күреп-абайлап, аны берәмтекләп җыеп, һәммәкиен бергә туплап, шуңа үзенең йөрәк җылысын да кушып, хыялы белән баетып, нәкъ менә киндергә табигый булып ятардай төсләрне-бизәкләрне сайлап, дәртләнеп-уҗәтләнеп яңа әсәр язарга керешә. Андый чакта сәнгатькәр

бөтен дөньясын оныта, игътибар үзәгендә фәкать күз алдында гәүдәләнгән табигать күренеше генә торып кала—әнә шул рәвешчә киндердә сәнгатьчә дөреслек гәүдәләнә. Әлеге күренеш табигатьнең үзендә без күргән кыяфәтен һич тә үзгәрешсез кабатламый, сине уйландыра, сокландыра һәм, иң мөһиме, ышандыра. Табигатьнең матурлыгын син үз күзең белән элегрәк күргәндәгечә итеп түгел, бәлки, нәкъ менә сәнгать әсәрендәгечә күнеләнә сендерәсең, тулаем кабул итәсең.

Илдарның, үҗәтләнеп, художник булам мин, училищега укырга керәм, дигәне Ягодныйда Касыйм абзый үз кулы белән салган иркен агач өйдә яшәп ятучы ишле гаиләдә берәүне дә сөендерми. Гаилә башлыгы өстенә бу сүз олы афәт булып ишелеп төшә: җиде бала бит, җиде бала! Нибары олы малае Мәхмүт кенә кул арасына керә башлады; инде менә монысыннан йортка бераз файда тимәсме, берәр юньлерәк һөнәргә өйрәнеп, мал китерә башламасмы, дип өметләнеп кенә торганда—мә сиңа! Шулай да сер бирми йомшак күңелле ата:

—Улым, беләм мин художникларны. Тапталган ботинка аларның аягында, салам эшләпә башларында. Үзләре салмыш-силмеш, кесәләрендә бер тиен акча юк. Булса—йөгерәләр пивнушкага. Нәрсәгә хаҗәт сиңа ул тузга язмаган һөнәр?!—дип, тәртәгә тибеп маташкан малаен иплəп кенә туры юлга төшерү ягын карый.

Әмма 16-17 яшьлек үсмернең үз туксаны туксан:

—Художник булам дигәч, булам!

Арага әни кеше—Мәймүнә апа төшә:

—Улым, әтиең бит, юньсез кешеләргә юлыкмагаең, дип кенә хафалана. Синең укуыңа каршы килми бит ул. Укымышлы кеше булырга тырыш, улым. Хәлебез авыр булса да, укырга кирәк. Укырсың, улым, укырсың, Аллаһы боерса,—дип мәсьәләне үзенчә хәл итә дә куя.

Казан сәнгать училищесына Зарипов кыю барып керә. Беренче курсны Фешинның шәкертендә укып, искиткеч әйбәт бетерә. Әмма икенчедә ун яшькә генә үзеннән олырак булса да картларча катып беткән бер татар агаена туры килеп, аның «академическое требование»сенә җавап бирә алмый һәм... икенче елга кала. Ярый әле, аннары юньлерәк укытучыга—Ротницкийга эләгә. Семен Аронович аңлый аны, талантын ачып бирергә омтыла:

—Кыюрак яз! Яшермә сәләтеңне!—ди.

Казан сәнгать училищесын Илдар Зарипов гаять уңышлы тәмамлый, һәм аңа, диплом белән бергә, укуын дәвам итәргә сәләтле, дигән—югары уку йортына укырга керү өчен тәкъдим кәгазе дә бирәләр. Бу язу ярап куя да соң. В. Суриков исемендәге Мәскәү сәнгать институтына конкурс шаккатарлык зур була. Студентлар шәһәрчегендәге бинаның ул яшәячәк бүлмәсе шыгрым тулы икәнне күргәч, егетебез хәтта югалып кала. Нинди генә милләт халыклары юк анда?! Татар малае гына ялгызы. Тик инде беренче сынаудан соң ук халык саны кими, соңгы сынаудан соң Казан егете бүлмәдә берүзе торып кала. Шунда язган картинасы, бүтән өлгеләр белән бергә, ул укыган дәвердә методистлар бүлмәсендә эленеп тора: менә шулай язарга кирәк, янәсе. Автор үзе дә кереп-кереп караштыргалый.

Нәкышь һөнәрен яшь рәссамыбыз академик Д. К. Мочальский классында үзләштерә. Остазының акыллы киңәшләрен тота, гыйбрәтле мисалларына колак сала, һәр әсәргә иҗади килергә өйрәнә. Әмма... укулары хәйран матур барган бер заманда, өченче курста чакны Илдар өйләнеп җибәрә. Кәләшен Мәскәүгә китереп, бергә-бергә дөнья көтүне уйлыйсы да юк, атна саен кайтып йөрергә кала. Атна буе сагынып, ничек җитте алай акча юнәтеп, һич югы билетлык кына остазыннан әҗәткә алып, Светланасы янына ашыга Илдар.

Җәйге имтиханнардан котылгач, сабакташлары аны Казанга качудан тоткарламакчы булалар:

—Практикага бармасаң, крышка!—дип куркыталар: башың бетте, янәсе.

Акыл белән уйлап карасаң, шулай анысы. Тик менә дәртең ташып торганда, назлы ярың төшләреңә кергәндә, һәрвакыт акыл белән генә берни

майтарып булмыйдыр шул. Аннары бит әле китап яисә картина язган чагында гына дәртле булып кылана да алмыйсың—ул синең җаныңда-тәнеңдә, ул синең холкыңда-фигылеңдә.

Алып бара студент яңа уку елында бер өем эш. Йөрәге бер дә тыныч түгел: практикада булмадың, качып киттең, дисәләр? Институттан кусалар?! Тик Дмитрий Константинович акыл сатарга уйламый да, талантлы татар егетенең өр-яңа эшләрен игътибар белән күздән кичерә:

—Бусы бара. Бусы да ярый. Һай, бу этюдың әйбәт чыккан! Бусы да шәп эш! Боларын—хәзер үк метфондка!—дип, көткәннән артыграк бәя бирә.

Илдар укуын тәмамлаганда, СССР Сәнгать академиясе остаханәсен алып баручы мәшһүр сәнгатькәр Г. М. Корженевның өч студент кабул итәчәге мәгълүм була. Көч сынап карау нияте белән Зарипов та конкурста катнаша һәм җиңеп чыга. Әмма аңа тагын өч ел укырга, янә бер академиктан нәкышь серләрен өйрәнергә насыйп булмый: Илдар бик нык авырып китә. Язмыш аны үзебезнең иске мәркәзебезгә кайтарып куя.

Татар сынлы сәнгатенә Илдар Зарипов яшьлек дәрте, хыялга бай үз бизәкләре, үз стиле белән галәмәт кыю рәвештә, өермәдәй ябырылып килеп керә һәм нәкышь өлкәсендә яшәп килгән төшенчә-кысаларны киңәйтеп, сәнгатебезне баетып, җанландырып җибәрә.

Мәгәр аны Казанда әлләни сагынып көтмәгәннәр булып чыга. Тормышны матурлап-бизәп күрсәтү хөкем сөргән 1960-70 елларда аның иҗади эзләнүләре күпләргә көлке тоела. Түрәләр, ихтимал, яшь рәссамның никадәр талантлы икәнен күргәннәрдер, фәкать ана юл сапмаска маташканнардыр.

Әйтик, менә 1970 елда Мәскәүдә үтәчәк зур күргәзмәгә дәрәҗәле комиссия нәкышь әсәрләрен җыя-барлый. Зарипов китергән «Өйдә» киндерен бөтенләй сүтеп ташлыйлар:

—Монда бит композиция юк...

—Тормыш юк монда, безнең бүгенге чынбарлыгыбыз читтә калган...

—Анатомия генә дә юк бит әле, ичмасам, башкасын әйткән дә юк инде...

—Колак хатыны түгелме соң бу?! Карагыз әле, карагыз, недобитый колак хатыны!..—дип акыл саталар, якын да китермиләр.



*Чабаксарда узган «Зур Идел» күргәзмәсендә И. Зариповның «Батыр» картинасы янында. Уңнан сулга: И. Зарипов, Ә. Мәҗитов, Н. Егоров, Р. Ибраһимов. 1985 ел.*

«Өйдә» картинасы, чыннан да, артык гади шул. Гап-гади авыл өе: бүрәнә аралары күзгә бәрелеп тора; кисмәк белән су; шунда ук йорт хуҗасының эштән кайткач та салып ташлаган итекләре... Ян тәрәзәдән кышкы табигатьне һәм күрше өйнең тәрәзәсеннән кичке утны шәйләргә мөмкин. Ә өйдә—май җылысы: әлерәк кенә йөреп киткән ыштансыз малай әнисенә табан атлап бара. Ана үзе кара җәймәле караватка тыйнак кына утырган да сабыена ике кулын сузган: егылып китә күрмәгәе аның йөрәк парәсе! Фон тоташы белән җылы гаммада язылган: өйнең бүрәнәләре дә, ак рамлы тәрәзәгә эленгән челтәрле һәм бизәкле кашага да, ана артындагы келәм дә, күпертеп куйган түшәктәй мендәр дә, мич буена кибәргә эленгән тастымал да, мөлаем йөзле хатынның муенсасы белән күлмәгенең итәге дә, аяк астындагы паласка чаклы—һәммәсе шуңа тартым.

Яшь чакларында әбиләр һәм әниләрнең үз куллары белән суккан эскәтер һәм сөлгеләрдә кызыл җепнең өстенлек итүен искә төшерсәк, бу төснең милли төс икәнлеген дә инкяр итүче булмас иде. Мәгәр бу очракта сәнгатькәр, кызыл төсне шулай мул кулланганда, ихтимал, өй җылысын, җан җылысын аеруча көчәйтеп бирүне дә күздә тоткандыр сыман тоела. Нәтиҗәдә автор гаҗәеп бер гармония, сәнгати дөреслек китереп чыгара, авыл өендә, бала-чагалы, тату гаиләдә агылган милли моңны ишетү мөмкинлеген тудыра.

Гәрчә бу моңны ишеткән һәркем әсәрдәге җанлылыкка, гадилеккә хәйран калып тамаша кылса да, монда тасвирланган күренешкә тулаем ышанса да, күргәзмә комиссиясендә утыручы дәрәҗәле агайлар җете кызыл төсләргә күзләрен йомалар, милли моңны ишетмәс өчен колакларын томалыйлар.

Сынлы сәнгать өлкәсендә үз сүзен әйтергә атлыгып торган, көн-төн иҗат итәргә, хыялланырга, буяуның төсләрен бик белеп эш итәргә өйрәнгән, шуны үзенең яшәү максаты итеп күргән егетебез акны карадан аера белә, сайлап алынган-хупланган эшләрдән калышрак түгел икәнен күрә-абайлый.

Үҗәтлекнең файдасы тия бит, әй! Урманга сыяр, кырга сыймас дигәндәй зур күләмле (инә-буе икешәр метр!) картинаны автор үзе поезд белән Мәскәүгә алып бара. Андагы сәнгатькәрләр объектив бәя бирәләр: әсәрнең язылышын камил күрәләр, егетне гаҗәеп зур иҗади уңышы белән тәбриклиләр һәм, әлбәттә инде, күргәзмәгә кабул итәләр. 1971 елда Манежда үткән әлеге күргәзмәнең нәтиҗәсе тагын да гыйбрәтлерәк килеп чыга: сәнгать белгечләре 16 автономияле республикадан җыелган рәссамнар иҗат иткән йөзләрчә картина арасында фәкать Илдар Зарипов киндерендә татар халкына аеруча хас милли сыйфатларны шәйләп, җанлы нәкышь әсәрендә салмак кына агылган милли моңны ишетеп, күргәзмәдә бердәнбер киндерне илебез сәнгатенең алтын фондына лаек табалар һәм Ленинградның Рус музеена сатып алалар. Шулай итеп, әлеге дә баягы «кулак хатыны», гомумән, Татарстаннан беренче буларак, Нева буендагы калага пропискага керә һәм дивардан үзенә лаеклы, күнеленә хуш килгән урынны сайлап ала.

Аягы җиңел була бу татар хатынының: Илдар Зарипов иҗат иткән «Әхәт абый» картинасы да шул ук музейга алына; «Зөлфия», «Батыр», «Айсылу», «Тын табигать» һәм пейзажлар Мәскәүнең Третьяковлар галереясенә, шактый эше үзебезнең Татарстан сынлы сәнгать музеена, Ижевск, Киев, Петрозаводск, Красноярск һ. б. кайсыбер шәһәрләрдәге сәнгать музейларына кабул ителә. Моннан тыш әле тагын татар егетенең 50 ләп картинасы Германиядә, 40-50 се—Франциядә, 20 ләбе—Израильдә, 10-15 е—Англиядә, 10-15 е Америкада шәхси коллекцияләрне бизи.

Илдар Зарипов иҗатында хатын-кыз образлары иң үзәк урынны били дисәм, һич тә ялгышмамдыр. Чөнки җир йөзендә иң ямьле вә иң нурлы җан ияләре—асыл затлар. Фәкать ир-аттан гына торган җәмгыятьне яисә тәшкилатоешманы, гомумән, күз алдына да китерү мөмкин түгел. Хатын-кыз булмаган очракта алар фантазиясез-хыялсыз, дәртсез-дәрмансыз, бичара бер хәлгә төшеп, сүнәргә-сүрелергә тиеш, бетүгә дучар ителер иде. Бары тик хатын-кызлар гына җәмгыятькә, барча җиһанга даһиларны, шагыйрьләрне бүләк итә, дөньяны миһербанлы-шәфкатьле ирләр исәбенә баета. Шул ук вакытта

үзләренең чибәрлекләре һич кенә дә кимеми, алар әле торган саен сылурак та мөлаемрәк, гүзәлрәк тә шәфкатьлерәк була бара.

«Казан чибәре Зөлфия» дигән мәшһүр киндерен сәнгатькәр 1975 елда иҗат итә.

Зур сәнгать әсәрен һәркем бер үк төрле анламый. Һәркем аны үзенчәрәк кабул итә. Мина калса, Зөлфия инде житү кыз гына түгел, яраткан кешесенә кияүгә чыгып, анын белән чүкердәшеп, бер-берен сөеп, бәхет эчендә яшәүче асыл зат. Менә әле дә ул мәхәббәткә-назга бай кичен сөеклесенен кочагында уздырган, үзенең бөтен чибәрлеген, бөтен сылулыгын, бөтен яшәү дәртен кабат-кабат ана багышлаган. Чын бәхет бит үзенә тин яр табуда гына түгел, кавышканнан сон да сөеп-сөелеп яшәүдә, озын төннәр буе, озак еллар буе мәхәббәт һәр икендә сүрелмичә, дәртен һич кенә дә кимемичә, сөелеп тә сөешеп яшәүдә. Кеше фәкать әнә шунда гына чын-чынлап бәхетле була. Бәхет гүя хатынның ташып торган тулы тәненнән генә түгел, бәлки әле диварга эленгән келәмнән дә, күпертеп куелган мамык мендәрдән дә, кызыл бизәкләр төшкән саргылт чаршаудан да бөркелә. Бәхет исә кешене яшәртә, ана көч һәм куәт өсти, яшәү өчен дәртен-дәрманын арттыра.

Киндердән күренгәнчә, Зөлфия олуг бәхет иясе. Ул әле йокыдан гына уянган, назлы-татлы кичтән сон өстенә-башына да киенеп өлгермәгән, караватка чәч тарарга утырган. Куе кара чәче яшь ханымның алтынсу тәненә бигрәкләр инде килешеп тора: иннәрен генә түгел, дәртле күкрәген дә каплаган, тулы янбашына көлтәдәй ишелеп төшкән. Бәхет эчендә йөзгәне Зөлфиянең карасу күзләренә дә, алсу бит алмаларына да чыккан. Ташып торган тәнле, мәхәббәтле, дәртле яп-яшь хатынның бу чаклы да килешле кыяфәтен күргәч, ымсынмый калырга һич мөмкин түгел.

Зөлфия образын иҗат иткәндә рәссам, ихтимал, анатомияне бераз онытыбрак торырга мәҗбүр булгандыр, чөнки сәнгати дөреслек үзе шуны таләп итә, иҗат эше үзе шуна этәрә. Әмма олуг талант иясенең әнә белән казыган коесы тәмле сулы, татлы сулы килеп чыга: Зөлфиягә карап туймассың. Гүя анын табигать биргән гүзәллеге-матурлыгы фон буларак хезмәт иткән чәчәкле-челтәрле мендәр, келәм, чаршаудагы матурлык белән аралашып китә, яшь ханым гүя үзе алардан да матуррак жанлы бер чәчәк, жанлы бер гөл сыйфатында кабул ителә. Бу әсәрнең Франциядә, Германиядә үткәрелгән халыкара күргәзмәләрдә сынлы сәнгатьнең классиклары иҗат иткән мәшһүр әсәрләр белән рәттән куелуы да тикмәгә түгелдер. Әйе, дөреслектә матурлык, матурлыкта дөреслек!

Бу әсәр Дәрдмәнднең дүртьюллыгын искә төшерә:

Тәнкәен ак, түшкәйләрен кин яраткан,
Биткәенен иң очында мин яраткан;
Саклар өчен зифа буен яман күздән
Чәчкәйләрен аяк белән тин яраткан.

Сәнгатькәрнең әле шушы елларда гына иҗат иткән иң гүзәл, иң камил әсәрләре—асыл затларга багышланган. Арада бер нәзакәтлесе, ихтимал, «Фәйрүзә» картинасыдыр. Зифа буй, гаҗәеп мөлаем йөз, шомырттай кара күз, нәзек һәм төз борын, уймактай авыз, аккош муеныдай килешле муен, сизелер-сизелмәс кенә күкрәкләр, нечкә бил, озын ыспай бармаклы нәфис куллар... Зифа буйлы кыз баланың килеш-килбәтеннән үк тыйнаклыгы сизелеп тора. Башын ул чак кына унгарак салган, кара бөдрә куе чәч толымы—билдән түбән. Шәлъяулыгының кызылы кара бөдрә чәченә затлы гына бер төсмер бирә. Зифа буйлы, зур толымлы туташның сурәте күгелҗем-зәнгәр фонга язылган, һәм әнә шул нәфислек бөтен картинага исем биргән булса кирәк. Автор илаһи кодрәт иясенә хас бер осталык белән зифа буйлы кызның киемнәрен дә фон белән авазлаш итүгә ирешкән—гүзәллек алиһәсенә мәдхия-симфония китереп чыгарган.

Сәнгатькәр хәтта әле табигатьне тасвирлаган чагында да ара-тирә берәр чибәркәйнен сурәтен «ялгыш кына» язып куя. Картинаны башлаганда да, атналар-айлар буена язган чагында да берәр жанлы образ кертеп жибәрәчәген

ул үзе дә белми. Һәрхәлдә, картина язуны автор планлы эшкә санамый, аңа иҗат эше дип карый. Ә инде эшләү дәверендә ниндидер эчке сиземләү җанлы берәр образның кирәклеген исбатлый. Шуннан картина, әлбәттә, камилрәк тә, матуррак та килеп чыга. Әйтик, гап-гади авыл күренешен тасвирлаган чагында, автор, интуициягә буйсынып, берәр чибәркәйнең образын да өсти икән, әсәр моннан бик нык ота: чәчәкләр арасында нурланып-балкып торган җитү кыз гүя үзе дә чәчәк буларак кабул ителә.

Менә «Татлы хыял» дип исемләнгән картина. Бер асыл зат назланып-рәхәтләнеп чәчәкләр-үләннәр-абагалар арасында ята. Юк, ул йокламый, фәкать уйланып-хыялланып кына ята. Ике кулын баш очында кушырган, гүя дөньясын ук оныткан. Чәч толымы бөдрәләнеп нәфис күкрәгенә төшкән. Пар алмадай итеп тасвирланган күкрәкләр, гомумән, бу әсәрдә игътибар үзәгендә, һәркем сокланырлык һәм дә ымсынырлык итеп, гаҗәеп дәрәҗәдә оста язылган. Абага кыяклары кызның нәфис күкрәкләре белән уйный, назлый—татлы хыялларны тагын да татлырак иттерә... Әнә шул гүзәллекне шагыйрь әйткән «яман күздән» табигать гүя үзе саклый. Нәкышь остасы табигатьне безнең халыкка иң якын җан иясе булган ат образында бирә. Абага кыяклары атның ялына үрелгән—рәссам аларны тамашачыга бер үк гаммадагы буяулар белән язып тәкъдим итә. Әнә ат, башын иеп, юаш кына асыл зат янында басып тора—иясенең иминлеген кадерләп саклый.

Әгәр Испаниядә туып-үскән мәшһүр Сальвадор Далиның картиналарында ара-тирә арыслан сурәте очраса, татар сәнгатькәре Илдар Зариповның киндерләрендә без еш кына ат сурәте күрәбез.

Моның шулай булуы бер дә очраклы хәл түгел: безнең халык борын-борыннан ат белән дустанә яшәгән, көнкүрешендә һәрчак атны гаять оста файдаланган: җирен сөргән, ашлыгын басудан төяп алып кайткан, утынын-мазарын ташыган, саладан калага ат җигеп барган... Халык атны ир-егетнең юлдашы да, канаты да дип юкка гына атамыйдыр, атсыз көн күрүне хупламаса, атлы кешенең дәрәҗәсе зур булуын—«Атың булса, ил таный», дип юкка гына бәяләмидер, күрәсең.



*Казанның Күргәзмәләр залында. Уңнан сулга: Б. Урманче, Ф. Әхмәтова, А. Сабиров, Р. Килдебәков, Р. Вахитов, И. Зарипов. 1986 ел.*

Менә ни сәбәпле милли образлар иҗат итүче сәнгатькәр Илдар Зарипов әледән-әле үзенең киндерләренә ат сурәтен дә теркәп куярга ярата. Кайчагында рәссамның нәкышь әсәрләрендә ат сурәте үзебезнен җирлекне тәгаенләр өчен арткы планда, бәп-бәләкәй итеп кенә бирелсә, аерым очракларда ат алгы планда, каһарман сыйфатында калкып чыга. Һәрхәлдә, татар авылын тасвирлаганда рәссам ничек кенә булса да атны кертмичә калмау ягын карый, шунсыз аның күнеле булмый.

—Татар халкы үзе дә бит эшчән халык, унган халык, ат шикелле эшли,—дип әйтүе белән автор үзенең әсәрләрендә өстәмә бер мәгънә ятканына ишарә ясый, безне уйланырга мәҗбүр итә, сәнгать әсәрләрен аңлау өчен тирәнгәрәк керергә өнди.

И. Зарипов үзенең иҗатында төрле темаларга кагыла. Бу хәл аның чынбарлыкны реалистик буяуларда күрсәтергә омтылуыннан килеп чыга. Аның әсәрләре, гомумән, халыкчан рухта язылган. Аларда татар халкының тыйнаклыгына һәм унганлыгына самими бер соклану чагыла. Әйтик, «Батыр» дигән картинасында рәссам гап-гади татар агаен баһадир дәрәҗәсенә күтәрә. Бу образны иҗат итәргә җыенганда рәссам үз әтисенең сурәтен гәүдәләндерергә ниятли, тик өлгерми кала: Касыйм абзый чирләп китә һәм дөнья куя. Рәссам аның дусты Абдулла абзыйның сурәтен мәңгеләштерә. Юк, ул киндердәге агай тышкы кыяфәте белән пәһлеванга алай охшамаган да сыман, башын горур күтәреп, борын чөеп тә утырмый сыман. Тик инде аның туры күз карашы, нык җилкәләре, көрәктәй куллары бу агайның чын-чынлап хезмәт иясе икәнен исбатлый. Ә инде тыйнак затның күкрәк тулы орден-медальләре халкыбызның тапкыр сүзен һәркемнең хәтеренә төшерә: әйе, без тынычта аттан артык эшлибез, без сугышта юлбарыстай көчлебез! Гади хезмәт кешесен күрә-соклана белгән һәм аны пьедесталга күтәргән рәссам, һичшиксез, йөрәкләрдә горурлык хисе уята.

Илдар үзе дә сәнгать әсәрләренә соклана белүен яшерми. Әйтик, Германиядә аның шәхси күргәзмәсе була. Брауншвейг дигән бәләкәй генә бер шәһәрдә бугай, рәссамыбыз музейда шундый хәлгә юлыга. Биек диварларга эленгән зур-зур картиналар яныннан узып китә җинел генә—берни туктатмый рәссамны, берсе-бер үтеп керми сәнгатькәрнең күңел түренә. Шулай битараф йөри торгач, ишектән янә дә бер зал күренә.

—Зал буп-буш. Бер генә абзый урындыкка сенгән, тынын да чыгармыйча утыруын белә. Бу нинди хикмәтле нәрсә икән, дип, ул караган картинага күз салсам—Рембрандт! Шаклар каттым. Юкса мин әйбәт беләм бит инде Рембрандтны. Мондый автопортретын һич күргәнем юк иде. Үзенең сурәтен генә түгел, бөтен мохитын биргән, гаилә кешеләрен күрсәткән. Тик алары аның арткы планда, әсәрне баетыр өчен эшләнгән...—дип сөйли дә:—Теге абзый шикелле, мин дә, тәмам сихерләнеп, урындыкка сендем дә ике сәгать буена кымшанырга да куркып утырдым шул,—дип сүзен тәмамлый.

Талантлы рәссамның картина язуда үз юлы, үз ысулы бар. Шунлыктан ул язган картиналарны йөзләрчә әсәрдән аерып алуы ансат. Кайчагында тема яки сюжет ягыннан аларда беркадәр охшашлык та күрүең ихтимал. Әмма ул охшашлык еш кына детальләрдә булмыйча, буяуны киндергә салу, язу стиленә кагыла. Автор үзенең күңеленә аеруча хуш килгән әсәрен күчереп язарга ниятләсә дә, аны төкми-чәчми күчереп куя алмый: теләсә-теләмәсә дә яңа вариантка үзгәрешләр, монарчы булмаган табышлар кереп китә, һәм әсәр копия булмыйча, тагын да камилрәк яңа вариант килеп чыга. Иҗат эшендә әнә шундый могҗизалар булгалый шул, булгалый...

Берсе аның—«Кыш гүзәле». Гәрчә автор кышкы пейзажны бик тәфсилләп сурәтләсә дә, авыл өйләренен күбесен көрткә күмелгән итеп күрсәтсә дә, бу аңа фәкать контраст өчен генә кирәк булгандыр. Әнә бит ак кар фонындагы миләшләр арасында алсуланып пешкән алмадай булып бер асыл зат үзенең табигать биргән бөтен гүзәллеген-байлыгын күрсәтеп басып тора. Аның өчен гүя тыштагы суык берни түгел, гүя ул эсседән чыккан да тәненең сылулыгына һәммәбезне сокландырырга уйлаган. Ә бит, картинага күзең төшү белән, сокланмый калу һич мөмкин түгел.

«Ания» дигән әсәрдә исә җәйге пейзаж тасвирлана. Чәчәкләр арасында тыйнак кына, матур гына, моңлы гына татар кызы. Аның киеме дә, үзе шикелле үк, нәфистер, тыйнактыр. Җәй гүзәле диярлек Аниягә.

Ә менә—«Ачылмаган чәчәкләр». Бу әсәрен автор халкыбыз 1552 елны кичергән афәткә, онытылмаслык фаҗигانең йөзләгән-меңләгән корбаннарына багышлый. Арткы планда һәлак булган атлар, кан... Алда исә бер алиһә: искитәрлек чибәр, япь-яшь хатын аянычлы хәлдә үзенең сабыен күкрәгенә кысып кочаклаган. Аларга инде котылу юк. Әмма шундый фаҗигале соңгы мизгелдә дә һәр икесеннән милли моң, әчке гүзәллек сирпелә.

—Моннан дүрт-биш гасырлар элегрәк казан каласын алганда урыс гаскәре һәлакәткә дучар иткән меңнәрнең бере бу Ана...—дип төшендереп бирә автор үзе.—Бу образ конкрет шәхес түгел, Ана—җыелма образ. Күпме чәчәк әнә шулай ачылырга да өлгермәгәндер...

Картиналарның берсендә сагышлы-сары төсләрдә татар халкына җан атып торган, аз гына вакыт эчендә күп изгелек кылган Сөембикә ханбикәнең гүзәл образы тасвирлана. 1550 ел. Явыз Иванның күнелен күрергә тырышып, әле кайчан гына урыс явын кире кайтарган ханбикәне әсирлеккә дучар итәләр—Мәскәүгә озаталар. Соңгы ханбикәбезнең илдән сөрелер алдыннан бәхилләшү мизгеле мәңгеләштерелгән. Арткы планда Казан каласының символына әверелгән һәм ханбикәнең исемен йөреткән, мәгърур башын болытларга чөйгән мәһабәт манара да сурәтләнгән.

Татар әдәбиятының бөек классигы Габдулла Тукайның тууына 100 ел тулу шәрәфенә шигырь яки поэмасына иллюстрация формасында берәр әсәр язарга мөмкин булган булыр иде. Әмма Илдар алай итмәгән, бәлки һәммәбез өчен дә изге Ананың йөрәк җимешен, багалмасын бишектә тирбәтеп торган бер мизгелне мәңгеләштергән. Сабый әле бишектә ята, ул гап-гади бер авыл өендә дөньяга килгән; бозавы да шунда авыл кешесенең, миче-казаны да... Бәләкәй Апушның туган әнисеннән күңел җылысын һәм әнкә назын алып калган чагы тасвирлана картинада.

Гәрчә шигырь ничек язылганны, шигырьнең шәбе ифрат сирәк чыкканны белсәң дә, Габдулла Тукай шигырьне бик ансат, бер утыруда язып ташлый торган булгандыр сыман тоела. Чөнки аның әсәрләре гап-гади һәм аларда һәр сүз нәкъ үз урынында. Зариповның «Шагыйрь туды» картинасында да һәммә нәрсә үз урынында, һәммә деталь гап-гади, артык гади. Миңа калса, талантлы рәссам бу әсәрендә гаҗәеп үзенчәлекле төсләр гармониясен китереп чыгарган, гадилеккә—халык шагыйренең бөеклегенә тиң һәм дә авоздаш, моңлы әсәр иҗат итү бәхетенә ирешкән.

Дөньяга даһи шагыйрь Габдулла Тукайны бүләк иткән Бөек Ана образы һәркемнең хәтеренә уела. Караңгырак төсләр белән язылган шушы киндердә күпме җан җылысы, мөлаемлек, шәфкатьлелек... Ана гүяки бердәнберен, үзенең йөрәк парәсен дөньядагы барлык михнәттән араларга, барча кайгы-хәсрәттән, күп төрле бәла-казадан сакларга әзер, гүяки ул кодрәтле канатларын газиз балакае өстенә җәеп җибәргән дә, сабыеның нурлы вә күркәм булуына сокланудан гаҗиз. Әмма Ананың карашында моң сизелә: гәрчә өметләре гаять зурдан булса да, ышанычы алай ук куанычлы түгел шикелле... Безнең халыкта, берәр кешенең миһербанлы җан иясе икәнлеген күрсәләр, әнисенә рәхмәт әйтәләр. Ошбу гадәткә ияреп, Бөек Ана тасвирланган картинага караган хәлдә, Тукайның даһилыгы алдында баш иясең һәм ирексездән: «Һәммәбезне сөендерәсең, Шагыйрь! Әниеңә рәхмәт!»—дип пышылдыйсың.

«Истәлекләр» дигән мәшһүр әсәрендә исә Илдар үз әнисенең образын чагылдыра—сабый чактан бирле хәтерләгәнен мәңгеләштерә. Авылда урак өсте. Ана үзе урак ура. Малае көлтәгә күмелеп йокы симертә. Авыр сугыш елларында, галәмәт зур җәфа-казалар кичереп, әнә шул сабыен тәрбияләп үстергән,кеше иткән унган-булган Затка—Анага да минем рәхмәт!

Габдулла Тукайның Уральскидан Казанга килгәч тә Галиәсгар Камал белән беренче күрешү-танышуы, ихтимал, исегездәдер: редакциягә кыюсыз гына килеп кергән шагыйрьне Галиәсгар ага башта малайсыта; ә инде Уральскидан килгәнен ишеткәч, безнең Тукайны белми микән, дип кызыксына.

Шундыйрак хәл безнең талантлы рәссамыбыз тормышында да булып ала. Бер елны шулай, хатыны Светлана белән бергәләп, рәссам Кырымга, иҗат йортына бара. Шунда ул үзе белән бергә Суриков институтында укыган, хәзер инде Ленинградта яшәп яткан рәссамны очратып, дустанә генә күрешә. Моның сабакташы исә үзенең юлдашына:

—Болар Казаннан килгән иптәшләр,—дип авыз ачарга өлгерми, тегесе, өлкәнрәк яшьтәге сәнгать белгече:

—Бәй, Казаннан булгач, сез анда Илдар Зариповны да беләсездер әле?!—дип әләктереп ала да мактау сүзләрен яудыра.

Илдар белән Светлана бер-беренә карашып алалар да тыйнак кына елмаешалар.

Читтә йөргәндә, рәссамнар белән аралашып китеп, әңгәмә вакытында:

—О-о! Илдар Зариповыгыз белән горурлана да аласыз!—дигәнне үз колагым белән ишетергә туры килгәне бар.

Сәнгатькәр Илдар Зарипов дөньяга зур талант иясе булып туган һәм бөтен сәләтен халыкка хезмәт итүдәй изге нияткә багышлаган—дөньяда яшәвенең кыйбласы итеп кешеләрнең җаннарына җылы сулыш өрү, аларны рухи яктан баету максатын сайлаган.

Рәссам Илдар Зарипов сынлы сәнгать өлкәсендә зур казанышлар яулап алган, үзенең киндерләрендә халкыбызның милли моңын чагылдыру бәхетенә ирешкән икән һәм иҗат җимешләре—гүзәл вә камил әсәрләре күп кенә музейларның диварын бизи икән, гали тамашачыларның мәхәббәтен яулап ала, сәнгать белгечләренең игътибарын җәлеп итә икән—дөньяга шундый талантлы, унган вә эшчән, игелекле вә инсафлы угыл бирүе белән татар халкы чын-чынлап мактана-горурлана ала дигән сүз.

Россия Сәнгать академиясе, аның талантын, ирешкән зур уңышларын һәм тырышлыгын искә алып, И. Зариповны 1997 елда Көмеш медаль белән бүләкли.

Татарстан хөкүмәте И. Зариповның иҗатына зур бәя бирә: 1994 елда Габдулла тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек таба.

**Кыям МИҢЛЕБАЕВ**

Китап күзәтү

# «АТЛАРЫМ, КОЛЫННАРЫМ»

Татар прозасында кешенең рухи дөньясын чагылдыру сугыштан соңгы чорда аерым бер юнәлеш буларак үсеп киткән иде. Кешенең әхлагын табигатькә, тереклеккә булган мөнәсәбәттә бәяләү, ягъни табигатьне ярату, саклау бурычларын күтәреп чыгу, бу чор прозасы өчен яңалык буларак та калыкты. Гүзәл туган җиргә, табигатькә саклык, кайгыртучанлык белән карарга әйдәгән Гомәр Бәширов әсәрләре үсеп килүче бу юнәлешнең ышанычлы башлангычы иде.

Борынгы акыл ияләренең мондый фикере бар: «Кешенең кешелеклелек дәрәҗәсен аның табигатькә һәм балаларга булган мөнәсәбәте билгели.» Милли прозабыз хәзинәсенә яңа матур битләр өстәгән «Атларым, колыннарым» китабының авторы Нур Әхмәдиев нәкъ менә шушы фикердән этәргеч ала кебек. Китапның нигездә табигать һәм балалар, ягъни тереклек һәм балаларның ана мөнәсәбәте хакында булуы бүгенге әхлакый тотрыксызлык чорында, тәрбия мәсьәләләре үтә кискен торган мәлдә аеруча отышлы.

Кечкенә авыл һәм гади авыл малайларын сурәтләгән «Атларым, колыннарым» повесте кешенең чиксез күңел хәзинәсен, табигый матурлыкның бөеклеген гәүдәләндерә алган. Үзәк герой Таҗи—үзенең язмышы, булмышы, күңел дөньясы белән бер үк вакытта типиклаштырылган һәм гаҗәеп үзенчәлекле, күркәм образ. Автор аны тикмәгә генә ярым ятим, әнисе тарафыннан бабасына һәм әбисенә өч яшендә үк ташлап калдырылган, язмыш тарафыннан рәнҗетелгән сабый итеп тасвирламый. Мондый балалар гадәттә хислерәк, уйчанрак, шагыйранә күңелле була. Таҗи да нәкъ шундый, житмәсә җор, үткен телле, киң күңелле, зирәк бала. Аның кешеләргә, табигатькә, атларга булган мөнәсәбәте мавыктыргыч, җанлы вакыйгаларда күрсәтелә. Автор героен үз укучыларына кызыктыргыч өлге итеп куя. Таҗи һәръяктан үрнәк: яхшы укый, эш сөючән, куркусыз һәм тәвәккәл, ягъни, авыл малайларына хас бер генә сыйфаттан да мәхрүм түгел ул.

Тагын шунысы отышлы: язучы авыл малайларының шәһәр малайларына караганда ихтирамлырак, кешелеклерәк икәнлегенә басым ясаган. Бу аларның табигатькә, хайваннарга мөнәсәбәтендә, конкрет шөгыльләрендә дәлилләнә. Мәсәлән, «шәһәр шпаналары» пионер лагеренда песи суйган вакытта, Таҗи белән аның дуслары бәлагә очраган сукыр поши һәм аның баласын үлемнән коткаралар.

Таҗины Таҗи иткән төп сыйфат—малайның атларга булган мәхәббәте. «Ат бете» кушаматын йөрткән малай хайваннарның ирене кыймылдаганын да аңлый, аларны күз карашыннан укый, иң мөһиме—ул аларны бәяли белә. «КамАЗ әйбәт машина булса да, тимер генә бит ул, ә бу атлар дөньяның әкияти могъҗизасы»,— ди ул.

Ун-унике яшьлек малайны әнә шундый сөйләмгә ия иткән автор. Әйе, лирик геройның үзенчәлеге дә, әсәрнең милли прозага алып кергән өлеше дә, һичшиксез, аның үтемле, бай, халыкчан телендә. Күптәннән шагыйрь буларак танылган Нур Әхмәдиевнең чәчмә әсәрләрендә дә җор, үткен шагыйранә тел игътибарны җәлеп итә. Бу повесть исә Таҗинең олылар авызыннан эләктереп алган төрле канатлы гыйбарәләре, мәкальәйтемнәре, фразеологик тезмәләре белән тулы. Болар барысы бергә әсәрнең халыкчан стилен тәшкил итәләр. Мәсәлән, «алдасам, ике күзем чәчрәп чыксын», «әттәхиятен укытам», «башың култык астына кыстырып җибәрәм мин ул мактанчыкның», «тел очына төер чыкканчы сөйләштек» h. б. Үтемле сөйләм нигезендә автор геройның рухи халәтен кыска гына җөмләләр белән төгәл, образлы итеп әйтеп бирә алган. «Телем аңкавыма ябышты, ул тегермән

ташына әйләнде»,—ди Тажи үз халәтен тасвирлап, ташлап киткән әнисе белән күрешкәч. Бабасының асылын да герой бер җөмләдә ачып сала: «Гомер эчендә бер сүз әйтер, анысы да табышмак булып калыр». Авыл картлары авызыннан чыккан «бинават ясарлар», «матри аны» кебек сүзләр янә повестька юмористик төсмер өсти. Бигрәк тә Тажинен Наиләгә язган русча хаты мәзәктәгечә көлкеле. Аннан сон, утилче абзыйның мыек астыннан көлеп, «Әбинен бар комганы»н көйләве дә авыл кешесенен авыз ерырга хирыслыгын ассызыклый.

Тел байлыгы, фикер әзлеклелеге ягыннан колхоз рәисе Йосыф абый образы да игътибарга лаек. Балалар йортында үскән Йосыф абый дөньяга гаять кин карашлы, эрудицияле, гыйлемле кеше буларак күз алдына баса. Ин мөһиме—ул ат җанлы кеше. Атлар хакында ул тарихчы галимнән бер дә ким белмидер. Бу образ ярдәмендә автор укучы колагына шактый бай тарихи мәгълүмат индерә.

Әсәрне укыганда геройларнын гына түгел, язучынын үзенен дә табигатькә, авылга, атларга гыйшкы чалымлана. Үзе ярсу атта чабып карамаган кеше: «Биткә кояшта кайнаган куе җил килеп сылана, ул күзгә кереп әчеттерә, сулыш алырга ирек бирми, колакларны яндыра»,—дип яза алыр иде микән?!

Тагын шунысы игътибарга лаек: язучы тормыштагы каршылыклардан фәлсәфи мәгънә чыгара. Шәмсуар абыйнын: «Тормыш гел Сабантуйлардан гына тормый шул»,—дигән сүзенә автор үзенә күрә бер басым ясый. Менә малайларның көтеп алган Сабан туе житә. Тажи бүген кукнен жиленче катында—ул беренче килде. Мөгаен, чаптарлар ярышында да ул жинәр. ... Ләкин кинәт анын яраткан аты Йолдыз һәлакәткә юлыга.

Нур Әхмәдиев әсәрләрендәге тагын бер үзенчәлек—ул сүзен тыныч, салмак нотада тегәлли белә. Әйтерсен, укучыны хыял дөньясында очырта-очырта да, йомшак кына итеп жиргә, гадәти тормышка төшереп бастыра. Хыял, омтылыш һәм чынбарлык арасында барлыкка килгән психологик халәт әсәрнен төп мәгънәсен билгели.

Әйтик, «Аксак төлке» хикәясендә капкынга төшкән төлкене коткарып, савыкканчы өйдә асрап, соныннан иреккә җибәрү вакыйгасы сурәтләнә. Малайнын җәнлекләргә карата мондый итагатьле мөнәсәбәте әтисеннән күчкән икән ләбаса! Житди генә күренгән әти кешенен төлкене иреккә җибәргән мәлдә булган кичерешләрен улы болай ачып сала: «Тавышына сәерсенеп күтәрелеп карадым—әткәйнен озын керфекләренә эленгән яшь тамчысында нәни кояш яна иде».

«Күгәрченкәй көнбагыш ярата» хикәясендә исә Маһирә апа һәм анын кечкенә кызы Галия песи тырнагыннан ычкынган чәукә баласына шәфкать күрсәтәләр. Кечкенә генә хикәя укучы күнелендә җылы хис уята, рухи канәгатьләнү бирә.

Унай образны хайваннарга булган мөнәсәбәт аша яктырту «Рафис» хикәясендә дә гадәти вакыйгаларда тормышка ашырыла. Мәктәпне медальгә тәмамлаган Рафис тормышта тагын бер кат үзен сынамакчы була. Начальник малае икәнлеген дә онытып, слесарь эшенә урнаша. Менә идән астына су тула, су япкычны тиз арада төзәтергә кирәк. Бәхетсезлеккә каршы, су япкыч тирәсенә балалы эт «хужа», ул бераүне дә якын җибәрми. «Атарга!» дигән карар кылына. Ә Рафис мона җаны-тәне белән каршы, анын «тамагына төер тыгыла», «күзен яшь пәрдәсе томалый». «Атмыйсыз!»—дип кычкыра ул, җаны әрнеп һәм бөтен сәләтен эшкә җигеп, этне икенче урынга күчәргә мәҗбүр итә. Менә шундый кечелекле һәм кешелекле Нур Әхмәдиевнен геройлары!

Китапны тулысынча күз алдына китерү өчен тагын бер әсәргә тукталыйк. «Бәдретдиннен Америкага сәяхәте» дигән мажаралы повесть башка әсәрләрдән күпкә аерыла. Язучынын биредә нинди максатны күздә тотуын да төгәл генә әйтеп булмый. Уйдырмага һәм чиктән тыш арттыруга корылган вакыйгалар тезмәсе Америка мультфильмнарын хәтергә төшерә. Мондый шаккатыризмнарга корылган әсәр, билгеле, укучынын зәвыгына бәйле рәвештә төрлечә кабул ителергә мөмкин. Ләкин шунысы куанычлы: Нур Әхмәдиев әдәбиятыбызда шагыйрь булып кына түгел, прозаик буларак та үз эзанын тапкан, ул төрле юнәлештә каләм сыный, эзләнә, актив иҗат итә. Бүгенгесе куанычлы, киләчәге өметле анын.

**Ләйсән КӘШФИЕВА,**
***филология фәннәре кандидаты.***

# ШИГЪРИЯТ

## КҮҢЕЛДӘГЕ КЫЗЫЛ МИЛӘШЛӘР

РӘШИТ БӘШӘРГӘ 50 ЯШЬ

Шәп әсәрләр картаймый, диләр. Әсәрләре генә түгел, үзләрен дә олыгаю, картлык галәмәтләре читләтеп үтә торган әдипләр бар. Бөтен иҗатларын балаларга багышлаган язучылар шундыйлар инде. Алар иҗатка Балачак Иленнән килгәннәр, Балачак Илендә гомер кичерәләр, иҗат итәләр. Хәтта сөйләшүләрен, килеш-килбәтләрен, холыкларын читтән бераз күзәтеп торсаң, үзләрендә үк балалык, үсмерлек чаткылары күрергә була. Инде күптән арабыздан киткән А. Алиш, Б. Рәхмәт кебек әдипләр хакында сүз кузгатсалар, аларның холкындагы нәкъ балалык сыйфатларын аерып күрсәтәләр. Юкка түгелдер шул...

Рәшит Бәшәргә илле яшь тула дигәч, бик күпләр кебек мин дә: «Кит әле, кая аңа илле яшь булсын!»,—дигәнне сизми дә калдым. Нишлисең, метрика кенәгәсенә: «Рәшит Гафар улы Бәшәров 1949 елның 7 октябрендә Кукмара районы Яниль авылында дөньяга килде», дип, акка кара белән язып куелган. Ышанырга туры килә. Үткән гомер бәрәкәтле, киләчәге хәерле булсын дияргә генә кала. Бәрәкәтле дигәннән, Рәшит Бәшәр бу түгәрәк датага бай иҗат йөге белән килә.

Әсәрләре дәреслекләргә кергән. Үзе көлеп әйткәнчә: «Быелгы стена календарена да язганнар инде, юбилей дип җенләнеп йөрмәсәң дә була, барсы да белә, болай булгач».

Белүен беләләр дә, әмма иҗаты бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән әдип булып кала бирә ул. Сәбәпләре төрледер, тик язганнарының сыйфаты сәбәпче түгел. Әйткәнемчә, инде бүген үк аның исеме татар балалар әдәбияты классиклары белән рәттән телгә алына. М. Әгъләмов бер мәкаләсендә, З. Туфайлова, Ә. Бикчәнтәева, Н.Исәнбәт, Б.Рәхмәт исемнәрен санап үткәннән соң: «Ә бүгенге Рәшит Бәшәрне кая куясың?»,—дип сорау бирде дә, һич икеләнмичә, аны да шул классиклар янына «китереп бастырды».

Роберт Миңнуллин: «Балалар шигыренең файдалы эш коэффициенты күбрәк. Бу жанрда безнең зур шагыйрьләребез иҗат итә: Ш. Галиев, Х. Халиков, Р. Мингалим, М. Фәйзуллина, Р. Бәшәр. Аларның китаплары һәрчак балалар кулында...»—дип язды... Сәбәп башкада: Р. Бәшәр, әдип буларак өлгереп җиткәч тә, Казаннан читтә яши. Университет тәмамлагач, Лениногорск районында шактый еллар мөгаллимлек итә. 1979 нчы елдан Чаллыда. Ун елга якын КамАЗда эшли. 1987—1989 елларда аңа да күк капусы ачылып китә—ике ел Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укып кайта.

Курсташларының берсе—озынча кәкре борынлы, үзгәнә үткәреп карый торган шагыйрь егет, берничә елдан кулына корал тотып Ичкерия азатлыгы өчен көрәшүчеләр сафына басачак, Дудаевның иң якын көрәштәше, Дудаевтан соң президент булып, Ичкериянең бәйсезлек көрәшен әйдәүче Зелимхан Яндарбиев. Өске каттагы бүлмәдә яши. Рәшит Бәшәрнең публицистик язмаларындагы кайнарлык, кискенлек, шушы чорда формалашкандыр кебек тоела миңа. Югары кимәлдә язылган Зелимхан Яндарбиевка ачык хатында ул: «Синең идән—безнең түшәм»,—дип, гаять кинаяле, безнең вәзгыять өчен ачы чынбарлыкны чагылдырган сүзләр язган иде.

Бәшәр шулай ук бергә укыган дусты Фәиз Зөлкарнәйне сагына... «Аргамак» журналында җаваплы сәркәтип вазыйфасын башкаручы, журнал эшен җигелеп тартучы ул Рәшит Бәшәр. Менә шушы вәзгыятьтә үзең булып кала алу да батырлык.

Ә чын дуслар китә тора: Кадыйр Сибгатуллин, Хәниф Хөснуллин, Ямаш Игәнәй, Альберт Сафин... Бер очрашканда әйтеп куйганы бар: «Дуслар китә, Факил. Яшәүнен яме бетә». Бу сүзләрне бит яшәүгә табынган, «Иртәгә дә яшисе бар»,—дип, башкаларга көч-дәрт өстәргә омтылган язучы, балалар язучысы әйтә...

Рәшит Бәшәрнен әдәби тәнкыйть күзеннән бөтенләй читтә калып килгән прозасы бар. Укучыларнын исләренә төшереп, аларны санап үтәсем килә: «Акбалык», «Ачык капка», «Яшел поезд», «Иртәгә дә яшисе бар», «Миләш», «Бер өйдә жиде кеше», «Минем әтиемне сугышта үтерделәр», «Жилдә тирбәлүче бишекләр»... Һәр кайсы истә калырлык, ихлас язылган жыйнак, әмма саллы повестьлар.

Очрашуларга анын белән күп йөрим. Мәктәпләрдән чакыру булса, өчәү—Рәшит Бәшәр, Ямаш Игәнәй һәм мин хәбәрләшәбез дә, дәртләнеп балалар янына ашыга идек. Рәшит Бәшәрне тынлап торуы кызык. Бер карасан—олпат шәхес, бер карасан—каршыда утыручы, бераз тәртип-кануннарны санга сугып бетермәүче малай-шалай кебек. Шигырьләрне яттан сибә генә. Бала-чага көлә, үзе көлә. Шундук житди шигырьләргә күчә, балаларга дәрес бирүче шактый кырыс мөгаллим сыман тоела башлый. Ин мөһиме—экерсез ул, кылану, ясалмалылык юк. Балалар шуны сизәләр, шуңа аны үз итәләр. Балалар белән очрашуга дисән, жир читенә дә китәргә әзер бик сирәк шагыйрьләребезнен берсе ул. Очрашудан сон дәртләнеп, канатланып кайтабыз. Бәшәрнең куанычы эченә сыймый. Йөзенә кунган елмаю мәңге сүнмәс кебек...

Язмамны Р. Бәшәрнең «Миләш» повестеннан үз сүзләре белән тәмамлыйсы килә: «... Тәрәзәгә орынып ук миләш үсә. Көзге салкын жилләрнең анының соңгы яфрагын өзеп алып, буп-буш һава буйлап очыртып киткәненә дә әллә ни гомер узды. Миләшнең яшькелт шәрә кәүсәсе, ялангач ботакларын жәеп, соп-соры һава астында оеп утыра. Тирә-якта чәчелешеп яткан кызгылт-сары яфраклары тын гына кыш килгәнне, кар каплаганны көтә. Агачның иң очында кып-кызыл тәлгәшләр тирбәлә...»

Менә шушында язманы туктатып торам. Янып торучы кызыл миләшләр дигәне Рәшит Бәшәрнең үз әсәрләредер кебек. Аларны кырау сукмас, чөнки инде алар күптән укучылар күңелендә.

**Факил ӘМӘК**



# Рәшит Бәшәр

## Мин бит татар егете

Һаваның да ае бар,
Мәчетнең дә бар ае,
Үземнең дә аем бар—
Айнур минем исемем—
Мин бит татар малае.

Хәлсезләнгән песине
Һәм хуҗасыз маэмайны
Ишегалдына дәшеп,
Бисмилла әйтеп сыйлыйм—
Мин бит татар малае.

Ялкауларны гел сөймим,
Әти түбә япканда
Тотып торам калайны,
Әти кадак какканда
Биреп торам кадакны—
Мин бит татар малае.

Кул юабыз, сөендереп
Баскычтагы комганны.
Чәй эчәргә керәбез,
Бисмилласыз ашамыйм—
Мин бит татар малае.

Шамаил тора түрдә,
Шамаилнең бар ае.
Әни килә елмаеп,
Үбеп алам мин аны—
Мин бит татар малае.

Догалар да беләм мин,
Түбәтәй дә киям мин.
Очратсагыз урамда
Әгәр минем кебекне,
Белеп торыгыз, яме—
Ул бит татар егете!

## Намаз

«Бисмиллаһир-рахманир-рахим!»
диеп кенә,
Намазлыгын идәнгә
Пөхтәләп җәеп кенә,
Бабам укый намазны
Кәләпүш киеп кенә.

Тып-тын калган өй эче:
Сәгать тә келт-келт йөрми,
Самавыр да гөрләми,
Мәчебез дә мырламый,
Радио да җырламый.

Ишек алды да тыныч:
Сыерлар мөгрәми,
Тавыклар кытакламый,
Үрдәкләр бакылдамый,
Казлар да каңгылдамый,
Хәтта Алабай өрми,
Бәрәннәр бәәлдәми—
Намаз вакыты икәнне
Алар да белгәнмени?

## Әни келәме

Хәйран матур бу болын!
Карап торам, тамаша:
Ямь-яшел ул, сап-сары,
Зәңгәр, кызыл, шәмәхә,
Хәтта күзләр камаша.

Хәйран матур бу болын!
Әни келәме төсле,
Әни тукыган төсле.
Ничек әйтеп бетерим
Мондагы бөтен төсне?

Хәйран матур бу болын!
Чәчәктән башын сузып
Карап кала бал корты.
Елмаеп үтәм аңа,
Бик матур икән йорты!

Хәйран матур бу болын!
Болында йөрим ялгыз,
Пумаласыз, буяусыз.
Рәсемен сез ясарсыз,
Матур итеп буярсыз!

## Алмалар аллана

Төн жылы. Алмалар
Чирәмгә күмелеп
Йоклаган мәлләрдә
Киттеләр тәгәрәп.
Кемнәр соң уятты,
Жил мәллә, жил мәллә?

Төн жылы. Ак песи
Тәпиен сак кына
Тидерә алмага.

Төн жылы. Бакчада
Алмалар аллана.

## Гаҗәеп көн

Әллә нинди көн бүген!

Жылы нигездә йоклап
Ята тычкан баласы.
Ак песи жырлап йөри,
Аны күрми, янәсе.

Ишегалдында әни
Сыер савып утыра.
Тавыклар да жырлашып
Күкәй салып утыра.

Әти дә эчми генә
Ап-аек кайтып керде.
Алабай аңа бүген
Яратып кына өрде.

Әтигә алмаларын
Өзеп бирде алмагач.
Мичкә коймак тыгарга
Әзерләнә табагач.

Нинди гаҗәеп көн бүген!
Йолдызлар тәэсиреме,
Жирдәге бөтен нәрсә
Йолдызлар әсиреме?

*Uquçı süze*

## LİRİK SƏÜDƏGƏR KEM UL?

Berkənne şağir Renat Xarisnıņ «Totqasız işek» kitabına yulıqtım. Kitapnıņ tışqı bizəleşe ük üzenə tartıp tora. Yuğarı zəweq belən bizəlgən tışlıq eçendə şundıy uq ruxlı şiğerlər də bulaçağına ışanıç belən uqırğa kereşəm.

Küņel işeklərem totqasız.
Ləkin biksez.
Xətta keləsez.
Hər keşegə anda açıq yəz -
Xuş kiləsez... Kerə belsəgez.

Lirik-fəlsəfi şiğer həm poemalarnı uqıp «Çexov bazarı»na barıp citəm. N. Xisamov dəres əytə: «Xəzerge tormışnıņ cıynama surəte bu əsər».

Şağir icatı belən tağın da qızıqsınu mine tirən uylanularğa kiterde. Biredə qayber uylarnı seznen belən də urtaqlaşırğa telim.

İņ əüwəle min şağirnen lirik şiğerləren uqıp soqlandım. Avtor dønyağa qaraşın, aņarğa mønəsəbəten qayber bügenge şağirlər kebek turıdan-turı əytep salmıy, bəlki kinayəle süz-surət yərdəmendə beldерə. Bilgele bulğança, kinayəle taswir poetikada başlıça şiğer belən yazılğan əsərlərgə xas. Alarnıņ tørlərе berniçə: metafora, metaforik epitet, metonimiə, sinekdoxa, perifraz, metaforik çağıştıru, yumor, giperbola, litota h. b. Alarnı lingvistik poetika belemendə «troplar» digən ğømumi baş astında yərtələr. Başqaça əytkəndə, bolarnıņ barısı da süzlərne küçerelmə məğnədə qullanuğa qaytıp qala. Şul alım belən səngətle ədəbi əsər barlıqqa kiterü metalogik alım dip atala. Əmma şağir, prozaik yəki dramaturg hərwaqıtta da küçerelmə məğnədəge süzlər belən genə (yəğni metalogik alım belən genə) eş itmi. Çønki bolay da poetik bulğan küreneşlərne, uy-kiçereşlərne barı tik bu alım belən genə taswir qılu artıq qupşı kilep çığar ide. Qısqası, turı məğnədə qullanılıp yazılğan matur ədəbiat tekstları (əgər alar çınnan da poetik bulsalar) avtologik alım belən icat itelgən dip qarala. Ləkin bu oçraqta inde avtordan ayıruça saqlıq taləp itelə, süzlərnen iņ kirəkleləren genə saylap qullanu kirək bula. Çønki poetik bulmağan xəl-əxwəl, küreneş turı məğnədəge süzlər belən genə kürsətelgən oçraqta, Puşkin əytkən «что если это проза, да и дурная» kilep çığa.

Şunı da iskərtep uzarğa kirək: avtologik alım belən icat itelgən əsərlərgə küp kenə oçraqta poetik sintaksis ta yərdəmgə kilə, ə qaywaqıt, bik kirək oçraqta, alarda tropnıņ qaysı da bulsa ber tøre də qullanılıp kitərgə məmkin.

Xəzer Renat Xarisnıņ əlege yaņa kitabındağı qayber əsərlərnen poetik üzençəleklərenə tuqtalıp ütik. Bu şağir üzenen başqa qələmdəşlərennən ayırmalı bularaq, ike alımnı da bik üzençəlekle qullana. Xətta şundıy oçraqlar da bar: anıņ tege yəki bu metaforasın, metaforik epitetın, metonimiəsen h. b. qanatlı süzləren qaywaqıt tiz genə aņlap yəki qabul itep tə beterə almıysıņ.

Əmma nıqlabraq uqıy başlağaç, şağirnenҡ süz qullanılışında niqədər original' avtor buluın anļıysın. Misal өçen anın «Lirik səüdəgər» şiğeren alıyq. Bu əsərnenҡ isemendəge epitet uq ğəcəpkə qaldıra. Niçek inde lirik səüdəgər bulırğa mөmkin? Əmma şiğerne baştan alıp azaqqaça uqıp çıqqaç, (ul altı strofadan tora, sillabikanınҡ 10 da 9 lı ülçəme belən yazılğan) zihenne yaqtırtıp kitkən ber fiker pəyda bula: avtor üzenenҡ şiğerləren bez ğadi genə uylağança «səüdəgər kebek» uquçığa təqdim itmi ikən, ul alarnı matur ber toyğı qaldıra torğan yuğarı zəweqlı bülək dərəcəsenə citkerə.

Min alarnı satmıym, bülək itəm
şiğerəmə tөrep, süzemə.

Səngət başlıça өç tөrgə bülenə: berençe kürüdə ük qabul itelə torğan (arxitektura, rəsem səngəte), ikençese uqu yəki tınҡlau barışında qabul itelə (muzıka, matur ədəbiat), qatnaş tөrdəge səngət tə bar (balet, səxnə səngəte). Poeziə əsəre isə ikençe tөrgə qarıy.

«Lirik səüdəgər» şiğere avtologik alım qullanıp yazılğan. Şiğer peyzaj taswirınnan başlana. Ə peyzaj, bilgele bulğança - maturlıqnı turı məğnəsendə, yə bulmasa kinayələp əytep birüdə in otışlı ısul. Menə qarağız, niçek başlana şiğer:

Sirək urmah. Tübən qoyaş yumart.
Alsu qarda zəngər şəülələr.

Əle tağın şunısın da iskərtep uzarğa kirək: peyzaj lirikasında, teoretiklar bilgeləp ütkənçə, «üze kürenməgən keşenenҡ lirik kiçereşe çağılış taba». Bu matur şiğer Renat Xarisnınҡ yanҡa cıyıntığında ayıruça poetik əsər bularaq qabul itelə.

Əlbəttə, bu cıyıntıqqa kergən başqa poetik əsərlər turında da şundıy uq yuğarı bəyə birergə mөmkin bulır ide. Ləkin biredə əle bez «Çexov bazarı» poemasına iğtibarıbıznı yünəltergə buldıq. Bügenge kөndə tatar şağirləre arasında ni өçender poema yazuçılar sirək. «Çexov bazarı» - çınnan da poema, çөnki anda üzenə kürə ber waqiğa bar, ə poema bulu өçen vaqiğa bulu zarur. Epik personaj zamannınҡ qaynap torğan bazarında üzençə ber səyəxət qıla, üzenə kirəkle ber «towar» ezli. Şunda ul tөrle tiptağı, elegrək tөrle professiə iələre bulğan keşelərne oçrata, alar belən gəp qora. Ə ul gəp digənenҡ ğadi ber kөnküreş vaqiğalarına ğına qağılmıy, bəlki səyəsi, etnik həm əxləq məs'ələləren də kütərə.

Betə, brat, betə bu Rossiə,
küpme tazartsanҡ da tazarmıy.
Başqa illər - dəülət, ə Rossiə,
ə Rossiə - Çexov bazarı.

Bu gəp ğadi ber səyləşü genə tügel, ul əsərnenҡ buyınnan buyına yumor belən suğarılıp birelə. Bazar əhelləre üzlərenenҡ monҡ-zarların, şatlıq-qayğıların şayan süzlər belən əytə, alar əngəmə qıluçı belən də qunaqçıl, anı küptənge tanışları sıman üz kürep qabul itələr.

Çıbıq oçı qərdəş yeget ikən...
Şundıy matur, pөxtə kiengən.
Diktor ğına belgən rus telendə
balalarça matur sөyenə!..

Rus telen ul, şiksez, «biş»kə belə.
İnglizçə, şiksez, artıq ta!
Tatarçası - ənisenen tele -
«berle» kuyıp bulmıy tartıp ta.

Bu poema turında şundıy ber telək əytəse kilə: «Çexov bazarı»n ber talantlı artist səxnədən torıp uqısa (anı qorı kəlkegə genə qaldırmıyça, citdi itep), ul bəten auditoriəne - televizor qarauçılarnı, radio tıņlauçılarnı - üzenə cəlep itər ide. Çənki poemada kütərelgən problemalar bik aktual' həm alar eçkə yəşerelgən yumor belən bergə bik əhəmiətle vaqiğalarnı da kütərələr.

«Çexov bazarı» cıyıntıqta berdənber poema tügel. Anda əle «Garmunçı», «Səydəş yarı», «Borılışta» əsəre həm T. Ğəliullin dəres bilgeləp ütkən «tatar poeziəsenə Kənçığış şiğriətne ruxın, Qandalıylar məxəbbəten alıp qaytqan» «Əç übeşü» poeması da bar. Cıentıqqa «İdegəy» dramatik poeması da kertelgən. Anıņ nigezendə kompozitor R. Ğəbəydullinnıņ opera yazarğa teləwe də məğlüm.

Renat Xarisnıņ «Totqasız işek» kitabı üz uquçısın tabar, çənki avtor tənqıtçe R. Mostafin əytkənçə, «bügenge kən keşesen qızıqsındırğan əyberlər turında yaza, zamandaşı belən ber sulışta yəşi».

**Fərida XƏSƏNOVA,**
Qazan şəhərenen 16 nçı gimnaziə uqıtuçısı.

* * *

Xərmətle redaksiə!

*Menə bik küp yıllar inde min «Kazan utları»n yazdırıp alam həm yaratıp uqıp baram. Jurnal minem əçen iksez-çiksez ədəbiat dənyasında yul kürsətüçe mayaq xezməten üti disəm, yalgışmamdır. Kitap alu matdi yaqtan şaqtıy nıq xəlsezlənderelgən keşelər əçen çıp-çın ber problemağa əyləngən bu zamanda "Qazan utları" şul buşlıqnı tutırıp kilüçe berdənber basma diəsem kilə. Çənki hərber yaņa əsər, bulsın roman yəisə povest', bulsın poema yəisə şağirlərneņ ər-yaņa şiğerləre, ədəbiat əlkəsendəge yaņa tikşerenülər, açışlar—barısı da iņ əüwəl jurnal bitlərendə urın ala.*

*Kürenekle ədip İbrahim Salaxof icatı belən də min qayçandır jurnal bitlərennən tanışa başlağan idem. Şunnan birle Stalin konslager'ları afəten kiçergən bu yazuçınıņ hər əsəren diərlek qaldırmıy uqıp barırğa tırışam. Şulau uq anıņ xaqındağı istəleklər, tikşerenülər də minem əçen bik qızıqlı.*

*Bıyıl «Matbuğat yortı» nəşriatında Ləylə Minhacevanıņ «İbrahim Salaxof» isemle kitabı basılıp çıkkan ide. Şul uņaydan üzemneņ fikerlərem belən urtaqlaşasım kilep, Sezgə xat üazarga buldım.*

Kitapta yazuçınıņ əsərləre analizlana, tormış yulı yaqtırtıla. Bu kitap yərdəmendə bez, KDPU studentları, İbrahim Salaxofnıņ icatı belən yaqınnan tanışabız, qatlaulı tormış yulın küz aldına kitereəbez. Ədip üze turında bolay di: «Min xalıq traditsiələreneņ - qayğı, ğorurlıq həm qurqaqlıq, keşeleklelek həm vəcdansızlıq kartinalarınıņ tere şahitı». Əye, İbrahim ağa Salaxof üz ğemerendə tormışnıņ açısın-təçesen küp tatığan şəxeslərneņ berse. Üzeneņ L. Minhacevağa yazğan ber xatında şundıy yullar bar: «Dəresen əytkəndə, min üzem bu yıllarğa xətle kilep citərmen dip, xıyallana da almıy

idem. Kolıma altın priiskalarında 50-60 gradus suıqlarda 10-12 səğət zaboyda eşləgəndə, smenanıŋ axırına qədər citəmme, qatıp üləmme dip kenə uylıy idem. Küplər şul zaboyda qaldılar. Ə min... Bu yazmışımnıŋ ber xatası, məğayın». Yuq, xata tügel, bu Allahı Təğələ tarafınnan maxsus isən qaldırılğan şəxes diər idem min. Ğəyepsezgə yəşəü xoquqınnan məxrüm itelgən, rəncetelgən zamandaşları Ğ. İbrahimof, K. Tinçurin, Ş. Usmanof kebek asıl zatlarıbız əytergə əlgerməgənne xalqıbızğa citkersen əçen Xoday aŋa ozın ğəmer birgən.

Kitapta yazuçınıŋ avtorga yazğan xatlarının fotoküçermәse, ədipneŋ yaqın dustı A. Kəbirof, Ş. Mostafin həm L. Minhacevanıŋ şəxsi arxivlarında saqlangan fotosurətlər faydalanılğan. Şulay uq ədipneŋ şəxsi arxivındağı yazmalar isemlege həm wəsıətnaməsenə aŋlatma birelgən.

Kitapka qarata tağın da tulıraq fikerne maxsus belgeçlər əyterlər. Ə minem isə sezgə ber üteneçem genə bar: jurnal bitlərendə İbrahim aga Salaxof mirasınnan da qayber səxifələrne urnaştırıp barsagız ide. Alar bezneŋ əçen haman da qəderle, istəlekle həm ğibrətle bit.

**Ramil ĞARİPOF,**
*Kazan dəülət pedagogika universitetının*
*tatar tele həm ədəbiatı fakul'tetı studentı.*

*

## КОНКУРС!

Әдәби тәнкыйтьне җанландыру максатларында «Казан утлары» журналы редакциясе 2000 елның гыйнвар аеннан иң яхшы рецензияләргә ачык конкурс игълан итә.

Конкурска килгән рецензияләрнең соңгы 3—4 ел эчендә басылып чыккан әдәби китапка яисә әдәби әсәргә (шигырьләр яки хикәяләр бәйләмен дә кертеп) булуы шарт итеп куела. Күләме машинкада 12 биткә кадәр.

Конурста җинеп чыгучылар өчен түбәндәге акчалата бүләкләр билгеләнде:

**I урынга—1000 сум.**
**II урынга—750 сум.**
**III урынга—500 сум.**

Конкурска рецензияләрне хат белән җибәрергә яисә редакциянең әдәби тәнкыйть бүлегенә кертеп тапшырырга мөмкин.

Конкурста язучыларны, тәнкыйтьчеләрне һәм әдәбият сөючеләрне актив катнашырга чакырабыз.

*Редакция.*

# 2000 ЕЛ ӨЧЕН ЯЗЫЛУ БАШЛАНДЫ

13 сентябрьдән 2000 ел өчен вакытлы матбугатка язылу башланды. Ул 20 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк. «Казан утлары»ның индексы—73210, ярты елга язылу бәясе 36 сум. Алдагы еллардагыча, быел да, журналыбызга язылуны җиңеләйтү максатыннан, 2000 ел өчен хәзерләнгән абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Сез шушы квитанцияне кисеп алып, анда үзегезнең тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, үзегез яшәгән җирдәге элемтә бүлегенә тапшырыгыз.

Татар әдәбиятының йөзек кашы булган бай тарихлы, күренекле журналы «Казан утлары»на язылырга онытмагыз!

Ф. СП-1

Министерство связи СССР
„Союзпечать"

АБОНЕМЕНТ на газету / журнал **73210** (индекс издания)

„Казан утлары" (наименование издания)

Количество комплектов:

на 2000 год по месяцам.

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда (почтовый индекс) (адрес)

Кому (фамилия, имя, отчество)

---

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА

ПВ место литер

на газету / журнал **73210** (индекс издания)

„Казан утлары" (наименование издания)

Стоимость: подписки ___ руб ___ коп; переадресовки ___ руб ___ коп

Количество комплектов:

на 2000 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда (почтовый индекс) (адрес)

Кому (фамилия, имя, отчество)



*Иҗтимагый—мәдәни тормышыбыздан*

## РЕСПУБЛИКА БӘЙРӘМЕ

Татарстан тантаналы төстә Республика көнен билгеләп үтте. 30 августта Казанда һәм Татарстанның һәр төбәгендә Республика көненә багышланган бәйрәм тамашалары булып узды. Казанда бәйрәм тамашаларын Татарстан Президенты М. Шәймиев, Премьер-министр Р. Миннеханов һәм республиканың башка җитәкчеләре белән бергә Россия Федерациясе вице-премьеры В. Матвиенко, Мәскәү шәһәре мэры Ю. Лужков. Россия Президенты Аппараты җитәкчесе урынбасары В. Сурков, Дәүләт Думасы депутаты О. Морозов, Мисырның Россиядәге илчесе Рәда Әхмәд Шихата, генерал-полковник Рәсим Акчурин һәм күренекле кардиохирург Ренат Акчурин, Россия Федераль чик буе хезмәтенең региональ идарәсе башлыгы генерал-лейтенант Р. Муллаянов, һәм башка кунаклар карады.

## КАЗАНГА 1000 ЕЛ!

«Казанга кайчан нигез салынган?» дигән сорау әллә ничә дистә еллар буе җәмәгатьчелекнең бәхәс чыганагы булып килде. Үзәктәге рәсми хакимият тә Казанның бик борынгы шәһәр булуын танымаска тырышты. Ниһаять, бәхәс-дискуссияләргә нокта куелды. Татарстан, Россия һәм чит ил галимнәре уртак бер фикергә килделәр: Казан шәһәренә иң ким дигәндә 1000 ел. Дөнья цивилизациясенә зур өлеш керткән, әре сәяси, фәнни-җитештерү һәм мәдәни әһәмиятен билгеләп Россия Президенты Б. Н. Ельцин һәм Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев «Казан шәһәренә нигез салынуның 1000 еллыгын бәйрәм итү турында» указлар кабул иттеләр. Аларда Казан шәһәренең 1000 еллыгы 2005 елның августында бәйрәм ителәчәге әйтелә. Халык депутатларының Казан Советы президиумы тәкъдиме белән Казанда ел саен Татарстан Республикасы төзелгән көнне—30 августта Шәһәр көне үткәрергә карар кылынды. 1 сентябрьдә Казан шәһәренә нигез салынуның вакыты ачыклану уңаеннан Зур концерт залында шәһәркүләм тантаналы җыелыш үткәрелде.

## НУРЛАНА КАЗАН

27 август рухи тормышыбызда истәлекле көн булып калыр. Динебезне ныгытуда ике зур изге гамәл кылынды. Беренчесе—Лобачевский урамының 6 йортында (элеккеге ТИУ бинасы) Татарстан Диния нәзарәте ачылды. Бу бинаны шәһәр бюджеты исәбенә «Казжилстрой» тресты заманча реставрацияләп гүзәл сарайга әверелдергән. Татарстан Президенты М. Шәймиев нәзарәт бинасын ачу тантанасындагы чыгышында республикада диннең торышын, халыкка дин тоту өчен уңай шартлар тууын, халыкны әхлакый һәм рухи тәрбияләүдә Диния нәзарәтенең дәрәҗәсе күтәрелүен, мөмкинлекләр артуын билгеләп үтте. Мөфти Госман Исхакый шәһәр һәм республика хакимиятенә бу кайгыртучанлык өчен рәхмәт белдерде.

Икенче зур шатлык—шул ук җомга көнне Яңа Савин районында, Чистай һәм Әмирхан урамнары чатында «Казан нуры» дип исемләнгән яңа мәчет ачылды. Бу тантананы ачуга бик күп дин тотучылар, гомумән халык бик күп килгән иде. Агачтан салынган «Казан нуры» мәчете архитектура бизәлеше, манарасының мәһабәт биеклеге белән башкалага чын мәгънәсендә нур өстәде. Мәчет—дин тотучылар иганәсенә салынган. Шулай ук, бу мәчетнең булдырылуына Казан мэриясе һәм Кувейт дәүләте зур булышлык күрсәткән.

## ТАГЫН БЕР ҺӘЙКӘЛ

Республика көне бәйрәме алдыннан Казанда тагын бер шатлыклы вакыйга булды: Бауман урамында бөек рус җырчысы Федор Шаляпинга һәйкәл ачылды. Тантана церемониясендә Татарстанның һәм Россиянең Дәүләт эшлеклеләре, танылган җырчылар, сәнгать әһелләре, музей хезмәткәрләре, чит илдән кунаклар катнашты. Һәйкәл ачылу тантанасында сәнгать белгече С. Бәльза, язучы Р. Батулла, һәйкәл проекты авторы А. Балашов, шулай ук Россиянең танылган опера җырчылары чыгыш ясады. Монумент нигезенә беренче чәчәкләр салынды. Аларны М. Шәймиев, К. Исхаков, Н. Ельцина, В. Матвиенколар куйды.

## БЕЗНЕҢ ЯҢА МИНИСТР

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән хөкүмәт структурасына үзгәрешләр кертелде. Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы бетерелеп, аның урынына Татарстан Республикасының Матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникация чаралары министрлыгы булдырылды. Татарстан Республикасы Президенты Указы белән әлеге министрлыкка министр итеп Зилә Рәхимҗан кызы Вәлиева билгеләнде. З. Р. Вәлиева һөнәре буенча журналист. 1980-1992 елларда «Вечерняя Казань», «Советская Татария», «Известия Татарстана» газеталары редакцияләрендә эшләде. 1992 елдан 1999 елның сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары вазифасын башкарды.

## «ТАТАРСТАН—ЯҢА ГАСЫР» ХӘРӘКӘТЕ АКТИВЛАША

Сентябрь аенда «Татарстан—яңа гасыр» республика иҗтимагый-сәяси хәрәкәтенең сәяси шурасы утырышы булды.

Утырышны хәрәкәт лидеры, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин алып барды. Ул шура әгъзалары алдында шушы елның 19 декабрендә булачак сайлау компаниясе һәм ана әзерлек мәсьәләләрен бәян итте, урыннарда эш алып бару буенча бурычлар билгеләде.

Сәяси шура утырышында Татарстан Журналистлар берлеге, «Татарстан янарышы өчен», «Эшмәкәрлекне үстерү» хәрәкәтләре, Татарстанның кеше хокукларын яклау комитеты, вкладчы һәм акционерлар хокукын яклау буенча республика фонды җитәкчеләре «ТЯГ» иҗтимагый-сәяси хәрәкәтенә кушылуларын белдерделәр.

## ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

16 сентябрь көнне Татарстан Язучылар Берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Иҗат эшләре белән бергә, утырышта оештыру мәсьәләләре дә каралды. Идарә рәисенең урынбасары итеп Г. Гыйльманов сайланды. Шулай ук, иҗади остаханә җитәкчеләре дә ачыкланды: проза буенча—Солтан Шәмси, поэзиядә—Зиннур Мансуров, тәнкыйтьтә—Мансур Вәлиев, балалар әдәбиятында—Равил Рахман, рус әдәбиятында—Владимир Корчагин. Язучыларны Берлеккә кабул итү буенча Коллегия рәисе итеп Равил Фәйзуллин сайланды.

## ШАГЫЙРЬНЕҢ ТУГАН ЯГЫНДА

Мәгълүм булганча, үткән ел татар шагыйре Яков Емельяновның тууына (1848-1893) 150 ел тулды. Татарстан Министрлар Кабинетының карары белән бу юбилейны республикада зур итеп үткәрү чаралары билгеләнгән иде. Шул уңайдан республика матбугатында шагыйрь турында байтак мәкаләләр һәм чыгышлар дөнья күрде. Юбилей чаралары быел да дәвам итте. 17 сентябрьдә «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин җитәкчелегендә бер төркем әдәбият һәм сәнгать вәкилләре—язучылар Г. Рәхим, Ш. Мостафин, Ә. Сафиуллин, җырчылар—Г. Ибушев, Л. Әхмәтова, музыкантлар—М. Макаров, Г. Макаров һ. б. Яков Емельяновның туган якларында булдылар. Иҗат вәкилләре делегациясе башта Котлы-Бөкәш авылында, соңрак шагыйрьнең туган авылы Алан-Полянда халык белән очраштылар, әдәби-музыкаль кичәләр оештырдылар. Юбилей тантаналарында Балык-Бистәсе хакимияте башлыгы Р.Хәйруллин һәм аның урынбасарлары—Б.Фатыйхов һәм Р. Хәбибуллиннар катнашты.


## АВЫР ЮГАЛТУ

Башкортостанның халык шагыйре, Россия һәм Башкортостанның Дәүләт, Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге премияләре лауреаты, «Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы, башкорт һәм татар әдәбиятларын үстерүдә зур өлеш керткән бөек әдип **Нәҗәр Нәҗми** вафат булды.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Илдар Зарипов. «Асылъяр».
**Өченче битендә:** Равил Заһидуллин. «Казанны саклаучылар».
**Дүртенче битендә:** Язучы Марат Әмирханов.

# 15 ОКТЯБРЬ—ХӘТЕР КӨНЕ



Казанны саклаучылар

Индекс 73210



Марат Әмирханов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)